ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

9.2014



№9 (1103) 2014

# БУ САНДА:



## Миркасыйм ГОСМАНОВ:

«Нажар агай Нәҗми белән танышу, ун көн чамасы бергә йөрү миңа 1984 елның көзендә, төгәлрәк әйткәндә, жылы, якты август аеның 18-27нче көннәрендә насыйп булган иде. СССР Язучылар берлегенең әдәби фонды тарафыннан Франциягә оештырылган туристик сәфәр вакытында. Соңра Нажар агайның башкортчалатып көйләп әйткәненчә: «Йөрдек бергә Париждың калаһында, / Йыйын йәһүд, хырансуз араһында».

## КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ



**Кәрим КАРА**

**«Инга Мейтаның жинаять эше»**

«...Көндезге сәгать өчтә «Тандем» универмагында сак төркеменең игътибарын урта яшьләрдәге ханым үзенә җәлеп итте. Хатын үтеп-сүтеп йөргән кешеләргә бәйләнгән кебек тоелды. Ул үткәннәрнең җиңнәренә асылынды, юлларына аркылы төште, артларыннан тагылып нидер таләп итте».

# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Айдар ХӘЛИМ. Туган илгә йөгерәсе килә. *Шигырьләр.* ..... 3
Анатолий ЕГИН. Үзбәк хан. *Роман.* ..... 9
Рафис КОРБАН. Өч жыры бар бу гомернең. *Шигырьләр.* ..... 69
Әмиржан МОТАЛЛАПОВ. Гамь. *Роман.* ..... 74
Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Чорым калыр үткәндә. *Шигырьләр.* ..... 110
Эльнар БАЙНАЗАРОВ. Ерактагы килеш якын. *Шигырьләр.* ..... 139

**КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ**

Кәрим КАРА. Инга Мейтаның җинаять эше. ..... 115

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Сөләйман *(шагыйрь Җәүдәт Сөләйманның иҗат портреты).* ..... 144

**СӘНГАТЬ**

Гүзәл СӘГЫЙТОВА. «Юксыну». ..... 154

**ХӘТЕР**

Миркасыйм ГОСМАНОВ. Истә калган якты мизгелләр. ..... 157
Рауль МИР-ХӘЙДӘРОВ. Шуның белән шул... Вокзалдан язам. *Мемуарлар.* ..... 167

**ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ**

БАТУЛЛА. Мәгънә. ..... 172

**ПЕЧӘН БАЗАРЫ**

Дамир ГЫЙСМЕТДИН. Хикәяләр. ..... 176

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Уены-чыны бергә. *(Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде).* ..... 180

Мәкаль өмәсе. ..... 183
Мансур САДЫЙКОВ. Уйландыра торган әсәр. *(Кайтаваз).* ..... 185

**АК ҖИЛКӘН**

Алсу НУРГАТИНА. Сынаулар. *Повесть.* ..... 187

«Казан утлары» архивыннан. ..... 142
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 190

ТМ
татмедиа

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
ачык акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(җаваплы сәркатип)*
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Ләйсән Солтанова.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров, Флёра Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Җаваплы сәркатип, компьютер үзәге — 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст.5).*
**Факс** — (843) *222-09-83 (өст.1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 28.08.2014, график буенча 29.08.2014.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-2240. Тираж 3300.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2014 ел



Айдар
Хәлим

# ТУГАН ИЛГӘ ЙӨГЕРӘСЕ КИЛӘ

## Нью–Йорк сабан туенда

Уйлап кына җыр тумый. Хис кирәк!
Уй моң булып бармый башкага.
Нью-Йорк сабан туе күздән
Югалган моң эзләп башлана.

Фикер генә әле шигырь түгел,
Гамәл түгел үткер вәгазь дә.
Моңың имгәнмәсә, ул читтә дә
Милли булып төшә кәгазьгә...

Менә шуны югалтмадыкмы без?
Йөз илдән йөз татар кансырап,
Сабантуйда бии гамәл өчен
Гүя бер-берсеннән җан сорап...

Чит илләргә китеп, туган җирдә
Иген икми, бала имезми,
Иң акчалы-бакчалы татар да
Мең күзәнәктән бер моң эзли!..

Әнә, әбкәй, «Әллүки»дәй якты,
Авызын шәл читенә яшергән.
Инен капшый. Ул — буш. Балалары
Интернеттай читкә чәчелгән...

Моңсыз калсаң, бүлгәләнү җиңел.
Без, татарлар — кырык бүленгән! —
Сабантуйлардагы бию аша
Чыгып килмибезме үлемнән?..

Айдар ХӘЛИМ (1942) — *шагыйрь, публицист, прозаик; «Гомеремнең ун көне», «Өч аяклы ат», «Татар моңы», «Хунвейбин» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Чаллыда яши.*

## Эмпайр–Бильдинг, 106нчы кат

Ак һәм кара үзара килешкән.
Ил арынган ку-клукс[1] чиреннән.
Иман аша бары талант эзләп,
Ул терелгән үлгән жиреннән.

Саумы, Америка! Goud bay, туган!
Күкрәк өсләреннән очамын.
Болытларны тишкән йортларыңны
Жылы яңгыр булып кочамын!..

106 нчы каттан илгә карыйм.
Кул чугымда — Уолл-стрит.
Бу стрит дөнья ялкаулыгын
Таңга алып чыга өстерәп.

Стритны доллар саный, диләр.
Доллар ак-карага бүленми.
Талант кебек.
Стрит акча саный,
Гәрчә санаганы күренми.

Эшлә, кеше! Укы!
Бары чукынып,
Житте мич башында ятарга!
Баегырсың, бүлми адәмзатны
Яхшы урыс, начар татарга!..

Талантларны жиде кат жир һәм
Күк аша
Телескоптан күрәләр.
Хөкем катгый: бүген итек майлый
Кичә ришвәт алган түрәләр...

Ник безләрдә кеше кадере юк?
Көтмәгәндә хистән жепшедем.
Аптырагач, 106нчы катта
Мин ник талантсыз, дип үкседем...

## Бамбук

Бу бамбуклар безнең таллар икән!
Яфрагы моң түгеп тамчылый.
Туган илгә йөгерәсе килә,
Аяк тарта, әмма жан чыдый...

Талларыбыз кебек чыдам бамбук!..
Гүя сынмас өчен сыгылган.
Әнкәй көтә газиз әткәемне,
Сугыш килгән «Кыргыз юлы»ннан.

[1] Ку-клукс-клан. Америка актәнлеләренең унтугызынчы гасырның алтмышынчы елларында кара тәнлеләргә каршы башланган өч ультра-милләтчел хәрәкәтнең иң явызы.

Күпме чыдарбыз без? Чыдый-чыдый
Үссәм синең чыдам буыннан,
Нишлим, әнкәй, дәүләт кадәр дәүләт
Шуып төште бәйле кулымнан...

Мин акланмыйм! Бу — хак!.. Өсләремә
Ява дисәм иркә тамчылар,
Җәза булып,
Кан чәчрәтеп кыйный,
Мине камчылаган тамчылар!..

Бамбук шавы, әнкәй, өязеңнең
Таллар моны белән тулалмас.
Синнән матур, акыллырак ана
Америкада да туалмас!..

Бамбук арасында адашмыйм, дип,
Алдашмыйм, дип, кат-кат әйләндем.
Бамбук, әнкәй, ил салган ярамны
Синең кулың белән бәйләде...

## Мөрәҗәгать

*Америка Кушма Штатларының булачак президенты Джордж Вашингтонның инглиз гаскәрләрен 1777 елда беренче тапкыр җиңгән Принстон яланында инглиз һәм америкән континенталь армиясе корбаннары бергә җирләнгән зират бар. Моннан 170 ел элек Америка җәмәгатьчелеге, күпьеллык низагны онытырга чакырып, зиратта илбасарларга һәм ил бәйсезлеген саклаучыларга уртак һәйкәл куйган.*

Гаскәр белән гаскәр сугышса да,
Халык дошман булмый икән лә! —
Принстон кырында, зиратта,
Ята инглиз, америкәннар...

Йөз ел сугышып, йөз китмеш елдан соң
Тарихка ак тәрәз уйганнар:
Дошманлыктан дуслык кадерле дип,
Уртак Сагыш Сыны куйганнар...

Казанда да булган бу канкоеш.
Әмма дан җырлап гел орышка,
Анда — һәйкәл
Татар сөягендә
Бары Явыз Иван — урыска...

Гүя мөселманны ул кырмаган,
Җиңүгә баш кисми ирешкән.
Оккупант биш гасыр татарлардан
Варвар ясап килеп килешкән.

Кая киткән икән безнең Ватан?
Илдән гүя күз дә, каш та юк.
Татарлар сыртында — баскынчылар,
Бабамнар башында таш та юк!..

Булган сугыш булган — буяу сеңгән!..
Безме зиратта таш куптарыйк?!
Бабайларга рәттән Ак Таш куеп,
Хәтер каршысында пакь калыйк!..

Мондый гаделлеккә ирешү өчен,
Мөстәкыйльлек кирәк татарга:
Дошман белән хәтта зиратта да
Тигез һәм мөстәкыйль ятарга!..

Без, күршеләр, дошманлыкка түгел,
Бергәлеккә дучар ителгән.
Житте мәңге кәтлит әвәләргә
Мөселманның пушка итеннән.

Үч сакламыйк!.. Тыныч ятсын алар!..
Дөнья әйтсен: «Дуслар икән лә!»
Тыныч яткан кебек Принстонда
Инглизләр, американнар...

## Җырчы Айдарга Айдар абыйсыннан

*Кәркәле таулары биек...*
Җырдан

Сине монда яхшы хәтерлиләр.
Асыл хәтер — аек халәттә.
Сәбәп белән яши жан иясе,
Шул сәбәбен танып сәләттә.

Ә син, энем, яшәү мәгънәсенең
Сәбәпләре сәләт икәнне,
Нью-Йоркта да раслый алдың,
Монга салып Американы!..

Ни язма, жырлама — идеал бир!
Кайда дан туртасын эчмә син,
Жырчы итте безне Кәркәленең
Басу юлы — «Салкын Чишмә»се!..

Тавышыңда синең шул чишмәдән
Мәңгелеккә килгән көмеш бар.
Син тыныч бул, жырчы. Көмешеңдә
Көнчегә дә жавап өлеш бар.

Юллар монда көзгедәй булса да,
Табыла кичә салган ямаулык.
Чекрәеп карасаң, капиталның
Күзендә зур чүпне табарлык.

Әнә, карурманнар артларыннан
Кәркәлечә оеп ай чыга.
Америка, финик төше сыман,
Кыздырганда гына ачыла...

Җырлыйк, туган! Хак, мин — Хэмингуэй,
Син дә, хак, Поль Робсон түгелсең.
Кәркәлечә илгә хезмәт итик,
Моңнар Кәркәлечә түгелсен!..

## Сания апа[2] үлеменә

Көн туды исә, безне бер-бер артлы
Үзенә суыра төпсез чоңгыллар.
Сез бит сомгыллардан сомгыл булган,
Тукай кеше иткән соңгылар!..

Хәбәрен ишеткәч, өнсез калып,
Йөгреп кайтыр булдым, канәтем,
Әй, канады йөрәк!
Син идең бит
Татарымның сынмас канаты!...

Кайда булсак та без, ил алдында
Антны боза торган ир түгел.
Нишләргә соң?
Илче Гайсә кебек
Йөгереп кайта торган җир түгел...

Хәбәреңнән синең дәһшәт белән
Кайнаша Атлантик океан.
Исемең синең татар тарихына
Хаклы керер диеп кул куям.

Әлки урманнары һәр кыш саен
Кар белән ярларны тутырса,
Без яшәрбез, татар сиңа тиңдәш
Ай-Тукайлы буын тудырса!..

Үз саулыгың онытып, көрәшләрдә
Кайгыртып милләтең саулыгын,
Кереп киттең.
Хуш, Апам.
Башыңда
Җәйри жилкән —
Ап-ак яулыгың...

[2] Чаллы татар милли хәрәкәтенең күренекле җанатары. Үлеме хәбәрен Америкада ишеттем.

## Урманда уйнаган оркестр

Бу ил гранитка тамыр җәйгән.
Ташта чәчкә ата каштан да.
Тиеннәр дә Бетховенны тыңлый,
Ботак тишегенә качкан да...

Өерелә фуга — ковбойларча
Моңны урак белән урып ал!
Милләт өчен җан бирәсең килсә —
Бир!..
Бир дә куй!
Моннан курыкма!..

Черри-хиллга[3] почта гәзитләрне
Атып китә пневмопушкадан.
Гүя ФСБдан вак фиргәвен —
Безнең ханнар шулай кушканнар...

Тишек ишегеннән — тиен белми:
Фиргавен кем? Ниткән ул кавем?
Фиргавен ил талап котырганда
Яратыла ала Бетховен.

Булды микән, тагын булырмы бер
Мондый дәһшәтле аһ иясе?
Тыңлаганда иске җанны салып,
Килә яп-яңа җан киясе!..

Коткарасы килә татар ирен
Үшәнлектән, атын — казыктан.
Кызын — ят түшәктән, халкыбызны —
Дошман агулаган азыктан...

Моңнан оеп, тиен халкы йоклый,
Сайравыннан тынган кошлар да.
Бер Бетховен бар дөньяга җиткән.
Ничек?
Җитми акыл, һушлар да...

[3] Черри-хилл — Принстонда Вил Мирзаянов яшәгән урам.



Анатолий
Егин

# ҮЗБӘК ХАН

*Әтием Егин Иван Сергеевичка багышлыйм*

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### Варис

Төн пәрдәсен ертып, көнчыгышта якты тасма күренде дә офыкны шәфәкъ алсулыгы төреп алды. Офык артыннан тәгәрәп килеп чыккан алтын-сары кояшның якты нурлары Сарай шәһәренең мәчет манараларын һәм чиркәү гөмбәзләрен алтын төскә манып, Актүбә суында коенган агачларның лепердәшкән яфракларына барып кунды. Яна көн тууын хәбәр иткән әтәчләрнең, тегендә-монда кагылып-сугылып йөргән этләрнең тавышлары сүнеп, шәһәрне язгы саф һавадай җинелчә тынлык чорнап алды. Яна көн башланды.

Кинәт, колакларны зеңгелдәткән шушы илаһи тынлыкны бозып, бөек Батуның торыны[1] — урыс кенәзлекләрен һәм Көнчыгыш Ауропаны яулап алган, Чыңгызхан тарафыннан тергезелгән Бөек Монгол империясенең көнбатыш өлешендә урнашкан Җучи Олысының тәүге хуҗасы Тогрыл хан утарының авыр капкалары ыңгырашып ачылды да әкрен генә балчыктан ясалган исәпсез савыт-саба төялгән арба шуышып чыкты. Качырлар[2] сак кына, иплә кенә йөкне Актүбәнең текә ярыннан ярсып дулкынланган болганчык су янына алып төштеләр. Милади буенча 1291 елның агачларның яфрак ярган, йөгерек кар суларының төньяктан котырынган ташкын булып ургылып, юлындагы күп сандагы күлләрне су белән тутырып, Итил белән Актүбәне тоташтырып зур бер елга итә торган ае иде.

Яр буенда арбаны зур көймә көтә иде. Таза, нык ун кол савыт-сабаны тиз генә иплә төяделәр дә ишкәкләрне тиз-тиз йөртеп яртылаш суга кергән агачлар артына китеп югалдылар. Актүбә авыр көймәне читкә каерырга теләп ярсый-кабара, әмма усал армай[3] тарафыннан куаланган коллар үҗәтләнеп ялсыз-нисез, туктаусыз иштеләр дә иштеләр.

Кояш шактый күтәрелеп, нурлары даланың мул булып чык төшкән хуш исле үләннәренә сирпелгәндә, Итилнең уң ярына килеп туктадылар. Көймәне гаскәриләр көтеп тора иде. Алар көймәгә күтәрелделәр дә савыт-сабага шак-шок суккаларга тотындылар. Тиздән бер савыт эченнән җавап итеп кагып алдылар. Капкачны ачуга, кояш яктысыннан күзен челт-челт йомгалап

[1] Баланың баласы, онык.
[2] Ишәк белән биянең яки айгыр белән ишәкнең кушылгагы.
[3] Коллар өстеннән күзәтеп торучы кеше.

ун яшьләр тирәсендәге малай килеп чыкты һәм шатлыктан елмаеп торган байларча кием-салымлы сугышчы аны кочагына кысты. Бу адәм баланың әнисе ягыннан туган тиешле абыйсы — Айдарбәк иде. Киң җилкәсе, көчле, нык аяк-куллары, яхшы коралланган булуы абзасын дәһшәтле итеп күрсәтсә дә, аның ягымлы күзеннән апасы алдындагы бурычны җиренә җиткереп үтәүдән туган канәгатьләнү, шатлык сирпелә иде. Хәзер инде аларны бернинди әзәрлекләү дә куркытмый иде.

Апасының энесе белән Итилнең текә уң ярыннан күтәрелә башлауга, Айдарбәкнең сакчылары рәхимсез, кансыз рәвештә ишкәкчеләрне һәм аларның армаен кулларындагы хәнҗәр белән тураклап, савыт-сабаларын ватып, көймәне суга батырдылар. Кызылга манчылган ашкын су, бернинди гаепләре булмаган адәмнәрнең мәетләрен читкә алып китеп, Алтын Урда ханнарының тагын бер серен үз эченә яшерде.

Баштанаяк гаскәри киемгә төренгән малай бил каешына җитез генә зур булмаган кәкре кылычны кыстырып куйды, аннары җәя белән садагын рәтләде дә тәбәнәк монгол атының ияренә гадәтенчә җиңел генә сикереп менеп утырды. Үсмерне ике йөзләп сайлап алынган яугирләр чорнап алды һәм кечерәк кенә отряд, алмаш атларын ияртеп, дала буйлап Чиркәс тауларының көньяк-көнбатышына таба чаптырдылар. Ям[4] станцияләрен, күчмәләрнең күнегелгән юлларын уратып уздылар, чөнки сакчылар Алтын Урда тәхете варисы, Бату ханның торыны Үзбәкнең гомере өчен башлары белән җавап бирәләр иде.

Алтын Урданың Актүбә ярында урнашкан башкаласында исә Үзбәкнең әнисе — кара күзле, йөзем куагы кебек сыгылмалы зифа сынлы Арибах сагыштан сарыга сабышкан иде. Әмма күзе тулы моң-хәсрәт тә яшь сылукайның күз явын алырлык чибәрлеген җуя алмаган. Аның күзенә бүген язгы матур көн дә, яңа зиннәтле бизәгечләре дә күренми, шәрык сәүдәгәрләре китергән яңа өлгергән җиләк-җимешләр дә күңелен ача алмады. Үзен юатырга тырышып янында бөтерелгән хезмәтчеләреннән котылырга теләп хәрәм[5] бүлмәләре буйлап әрле-бирле йөренде һәм Аллаһтан кечкенә улы Үзбәкнең гомерен саклавын сорады.

Бар да Арибахны кызгана, аның хәленә керергә тырыша. Шулай булмый ни: бер көн эчендә иренне дә, улыңны да югалтып кара әле! Хатын-кыз өчен моннан да зур кайгы була алмыйдыр.

Арибахның кайнатасы — Алтын Урданың кодрәтле ханы Мәңгүтимер ун улына сулыш биргән, әмма кырык яшендә үләсен белмәгәнгә, варис турында кайгыртмаган, бернинди васыять кәгазе калдырмаган иде. Берәү дә Мәңгүтимернең гомере кыска булыр дип уйламады, әмма ул кинәт кенә 1280 елда тамагындагы шештән үлеп китте.

Алтын Урдада идарә дилбегәсен төмән башы[6] Нугай үз кулына алды диярлек. Аның бабасы Бувал — Чыңгызханның беренче улы Җучиның кәнизәктән[7] туган улы булып, киләчәк буыннарга тәхеткә килү юлын бикли. Әмма үзсүзле, үҗәт Нугай Бәркә хан вакытында кечерәк кенә отряд командирыннан гаскәр башлыгына кадәр күтәрелә алды. Яу арты яу оттырса да, Бәркә аны башка чыңгызыйлар белән тәхет өчен көрәшкә чын күңелдән бирелгәне өчен үзе тирәсендә тотты. Нугай әйләнә-тирәдә билгеле кеше, сүзе үтемле һәм зирәк түрә буларак гарәп идарәчеләре арасында аның абруе зур булды.

Мәңгүтимер хакимияткә килгәч, Нугайны патша сараеннан читләштереп, халыкара эшләрдә катнаштырмый башладылар. Алай гына да түгел, башкала

[4] XIII-XVIII гасырда юлчыларга хезмәт күрсәтә һәм почта атларын алмаштыра торган станция; почта станциясе.
[5] Бай мөселманның кәнизәк һәм жарияләр яши торган сарае.
[6] Ун мең кешелек гаскәр башлыгы.
[7] Хан сараена яисә ханның берәр якынына хезмәткә алынган кол хатын яки кыз.

эшләренә борынын тыга алмаслык итеп, яшь хан аны ерак Олыска ук озатты. Мәңгүтимернын үлеменнән соң анын сәгате сукты, ул шунда ук Сарайга кайтып, хәйлә-мәкер белән мәрхүм ханнын ялкау һәм максатсыз ир туганы Тәдән Мәңгүтә тәхеткә үрмәләргә ярдәм итте. Ә тегесе исә Нугайдан дәүләттә икенче кеше булып саналган бәкләр бәген ясады. Көч-гайрәте ташып торган төмән бәгенең монын белән генә туктап калырга исәбе юк, бу хәйләкәр адәмнең башында икенче бер ният туып өлгергән иде. Ул хәзерге ханнын тәхет өчен көрәштә көндәшлек иткән Телә Буга белән элемтәдә тора һәм жае чыккан саен анын колагына:

— Сабыр ит, синең дә кояшын чыгар, мин сиңа тәхеткә менәргә ярдәм итәрмен, — дип пышылдый.

Алты елдан артыграк Урда белән Нугай идарә итте, әмма тора-бара иренчәк Тәдән Мәңгүнне бәкләр бәгенең бар нәрсәгә кысылып, гел өйрәтүе һәм һәр адымын тикшереп торуы тәмам туйдырды. Ниһаять, ханнын түземе төкәнде:

— Син, бәлки миңа кайчан һәм кайда кече йомышны йомышларга икәнен дә өйрәтерсен? Житте, булды! Нишләргә кирәген үзем уйлармын!

Нугай да төшенде: кискен борылыш ясар чак житте!

Һәм ясады!

1287 елда анын ярдәме белән Телә Буга тәхеткә килде, үзе генә түгел, өч ир туганы белән! Алар арасында Арибахнын ире, Үзбәкнең атасы Тогрыл да бар иде. Ул вакытта Үзбәккә алты яшь иде.

Ир туганнар күп тапкырлар хәйләкәр һәм нык ихтыярлы бәкләр-бәгеннән котылырга омтылып карадылар, әмма яуда күп тапкырлар жинелсә дә, сәясәттә баш бирмәгән Нугай борын аслары кипмәгән малайларнын (үзалдына ул аларны шулай дип атап йөртә) каршы әйтүләренә гарьләнә иде. Нугай күрә: анын ниятләре, суга сәнәк белән язган сыман, барып чыкмаска охшаган. Ул, бергә озак идарә итә алмаслар, талаш-гаугалар килеп чыгар, дип уйлаган иде. Киресенчә, Нугайга каршы көрәш аларны берләштерде генә. Кичекмәстән, чарасын күрергә кирәк иде.

— Зарар юк, — дип фикер йөртте ул, — Мәңгүтимер оясында күндәмнәре дә житәрлек.

Бәкләрнең бәге ашыгыч рәвештә ир туганнарга алмаш эзләргә тотынды. Ул Мәңгүтимернен үжәтләнеп тәхеткә омтылган уналты яшьлек улы Туктайга тукталды. Тик ничек итеп барысын бергә алып ташларга? Мәгәр хәйлә коруда, астыртынлыкта Нугайга тиңнәр юк иде. Ул, үлем хастасына сабышып, хаким ир туганнарны үз торагына бәхилләшергә дип чакырды.

Телә Буга, Көчек, Алгуй һәм Тогрыл — дүртесе дә Нугай әкәнен чатырына килделәр. Чыңгызыйлар ырунын өлкәне дигән исемне үз белдегенчә үзләштереп, ул үзен әкә дип санап йөртте. Бәкләр бәге үзенең хушлашу нотыгын башлады:

— Балакайларым, мин элек тә, хәзер дә әтиләребезгә хезмәт иттем. Миңа Бәркә хан заманында ук дөньянын Бөек галижәнабе Чыңгызхан бабабызнын токымы яшәгән йортта тәртип саклау эше ышанып тапшырылды. Бөек Бату ханнын тәхете тирәсендә барган ызгыш-талашларны күрү миңа бик авыр. Исән чагымда сезгә солых төзеп бирер идем, кичекмәстән корылтай жыярга кирәк...

Нугай әкә сөйләгәнне басынкы гына тынлап торган арада, Туктай белән Нугай кешеләре сиздермичә генә ир туганнарнын аз санлы сакчыларын суеп чыктылар да алдан сөйләшкән буенча юртага бәреп кереп, дүртесен дә эләктереп алдылар.

Нугай картлач берни булмагандай урынынан торды да Туктайнын кулыннан тотып, Телә Бугага төртеп күрсәтте:

— Синең атаңнын тәхетенә ул хужа булды, болары исә анын белән килештеләр. Менә шушылар сине эләктерергә һәм үтерергә теләделәр. Мин аларны синең хозурыңа тапшырам, теләсә нинди жәза бир.

Туктай икеләнеп тормый абыйларын, шул исәптән кандашы Тогрылны да үтерергә фәрман бирде.

Әмма хаким ир туганнарнын бар сакчысы да тар-мар ителмәгән икән. Тогрылның каенише — чиркәс Айдарбәк бәла-каза барын чакрым алдан сизеп, үзенең кешеләрен ераккарак — караңгылык эченә алып китте. Ул башта Нугай юртасында суеш-кырылыш барганын белмәде, нәрсә булганын аңлап алгач, Туктай белән Нугайның зур көчләрнә каршы торуны мәгънәсезгә санады. Юртадан ир туганнарынын мәетләрен алып чыгуга, ул атын бар көченә Сарайга куды. Ниһаять, өч ат алмаштырып, иртәнгә Айдарбәк апасы Арибахның йокы бүлмәсендә иде инде. Ул тау бөркете сыман тиз һәм кискен эш итте:

— Апа, хәләлең Тогрыл ханның үлеме турындагы хәбәр килеп җиткәнче, аның улы Үзбәк дөньядан китәргә тиеш!

Арибах аздан гына аның җуеп егылмады.

— Апа!Апа! Акылына кил, ул үләргә тиеш түгел, кешеләр өчен аның исән булмавы кирәк. Ул бүген төнлә үлде дип сана, иртән, менә хәзер, кәфенгә төреп курчак күмәрбез. Иртәгә мин малайны тауларга — әти янына илтермен, анда аны беркем, беркайчан таба алмас. Тиз бул, малайга үзен ничек тотарга кирәклеген аңлат, барлык асраулар аны үле килеш күрсеннәр, мин исә мулла белән сөйләшәм.

Вакыйгалар куерды. Хәзер Арибах өчен Тогрылны үтергән Туктай ир тиеш була, нишлисең, канун шундый. Хакимлек итү өчен, ул үз юлында торган һәркемне юк итәчәк. Үзбәкне беренче чиратта, чөнки малайның әтисенең тәхеткә орынуын Туктай кичермәячәк. Тизрәк, тизрәк малайны коткарырга кирәк! Мөмкин кадәр тизрәк хәрәкәт итәргә! Арибах әлеге фаҗигане шулкадәр оста һәм тәэссирле башкарды ки, әйләнә-тирәдәгеләр кайнар күз яше койдылар, хәтта сарайның диварлары да аларга кушылып үкседе сыман.

Арибах та, ирен уйлап, чын-чынлап ачы күз яшьләре түкте, башка чиркәс хатыннары кебек үк ул да ирен жаны-тәне белән яратты, аның уенда сөйгәне генә, ул сизә: иренең жаны монда, аның янәшәсендә.

Тогрыл талантлы, кыю-батыр булды, күп яктан ул үзенең әтисенә — Бөек хан Мәңгутимергә охшаган, тик аңа хакимнәргә хас сыйфат — ертлачлык житмәде. Әтисе аны башка балаларына караганда үз итә, менә нәкъ ул тәхеттә утырырга тиеш иде, тик ул чагында аңа ир туганнарын үтерергә туры килер иде. Алай эшли алыр иде микән ул? Мөгаен, юктыр. Анын ире хыялый, кешегә ышанды, шуңа үзе корбан булды да. Тогрыл һәрвакыт хатынына карата ягымлы булды, Арибах аның сөекле хатыны, киңәшчесе һәм жан сөйгәне иде. Тик аның яраткан ире инде юк, аны берничек тә кире кайтарып булмый. Ә улын, улын ул коткара ала. Арибах, беркемгә ышанмыйча, Үзбәкне зур савыт эченә үзе яшерде, һәм алар ир туганы белән малайны коткару планы төзеделәр. Бар да алар уйлаганча булды, бүген аңа Аллаһы Тәгаләгә һәм кандаш ир туганына дога кыласы гына калды.

***

Айдарбәкнең ике йөзләп яугир киң дала буйлап, атларны ял иттерү өчен кыска гына тукталышлар ясап, бардылар да бардылар. Чыңгызхан үз заманында сугышчыларын аякларын язар өчен генә тукталып алырга, иярдә килеш йокларга, ашарга-эчәргә, кирәк икән йомышларын да башкарырга өйрәтте.

Биш көнләп узгач, офыкта тау шәйләнде. Якынайган саен тау биегәйгәннән биегәя барды. Тау түбәсенә кагылып көдрә болытлар йөзә, үпкәләргә салкынча саф һава тулды. Төпләре аермачык күренеп торган чиста салкын сулы елгаларны үттеләр.

Биш түбәле тау тирәсендә атларыннан төштеләр. Бер төркем чыбык-чабык,

утын әзерләргә тотынды, калганнары исә киек ауларга юнәлде. Бу тарафларда аларга кытлык юк иде. Айдарбәк жигү кирәк- яракларын, дагаларны тагын бер кат тикшереп чыгарга әмер бирде. Алга таба юл ташлар күпереп яткан дала буйлап түгел, таулар аша сузыла.

Икенче көнне кичкә таба алар Мары елгасы буйлап сузылган тарлавык аша Кавказ тауларына карап юл тотты. Айдарбәк белән Арибахның аталары чиркәс кенәзе Елбаздук утарына барып житкәндә көн кичкә авышкан иде. Айдарбәк атыннан төшеп, туган йорты капкасыннан ишегалдына узды. Алагаем зур кавказ эте алга сикерергә омтылыш ясады да таныш ис сизеп, берничә адым читтә туктап да койрыгын болгап керүчене көтеп алды.

Айдарбәк ишекне ачты. Елбаздук кенәз бәйрәмчә киемнән өстәл янында утыра иде. Ак йон бүреге аңа тантаналы кыяфәт өстәгән. Кенәзнең улы белән очрашуга әзерләнүенә берничә сәгать булды. Аның гаскәренең урыннарда йөрүчеләре көндез үк тауга күтәрелеп килгән отрядны күреп алганнар иде. Үткен күзле күзәтүчеләр Айдарбәкне шәйләп, шунда ук Елбаздукка хәбәр ирештерделәр.

Чиркәс гаиләләренә хас булганча, улы әтисе белән аягүрә күрешә дә аның әмерен көтеп сүзсез генә тураеп басты.

— Ни белән куандырасың, Айдарбәк, данмы әллә йөз карасымы?

— Тәхет өчен көрәштә Туктай абыйсы Тогрылны үтерде.

— Син нәрсә, үзеңнең ханыңны саклап кала алмадыңмы?.. Алайса ник йортка кайттың? Атаң өен хурлыкка калдырыргамы?

— Атам, әйтергә ирек бир.

Елбаздукның таш кебек катып калган йөзендә ник бер мускулы селкенсен.

— Мин үзебезнең Уэркъ Хабзэ әхлакый кодексыбызны бик яхшы хәтерлим: гомереңне сат, намус сатып ал! Тик көчләр тигез түгел иде, күрәләтә үлемгә бару дәрәҗә китермәс иде. Тогрылга ярдәм итеп булмасын аңлагач, мин аның улын — Бату хан тәхете варисын коткарырга уйладым.

— Кайда инде ул варис?— дип сорады кенәз, ярсуын тыярга тырышып.

— Үзбәк монда, капка төбендә.

— Ник торасың, бар тизрәк оныгымны өйгә алып кер.

Айдарбәк бусаганы атларга өлгермәде, Елбаздук урыныннан купты:

— Үзбәк оныгым гына түгел, ул минем ханым. Ханымны үзем каршы алам.

Энгер-менгер төштә, алтын-сары кояшның соңгы нурлары жирне күләгә белән каплап, тау артына ышыкланды. Капкадан кенәз күренде.

Отряд күз ачып йомганчы атыннан сикереп төшеп, аның каршында тез чүкте. Үзбәк тә тезләнде. Елдазбук оныгы янына килеп, аны торгызды да баш иеп сәламләде:

— Рәхим ит, ханым, Аллаһ сиңа озын гомер бирсен! Тугры хезмәтчең Елбаздук сине үз йортында күрүенә шат!

Үзбәк ихатага керде, аңа кенәз белән Айдарбәк иярде. Бусага төбендә атасы улын туктатып:

— Ә сиңа, улым, Урдага кайтырга һәм хурлыкны каның белән юарга вакыт. Туктайның гомере чикләнергә тиеш. Үзбәкне миңа калдыр, мин аннан менә дигән егет ясармын.

Улы ишеккә борылуга, Елбаздук:

— Минем көтү кайсы аланда икәнен беләсең, — дип өстәде.

Айдарбәкнең анасы отряд артыннан кайгырып карап калды, улын кочагына ала алмавына, яраткан бодай өйрәсе белән сырыннан да авыз иттерә алмавына жаны көйде. Никадәр генә борчылмасын, әмма ул ике ир-сугышчы арасына кереп, бер ни хәл кыла алмый иде.

— Ярар, улымны сау-сәламәт килеш күрдем, мәрхәмәтле Бөек Аллаһыма дан булсын, — дип юатты ана үз-үзен.

Айдарбәк бервакытта да карангыдан курыкмады. Ә монда бигрәк тә, кечкенәдән аталык[8] белән аркылысын-буйга ураган таныш тауларда ул үзен иркен тотты. Ышанычлы адымнар белән отрядны тар сукмак буйлап Ком башы кичүенә алып китте, ә аның артында карачай һәм чиркәсларнең җәйге көтүлекләре — Бийчесын җәйләве башлана. Озак та үтмәде, отряд максатына иреште, тик карангыда көтүлеккә якын килмәскә булдылар. Таң атып, Эльбрусның карлы түбәләре җем-җем килә башлаганда, җайдаклар җәйләүгә төште. Көтүчеләр Айдарбәкне шунда ук таныды. Чиркәсләр кануны буенча яшь кенәз көтүдән колын, һәр сарык көтүеннән берәр бәрән алып үзе һәм юлдашлары өчен табын әзерли ала.

— Атам акыллы, атам зирәк, атасы улын ярата! — дип уйлады Айдарбәк, өер-өер торган көтүгә карап.

Сый-хөрмәттән бар да риза калды, әмма ашыгырга кирәк, чөнки эзли башларга мөмкиннәр. Арыган атларны көтүдәгеләр белән алмашып, Урдага юл тоттылар.

***

Туктай Сарай чикләренә күченеп, дәүләт белән идарәне үз кулына алды. Нугай яшь ханны күз уңыннан җибәрмәде, аның киңәше белән Туктай атасының тагын өч улын үтереп, бәкләргә тотынды, аннары Мәнгүтимергә хезмәт иткән хәрби җитәкчеләр белән Нугайның үтенече буенча дүрт ир туганны Туктай янына алдап китергән үги анасына чират җитте.

Урда аксөякләре салкын канлы, каты күңелле яшь ханның рәхимсезлегеннән бермәлгә катып калды. Аннарына килгәч, аларның кайберләре урыс ягына каерды, кайсылары Туктайның әмерләрен карусыз гына үтәргә тотынды. Яшь ханның гайрәтен күреп, Нугай тынычланды һәм көнбатыштагы үз Олысына кайтып китте.

Туктай хан ашыкмый гына үз әйләнә-тирәсен ныгытты. Анасы ягыннан Сәлҗидәй Гүргән бабасы белән хәрби җитәкче Тамма-Туктайны төп киңәшчеләре итте, аннары Сарайга ана тугры булган ир туганнары Сарай-Буга, Бөрлек, Тудан тартылды. Алар ярдәме белән ул бар җиргә борынын тыгарга яратучы бәкләр-бәгеннән башка үз сәясәтен үткәрергә тотынды.

Алда кичектергесез башка эшләр дә көтә иде. Хакимлегенең беренче көннәрендә яшь хан үзе тарафыннан каннары коелган ир туганнарының һәм бәкләрнең милекләрен барлауны оештырырга тиеш иде. Тәхеттә утырган килеш боерырга да була иде, әмма кызыксынуы җиңде һәм егет бар нәрсәне үзе карап барларга булды.

Тогрылның йорты ул уйлаганча зур булып чыкмады. Ихатага аяк басуга, бай булмаган корылышны күреп, дөрес чамалавын аңлады. Аны энесе — мәрхүм абыйсының улы Үзбәкнең каршы алмавы аптырашка калдырды.

Тогрылның аталары Мәнгүтимердән мираска калган өлкән хатыны Баялун бөек ханны сәламләп башын иде һәм кайгылы тавыш белән:

— Әй, ханым, Үзбәкне Тогрыл күкләргә киткән көнне үзе белән алды, — диде.

Нәрсәдер, аңлашылмас шоммы, әллә кызганумы Туктайның күкрәген кысып алды, әмма ул бу хисләрне бик тиз җиңеп, өйне карарга кереште.

Хәрәмдә ханны Тогрылның тагын өч хатыны көтә иде. Бу гүзәлләр арасында Арибах күзгә ташланып тора, чиркәсләр киеме аның сылу гәүдәсенең зифалыгын,

[8] Хан, би, дворян һ.б.ларның ир баласын тәрбияләүче яки, гомумән, берәр кардәш-танышының ир баласын махсус тәрбиягә алган кеше.

төзлеген күрсәтә, коңгырт-кара күзе, яхшы кысага утыртылган җәүһәрдәй җемелди һәм бу утлы күз карашы егетнең йөрәгенә килеп кадалды.

Хан борылды һәм артыннан күләгә кебек ияреп, исәп-хисәп эшләрен алып баручы кытайга:

— Абыйның бәхетсез хатыннарын үземә алам. Ә өйне?.. Мина мондый йорт кирәк түгел. Мина сарай кирәк!

Туктай сораулы карашын кытайга төбәде. Күпне белүче, күндәм генә башын иде дә:

— И кодрәтле һәм гадел ханым, ачуланмагыз, әмма сезнең тугры хезмәтчегез исегезгә төшерергә тели, — дип әкрен генә сүзен башлады, — кичә Сез Айдарбәкне түбән башы итеп билгеләдегез, тик бүләкләргә өлгермәдегез...

— Менә шулай, өйне аңа язып куй.

Кытай Арибахка күз ташлады, хатынның күзләре сөенечтән балкый иде. Язмачы шунда ук бу хатын тиздән ханның иң яраткан хатыны булачагын аңлады һәм үзенең зирәклеге өчен күп тапкырлар әҗерен алачагын уйлап сөенде.

Хан китте, аның яңа хатыннары исә күченергә җыена башлады. Баялун һәм Арибах күптәннән, яшь чиркәс кызы Тогрылның хатыны булуга, сердәшдусларга әйләнделәр. Икенче хәрәмдә яшәүче тәҗрибәле Рум принцессасы аны шефлыкка алды. Ул яшь чибәркәйгә йөклелекнең авырлыгын үткәрергә, тудырырга ярдәм итте һәм нәни Үзбәкне имезергә өйрәтте. Бер-берсеннән яшерен серләре булмады, кайгыны да, шатлыкны уртак бүлештеләр, әмма Тогрылның фаҗигале үлеменнән соң, үз-үзләренә бикләнеп, кайгыны ялгызлары гына күтәрде. Баялун иренең генә түгел, балаларының да җанын кыйган Туктайны күралмый иде. Ул бу кансыз яшь егеттән үч алырга сүз бирде һәм, үзен хатынлыкка алуына бик сөенде, чөнки дошманың янәшәсендә булу — аннан үч алу өчен менә дигән мөмкинлек иде.

Арибах та яраткан иренең үлеме өчен Туктайны кичерергә җыенмады, тик ханның карашыннан үзенең яраткан хатын һәм кинәшче булырын аңлады. Дөрес, моның өчен күп тырышлыклар сорала, әмма улы Үзбәкне тәхеткә утыртыр өчен ул барысына да риза иде.

Бу юлы сердәшләр уй-ниятләре белән уртаклашмады. Алар үз сәгатьләре сукканны көтәргә булдылар һәм бар игътибарны Тогрылның яшь хатыны Зарифадан яңарак кына туган бәләкәч кызга юнәлттеләр.

Хәрәмдә көннәр үз көенә салмак кына уза торды, һәр хатын үз урынын белде. Баялун монда да хокукы буенча өлкәнлеген дәвам итте, Арибах башкаларга караганда хан янында күбрәк булды. Һәркайсы — Туктай да, аның хатыннары да акрынлап, әмма үз максатларына бара иде.

***

Елбаздук һәр туган таңны аягүсте каршы алды. Тик яз ахырының кыска төне аңа кышныкыннан озын тоелды, черем итеп алдымы ул, юкмы — кенәз аңламады, уйлары кичәге кичтә булган вакыйгаларга әйләнде дә кайтты.

— Бәлки син улыңа карата артык кырыс булгансыңдыр? Юк! Ул хуҗасын, өстәвенә якын туганын бәлада ташлап калдырырга тиеш түгел иде. Тик дошманнар артык күп булсалар? Ул очракта нәрсә? Ул очракта Айдарбәк һәлак булыр, Тогрыл һәм аның артыннан үз каның, үз оныгыңның да башы китәр иде.

Димәк, Айдарбәк хаклы булып чыга. Ләкин чиркәс кодексындагы намус, дәрәҗә бар! Ул башкача сөйли бит!

Төне буе кенәзнең җаны телгәләнде. Ниһаять, таң сызылганда катгый карарга килде: вакыйганы куертмыйча ничек бар, шулай калдырырга, оныкны чиркәсләрчә тәрбия бирергә һәм тәхеткә әзерләргә, ә аннары нәрсә буласын

бөек һәм зирәк Аллаһ искәртер. Ә улы? Юк, ул үзенең кан дошманын кичермәс!

Кенәз урынынннан торып гәүдәсен язды, үзен тәртипкә китерде дә оныгын уятырга китте.

Бабасы бүлмәгә керүгә, Үзбәк сикереп торды да тиз-тиз киенергә тотынды.

— Ашыкма, ханым. Сина монда куркыныч янамый, киенеп торма, хәзер тәнне язылдырабыз да юынабыз, менә шуннан соң иртәнге ашка ярашлы итеп киенеп куярбыз. Әгәр хан каршы килмәсә, тамак ялгаганнан соң алда торган эшләр турында сөйләшер идем. — Елбаздук тыныч кына әйтсә дә, тавышы шулкадәр нык һәм ышандырырлык иде ки, кечкенә Үзбәк каршы сүз әйтмәде.

Атасының үлеме, иксез-чиксез даланы тиз һәм ашыгыч үтеп тауга күтәрелү, анасы белән аерылышу шулкадәр тетрәткән иде, аның җаны яклау һәм таяныч эзли, ә көч-дәрманында булган могтәбәр ир бу рольгә туры килеп тора иде. Иртәнге аш вакытында онык әбисе белән танышты; чәчләренә чал кунса да чибәрлеген, буй-сынының зифалыгын җуймаган хатынның адымнары салмак һәм мәһабәт, Үзбәк ирексездән аны кызыксынып күзәтте.

Әбисе матур итеп сырны кисеп куйды, тәлинкәләргә бодай боткасы бүлде, сөт салды — бар да тәмле булды. Малайга рәхәт иде, аның җанын бимазалап торган борчу-сагыш юкка чыкты һәм шом-тәшвишнең калдык-постыклары да Кавказ тавының күккә ашкан түбәләрен узып китеп таралдылар.

Сонрак бабасы оныгын тау елгасы ярында урнашкан утар белән таныштырды. Йорт-җир биек койма белән әйләндереп алынган. Уртада — салам белән ябылган сакля[9], мал абзары, амбар, баз һәм ат араны. Терлекне көтүгә куганнар, берничә хезмәтче хуҗалык биналарында тәртип урнаштыралар иде. Иртәнге ыгы-зыгы әкренләп тынды, кояш тау түбәсенә кунаклады. Берсе олыгая башлаган, икенчесе яшь — ике хуҗа, капкадан чыгып, ашыкмый гына төбе күренеп торган чиста сулы елга буйлатып өскә күтәрелделәр. Һава саф, тирә-якка тау үләннәре һәм куаклары чәчәкләренең баш әйләндергеч хуш исе таралган.

— Улым, — диде карт, юмакай тавыш белән, — сиңа инде ун яшь, далада туып-үстең, аның кануннары буенча яшәдең һәм тәрбия алдың, Чыңгызханның торыны, тик син бит минем дә оныгым, чиркәс кенәзе Елбаздукның оныгы. Минем нинди кеше булуымны үзең күрерсең. Бездә, тау халкында, үз-үзенә бәя бирү гадәткә кермәгән. Шулай ук улларыбызны өйдә тәрбия кылу да кабул ителмәгән, без аларны үзебезнең морзалар күзәтүенә тапшырабыз. Алар атасының үз баласы өчен җан атуы, кызгануы кебек сыйфатлардан азат, безнең тәрбиянең нигезендә ныклык, каты тәртип, барлык фәннәр буенча мәгълүмат алу ята. Син минем улым түгел, атаң Тогрыл сиңа тәрбиячене — аталыкны үзе сайларга тиеш иде, әмма ул бу дөньяны ташлап китте, шуңа күрә мин сиңа үземне тәкъдим итәм, әгәр син, ханым, каршы килмәсәң, әлбәттә.

Елбаздук эченннән генә, Үзбәкнең аның оныгы икәнен монда беркем белмәвен теләде, тәрбиягә малай китерү тауларда табигый хәл — бетте-китте. Үзбәк ни дип җавап кайтарырга белми шактый озак сүзсез торды. Малай әлегә үзенең тумышы белән нинди югары урын биләвенә төшенеп җитә алмады, бәйсезлек, батырлык һәм хөрмәт кебек иң бөек кыйммәтләрне эченә алган чиркәс дәрәҗә кодексы белән танышлыгы юк иде.

— Йә нәрсә, дәшмәү — ризалык билгесе, — диде Елбаздук, озакка сузылган тынлыкны бүлеп. — Миңа синең шунда ук җавап бирмәвең ошады, димәк, син уйлый беләсең, бу исә буш кеше түгеллегенне раслый. Бу — бик яхшы! Рас шулай икән, хәзер үк дәресләргә тотынырбыз.

Көн саен һәм эзлекле рәвештә авырлыкны арттыра барып, укулар башланып

[9] Кавказда тау халыкларының өе.

китте. Иртән галәти физик күнегүләр ясадылар, иртәнге аштан соң тауларга киттеләр, ерткыч хайваннар гына йөргән җирләрдә җәяүләп яки ат өстендә бардылар. Үзбәк җайсыз көе ял итәргә, урындагы билгеләргә, кояш һәм йолдызларга карап кайда икәнлеген ачыкларга, эзләрне укырга, агымсу буенча чамаларга, сукмак буйлап үзеннән алда башка кемнендер киткән-китмәгәнлеген белергә өйрәнде. Кенәз оныкыгының иярдә нык утыруын, үз яше өчен татар кылычы белән яхшы эш итүен, җәядән менә дигән итеп атуын канәгатьләнеп күзәтте, ә иң мөһиме — ул көчле һәм житез булырга омтыла, арыса ял сорамый, зарланмый-сыкранмый, ашамлыкка артык хирыслыгы юк. Үзбәктән менә дигән егет чыгачак, дип сөенде Елбаздук.

Кичләрен бабасы белән онык озак кына гәпләшеп утырдылар, аталык үзенең шәкертенә чиркәс гореф-гадәт, йолаларын төшендерде.

— Тугрылык — җәмгыятьтә тормыш нигезләренең асылы, менә шул, — диде бабасы, — гаиләгә тугрылык, дуска, ватанына һәм үзеннең буынына тугрылык. Тугрылык һәм хөрмәт! Әгәр гаиләңдә үзе дә аңламыйча нәселеңнен йөзенә кара ягучы, оятка калдыручы, җирбит яки комсыз шакал бар икән — хурлык китерүен аңлап яманатын каны белән юарлык ит, үтәми икән — кызганма, үтер аны.

Үзенең хуҗасын бәла-казадан йолмый ташлап китүче яки дустын кайгы-хәсрәттә калдыручыга монда урын юк, аннан бар да читләшергә тиеш, аның урыны үләксә ашаучы шакаллар өерендә, әгәр бу эт үз үлеме белән китсә, күмәргә барма, андыйлар хөрмәткә лаек түгел. Бездәге: «Гомереңне сат — хөрмәт сатып ал» дигән гыйбарәне син инде ишеттең, ханым. Табигый, хөрмәт бернинди алтынга да, акчага да сатылмый һәм сатып алынмый.

Онык барысын да күңеленә сеңдерә барды, сораулар да биргәләде:

— Кемдер сине алдады, соныннан килеп тәүбә итте, ди. Аны кичереп буламы?

— Бу сорауга берьяклап кына җавап биреп булмый. Бу кеше кем, нинди сәбәпләр аны алдауга этәргән? Әгәр аның җинел генә табышка ия булу нәфесе томалап беренче кат урлаша, тик дөрес эшләмәвен аңлап кире кайтарып бирә икән — кичер һәм хурлыгын каны белән юарлык авыр эшкә тарт. Әгәр дә кемдер үз гомерен куркыныч астына куярга теләмичә орышта чигенә, синең ышанычыңны акламый, кыен хәлдә калдыра икән — читкә тибәр, әмма кычкырып, мыскыллап үзеңне түбәнсетмә. Тәрбиялелек — әдәп, әхлагыбызның төп нигезе.

Һәркайда һәм һәркемгә, югарыдагыларга һәм түбәндәгеләргә, өлкәннәргә, хатын-кызларга хөрмәт. Хатын-кызга кул күтәрү — егетләр өчен хурлык. Син һәрбер кешене: танышмы ул яисә таныш түгелме хөрмәт итәргә тиеш, әмма дәрәҗәңне, бәйсезлегеңне, үз-үзеңә ихтирамыңны беркайчан беркем алдында югалтырга тиеш түгелсең.

Ау эте өрми — аксөяк сүгенми. Хатын-кыз, бигрәк тә әдәпсез ир-ат алдында тавыш күтәрүдән Аллаһ сакласын, әгәр ир-егетнең хатын-кызга кул күтәргәнен күрәсең икән — үтер, ул ир-ат исемен йөртергә лаек түгел.

Алар ир-егетнең намусы һәм мәртәбәсе турында күп тапкырлар сөйләштеләр, шулай ук җиңүченең хәрби бурычы, батырлыгы, рәхим-шәфкатьлеге турында да сүз кузгаттылар. Елбаздук күңеле, җаны чиста оныгының комсызлыкка омтылышы юклыгын, ялагай түгеллеген күреп, Үзбәкнең киләчәктә Аллаһ булышлыгы белән яхшы хаким буласын сизә, белә иде.

Көн арты көн узды, хәер, көннәр генә түгел, еллар да сизелми генә артта кала бардылар. Үзбәк буй тартты, ныгыды, матур кызлар очратканда йөзенә кызыл ягылды, тегеләре исә карашларын яшереп, башларын иделәр. Чиркәс кызларына таныш булмаган ирләр белән сүз алышу тыела. Елбаздук алга таба да оныгын үз карамагында тотарга ярамасын сизә, унбиш яшьлек егеткә ирләр белән хатын-кызлар арасында булырга тиешле аралашу әдәбе турында ничек аңлатырга дигән сорауга җавап эзләде. Һәм оныгына ничек бар, шулай аңлатты.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ

Алга таба оныкны ничек тәрбияләргә дигән уйлар Елбаздукның йокысын качырды.

— Уйла, Елбаздук кенәз, уйла, шуның өчен сиңа баш бирелгән. Оныкка хәзер аралашу әдәбе турындагы белемнәр генә җитми, аңа биек таулар артындагы тормыш белән танышырга вакыт. Мәккәгә барып хаҗ кылып кайтырга иде, әмма куркыныч — Үзбәкне танучы очрарга мөмкин. Туктай ялганны кичермәс. Ә нишләп әле Ширван иленә сәяхәт кылмаска ди? Бу патшалыкта күптән ислам дине кабул ителгән, бик күп әйбәт мәчетләр бар, укымышлылар, фәлсәфәчеләре һәм шагыйрьләре күп, малайга менә дигән укытучылар табып, фарсы һәм гарәп телләрен өйрәтергә була. Дөрес, хәзерге вакытта Ширван дәүләтен монголлар яулап алды, тик бу Алтын Урда түгел, бу һулагулар, Чыңгызхан нәселе патшалыгы, аның кече улы Толуй нәселе. Кемдер Үзбәкнең Алтын Урда тәхете варисы икәнен белеп алса, ярдәм дә итәргә мөмкиннәр. Хәер, кем белгән? Әсир булып куюы да ихтимал... Ни генә булмасын, сәяхәткә кузгалырга вакыт, тик яшертен эш итәргә, Үзбәккә башка исем табарга кирәк. Йә, Бөек, кодрәтле Аллаһ, бәндәләреңә ярдәм ит. Тауларым, сез дә рәхим-шәфкатегездән ташламагыз, сез сер саклый беләсез.

Икенче көнне Елбаздук сәяхәт планын төзеп, оныгын юлга хәстәрләү мәшәкатьләренә чумды.

***

Туктай хакимлек итү башында Нугайның киңәшләренә колак салса да, хәзер моңа мохтаҗлыгы юк иде, чөнки еллар узу белән ул ныгыды, акыл, тәҗрибә туплады. 1293 елда Туктайга имеш-мимеш хәбәрләр килеп ирешә. Урыс кенәзе Дмитрий Александрович, ачы балдан артыграк авыз иткәнме, янәсе, Сарай тәхетендә яшь, йомшак, көчсез хан утыра, Нугай исә көчле, нәкъ менә аның әмерләрен үтәргә кирәк, ханның күрсәтмәләренә килгәндә исә, ашыкмаска кирәк, чөнки бәкләр-бәге барыбер үзгәртәчәк, дигән имеш. Туктай шулкадәр ярсыды ки, ярый әле, бабасы Сәлҗидәй Гүргән янәшәсендә туры килде. Ул оныгын туктатып калды:

— Бөек ханга ачулану килешми, тәбәгаларың[10] алдында көчсезлегеңне күрсәтергә дә ярамый! Башта тынычлан, ял итеп ал яисә башка эш белән шөгыльлән, ә иртәгә ашыкмыйча уйларсың. Иртә кичтән хәерлерәк.

Иртән Туктай абыйлары һәм бабасы белән киңәшләште. Ахырдан урыс җиренә күп итеп гаскәр җибәрергә дигән фикергә килделәр. Белсеннәр кенәзләр кемнең кем икәнен. Берочтан Нугайны да урынына утыртырга кирәк.

— Карарбыз, аның үксез бозавы — Дмитрий Александрович үзенә тиешлесен алгач, бу карт төлке ничек боргаланыр икән,— дип тәмамлады сүзен Сәлҗидәй Гүргән.

— Сарайны саксыз калдыру ярамас, аерылып йөрү дә куркыныч, бер тирәгә тупланырга кирәк, югыйсә хәйләкәр Нугай әкә берәм-берәм бәреп чыгарыр. Әнә Тудан гаскәрнең яртысын алсын да урыс кенәзлекләренә юнәлсен, калганы безнең белән булыр, йоклап ятып булмый, — дип, Сарай-Буга үз фикерен җиткерде.

Туктай, килешеп, үз янына кенәз Дмитрийның кече энесе Андрей Городецкий чакыртты, аңа бөек кенәз кәнәфиен вәгъдә итеп, Тудан белән бергә урыс шәһәрләренә яуга озатты.

Владимир, Суздаль, Муром , Юрьев, Переяславль, Коломна, Мәскәү, Можайск, Дмитров, Углич — барысы да бушап калды. Урыс иле елый, үкерә, ыңгыраша, әйтерсең Бату хан кабат аның аша узган. Кенәз Дмитрий Андрей файдасына бөек кенәз тәхетеннән баш тартты, урыс кенәзләренең башкалары исә өйдә кем хуҗа булуына төшенделәр.

[10] Нинди дә булса дәүләтнең гражданы, шуның кул астындагы халык.

Нугайның бу яу сәфәренә карата фикере ишетелмәде, берни белмәгән кыяфәт чыгарды. Юк инде! Ничек кенә белде әле! Иң мөһиме — оттырганын аңлады. Шулай итеп Туктай хакимлеген тагын да ныгытты, монарчы икеле-микеле торган бәкләр дә аңа тартылдылар. Әмма хәйләкәр карт җинелергә өйрәнмәгән, кайда, ничек тиешле дәрәҗәдә җавап бирергә дип уйга калды.

Унөченче гасырның туксанынчы елларының икенче яртысында, Туктайның тәхеттә көчәя барганын күреп, күп кенә аксөякләр аңа якынайдылар, шул исәптән Нугай Олысыннан да килүчеләр артты. Бәкләр бәгенең башка түзәр чамасы калмады, ул ханнан Сәлҗидәй Гүргән белән Тамма-Туктайны Сарайдан кууны, шулай ук Олысыннан аңа качкан бәкләрне кайтаруны таләп итте. Туктай бу таләпләргә колак салмады, гомумән, Нугайга җавап биреп тормады, чөнки иртәме-соңмы бәкләрбәгенең өч йөз меңлек гаскәре канунлы хакименә кучәчәгенә иманы камил иде.

Тик әлегә Нугай үз көчендә иде, ул орышка әзерләнде. Әмма Олысында туган кыенлыклар, картның аяк-кулларын бәйләде дә куйды.

Туктай көннән-көн дәүләт эшләренә төшенә барды, анда Сарай шәһәрен корып бетерү теләге уянды. Бөтенләй үк баш тартмасалар да, күчеп йөрү гадәтләреннән әкрен-әкрен ераклаша барып, утрак тормышта яшәүне яклаган Алтын Урта аксөякләре бу фикерне куәтләделәр. Бәкләргә затлы әйберләр, йорт һәм матурлап эшләнгән бизәкләр, нәфис итеп эшләнгән хатын-кыз бизәнгечләре, күркәм савыт-сабалар ошый иде. Йортларны биегрәк, иркенрәк, ихаталарны киңрәк, бассейннарны тирәнрәк итеп төзеделәр. Һәр бай йортка кытайның ефәк тукымалары, гарәп китаплары, язу-сызу кирәк-яраклары килеп керде. Эчке сәясәттә заман белән бергә ярашырга теләгән Туктай олыслар арасындагы хәлләрне күз уңыннан ычкындырмады.

Тик тышкы сәясәт тә бар иде. Ханга Азәрбайҗанны яулап алу теләге тынгылык бирмәде, чөнки аның фикере буенча хулагидлар аны канунсыз рәвештә үзләштергәннәр. Шәрыктагы чикләр турында да онытмады ул һәм иминлек тәэмин итү максатында чыңгызыйларның бердәм империясен торгызу өчен бөек Тимер хан белән сөйләшүләр алып барды, шулай ук Иран илханы белән тынычлык торгызуга иреште.

— Әгәр Азәрбайҗанга кузгалсам, Иран падишаһы үзенә һөҗүм итмәсенә ышанырга тиеш, ике фронтта сугышырга теләмим, чөнки Тимер үзенә карата ихласлыгыма ышана, — дип фикер йөртте Туктай.

Үсмер чак уен-мәзәкләре күптән икенче планга күчте, аннары өченчегә, бар вакытын дәүләт эшләре йотып барды. Алар белән шөгыльләнү ханга рәхәтлек бирде, бары төннәрен генә үзенә ял рөхсәт итте ул.

Туктайның егермедән артык, сайлап алгандай берсеннән-берсе матур хатыны бар иде. Тик өзелеп яратканы — озын буйлы, зифа сынлы, нечкә билле, тулы тыгыз ботлы яшь хатын Арибах. Хан янына һәрвакыт күтәренке кәеф белән килде, аннан берни турында сорамады, тынлый-ишетә белде, Туктай аның фикере белән кызыксынса, тыйнак кына аска карап, акыллы киңәшләрен бирә иде. Сөеклесенең тагын бер искиткеч сәләте бар, ул учын иренең башына куеп, аның арганлыгын бетерә иде. Аның кулы тиюгә чәчләр чатыр-чотыр итә иде, хатынның тыгыз күкрәге иренең иреннәрен иркәли, хан, мәхәббәт патшабикәсенең назыннан, күкләргә аша, ару кул белән уеп алгандай юкка чыга иде. Арибах Туктайдан ун яшькә олырак иде. Нәкъ менә ул ханны җенси хикмәтләргә өйрәтте һәм бары тик ул гына дәртнең ширбәт тәмен бирә алды. Хан аны сарайда да, күченеп йөргәндә дә, кыска вакытлы сәфәрләрдә дә гел янәшәсендә йөртте. Арибах уеңдагын тормышка ашыру юлында иде. Хәзергә бар да үзе уйлаганча бара, тик кайчан нәрсә буласын беркем белми, өстәвенә хәрәмдәге хатыннар бик көнче, шуңа Үзбәкнең анасына бик сак булырга туры килде.

***

Кояш күтәрелеп килгәндә, Елбаздук оныгы белән елга янында очрашты. Җәй башы, кичү юллары ачылган, үләннәрнең хуш исеннән баш әйләнә, агымсу юлында очраган ташларга бәрелеп, матур көй чыгара, матур җәйге иртәне котлап, кошлар чыркылдаша. Бабасы белән оныкк җәһәт кенә юынгандай иттеләр дә тау аланына — кизләүгә киттеләр. Нарзан исе борынны ярып керде, үтә күренмәле тәмле суны кушучлап авыз иткәч, йокы уч белән сыпыргандай юкка чыкты, күнел күтәрелеп, гәүдә җиңеләйде.

Йомшак үләнгә утырдылар.

— Ханым, — дип сүз башлады аталык, — безнең таулар артында Ширван дәүләте урнашкан, әкренләп шунда сәфәргә әзерлекне башлыйк. Гаҗәеп патшалык, күп нәрсәләр белерсең, Итилеңнән кайсы диңгезгә койганын күрерсең. Анда шагыйрьләр, галимнәр белән танышырбыз дип ышанам. Сиңа галәм, дөнья кануннарына төшенергә, башка халыкларның телләрен белергә вакыт җиткәндер. Әмма без анда, син тауның тагын бер гыйлемен — урлау фәнен өйрәнгәч кенә кузгалырбыз.

Яшь хан шаккатып тәрбиячесенә карады.

— Әйе-әйе, ялгыш әйтмәдем, син урларга өйрәнергә тиеш, — диде Елбаздук.

— Аңламыйм, кенәз йә ханга урлашу нигә кирәк, алар тарханнардан[11] булай да барысын да ала, хуҗасыннан яшергәннәрен яугирләр тартып ала.

— Ә син уйла! Нәрсә ул урлашу? Бу — теләсә кайсы утарга, бинага этләр өрмәслек, хайваннар сизмәслек итеп үтә алу сәнгате. Бу — нәрсә дә булса эләктерү, хуҗаларның ни сөйләшкәнен тыңлау, ияр кисү, әкрен генә сиздермичә атларны алып китү сәләте. Менә бу — ир-егетнең елдамлыгы! Сугыш вакытында яисә сәфәр чыккач болар кирәк түгелмени? Болар баер өчен өйрәтелми. Сарык яисә тавыкны шыпырт кына чәлдесең, әгәр хуҗасы сораса — кайтарасын, ә инде зыян күрүче кем урлаганын белми икән, димәк, ир-егет түгел, ул начар хуҗа. Урлашырга өйрәтү — житезлеккә, кыюлыкка һәм салкын канлылыкка өйрәтү, әгәр син дошман белән кара-каршы килгәндә ул сине шәйләми, ә син аны күрәсең, ишетәсең һәм бер генә мускулың да селкенми икән, димәк, син бу фәнгә төшенгәнсең булып чыга. Сиздертмәү сәләте — зур сәнгать ул. Хәзер инде аңладыңмы?

Үзбәк башын селкеде:

— Мин хәзер үк башларга да риза, аталыгым.

Яшь хан, һава торышы нинди булуга карамастан, физик күнегүләрне калдырмаска тырышты. Күзгә күренеп ныгыды, мускулы таш кебек катыланды. Зур кылычны кулында мамык бөртегедәй биетте, нык тартылган җәядән бертуктамый утыздан артык ук атарга, озак итеп сулышын кысып торырга өйрәнде. Поскында12 яртышар көн кымшанмый ятканнан соң, тәнен тиз генә язып, барс сыман табышына атылды.

Үзбәк бик тиз урлашырга өйрәнде, төнләме ул, көндезме — сиздерми генә утарларга үтеп кереп, күләгә кебек шыпырт кына теләгән почмагына уза алды. Ашыкмаска-кабаланмаска өйрәнде, озаклап бер аягында торып, уңайлы вакытны көтеп алып, үзенә кирәкне эләктереп, тавыш-тынсыз юкка чыкты.

Берәр ай үттеме икән, Елдазбукка, беркем беркайчан күрмәгән каракны тотарга ярдәм итүен сорап килделәр. Һәркайсының ниндидер кыйммәтле әйберләре югалган икән. Кенәз, мыек астыннан көлеп, нәрсәләре урланганын сорашты.

— Мин каракның кем икәнен беләм, әгәр яхшылап сорасагыз, ул сезгә мөлкәтегезне кайтарыр, — диде Елбаздук.

---

[11] Ханга буйсынучы булып саналган, ләкин аңа ясак түләми торган вассал, салымнардан азат феодал. Ханның урынбасары һәм киңәшчесе.

[12] Яшерен урыннан дошманга көтмәгәндә һөҗүм итү алымы.

***

Елның иң кыска саналган төне үтеп китте. Йөздән артык җайдак Мары елгасы яныннан үзәнлеккә төште. Кәрван уртасында ашыкмый гына авыр йөк төялгән качырлар атлый. Алда — нәселле чабышкыга атланган Елбаздук, яшь булсалар да абреклар белән вак-төяк бәрелешләрдә сынау үткән яугирләр уратып алган Үзбәк аз гына аннан калышып бара. Отрядта Үзбәкне бар да Елбаздукның туганнан туганын, гәрчә беркайчан улы булмаса да, малае Антанук дип беләләр. Сәяхәтнең максатын бар да белә: отрядтагы сигез дистә яшь кенәз һәм дворян сугышчыларына тирә-юньне күрсәтү, күршеләрнең тормыш-көнкүреше белән таныштыру, Шәрыкка юл ачу иде. Үзбәк-Антанук уйчан иде, ул нәрсә күрә, ишетә, белә — барысын да сеңдерә барды.

Сәфәрнең өченче көне кичкә авышканда, алар каршында биштүбәле тау пәйда булды. Үзбәкнең күңелен балачакның шомлы истәлекләре урап алды, әмма ул бик тиз алардан арынды да табигатьнең матурлыгына сокланып, дала хуш исе аралаш чиста, саф һаваны күкрәк киереп сулады.

Биштүбәле тау яныннан көньяк-көнчыгышка борылып, кабардин— балкар җирләре аша Алания түбәсенә якынлаштылар. Юл барган саен кыенлашты, бер-бер артлы тау елгаларын һәм инешләрен кичәргә туры килде, шуңа әкрен барылды.

Кичке тукталышларда тирә-юньгә пешкән бәрән итенең, кәбабның хуш исе таралды. Елбаздук һәм тәҗрибәле дөнья күргән узденнар[13] риваятьләрнең төп каһарманы таш улы Сосруко, аның анасы Шайтан, тимерче Тлепша турында сөйләделәр. Ә яшь-җилкенчәк Сосруконың Иныж алыпны бик оста алдап, тунган-өшегән нартлар өчен ут табуы турында ишеткәч, андый батырның кабардиннар арасында да булуын аңладылар. Ә аланнарның батырлары арасында иң түзем, иң елдам һәм иң башлысы булып Сослан санала.

— Шулай да нартлар кая югалган соң? — дип кызыксынды яшьләр арасыннан берәү.

— Аларга Аллаһ җәза биргән! Имансыз булганнары, үзләренең көч-акыллары белән масайганнары, Аллаһы Тәгаләгә ышанмыйча, үзләрен Аның белән тиңләүләре өчен Ул аларны җир йөзеннән юк иткән, — диде Елбаздук озак кына дәшми торганнан соң. — Арагыздан теләсә кайсыгыз никадәр генә көчле, күпме генә акыллы, кешеләр өстеннән никадәр зур хакимлеге булмасын, әллә ничә тел, фән белмәсен — үзен Аллаһ дип санарга хакы юк, ул Аллаһның көч-куәте, гакылына чәнчә бармак кадәрле дә якын килә алмас. Без, кешеләр, бала тудырырга сәләтле, әмма Аллаһ кына аның җанына сулыш өрә ала. Йә, берәрегез кайсы заманның, кайсы халыкның сугышчысы дошманын үтереп, аның җанын күргән, дигәнне ишеткәнегез бармы? Җан белән бөек һәм кодрәтле Аллаһ кына идарә итә ала, ә без аның җирдәге коллары, вакыт-вакыт башларын күтәреп карый торган шуышып йөрүче суалчаннар. Боларны исегездә калдырыгыз һәм беркайчан беркайда масаймагыз!

Яшьләр, буркаларына[14] төренеп, тынып калды. Зәңгәр күктәге йолдызлар, егетләргә озын, давыллы тормыш вәгъдә иткәндәй, күңелле генә күз кысты.

«Нәрсә бар икән ул йолдызларда? Бәлкем Аллаһыбыз шунда яшидер? Әллә якын-тирәдә генә йөри микән?! Күпне күргән аксакаллар белән гәпләшкәннән соң, һәрберсе диярлек шундый уйларга чумды.

Берничә көннән соң кичен кенәз барысына да, иртәгә Җәүҗикәүдә[15] булачакларын, анда аның кунагы[16] Хетэг кенәз яшәвен хәбәр итте һәм озаклап

[13] Кавказда тау дворяннны.
[14] Җилкәгә салып йөри торган җиңсез тула чикмән.
[15] Владикавказ шәһәре.
[16] Кавказның тау халыкларында һәм төрки халыкларда дус кеше, якын иптәш, хәл белеп ял итәргә килгән кеше.

аталарының дуслар булуы, Хетэгының атасы хөрмәтенә үзен Елбаздук дип атаулары, аталарының урыслар белән яу чыгып, зур табышлар белән кайтулары турында сөйләде.

— Жәужикәудә берничә көн торырбыз, Кук тарлавыгына юл тотканчы атларны ял иттерербез. Алдан ук әйтеп куям, безнең хуҗа — гыйсави. Аның диненә хөрмәт белән каравыгызны сорыйм. Намаз уку өчен аерым бүлмә бирүен үтенермен, әмма иң мөһиме, өлкәннәрнең сүзләрен онытмагыз: Аллаһтан бөек булып булмый.

Таң алдыннан Елбаздукны күзәтүчеләр уятты. Аларга янәшәдә генә кемдер йөри, аларны күзәтә кебек тоелган. Тәҗрибәле сугышчы тынлыкка колак салды, карашы белән як-якны айкады. Кинәт аның үткен күзенә көнбатыш яктагы зур-зур йомры ташлар артыннан бурка читеме, бүрекме чагылып киткәндәй булды.

Елбаздук дәшми генә бармагы белән шул тарафка төртеп күрсәтте, һәм өч егет, барслар кебек җинел генә таштан ташка сикереп, шымчыны камап алмакчы иттеләр. Әмма теге күз ачып йомганчы иярenә сикереп менде дә Калкулык артына кереп качты, шул арада тояк тавышлары да тынды. Елбаздук каты гына:

— Син кем? Дус икәнсең, кылычыңны кынында тотып чык, — дип кычкырды, — дошман булсаң да күрен, көч сынашырбыз. Мин — чиркәс кенәзе Елбаздук, Ширван дәүләтенә юл тотышым.

Жайдак, игътибар белән карангалап, калкулык артыннан чыкты:

— Мин — Хетэгның улы Ахсар.

— Сон, кил монда, улым, кочаклыйм үзеңне, — Елбаздук сөенде һәм үзе, кочагын киң җәеп, кунак углына каршы атлады.

Хетэг кунакларны патшаларча каршы алды. Кавказда кунакның урыны һәрвакыт түрдә. Һава торышы яхшы, шуңа өстәлне елга буенда әзерләделәр. Дистәләгән ирләр, хатын-кызлар азык-төлек ташыдылар, тәмле осетин сыры белән сыйладылар, кайнар фыдджын (итле бәлеш яки бөккән), сырлы цыхтджын китерделәр. Аларга алмашка яшь колын итен каймаклы цахдон соусы белән бирделәр, бәрән итеннән ясалган кәбабтан авыз иттерделәр. Алларыннан бик тәмле, бары тик аланнар гына ясый торган сыра өзелмәде. Таулардагы гадәт буенча, исәнлек-саулык, байлык-муллык теләп, тост арты тост күтәрелде.

Елбаздук белән Хетэг озак кына утырдылар, бер-берсенең, халкының хәл-әхвәлләрен белештеләр, шатлык-борчуларын уртаклаштылар, ата-аналарын искә алдылар, аларны һәм мәрхүм булган якыннарын искә алып, әче бал тулы җамнарын күтәрделәр.

Яшьләр өчен ук ату ярышы оештырдылар. Азакка Ахсар белән Антанук чыкты, күп тапкырлар атышканнан соң, хуҗа кунакка юл бирде — Елбаздук шәкерте җиңде. Кылычка кылыч ярышы башлангач, кенәзләр таләпчәнлек күрсәтеп хөкемдарлыкны нык күзәттеләр, әмма тегеләр тагын башка сугышчылардан аерылып тордылар. Соңгы бик озакка сузылган көрәштә Ахсар, ниһаять, Антанук кулындагы кылычны бәреп төшерде. Хетэгның кәефе китте:

— Син таулар кануны, кунакчыллык турында оныттың,— диде ул улына кырт кисеп.

— Ачуланма, туганым. Минем укучым да сынатмады. Теләсә кайсы орыш — гыйлем ул.

Менә дигән итеп ял иттеләр, хәер, иң яхшы дустың белән очраш та — начар булсын, имеш.

Иртәгә кузгалабыз дигән көнне иртән Елбаздук елга буенда юынганда кемдер аны күзәтә кебек тоелды. Елт кына артына борылды һәм куаклыкта балаларча үткен караш чагылды.

— Әйдәле, чык монда, ут борчасы.

Куаклар арасыннан тыгыз итеп үрелгән толымлы кыз килеп чыкты.

— Кил, балакаем, янымa.

Кызчык шома ташларга сак кына басып, кыю гына ир-ат янына килде дә:

— Кенәз, сез нишләп башыгызны шулкадәр югары тотасыз? — дип сорады.

Елбаздук шаркылдады:

— Ә син бу тауларны күрәсенме? Матурмы алар?

Кыз башын селкеде.

— Ә син күзалдына китер, таулар кинәт кенә түбәләрен түбән иделәр, ди. Нәрсә булыр иде?

— Начар булыр иде, түбәдәге карлар ишелеп, юлларны күмәр иде. — Кыз елмайды һәм сөенеченнән сикергәли башлады. — Хәзер мин беләм! Хәзер мин беләм! Кенәз — тау ул, мәрхәмәтле таулар кешеләрне коткаралар.

Иртәнге аш вакытында Елбаздук Хетэгтан:

— Синең йортында бик житез, тере кызчык бар. Синеке түгелдер бит? — дип сорады.

Хетэг дәшми торды, аннары тирән сулап авыр гына сытып чыгарды:

— Ул — минем жан әрнүем.

— Кичер, сине унайсыз хәлгә куясым килмәгән иде.

— Бу шулай, тик мина жанымны басып торган авыр йөкне, дустым белән гәпләшеп, жинеләйтергә вакыт. Синнән башка кайгы-борчуымны сөйләрлек кемем бар? Тынла, туганым. Минем чибәр, акыллы, үземә охшап горур кызым Ирэ бар иде. Ягымлы бала иде, тик һәрбер кызчык житкән кыз була, аннары — хатын-кыз. Минеке дә үсеп буй житкерде. Кодалар да күттермәде, кияү егете менә дигән — ширван шаһы тамырына тоташкан кесранид ыруыннан Бәйрәм атлы. Туй бик купшы булды, әмма кызымның тормышы барып чыкмады. Аллаһ Ирэ кызымның ирен юкка гына андый исем белән атамаган икән. Исеменә туры китереп, көн дә эчү, көн дә күнел ачу мәжлесе ясады ул. Бервакыт абыйсы Ариф аларда кунак булганда, бу шакал хатынын — кызым Ирэны ана бүләк иткән. Ариф озак вакытлар яна хатынын йокы бүлмәсенә дәшмәгән. Ниһаять, күрәсе килеп дәшмәкче булган, ә хәрәм агасы анын корсаклы икәнен житкергән.

Вакыты житкәч, Ирэ кыз бала тапты, Тай-туглы дип исем куштылар, төрк телендә ул «агасы өендә туган» дигәнне анлата. Ариф, табигый, аны үз кызы итеп танымады, атасына да кайтара алмый — тегесе эчкечелек сөременнән айный алмый үлеп киткән. Кызымны өйләге бар пычрак эшне башкаручы иткәннәр, әмма горурлыгы андый тормышны күтәрә алмаган һәм ул кызы белән качарга уйлаган. Кечкенә бала белән тау-ташларны ничек кичкәндер ул, көч-хәл белән бусагага кайтып егылды. Анын кыяфәтен күреп, йөрәгем әрнеде. Ил телен беләсен, үлгәннәрнен дә барысын аямый, янымда имеш-мимешләр сөйләргә базмасалар да, артымда ниләр генә уйлап чыгармадылар, «кин күнелле»ләр Ирэга төрле шакшыны житкереп тордылар. Кайгысын күтәрә алмады — кыяташтан ярсып аккан Терек суына сикерде. Кайгымнын чиге юк, ничек Аллаһнын ачуын китергәнмендер — белмим, әмма кызыма шундый ачы язмыш бирде. Бездә үз-үзләренә кул салганнарны искә алу кабул ителмәгән, әмма мин кызымны онытмыйм, оныгымны кайгыртам, ә ул, күреп торасын, матур, өстәвенә зирәк акыллы булып үсеп килә.

— Чынлап шулай, — дип жөпләде аны Елбаздук, — аты ничек, тагын бер кабатла әле, колакка кермәгән ят исемне бу зиһенсез баш тиз генә истә калдыра алмый.

— Тай-туглы. Исемен алыштырып тормадым. Безнен ырымнарны беләсен, туганда Аллаһ тарафыннан бирелгән исемне үзгәртергә ярамый, кешегә бәла чакырырсын, диләр. Мин анын анасынын язмышын кабатлавын теләмим. — Хетэг тирән итеп сулыш алды.

Төш алдыннан Елбаздук үзенең яраннарын жыеп, иртән иртүк кузгалырга әзер булыгыз, дип боерды. Кичен озату мәжлесендә Хетэг белән икәү генә утырдылар.

— Әгәр бар да яхшы булса, икенче елга кичүләр ачылуга кайтыр юлга чыгам. Кавказның төп сыртын кичкәч синдә ял итәргә тукталырмын, — дип вәгъдә бирде Елбаздук.

— Керми китсәң үпкәләрмен, — диде Хетэг. — Сорарга рөхсәт итче, теге син күз уныннан ычкындырмаган кысыграк күзле үсмер кем ул?

— Ул минем укучым, мин аның аталыгы. Син бит безнең гореф-гадәтләрне беләсең, без үзебезнең балаларга үзебез тәрбия бирмибез, әмма дәрәҗәсе белән бездән өстен торган күршеләребезнекен үстерергә ярдәм итәбез.

Кавказда күп сөйләмиләр, бер-берсен ярты сүздән аңлыйлар һәм кирәкмәгән сорау биреп маташмыйлар. Хетэг та сүзне озайтып тормады.

— Укучың сәләтле күренә, ерак китәр, — дип осетин кенәзе сүзен йомгаклап куйды.

Елбаздукның тәне буйлап жылы йөгерде.

— Туганым, улың Ахсарны безнең белән сәяхәткә жибәрү теләгең юкмы? Илжир күрер, акыл туплар, кешеләрнең һәртөрлесен күрер, фәннәргә төшенер.

— Әйе... — диде Хетэг, — дәшүенә рәхмәт. Уйлап карарга кирәк.

Карарны озак көтәргә туры килмәде, сәфәр бары тик бер генә көнгә кичектерелде. Хетэг улын әзерләп бетерде, дустын кочаклады, барысын да таулар аша озын юлга озатып калды.

***

Отряд Дарьял тарлавыгына якынлашты, агымсу тавышы колакларга бәреп керде. Бу Терек иде, каршында торган зур йомрыташларны кузгатырга теләгәндәй зур көч белән килеп бәрелә, әмма ташлар каршы торып, агымсуны болганчык ярсу ташкын һәм чәчрәвекләргә яра-бүлгәли. Котырынган су тавышы таулар арасыннан югарыга ыргыла, әмма юлына киртә булган кыяташларга бәрелеп кабат аска төшә, тагын да шаулап-ярсып бөтерелә, кешеләр, хайваннарның колагына бәрә һәм каушау, курку тудыра.

Юл әкрен генә тауга күтәрелә, таулар исә, елганы кысрыклап уратып, болытларга таба кул сузган. Һава салкынайганнан салкыная барды, тарлавыкны карангылык басты. Әйтерсең, күк йөзендә беркайчан да кояш балкып яктыртмаган. Терек, ярсуын дәвам итеп аста кала барды барды да кинәт тавышы өзелде. Отрядның юлы Терек артыннан йөгергән Байдарка ярлары буйлап дәвам итте.

Ин югары үткелдә сәяхәтчеләр кар белән капланган тау күрделәр, аның түбәсендә ак кардан жинеллеге һәм зәңгәрсу төсе белән аерылып торган ике бөдрә болыт ял итәргә тукталган.

Шул кичү юлында төн кундылар. Салкын булса да, учак янында Багратион ыруының бөек, серле патшабикәсе Тамара турында тынлап, тунуларын сизмәделәр. Иртәнгә кадәр юл күрсәтүче осетин бик теләп патшабикәнең зирәклеге, юмартлыгы турында, руханиларга, дәрвишләргә бүләкләр өләшүе, гыйбадәтханәләр төзетүе турында бәян итте.

Сәяхәтчеләр үзенең уртак балалары булмаган беренче ире — урыс кенәзе Андрей Боголюбскийның улы Юрийны ничек итеп кире кагуы, аннары балачак дусты осетин Давид Сосланга кияүгә чыгуы турында ишеттеләр. Давид батыр һәрвакыт яуда йөргән һәм тапкан бар табышын тулысы белән хатынына кайтарып биргән, ә тегесе аны грузин дәүләтен ныгытуга тоткан. Озата баручы осетин бөек шагыйрь Шота Руставелиның патшабикәгә мәхәббәте, ана багышлап поэма язуы турында да сөйләде.

Үзбәк-Антанук халыкның төзүче-патшаларга мөкиббән булуы турында колагына киртләп куйды. Тамараның үлеменә гасырдан арткан, халык ләззәтләнеп аның төзү-корулары турында булганын да булмаганын да кушып сөйли бирә. Яшь хан таудан төшкәндә мона кат-кат ышанды, чөнки һәр салада зирәк Тамара турындагы риваятьләрнен янадан-яналарын ишетте. Ана бөек патшабикә төзеткән манаралар, күперләр, гыйбадәтханәләрне күрсәттеләр.

Озакламый Грузиянен борынгы башкаласы Мцхетега җиттеләр. Ул кайчандыр ике елга — Арагви белән Кура кушылган җирдә урнашкан, анда грузиннар арасында агарту эшләре алып барган бик матур изге Нина монастыре булган. Тик хәзер шәһәрдән җир асты йортларын хәтерләткән берничә корылма белән ватык-җимерекләр генә калган.

Ялыктыргыч озын тау юлыннан сон, зур булмаган, әмма якты һәм уңайлы шәһәрчек — Тифлиста тукталырга булдылар. Кунакларны кавказлыларга хас булганча, шәраб белән каршы алдылар, күнелләрен күрделәр. Юл тузанын бишенче гасырда Вахтанг Горгасал ауга йөргән урында, Абанотубанида юып төшерделәр. Вахтанг Горгасалнын лачыны, үрдәкне бәреп төшереп, анын белән бергә кайнар чишмәгә төшеп пешкән. Нәкъ менә шушы урында грузин патшасы яңа шәһәр төзергә әмер биргән һәм башкала иткән.

Атна буе ял иттеләр, ауга йөреп ашау-эчү саклыгын өстәделәр һәм кабат, монысы инде җинелрәк, юлларын дәвам иттеләр. Руставелины узып, Гарбадан даласына килеп чыктылар. Бар салалар, Үзбәкнең ата-бабалары яу чабып бу җирләрне тар-мар иткәннән соңында, бик аяныч хәлдә калган.

«Ни өчен шәһәрләрне тәмам җимерергә һәм таларга? Табышны бит кешеләр китерә. Алар хәзер дә монда яшәрләр, эшләрләр, сату өчен әйберләр җитештерерләр иде, ясак-салымыңны сал да рәхәтләнеп яшә иден. Инде бик нык каршы килеп, үтерергә туры килгәндә дә торак, эш коралларын ник ватарга-җимерергә? Тар-мар ителгәннәр урынына башкалар килер дә эшли башлар һәм табыш китерер иде», — дип фикер йөртте Үзбәк, башын иеп. «Хан булгач, акыллырак эш итәчәкмен!»

Хәрабәләрне күреп, Елбаздукнын кәефе кырылды. Оныгын бирегә алып килгәне өчен үзен битәрләде, ул бит кайчандыр галимнәре һәм шагыйрьләре белән дан тоткан, нык үскән өлкәнең нинди хәлгә калуы турында үзе дә бихәбәр иде.

«Ач кеше фән турында уйламый», — диде ул үз-үзенә.

Кайчандыр даны һәм байлыгы белән дан тоткан Шәмәханга җиткәч, Елбаздук тәмам кешелектән чыкты. Тирә-якнын һәр патшасы чибәрләрнен чибәре — шәмәхан патшабикәсен хатынлыкка алу турында хыялланды, һәр хаким ширван шаһы белән дустанә булуны дәрәҗә саналы. Ә хәзер күпме тапкырлар монда булган Елбаздукнын күзеннән яшьләре тамды. Утыз ел элек Алтын Урда гаскәре тарафыннан җимерелгән шәһәр җир селкенеп тәмам кырылган, анда ике йөз тирәсе фәкыйрь көн күреп маташа иде. Хәлләләр күптән Шәмәханны ташлап киткән, кемдер тауларга, кемнәрдер башка шәһәрләргә юл тоткан.

Төн йокысыз узды. Авыр уйлардан кәефе киткән кенәз таң алдыннан гына күзләрен йомды, төшендә анын янына шаян кызчык Тай-туглы килде.

— Нәрсә, кенәз, тавыннын түбәсе җимерелдеме? — дип сорады ул, акыл җыйган хатын-кыздай. — Мөгаен, аны кар каплагандыр. Син бит һәрчак башынны югары тоттын. Онытмадынмы? Күзенне күтәр дә, кенәз, шәрыкка карап юл тот, шунда эзләгәненне табарсын.

Елбаздук манма суга батып уянды. Тирә-ягына каранып алды, кояш чыккан, чатыр тирәсендә яшьләр ыгы-зыгы килә иде. Кенәзнен җанына тынычлык иңде, ул юынды һәм шәрыкка таба кузгалырга боерды.

Өч тәүлектән соң отряд Баку шәһәренен яхшылап ныгытылган дивары

янында тора иде. Елбаздук каравыл өчен бүләкләр хәстәрләде, атчабарларны, үзен кабул итүен үтенеп, ширван шаһы Кей Кабус ибн Ахситан янына юллады. Атчабарлар: «Кенәз шаһтан хәбәр көтсен» дигән җавап белән кайтты. Өч көн узды. Сәяхәтчеләр ныгытма дивары янында, үзләренең күзәтү астында булуларын тойган хәлдә, басып тордылар. Дүртенче көн азагында шәһәр капкасы ачылды һәм ширван шаһның хәбәре җиткерелде: кенәз белән аның өч морзасына алдагы көннең төш вакытына килеп җитәргә кушылган иде.

Ниһаять, Үзбәк беренче тапкыр мөселман хакименең сараена аяк басты. Тәхет залының ишекләре ачылып китте, коралсыз милли киемле чиркәслар алтын кытай парчасы белән бизәлгән керү юлын үтеп, фарсылар кулы белән тукылган озын келәм өстеннән атладылар. Ачык кызыл келәмнең гаҗәеп бизәкләре ширван шаһы Кей Кабус ибн Ахситан утырган тәхеткә алып килделәр. Аз гына ындарак, тәхетнең кыйммәтле ташлар белән бизәлгән аркасы артында вәзир Агил ибн Хөсәен басып тора иде.

Елбаздук, башын җинелчә иеп, алдан барды, аның артыннан Үзбәк-Антанук һәм, кулларына бүләкләр салынган зур көмеш подноснар тотып, ике морза атлады. Тәхет куелган аскуймага берничә адым кала кенәз тезен бөкте, юлдашлары исә ике тезләренә төшеп башларын иделәр.

— Сәлам сиңа, әй бөек, кодрәтле Ширван шаһы Кей Кабус ибн Ахситан, Аллаһ сиңа озын гомер бирсен! Синең җаныңа Аллаһ тынычлык һәм иминлек иңдерсен! Бөек һәм мәрхәмәтле Аллаһ сиңа киң күңелле, шәфкатьле күршеләр җибәрсен һәм ил-җиреңә тынычлык бирсен! Көннәрең һәм төннәрең тыныч үтсен, патшалыгың һәм дәвамчыларың хәере белән халкың туып артып торсын! —диде Елбаздук тантаналы рәвештә.— Әй бөек хаким, бүләкләребезне кабул итеп алсагызчы.

Чиркәс морзалары шунда ук кыйммәтле ташлар белән бизәлгән алтын, көмеш эшләнмәләре, хатын-кыз бизәнгечләре тулы подносларны шаһның аягы очына куйдылар. Падишаһ бүләкләргә күзен йөртеп чыкты. Күренеп тора, ул бүләкләрне ошатты һәм күзен күтәреп, Елбаздукка сүзен дәвам итәргә рөхсәт бирде.

Кенәз, тезендә калган килеш, сүзен башламакчы иде, шаһ торырга кушып ым ясады. Елбаздук, илһамланып, дәвам итте:

— Әй бөек һәм дөньяның акыллылардан акыллы хакиме, Аллаһ синең көннәреңне озайтсын! Мин, Аллаһ тарафыннан зур бер патшалыкның тамыр үргеннәренең берсе өчен аталык дигән зур дәрәҗә бирелгән чиркәс җирләре кенәзе Елбаздук булам. — Үзбәк бу вакытта, башын түбән игән килеш, бер тезенә күтәрелде.— Ачуланма, әй падишаһым, Аллаһ сине сакласын, әмма исеңә төшерергә батырчылык итәм, без, чиркәслар, еш кына дөньяның бөек хакимнәренең балаларын тәрбия кылабыз һәм аларның исемнәрен, ата-аналары үзләренә чакыртып алганчы, игълан итмәскә ант бирәбез.

Кенәз Үзбәк янына килде:

— Ошбу үсмерне Антанук дип атыйлар, мин аңа үзем булдыра алганны өйрәттем. Минем укучым җәя һәм ук белән бик яхшы эш итә белә, егетлек осталыгы буенча дан казанды, түземле булырга, ашыкмаска өйрәнде, зур булмаган хәрби бәрелешләрдә чыныгу алды. Әмма мин әйләнә-тирә мохит, аның асылы, фәйләсуф һәм галимнәрнең соңгы ачышлары турында тирән белем бирә алмыйм. Шуңа мин, тыйнак колыгыз, Ширван галимнәре һәм шагыйрьләренең даны дөньяга мәгълүм булганыннан хәбәрдар булганга, сезнең биләмәләрегезгә аяк басарга батырчылык иттем. Әгәр дә син, әй бөек шаһ, тугры колларың өчен түбәнчелеккә барып, укучымның күңеленә белем өстәргә лаеклы укытучы табарга боерсаң, ата-аналары аның уңышлары, уй-фикерләү сәләте, яшәешнең илаһи ачышларын танып-белүенә шат булырлар, һәм Аллаһ Тәгалә дә, сөенеп, безне үзенең рәхим-шәфкате белән бүләкләр иде. Мин исә

үземнең яугирләрем белән кайда кушасың, шунда укучым белем чишмәсен төбенә кадәр эчкәнче хезмәт итәргә әзермен.

— Кенәз, мин сина яныма килеп, каршыма утырырга рөхсәт итәм. Андый кунакка шатмын, бүген сине укучың белән бергә төшке аш табынына чакырам. Үтенечен турында уйлармын һәм җавап бирермен.

Табынга вәзир дә чакыру алды. Кечерәк буйлы, үткен, күзе йөреп торган бу кешенең төшке аш вакытында авызыннан бер сүз чыкмады, бары үзенең падишаһы белән ара-тирә карашлары кисеште, әйтерсең алар арасында сүзсез генә әңгәмә бара иде. Үзбәк-Антанук моны мыегына чорнап барды, ул аларның күзләреннән ни булса укырга, аңларга тырышты. Ширван шаһының сорауларына шултикле ачык һәм әдәпле җавап кайтарды ки, тегесе аны шунда ук үз итте. Үсмернең Коръәнне тирәнтен белеп бетермәвен һәм галәм серләренә төшенеп җитмәвен аңлап, ул катлаулы сораулар бирмәскә тырышты, шулай да кенәзнең укучысының сәләте бар дигән нәтиҗәгә килде.

Дастарханга мул итеп шәрык тәм-томнары һәм җиләк-җимешләре куелгач, әкрен генә көй таралды һәм шаһ белән кунаклары алдына алты чибәр кыз пәйда булды. Алар, бию көенә чиратлап Антанук яныннан узләренең ялангач эчләрен, җинелчә ефәк белән капланган тулы шәп ботларын күрсәтеп бөтерелделәр. Гүзәлкәйләр яшь ханны кайнар, дәртле карашлары белән яндырды, көйдерде.

Үсмер егет дөньясын онытты, аларга кушылып әйләнәсе, тәннәренең ялангач җирләренә кагыласы, аннары ниндидер гаҗәеп назлы йокыга таласы килде. Ул моның кайчан да булса тормышка ашачагына нык ышана иде. Үзбәк-Антанук, кызлар арасыннан монысы иң чибәре дип, аерып күрсәтә алмас иде, чөнки алар сайлап алган кебек бар да искиткечләр, үзләренә тартып, җәлеп итеп торалар иде.

Шаһ яшь кунакка күз салуга, аның күңел халәтен аңлады. Шулай ук укытучысының аны күктән җиргә төшермәкче булуын, әмма һичничек булдыра алмавын да күрде. Шаһ эченнән генә: «Егеттә, һичшиксез, монгол каны, чыңгызый, — дип фикер йөртте. — Тик нәселнең кайсы тармагыннан? Хәзерге вакытта көнчыгыш белән идарә иткән һулагулардanмы? Ә бәлки Ауропаның яртысын диярлек яулап алган Җучилардандыр? Хәер, ник фаразлап торырга? Әгәр ул һулагу икән, аңа хөрмәт күрсәтергә һәм иң белемле укытучыны сайлап бирергә кирәк. Әгәр дә Чыңгызханның беренче улы Җучи ягыннан булса, шулай ук ихтирамлы булу һәм алга таба укуында ярдәм итү мәгъкуль. Галәмнең бөек җиһангиры нәселнәсәбәсе үзара һәрчак ызгыш-талашта, Ә Ширван дәүләте җирләрендә бәрелешләр еш кабатланып тора. Бу үсмернең озаклмый кем буласын берәү дә белми. Фараз кылучыларга — багучыларга әйтеп, бу кысык күзле, әмма төз буйлы, үзенә тартып торган шаһзадәнең язмышын юратып, киләчәген белергә кирәк.»

Шаһ кунакларның үтенечен, сүз дә юк, үтәргә атлыгып тора, чөнки дөньяда көчлеләрдән саналган бу кавемне дошманың итәргә һич ярамый.

Бию тәмамланды, сылукайлар китте. Үзбәк-Антанук та үз хәленә кайтты һәм бите өлгергән хөрмә кебек алланып чыкты. Шаһ берни сизенмәгән кыяфәттә кунакларга тәмле ширбәт тәкъдим итте. Табын янында иркенләп гәп кордылар. Аллаһка мактау һәм дан, шаһ белән кенәзнең сугыш һәм тынычлык мәсьәләсендә карашлары туры килде, икесе дә Мәккә белән Мәдинәгә Хаж сәфәре кылганнар, яхшы коралны бәяләүдә, уйнак чабышкылар яратуда фикердәшләр булып чыктылар. Көн әкренләп төнгә авышканда, кунаклар китәргә дип кузгалдылар, саубуллашканда хуҗа иртәгесен бәйге оештырырга әзер икәнлеген белдерде.

— Сугышчыларына күз салырмын, — диде. — Минем иң яхшы баһадирлар белән көч сынашырлар. Син, кенәз, үзеңнекеләрдән кемне куясыңны үзең хәл итәрсең. Ат чабыштырырбыз, ауда, егетлектә, кылычка кылыч бәйгесендә ярышырбыз.

Тыйнак кына хушлаштылар. Елбаздук тезен бөкте, ханга үзенә һәм укучыларына хөрмәт күрсәтүе өчен рәхмәтен белдерде.

— Дин кардәшләремә ярдәм итү — минем өчен дәрәҗә! Сезне патшалыгыма китергәне өчен бөек, гадел Аллаһка хөрмәт һәм дан!

Үз бүлмәләренә кайткач, һәрберсе тырышып дога кылды, беренче очрашуның уңышлы тәмамлануы өчен Аллаһ Тәгаләгә рәхмәтен җиткерде. Йоклар алдыннан Елбаздук иртәгә булачак ярышларга ныклап әзерләнергә әмер бирде, бүгенге көннең нәтиҗәле үтүенә канәгатьлелек кичереп, ятуга йокыга талды.

Ширван шаһы, хатыннарының берсе белән юанып алды, аннары: «Яшь ханга кызлар кулы тимәгән икән бит! Аңа лаеклы бүләк әзерләргә кирәк», — дигән уйлар белән күзен йомды.

Үзбәк тә арган иде, керфекләре кушылуга, аның ятагын гүзәлләр әйләндереп алды, биючеләр уйнап-шаярып әле аңа килеп орыналар, әле читкә тайпылалар. Ул да булмады араларыннан берсе назлы куллары белән муеныннан кочып алды һәм иреннәр үзләреннән-үзләре бергә килеп кушылды... Хан уянып китте, аның яшь тәне җинелчә калтырана иде. Үзбәкне өзгәләнү һәм оят хисе биләп алды һәм озакламый таралды да. Тәне бушанган, әйтерсең тышкы кабыгы гына калган, рәхәт хәлсезлек үзенекен итте, егет янә йокыга китте.

Үзбәк кояшның беренче нурлары белән үк уянды. Ятагыннан сикереп торды да физик күнегүләргә тотынды, аннары рәхәтләнеп салкын суга чумды һәм чыкканда шат, кәефе күтәренке, кул-аяк мускуллары уйнап тора иде.

Барысы бергә кабарып пешкән көлчә һәм сыр белән иртәнге чәй эчтеләр. Тиздән шаһның хәбәр йөртүчесе килде, баш иеп сәлам бирде һәм ярышның кагыйдәләре белән таныштырды:

— Һәр як унар сугышчы чыгара. Бүген ат чабышы, кылыч бәйгесе, егетләр уены булачак, ә иртәгә — ауга.

Чиркәс сугышчылары өчен, егетләр уеныннан башка, бар төр ярышларның да кагыйдә-тәртипләре таныш иде. Бу уен да артык катлаулы түгел иде: билгеле бер араклык буйлап тигез аралыкта утыз сарык тиресен җиргә салып чыгалар да, җайдаклар дәррәү кузгалып, шуларны җыялар. Кем күбрәк җыя, шул җиңүче булып таныла.

Чиркәсләр күнегүләр башлап җибәрделәр һәм билгеләнгән вакытта, салкынча дингез җиле эссе һаваны кысрыклап чыгаргач, унган-булган ун кунак шаһ алдына килеп тез чүктеләр. Кей Кабус ибн Ахситан ярышучылар арасында Антанукны күреп канәгать калды. Шаһ, елмаеп, хезмәтчеләргә ым какты, тегеләре исә кенәз Елбаздукны патша япмасына дәштеләр.

Ат чабышлары башланып китте. Ширван җайдаклары чабышкыларын ярыш башында көч-хәлгә тыеп тордылар. Кенәз атлар арасында ике саф токымлы гарәп чабышкысын күреп алды. Аларның ширван шаһы аранынннан китертелгәне күренеп тора. Иярдәге атчылар кош мамыгыдай җиңел гәүдәле, менә шулар җиңделәр дә. Чиркәсләрнең иң яхшы дигәне дүртенче, Ахсар — бишенче, Антанук җиденче килде. Гаҗәп түгел, кунаклар шундый таулар аша ялыктыргыч озын юлга чабышкыларның иң яхшыларын алырга уйламадылар да. Ә шаһ балалар сыман куанды.

— Мин сине тәбриклим, әй падишаһым, Аллаһ синең көннәреңне озайтсын. Ширваншаһ, күрәм, токымлы атларны бәяли белүче генә түгел, ә Шәрыкның иң яхшы берничә чабышкысына да ия икән, — дип олылады аны Елбаздук.

Хуҗа канәгатьләнеп елмайды. Кыска гына тәнәфестән соң егетләр уены башланды. Атлар чабып китте, иярдәге егетләр түбән иелгән хәлдә сарык тиреләрен эләктерергә тырыштылар. Атларның житезләре үк кебек атылдылар. Шаһка бу күңел ачу ошый иде, ул Антанукның тизлекне киметеп ике тирене

эләктерүен күрде, өченчесенә көндәше белән бергә якынлашты, шул арада бер чиркәс ширван сугышчысының юлын каплады. Антанук өченчесен дә алды һәм атын чираттагысына борды, анда инде ике кунак падишаһ егетләренең юлын кисте. «Хәйләкәрләр! — дип уйлады Кей Кабус ибн Ахситан. — Чиркәсләр бердәм эшли!»

Нәтиҗә ясалды: унсигез тире-кунаклар, уникесе хуҗалар кулында. Сигез ганимәт иясе Антанук бердәнбер җиңүче дип игълан ителде. Шаһ түбәнчелек белән елмайды:

— Укучың, кенәз, акылсыз түгел, мин аның ысулын күз уңыма алам.

— Шулай югары бәһа бирүегезгә рәхмәт, падишаһым, Аллаһ сиңа гомер бирсен.

Ялны озакка сузмадылар. Чиркәс сугышчылары ширваншаһның житез һәм кыю сакчылары каршына басты. Җиңүне билгеләүче билгеләр гади генә: көндәшеннең кулындагы салкын коралын бәреп төшерергә, яки өстендәге киеменнән кисеп чыгарырга, яисә каршы якны җинелчә генә, бер тамчы каны күренгәнче яраларга. Җиңелгәннәр көрәш мәйданын ташлап китә, җиңүче исә иптәшләренә ярдәмгә килә.

Кылычларның көмеш чыны янгырады, көндәшләрнең аяк асларыннан пырхылдап тузан күтәрелде, зур бәрелешләрдәге сыман, сугышчан авазлар янгырады. Бирәү дә чигенергә теләмәде. Сугышучылар арасында, очраклы һөҗүм корбаны булудан сакланып, ике хөкемдар кайнаша. Күпмедер вакыттан соң яу кырында ике чиркәс белән шаһның дүрт сугышчысы калды.

Хуҗаларның җиңүе шиксез иде. Чиркәсләр, болар Ахсар белән Антанук иде, бер-берсенә аркан бастылар да үз-үзләрен тота белүләре аркасында һөҗүмне кире кайтара тордылар. Кинәт Ахсар сугышчан аваз чыгарып, күз ачып йомганчы, алга таба кискен һөҗүм ясады һәм дошманының кылычы һавада әйләнеп, аны сул кулы белән эләктереп алды. Ганимәт корал белән икенче сугышчының чалбарын аерып төшерде һәм, арка яктан аны саклап торган Антанукка таба борылды. Әмер биргәндәй шундук берсе унга, икенчесе сулга сибелделәр дә сикереш ясап Ширванның калган икесен дә сафтан чыгардылар. Менә бу җиңү иде!

Кей Кабус ибн Ахситанның битендә ник бер мускулы селкенсен. Ул сүзсез иде, вәзир дә дәшмәде, сакчылар кылдай тураеп бастылар, сугышчыларның йөзләрендә курку катып калды. Шаһ әкрен генә башын Елбаздукка таба борды:

— Мин синең сугышчыларны яхшы түләү шарты белән хезмәткә алам. Минем бар сакчыларымны диярлек җиңгән әнә теге житез яшь кеше белән икегез аларны укыту, өйрәтү белән шөгыльләнерсез.

— Әй бөек һәм зирәк шаһым, сиңа карата Аллаһ Тәгаләбез рәхим-шәфкатьле булсын, синең теләгеңне үтәүне дәрәҗәгә саныйм, шулай ук мин кунак булган осетин кенәзе Хетәгнең улы Ахсар да.

— Мин моңа шат. Минем тарафтан Шәрык буйлап сәяхәт кылган хаҗи Самир Озан ибн Хөсәен Шәкәвине эзләп табарга әмер бирелде. Укучың өчен аннан яхшы укытучыны бирәү дә эзләп таба алмас, — диде дә шаһ кузгалып китте.

Икенче көнне, килешенгәнчә, ауга бардылар. Шаһ аны ирекле дип игълан итте.

— Аллаһы Тәгалә синең кешеләреңнең мөмкинлек һәм осталыкларына күземне ачты, — диде шаһ Елбаздукка, — шуна ярыш оештырмаска, атып алынган киекне синең кешеләрне туйдыру өчен бирергә боерам, калган сугышчыларың да чыксыннар.

Ике йөзләп кеше, зур этләр өере Бакуның әйләнә-тирә ягына чыкты. Кыска гына вакыт эчендә арбалар куян һәм газеллар[17] белән тулды. Аучылар камышлык арасына көчте, этләр әрәмәлеккә кереп үрдәк, каз, аккош көтүен өркетеп күтәрде. Укчылар чын-чынлап күңел ачты. Ау азагына якынлашканда, култыкның коры өлешенә, нәкъ ширваншаһ өстенә зур кабан атылып чыкты. Шаһ атып җибәрде, ук кабанның сул күзен тишеп чыкты, әмма бу ерткычны туктата алмады. Кыргый хайван артыннан эзәрлекләп киттеләр. Кей Кабус ибн Ахситан алда, аның артыннан сак чаба. Тагын бер ук ерткычның аркасына барып кадалды, ул кинәт кенә борылды да шаһка ташланды. Падишаһ кыныннан озын кылычын тартып чыгарып, кабанны уң яктан алырга әзерләнде, әмма ул кисәк сулга каерды да казык тешләре белән чабышкының алдан тезен умырды. Авыртудан, ат үрә басты, аннары ухылдап, чак кына җайдагын ташламыйча, савырына чүкте. Шаһ җәһәт кенә иярennән сикереп төште һәм ерткычның кабат ташланырга әзерләнгән күрде. Кылычын селтәп, Ширван падишаһы нык итеп аягына басты. Сакчылар кабанга атып тидерергә тырыштылар, әмма төз атылган уклар аның ярсуын арттырды гына. Кеше һәм ерткыч бер-берсенең күзләренә туры карадылар. Аларны берничә адым гына аерып тора. Шул минутта үткен авыр сөңге кабанның умырткасын сындырып, бугазына барып кадалды. Кабан чабып ташланган үлән сыман җиргә ауды. Аның янында ат өстендә Антанук калкып тора иде. Шаһның тәне буйлап эссе йөгерде, маңгаена тир бәреп чыкты, аяклары камыр кебек сыгылып төште, үзе белән ни булу ихтималы Кей Кабус ибн Ахситанның яна гына башына барып житте, яралы ерткычка киртә юк, аннан барысын да көтәргә була иде бит.

Антанук атыннан төшеп, шаһ янына килде һәм тезләренә чүгеп:

— Әй бөек падишаһ, Аллаһ сезгә озын гомер бирсен, бу шакшы хайванны юк итәргә үзенә мөмкинлек бирмәвем, сине узып кысылуым өчен мине җәзага тарта аласың, әмма мин бу сасы ит бүкәнен күреп, түзә алмадым — үтердем.

— Син дөрес эшләдең, яшь кенәз. Бу көрәштә син минем көндәшем түгел идең. Мин бит, белгәненчә, иректе ау дип әмер бирдем. Бас, безгә бу күңел ачу уенын тәмамларга вакыт. Сарайда безне кичке аш көтә.

Үзе эченнән генә: «Башлы, бик уңлы бу егет! Яхшы нәсел — яхшы нәсел инде ул», — дип уйлады.

Кичке аш бик мул иде. Өстәлләрдә сыр, һәртөрле яшелчә, хуш исле үләннәр. Анар соусындагы яшь бәрән ите авызда эреп тора. Тагын тәмле җиләк-җимеш эчемлекләре, хәлвә, ширбәт һәм биюләр! Күз явын алырлык чибәр кызлар Үзбәк-Антанукның җанын айкап, каядыр икенче бер дөньяга чакыралар иде.

— Сез игътибар иттегезме, кенәз, укучыгыз биючеләрне ничек күзе белән ашый? Ана мәхәббәт дөньясына фатиха бирер вакыт җитмәде микән?

— Мин күптәннән бу турыда уйлыйм, хаким, — диде тирән сулап, Елбаздук.

— Алайса мин хәзер үк кайгыртыйм.

Кей Кабус ибн Ахситан хәрәменең башлыгын дәштереп китертте.

Шәмнәр яртылаш янарга өлгермәде, ширваншаһ Антанукны үз янына чакырып алды һәм елмаеп:

— Мин сина бүләк әзерләдем, яшь кенәз. Без хөрмәтле аталыгын белән хәл иттек: сина ир-ат булырга вакыт җитте. Бу кеше белән бар, беркем, бернәрсәдән дә оялма. Сарайның хәзер син кергән бүлмәләре, эчендәге бар нәрсә синеке булачак.

Үзбәк-Антанукның йөрәге алда ниндидер рәхәтлек көткәнен тоюдан туктап калгандай булды. Нәрсә көтә аны? Хәрәм башлыгы артыннан сарайның егеткә бик озын тоелган күчеш юллары, коридорларын үтеп, ниһаять, хәрәм хезмәтчесе

[17] Антилопа төре.

аның каршындагы ишекне ачып җибәрде. Хан ярым караңгы бүлмәгә керде. Ятактан кара чәчле гүзәл күтәрелде һәм буйсынган кыяфәттә иелеп катып калды. Егетнең йөрәге күкрәгеннән чыгардай булып тибә. Нәрсә эшләргә белми, ул да баскан урынында катып калды.

— Ләйлә, минем исемем Ләйлә, — дип пышылдады кыз.

Ул күз явын алырлык чибәр иде. Үзбәк-Антанукның ярым караңгылыкка ияләшкән күзләре кызның гаҗәеп матур йөзен, балкып нур чәчкән күзләрен күрде. Аның чем-кара чәчләре алтын җепләр кушып үрелгән, калку күкрәге үзенә ымсындырып тора, нечкә биле һәм үтә күренмәле кин чалбар аша шәйләнеп торган төз, тулы ботлары ханны аяктан егарлык иде. Аларның күзләре очрашты һәм бер мизгелгә бүлмә якты нур белән тулгандай булды. Ләйлә әфәндесенә таба кыюсыз гына адым ясады, ә егет аның каршына атылды. Әйе, әйе! Бу ул, аның төшендә күргән сылу. Антанук үз гомерендә беренче хатын-кызын кочагына алды һәм иреннәренә ябышты. Беренче кайнар хисләр ташкынын үткәреп, Ләйлә аның колагына назлы итеп:

— Ашыкма, минем шаһзадәм, мәхәббәт ашыкканны яратмый, — дип пышылдады. — Үзеңнен һәм минем йөрәгемне тыңла, мин сине бар нәрсәгә өйрәтермен.

Ул иплэп кенә, иркәләп кенә Антанукны чишендерде, үзе дә анадан тума калды. Ләйләнең өлгер куллары, сыгылмалы зифа буе, татлы иреннәре яшь ханның аның томалады. Инде рәхәтлекнең иң югары ноктасына җиткәч, ана җаны оҗмахка күчкән кебек тоелды. Антанукның бушанып һәм көчсезләнеп калган гәүдәсе ятакта ял итә, ә җаны очышын дәвам итә. Менә сылуның имчәк башлары аның иреннәренә кагылды, һәм ханның бөтен әгъзасы яңадан ярсулы көч белән тулды, дәрт канатлары аны кабат йолдызларга алып менде.

Таң атты, кояшлы матур иртә. Яңа өметләр, яңа хыяллар алып килүче белән матур ул иртә. Бәхетле Ләйлә, йоклап яткан әфәндесен игътибар белән баштанаяк карап чыкты: нык гәүдә, түгәрәк диярлек йөз, туры, сумала кебек чем кара чәч, киң яңак сөяге.

«Ничә яшь икән ана? — дип уйлады кәнизәк кыз. — Уналты, унҗиле, артык түгел. Әй Аллаһым, нинди яшь ул! Ә мина инде егерме».

Ләйлә күңелсезләнеп алды, биш ел инде ул шаһның хәрәмендә, ә соңгы өч елда әфәнде аны бер тапкыр да янына чакырмады. Алга таба нәрсә булыр?

Падишаһ, мөгаен, аның турында оныткандыр инде. Һәм менә! Әй бөек һәм мәрхәмәтле Аллаһ! Хәрәм агасы аны чакырып алды. Болай дип тә әйтте әле, шаһ яшь кунакны мәхәббәт серләренә өйрәтсен, һәм әгәр, Ләйлә тырышлык куйса, аны үзенә хатынлыкка алыр, дигән. Бәлки, алмас та.

Әмма бүтән Ләйләнең хәрәмдә беркемгә кирәкмәс булып утырыр хәле юк. Ул ханның кунаклары барлыгын ишеткән иде, бер елгамы, әллә озаккаракмы килгәннәр, диделәр. Ләйлә яшь әфәндегә ошар өчен бик нык тырышырга кирәклеген аңлый, шуңлыктан ул гаҗәеп шашкын дәртле хисләр тудырырга булды, кичәге кебек, төнге кебек, ул үзе дә мәхәббәт мавыгуларына сусаган иде.

Антанук күзен ачты. Аның болай да кысыграк күзе бөтенләй күренми, иренен кызның иренәнә суздь, кәнизәк әфәндесен кабат иркәләргә-назларга теләгән иде, тик тегесе сак кына кызның кулларын читкә этәрде.

— Аның өчен төн бар, гүзәлем, сихерчем, ә көн безгә Аллаһ тарафыннан эшләр өчен бирелгән, минем монда килүемнең максаты да шул. Кичкә көт, чакырырмын.

Антанук тиз генә җыенды да иртәнге эшләр белән китеп барды.

Ширваншаһ күптән инде аяк өстендә иде, иртә таңнан аны бары тик бер уй борчыды: «Бу үсмер алдында иртәрәк җәелеп төштем түгелме? Күк

белгечләреннән хәбәр юк бит әлегә. Әйе, ул житез, көчле, үз яше өчен акыллы, белемле. Бәлки анын нәселе начардыр? Юк, охшамаган, патша нәселе икәне сизелеп тора. Тәрбиячесе дә төшеп калганнардан күренми, андыйлар теләсә кемне тәрбия кылырга алынмый.»

Шаһ әкренләп тынычланды да иртәнге ашка утырды. Аннан соң вәзир килде һәм күк белгечләре үзләрен кабул итүен үтенүләре турында житкерде. Кей Кабус ибн Ахситанны кабат жинелчә дулкынлану биләп алды.

— Бик тиз минем янга китерегез, безнең әңгәмәне берәү дә өзмәсен.

Өч галим — күк белгече ханга дан һәм хөрмәт теләделәр. Өлкәне алга чыкты:

— Әй бөек һәм кодрәтле ширваншаһ, Аллаһ сиңа озын гомер бирсен! Синең яшь кунагыңның язмышын төгәл һәм дөрес итеп ачыклау өчен көнен дә, төнен дә эшләдек. Башта аерым-аерым, аннары бергә жыелып хезмәтебезне чагыштырдык. Гажәп, әмма өч исәпләп чыгару шулкадәр тәңгәл килде, бу эшне бер кеше башкарып чыккан диярсең. Минем эшчәнлек елларымдагы куелган фаразларның иң төгәле булды бу. Тыңла. Сездә кунак булып саналучы егет дөньяның иң бөек идарәчеләреннән берсенең үргене, нәкъ менә ул син исән чакта бер зур патшалыкның тәхетенә утырачак. Ул бик яхшы сугышчы булачак, әмма бөек һәм кодрәтле Аллаһ, ана башканы әзерләп куя. Ошбу егет, патша булгач, бар халкын Аллаһ Тәгаләнең мәчетләренә алып килә, бу дәүләттә бик азы гына имансыз булып кала. Бу патша бик күп яңа калалар салачак, аларда кәсеп-һөнәрләр, сәүдә һәм гыйлем чәчәк атачак, калаларны сәүдә юллары читенә салганлыктан, халкы байыйачак, хакименең дә байлыгын арттырачак. Бу патша тәхеттә һәм мактаулы чагында үз үлеме белән китәчәк, ә урынын улларының берсе алачак.

Ширваншаһ канәгать калды. Күк белгечләре исә мул, бай бүләкләр алды.

***

Жәйнең соңгы аена керделәр, эсселек сүрелде. Көннәр жылы. Бу вакытта жиләк-жимеш, яшелчә мул булып, күзләрне һәм ашказанын сөендерә, ә башлары яхшы эшләгән кешеләр алда торган салкыннар, кышкы зәһәр жилләр турында уйлана башлый. Бу турыда Кей Кабус ибн Ахситан да уйлый. Ул инде булачак патшаны, телләр, ислам нигезләрен, фәлсәфә, дөнья яралышы серләрен өйрәнү өчен, мөмкин кадәр озаграк тотарга карар итте. Күк белгечләре әйткәннәрне шаһ чынбарлык итеп кабул итте, Антанукның йолдызы биек очачагына чын күнеленнән ышанды һәм шуна аны патшаларча итеп урнаштырырга уйлады.

Ширваншаһ булачак хаким өчен үзенең сараена махсус янкорма төзергә боерды, шундый бөек кеше кышын сәфәр чатырында туңып ятарга тиеш түгел. Елбаздукның сугышчылары да жылы биналарга урнаштырылды һәм әйбәт кенә түләү шарты белән ныгытма дивары тирәсендә хезмәт итә башладылар.

Кенәз укучысы иркенәймәсен, физик күнегүләр ясарга онытмасын, ширваншаһ үзе табып биргән укытучылар белән фарсы һәм гарәп телләрен әйбәтләп өйрәнсен дип, артыннан даими күзәтеп торды.

Көннәр, Үзбәк-Антанукка шатлык-куанычлар китереп, сиздермичә үтте, аның яшь тәне уйнап торды, күзләрендә очкыннар биеште, баш мие һәр фәнне үзләштереп, үзенә сеңдерә барды. Кичләрне исә гүзәле Ләйлә сөйләгән тылсымлы гарәп әкиятләрен тыңлап, аның кайнар кочагында уздырды.

Ниһаять, ул үзенең рухи тәрбиячесе һәм укытучысы Самир Озан ибн Хөсәен Шәкави хажи белән очрашты. Аның каршында үткен карашлы тыйнак кына киенгән адәм басып тора. Ул озын буйлы укучысын башын иеп сәламләде. Антанук тез чүкте:

— Сине күрүемә мин бик шат, хөрмәтле укытучым, Аллаһ сиңа озын гомер бирсен!

Намаздан соң, остаз һәм укучысы дәресләрне башладылар. Самир хажи, үсмер белән озаклап гәп корды, аның белем дәрәҗәсен бар яклап тикшерде һәм канәгать калды. Антанук шактый күп белә, әмма алар билгеле бер калыпка салынмаган, яна фәлсәфи карашлар күзлегеннән караганда берникадәр гадирәк дип уйлады. Укытучы иң беренче итеп Коръән буенча белемне тирәнәйтүдән һәм Шәрыкның бөек шагыйрь-фикер ияләрен укудан башлап җибәрергә булды.

— Үзеннән кыска гына гомереңдә Коръәнне ничә тапкыр укып чыгарга өлгердең, әй хөрмәтле укучым?

— Күп тапкырлар, остазым, санамадым.

— Коръәнне кат-кат уку бик әйбәт. Иманлы кеше аны гомере буе укырга тиеш. Тик күп тапкырлар уку гына җитми, иң мөһиме — Аллаһ Мөхәммәд пәйгамбәр (ана Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) аркылы безгә җиткерергә теләгән хәзинәнең асылына үтеп керү, күрү һәм ишетү.

Ни өчен кешеләрнең кайберләре изге Китабыбызда язылганнарның яшерен мәгънәсен аңлап бетерми? Мин болай дип уйлыйм: халыкның күпчелеге үз дөньяви рәхәтлекләре турында гына уйлый, хатыны, балалары, ата-аналарын кайгырта — аларның башында шул гына. Коръән дөньяви мәшәкатьләрдән азат кешеләр тарафыннан гына тирәнтен кабул ителә. Мөселман кешесе, кем булуына карамастан, Мәккә һәм Мәдинәгә хаҗ кылырга кузгалганда, нигездә кая баруы, Аллаһ Тәгалә белән ничек сөйләшәчәге, изге Кәгъбәны ничек әйләнәсе, Мина үзәнендә ничек гыйбадәт кылачагы турында уйлый. Хаҗга баручының уенда бары тик Аллаһ Тәгалә генә, хаҗда ул — Аллаһның кунагы. Менә шул чакта гына, Коръәннең асылына үтеп кереп, исламны яклаучы гына хәзинәне күрә ала.

Корьәнне төптән уйлап укуда безгә нәрсә комачаулый соң? Бөек патша нәселе үргене[18] һәм зур дәүләтнең булачак хакиме буларак, сиңа әйтәм: иң беренче чиратта — хакимлек.

Үзбәк-Антанук укытучысына гаҗәпләнү катыш таләпчәнлек белән күтәрелеп карады.

— Гаҗәпләнмә, әй булачак халыклар патшасы, мин кешеләрнең һәм аларның якыннарының ни уйлаганын йөзләреннән укый беләм, тик бу әле алар турында башкаларга сөйләп йөрим дигәнне аңлатмый. Мин ширваншаһ күк белгечләре тарафыннан алдан әйтелгән язмышың белән таныштым, ул тулысы белән күзаллауларым белән тәңгәл килә. Хәтерлисеңме дип уйлыйм: язмышка ышану — дингә инануның бер тарәге.

Димәк, хакимлек! Хакимлек кешегә тугач та бирелә, ул васыять ителә йә төрле юллар белән, еш кына пычрак алымнар белән яулап алына. Хакимиятне кулдан ычкындырмаска кирәк, моның өчен яныңда ышанычлы теләктәшләр, көрәштәшләр булуы шарт, билгеле инде үзең дә дәүләттә булган һәр нәрсәдән хәбәрдар булырга тиешсең, шул исәптән тарханнарың һәм әйләнә-тирәдәгеләреңнең эш-ниятләрен күз уңында тоту кирәк.

Хакимлек ул — дәүләтеңнең үсешен кайгырту, аны төрлечә: йә яңадан-яңа җирләр, халыкларны яулап алу яки яңа кәсепләр булдыру һәм фән, сәүдәнең чәчәк атуына ирешү юлы белән үстерергә мөмкин. Хакимлек — рәхмәтсез һәм авыр коллык хезмәте. Халыкны кысасың — ул канәгать түгел, игелек таратасың — ул кыска вакытка риза була да береаздан ана күбрәк кирәк була башлый. Бирмәсәң — ризасызлык белдерә, бирсәң — дәүләтең көчсезләнә. Хаким буласың да һәрдаим яхшы белән начар арасындагы урталыкны эзлисең. Хакимлек — һәркөнне башны эшләтү, акылны җигү, ул күршеләр, дуслар, дошманнар белән үзара мөнәсәбәтләргә бәйле, шуның өстенә гаилә

[18] Үсемлекнең орлыктан, тамырдан һ. б. ш. иң беренче шытып чыккан сабагы.

матавыклары, аңа йогынты ясарга йә урынын алырга омтылулар... Хәзер үзең уйлап кара: шулкадәрле мәшәкать белән башы каткан кеше Коръәнгә бар игътибарын бирә аламы? Син бит әлегә ул мәшәкатьләрдән азат, әй ханым!

Әле ишеткәннәрең турында уйла. Икенче дәрестә без моңа кире кайтырбыз әле, тик анысында син сөйләрсең. Хәзер намаз вакыты житте, аның алдыннан сина бер кечкенә генә киңәш, үгет бирмәк булам. Акыллы дин галимнәреннән берсе болай дигән: «Мин Коръәннең дистәләгән сүрәләрен укып чыктым, тик берсен генә үзләштерә алдым, чөнки хәзергә мин калган сүрәләр язганча эшләргә өйрәнмәгәнмен.»

Үзбәк-Антанук гыйлемгә көннән-көн тирәнрәк күмелде, аңа уйлау, фикер йөртү ошый иде. Озын кичләрдә яшь хан бабасы, кайчакта ширваншаһ белән әңгәмәләр куертты, тик әлегә моназарада[19] аларны җиңә алмады. Аңа гыйльми бәхәсләр, хакыйкать белән вакыйгаларны чагыштыру ошый иде, ул нәтиҗәләр ясап, аларны Коръән сүрәләре һәм аятьләре белән чагыштырырга ярата иде. Үзбәк-Антанук физик йөкләмә һәм хәрби күнегүләр турында да онытмады, шулай да яңа дәресләрне аеруча теләп, көтеп алды.

Самир Озан ибн Хөсәен Шәкәви хажи, кем тормышны аңлый, шул ашыкмый, дигән кагыйдә буенча эш йөртте. Остаз укучысын көн дә үгет-нәсихәт белән йөдәтмәде, бар да егетнең башына сеңеп, алга таба белү теләге уятырга тиеш, дип санады. Нәкъ шулай булды да.

— Коръәнне тирәнтен өйрәнергә тагын ни комачаулый? — дип сорады хажи.

— Байлык дип уйлыйм.

— Бик дөрес уйлыйсың, ханым! Кеше һәрвакыт байлык дип бәргәләнә, көтүдәше сарык-бәрәннәрен кат-кат саный, үрчем көтә, әгәр үрчем яхшы булса куана, начар булса — кәефе төшә. Кеше торагын кайгырта, яхшы ашауны һәм матур савыт-сабаны ярата, шуңа һәрвакыт аларны каян алырга, ничек әзерләргә, ничек китереп бирергә, дип борчыла, аның уенда бары шулар гына. Әйт әле, ис кергән итне алтын яки көмеш коштабакка салганга карап, тәме үзгәрәме? Ә һәйбәт итне гади балчык савытка салып китерсәң дә тәмле була. Шулай түгелме?

— Сезнеңчә фикер йөрткәндә, яхшы ризыкны, эт кебек, жирдән ашасаң да ярый булып чыга, — дип бәхәскә керде Үзбәк-Антанук.

— Әгәр синеңчә уйласаң, ул чагында — әйе, — дип кыздырды егетне Самир хажи, — минемчә, эт — уйлый белми торган, бары табигый сизгерлек белән генә яши торган жан иясе, кеше бит уйлый белә. Кемгәдер байлык, зиннәтлелек рәхәтлек бирә, ә торыр йорты, артык өс-башы булмаган, балчыктан ясалган гади чүлмәктән гади су эчкән дәрвиш, матурмы ул, юкмы дип уйлап тормый, аның өчен намаз аша Аллаһ Тәгалә белән аралашу, Коръәнне тирәнтен белү — кыйммәтрәк. Дәрвишнең уен бернәрсә читкә юнәлдерә алмый, аның уйлары кешеләргә караганда күбрәк Аллаһ янында. Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) Хира тавындагы мәгарәдә аулакта калмаганмы, дәрвиш булмаганмы? Шул чакта гына пәйгамбәргә Аллаһның ачышлары индерелгән. Мин сина дәрвиш бул димим, ләкин синең ни зур байлыгың, ни олы мәшәкатьләрең юк, сине читят йортта ашаталар-эчертәләр, Изге Китабыбызның хәзинәләренә төшенү өчен менә дигән вакыт.

Акыллы ир-ат күп сөйләми, аны аңлау өчен үзенә акыл тупларга кирәк. Шәрыкнын Бөек фәлсәфәчесе һәм шагыйре Гомәр Хәйям болай дигән:

[19] Бәхәс, сүз көрәштерү.

Фани дөнья диеп җан атма, инсан,
Ышанма хәйләләргә, аңлы булсаң!
Һәлак булды сиңа чаклы да күпләр,–
Алар кайда? Аларга инде ни сан?!.

Болар турында уйлан, әй яхшы ата-ана баласы!

Үзбәк-Антанук йолдызларга карап, аларның иксез-чиксез булуы турында уйлады. Ә алар артында нәрсә, йолдызлар өстендә нәрсә, алар нинди? Боларны бары Аллаһ кына белә. Мона ничек төшенергә? Бәлки Коръәндә җавабы бардыр. Бәлки сарайда яшәүчеләрнең мин-минлегенә каршы көрәшкән, аларны көнчелек һәм саранлыктан арынырга чакырган суфыйчылык дөньяның хакыйкатен һәм серләрен аңларга якынаерга булышыр?

Үзбәк туктаусыз белемен арттырырга тырышты, дуслары һәм хезмәтчеләр белән аралашканда үзен гади тотты, артык ризыктан баш тартты, гәүдә-сынын ассызыкламый торган җиңелчә кием киде. Тик Ләйлә белән мөнәсәбәтләрендә нәрсәне үзгәртергә мөмкин соң? Гашыйк хан гел аның турында уйлады, кыз аның җанына, йөрәгенә кереп урнашты, ул берни таләп итмәде, сорамады, егет исә аның саен кызны берсеннән-берсе матуррак, яхшырак бүләкләр белән күмде.

Көннәр аучы кулыннан качкан болан тизлеге белән агылды да агылды, укучының да белеме арткannан артты. Егет ир-атларның күпме уй-фикерен хатын-кыз алып торганын аңлый башлады, ә инде мәхәббәтен икенче яртысы бүлешмәсә, ул кешенең баш миен бутый, үзенә буйсындыра, яшәүнең мәгънәсен һәм җаен үзгәртә. Әй зирәк Аллаһ, син Коръәндә хатын-кызлар турында аерым сүрә иңдергәнсең, һәм иманлылар ирләрнең хатыннары белән нинди мөгамәләдә булырга тиешлеге турында беләләр. Хатын-кыз дөреслеккә, хакыйкатькә төшенүдән читкә этәрми, алар белән аралашу бары тик ләззәт кенә бирә.

Укытучы белән укучы дуслыкның файдасы һәм хәвефе турында озын-озак әңгәмә кордылар, тегеяки бу дусны ничек һәм күпме ераклыкта тотарга кирәк, ана кайчан ышанырга була, кайчан юк — шул турыда гәпләштеләр.

Апшеронда яз хакимлек итә, инде өрек, кизил[20] һәм әлүчә[21] агачлары чәчәкләрен койдылар, аларның ботакларында яшел төймәләр күренде, анар агачларында чәчәк бөреләре тулышты, кошлар чебешләрен чыгарды, шагыйрьләр сөйгәннәренә багышлап тирән эчтәлекле шигырьләрен иҗат итте, Үзбәк-Антанук исә армый-талмый фәннәр үзләштерде. Самир Озан ибн Хөсәен Шәкави хаҗи укучының уңышларына шатланып туя алмады, ана, Коръәнне күпме генә укысаң да, сүзләр һәм аятьләрнең яшерен мәгънәләрен күпме генә ачсаң да, бары тик кечкенә генә яктылык яисә Изге Китаптагы бер-ике нурның ялтырап китүен генә күрерсең, дип кабатлады. Үзбәк Коръәнне гомере буе һәм көн саен укырга карар итте. Изге Китаптан тыш, яшь хан Гомәр Хәйям, Сәгъди, Румины онытылып укыды, Фирдәүсинең атаклы «Шаһнамә» поэмасын яттан белә иде.

Бу дөньяда бар нәрсәнең дә башы һәм ахыры бар. Тау кичүләре ачылды, Елбаздук туган җиренә — тауларга кайтырга җыенды. Кей Кабус ибн Ахситан шаһ бер ел эчендә үз туганнарына әйләнгән кунакларны тагын беразга калырга үгетләде. Әмма үз учакларына кайтырга вакыт иде, өстәвенә кенәзгә Алтын Урдада тынычлык китүе турындагы хәбәрләр килеп ирешә. Туктай Нугай белән элемтәләрен бөтенләй өзеп аңа каршы чын-чынлап сугыш игълан иткән...

Үзбәкнең кайтасы да килә, шул ук вакытта мондагы тормыштан аерыласы да килми иде. Ширванда аны тоткарлаучы ике кеше бар: берсе — укытучысы Самир хаҗи булса, икенчесе — яшь егетнең куаныч-сөенеченә әйләнгән Ләйлә,

[20] Көньякта үсә торган сары чәчәкле, каты үзагачлы куак.
[21] Көньякта үсә торган җимеш агачы, сливаның бер төре.

бу хакта ул бабасы белән остазына да ачыктан-ачык әйтте. Елбаздук оныгына төбәп карады да елмайды:

— Син балигъ булдың, ханым, ир-ат булдың. Үзеңеке иткән, гашыйк булган, өйләнергә җыенган хатын-кызың ир-егеткә үзе белән алырга кем каршы килсен, син бит бай мөселман, кирәк тапсаң икенчесенә дә, өченчесенә дә өйләнерсең. Ә укытучыңа килгәндә, аның белән иртәгә сөйләшермен. Билгеле булганча, Кавказның теге якларында аның булганы юк икән, фән кешеләре өчен бу бик кызыклы, шулай итеп синең сабакларың өзелмәс.

Берникадәр вакыт юлга җыендылар. Елның иң озын көне — тауларны кичү өчен уңайлы вакыт якынлашты.

Ширваншаһ зур ау игълан итте. Юлчыларга һәм аларны озату мәҗлесенә бик күп киек кош ите әзерләргә кирәк иде. Күңел ачу уңышлы барып чыкты, хезмәтчеләр шактый тир түкте, шаһ өстәленә киек итеннән әзерләнгән бик күп төрле тәмле ризыклар бизәде. Шулай да өстәл янында сагыш саркып тора иде. Кей Кабус ибн Ахситан Антанукны бер елга сәяси уй белән кабул иткән иде, әмма шул вакыт эчендә максатчан егетне үз итәргә өлгерде.

«Шундый варисым булсын иде», — дип уйлады шаһ, ул Үзбәк-Антанукка исән калу, яшәү өчен көрәшергә туры килүе турында белми иде. Сөргендәге егет тырышып-тырмашып үргә үрмәли. Ширвашаһ Антанукның йотлыгып белем алуын күреп, муллыкта, иркенлектә яшәп, тормышлары гел шулай булыр дип фикерләп, ялкаулыкка чыккан үзенең варисларын күз алдына китерде.

Кей Кабус ибн Ахситан китүчеләргә бүләкләр әзерләде. Үзбәк-Антанукка Дәмәшкъ корычыннан ясалган кылыч тапшырды, аның сабы кыйммәтле асыл ташлар белән бизәлгән, кынына көмеш бизәкләр уелган. Егетнең күзләрендә ут кабынды, мондый кылычны аның төшендә дә күргәне булмады, кылычны суырып чыгарды да бөгеп карады, кылыч йөзе кыл кебек янгырап шунда ук кабат турайды.

— Бу корал сиңа һәрвакыт җиңүләр генә китерсен, бөек һәм кодрәтле Аллаһ сине сакласын. Бу корал дусларыңа түгел, бары дошманнарыңа гына күтәрелсен, — дип чын күңелдән теләкләрен җиткерде Ширваншаһ.

— Тәрбиячеләрем һәм укытучыларым хәер-догада булсыннар, Аллаһ аларга озын гомер бирсен. Бу кунакчыл йортка байлык-муллык һәм дан-шөһрәт өстәлеп торсын. Мактау һәм хөрмәт сиңа, Кей Кабус ибн Ахситан, ыруыңа дан, Аллаһ аны мәңге сакласын!

Хуҗа икенче бүләкне — ике ат караучы йөгәненнән тотып китергән озын муенлы, киң күкрәкле, нык озын аяклы нәселле җирән гарәп чабышкысын кенәз Елбаздукка багышлады. Алда булачак ат чабышларының ләззәтен сизгәндәй, айгырның ике күзеннән чаткылар сибелде, гүя ул җилгән кеше арасыннан үзенә ярашлы җайдак сайлый иде. Елбаздук ат янына килеп, аның муеныннан сыйпады, савырын шапылдатып алды, тегесе исә көчле, нык кулны кабул итеп, кешнәп җибәрде.

Моннан да яхшы бүләкнең булуы мөмкин түгел! Андый айгырлар бик сирәк, андый бүләкне юмарт күңелле, олы йөрәкле кеше генә ясый ала.

Кенәз Ширваншаһны мактауга күмде, тирә-юньдәгеләр ихлас дуслыкка сөенәләр иде, тик барысыннан бигрәк шаһ үзе шат иде, ул бүләкләрне ярата һәм бирә дә белә иде. Алда торган хушлашу гына куанычны бераз киметә шикелле, әмма аерылудан соң күрешүләр була, һәм бу күңелдә өмет тудыра иде.

Өйгә кайтыр юл һәрчак кыскарак тоела, ул таныш та булса, тагын да кыскара төшә, янәшәңдә әйбәт әңгәмәдәшең барганда чакрымны сизми дә каласың. Үзбәкнең мөхтәрәм укытучысы Самир Озан ибн Хөсәен Шәкави патшабикә Тамара, гыйсавиять[22] турында сөйләде

[22] Христианлык.

— Без инде, әй тырыш укучым, дәрвиш — гыйсавилар[23] турында сөйләштек. Теге тауның башындагы кәшишханәне[24] күрәсеңме? Менә алар шунда яшиләр инде, тик алар янына теләсә кем барып җитә алмый, чөнки күп кеше белән очрашасылары килми, дөнья белән элемтәгә керергә теләмиләр, сугыш һәм бәйрәмнәрне өнәмиләр. Аларның максаты — гыйбадәт кылып, Аллаһ тәгълиматлары буенча яңалыкларны танып-белү.

— Тик аларның Инҗилләре искерде. Исламнан да дөресрәк тәгълимат юк, мөселман юлыннан да турырак юл юк, Аллаһтан башка Алла юк һәм җирдә Мөхәммәд (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) — аның пәйгамбәре, — дип җавап кайтарды укучысы.

— Синең белән килешми булмый. Тик фәлсәфәче буларак, мин күп тапкырлар ни өчен Аллаһы Тәгалә кешеләргә башта Тәүратны, аннары Инҗилне һәм алар соңында Коръәнне җибәргән икән, дип уйланганым бар. Бу китапларның берсе дә көчләү-ирексезләүгә өндәми, динлеләрне тыйнак иманлы тормышка, якыннарыңны кайгыртырга чакыра, мәңгелек яшәү турында сөйли. Аллаһ бу тәгълиматларның кайсын кешеләр тизрәк кабул иткәнен, яхшырак аңлаганын, кайсы тәгълиматның җәннәттәге мәңгелек тормышка дөрес әзерләгәнен тикшереп тормый микән? Бәлки төньякта кырыс шартларда яшәүчеләр бер тәгълиматны, ә эсселек һәм сусызлыкка түзүчеләр икенчесен яхшырак күрерләр. Бәлки алай да түгелдер. Мин хәзергә бу сорауга җавап табалмадым, син дә бу турыда уйлан. Әмма шуңа карамастан, гыйсави хатын-кызы Тамара грузиннарны берләштерде, тауларда тәртип урнаштырды, нык дәүләт төзеде. Кешеләр ихластан Аллаһка ышандылар, иман белән яши башладылар, начармы бу?

— Әмма ислам хакиме дә нәкъ шулай уңышлы эшләр иде, Ширван дәүләтендәге шикелле.

— Син ислам таратучылар грузиннар җирендә йөрмәгәннәр дип исәплисеңме? Яһүдләр үз диннәренә өндәмәгәннәр дисеңме? Ә халык никтер гыйсави динен сайлаган. Ни өчен? Бу бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә билгеле, әмма без бу сайлап алуны хөрмәт итәргә тиеш, чөнки, дөресрәге, моны кеше түгел, Аллаһ сайлаган. Синең борынгы бабаң Чыңгызхан теләсә кайсы дингә уңай караштa торган.

Шундый әңгәмәләр коертып, фикерләр алышып, алар Зур Кавказ сырты аша кичү юлына якынлаштылар. Кичү юлын караңгылык баскан, томан тирә-яктагы тау башларын гына чорнап калмаган, куе булып юлларга да сырышкан.

— Антанук, томанның бер кисәген кесәңә салып куй.

— Мөхтәрәм укытучым, сез шаяртасызмы?

— Юк ла! Син шулай да тырышып кара.

— Балачагымда ук тырыштым инде, картайгач та булдыра алмам, шәт, — дип көлде Антанук.

Юл түбәнгә таба төшә башлады. Кояш күренгәләп алды, бераздан томан тарала башлады.

Тагын да түбәнгәрәк төштеләр, укытучы:

— Әй сәләтле укучым, тукта әле, югарыга кара һәм томанны күр, — дип үтенде.

— Бу бит болыт! — дип кычкырды егет. — Әнә түбәдә иярдә сыман утыра.

— Син хаклы. Томан ул — җиргә төшә торган болыт. Болытның бер кисәген кесәңә сал дигән идем, аңладыңмы инде?

[23] Гайса дине, христиан дине.
[24] монастырь.

— Хәзер төшенә башладым, ахры. Күпчелек кеше Аллаһ болытлар өстендә яши дип уйлый.

— Димәк, Аллаһ анда яши аламы?

— Әгәр авырлыгы булмаса, мөмкин.

— Ул очракта, Аллаһ кешеләрне үзе рәвешле, үзенә охшатып яраткан дигән фикер белән нишләргә?

— Ә Гайса суда катыда йөргән кебек йөри дигән фикер?..

— Мактауга лаек укучыдан лаеклы җавап. Әмма Гайса моны көн саен түгел, яшәешнең авыр вакытларында гына эшләгән. Бу рухи яктан зур киеренкелек таләп иткәндер. Моны һәр секунд саен, хәтта йоклаганда да эшләп буламы? Икеләнәм. Димәк, ул «епты» дигәнебез Аллаһы Тәгаләдән.

— Мәсәлән, ай, — дип сүз кыстырды Антанук.

— Бәлки айдыр, һәрхәлдә, эссе кояш түгел. Бәлки ул галәмдә әйләнеп йөри торган башка бер «каты»дыр.

— Әйләнеп йөри торган? — дип сорады яшь хан, гаҗәпләнеп.

— Әйе, әйе, нәкъ менә әйләнеп йөри торган. Әмма бу турыда юлда түгел, аерым сөйләшербез.

Юл түбәнгә таба тәгәри дә тәгәри, Дарьял тарлавыгындагы караңгылыкны әкренләп яктылык алыштыра барды. Терек һәрвакыттагыча үзенең шомлы җырын сузса, таулар исә читкәрәк тайпылып юл бирделәр.

Хетэг кунакларны бик сөенеп каршы алды. Бер ел эчендә ике кунакның күнелендә шактый тулышкан шатлыкларны, шик-шөбһәләрне уртаклашасы килде.

Аллаһка дан, берсенең дә тирән борчу-кичерешләре юк иде. Елбаздук Хетэгка аның акыллы, тыйнак улы Ахсар турында сөйләде:

— Ширваншаһ юкка гына ана үзендә хезмәткә калырга һәм шәхси сак белән җитәкчелек итәргә тәкъдим ясамады. Әмма улың, тезенә чүгеп, болай дип җавап бирде:

— Әй бөек һәм кодрәтле шаһ, Аллаһ сиңа озын гомер бирсен. Мин осетин кенәзе Хетэгның берданбер углы, ул сәламәт чагында да, көчсез чагында да аның янәшәсендә булу — минем бурычым. Ата-анам һәм туган җиремнән еракта башкача кала алмыйм, уйларым белән мин һаман шунда, таулар артында. Кичер мине, әй кодрәтлем, синең дәүләтеңдә һәм шәхсән үзеңнән яшәү өчен кирәкле белем тупладым, рәхмәт сиңа, әй зирәкләрнең зирәге!

Шаһның чырае яктырды, ул Ахсарны торгызды да:

— Син әтиеңә турылыклы, димәк, син — менә дигән ул. Син ил-җиреңә турылыклы, димәк, син — бөек. Аллаһ сезгә осетин җирендә зур эшләр башкарырга фатихасын бирсен. Мин сине һәрвакыт һәм шатлыкта, һәм кайгыда көтеп калам, чөнки мин беләм: без беркайчан да дошманнар булмабыз.

Хетэгның бите буйлап күз яше акты, күнелен улы өчен шатлык һәм горурлык хисләре биләп алды.

— Улларыбызның исәнлеге өчен берәр савыт әйбәт осетин сырасы эчеп куюдан баш тартмассың дип уйлыйм.

Күбекләнеп торган сыралы савытлар куелган поднос күтәреп, бүлмәгә кызчык килеп керде. Ул сүзсез генә подносны өстәлгә куйды да ишеккә борылды.

— Тай-туглы, нишләп исәнләшмәдең? Син мине танымадыңмы?

— Мин сезнең белән, кенәз, иртән исәнләштем, тик сез күрмәдегез дә.

— Кичер мине, кызым. Кичтән күп ашалганга, төнлә йокым начар булды, мөгаен, шуңа хәтерем чуалгандыр.

— Мин сезне кичерәм, кенәз, — кыз елт кына ишек артында югалды.

Кунаклар көлештеләр.

— Туганым, беләсеңме, Ширванда оныгын төшемә керде. Анда ниндидер серлелек бар. Мин сизәм, Тай-туглыны зур киләчәк көтә.

— Син нәрсә сөйлисен, дустым? Беләсеңме нәрсә көтә аны? Буйга житкәч — карангылык. Ил авызын ябып булмый, оныгымны жилдән туган диячәкләр. Ә мин кызнын тамырларында яхшы кан агуына ышанам. Яшенә күрә бик башлы. Ир туганнарым: «Чит авызга яулык каплап булмый»,— дип дөрес әйтәләр.

Кыз үсеп килә, озакламый гөлчәчәк бөресе кебек, чәчәк атачак. Кем аны хатынлыкка алыр? Борын астын сөртергә иренгән шапшак сукбай, йолкышмы?

Сүзсез генә сыра капкаладылар. Хетэгнын шатлыгын, жанын авыр гер кебек басып торган хәсрәт алыштырды. Елбаздук, тынлыкны өзеп:

— Кайгырма, туганым, иң котылгысыз вәзгыятьтән дә чыгу юлы табыла. Тыңла әле мине һәм уйла. Тай-туглыны минем белән жибәр.

Хетэг башын күтәрде, анын күзендә тискәре жавап чагылды.

— Ашыкма, әйбәтләп уйла, — дип дәвам итте сүзен кунак, — син бит беләсен, без чиркәс кенәзләренен кызларын да башка гаиләгә тәрбиягә бирәбез. Нишләп әле мин осетин кенәзенен кызын үземә алалмыйм? Хатыным әле көчендә, Аллаһ ана саулык бирсен, оныгынны чын патшабикә итеп үстерер, патшабикәнен ире бары тик патша гына була ала. Без әле Тай-туглынын шатлыклы туенда рәхәтләнеп күнел ачарбыз.

Елбаздук кызнын киләчәген алдан әйтүен үзе дә аңламый, тик кызны зур киләчәк көтүен сизенә иде. Хетэг сүзсез генә бик тырышып сыр чәйнәде. Жан сызлавы басылмады, ул аны ватты, уйларын тәртипкә салырга комачаулады. Кенәз кунагынын иң яхшы чыгу юлын тәкъдим иткәнен аңлый. Тик яраткан оныгы белән ничек аерыла алсын, ул бит әрнү-сыкравы гына түгел, жанынын ләззәте дә. «Мәгәр кечкенә әрнү зур борчуга әйләнәчәк, — дип уйлады Хетэг. — Мөгаен, туганым хаклыдыр. Хаклы! Карар кылырга кирәк. Мин сагынырмын, әмма анда кызчыкка әйбәтрәк булыр, кунак аны кыерсытмас, беркайчан да рәнжетмәс».

Анын уйларын раслагандай, Елбаздук нәтижә ясады:

— Ил теле безне аерып торган таулар аша кичеп чыга алмас. Безне телләр аермалыгында батар һәм тора-бара Терекнен ярсу агымы үзе белән еракларга алып китәр.

— Рәхмәт сина, хөрмәтлем! Синен кебек туганым булуга бик шатмын. Онытма — минем тормышым синен кулда!

Сәяхәтнен дәвамы алдындагы төнне Үзбәк Ләйлә белән үткәрде. Төнге күккә сибелгән йолдызлар арасында ул иң яктысы булып балкый, сөю-наз дигәндә ана тиңдәшләр юк. Ул ханны ай яктысыдай урап алды һәм сөю-сөелү ятагына әйдәде.

Кыска, әмма каты йокыдан, Үзбәк күтәренке кәеф белән уянды. Ләйлә анын янында утыра, әкрен генә гарәпнен күнелгә ятышлы жырын көйләп, битеннән сыйпый иде. Хан аны кочагына алды:

— Иркәм, назлым, сөйкемлем, бүген арбада үзен генә булмаячаксын. Синен белән бер кызчык — кенәз Хетэгнын оныгы барачак.

Ләйлә, гажәпләнеп, күзен күтәрде. Анын карашы: «Син ул кызны хатынлыкка алдынмы?» — дигән сорауны аңлата иде.

— Тынычлан, юкка борчылма. Бабам кызчыкны безнен гаиләгә тәрбиягә ала, бездә шулай кабул ителгән. Аны әбием тәрбия кылачак. Хатын булырга Тай-туглы әле бала гына. Анын белән ягымлырак бул, татлым.

Китәр алдыннан Үзбәк Ләйләнен ачу сакламавын аңлады.

Басу капкасы янында саубуллашу озакка сузылмады, ирләр бер-берсенә

сәламәтлек теләп кочаклаштылар. Тай-туглы әбисен үпте дә бабасы янына атылды. Биленнән кочып, аңа сарылды да озак кына басып торды. Аның күзе яшь белән мөлдерәмә тулган. Хетэг кызчыкны күтәреп битеннән үпте, аның да күнеле тулган иде, әмма Кавказ ирләре еламый.

Хетэг, күз яшьләрен күрсәтергә теләмичә, ияргә сикереп менеп, өенә таба чаптырып китте.

Тай-туглы арбага утырды, андагы хатын-кыз белән исәнләште, тегесе башын какты да читкә борылды. Кызчык башын артка каерып ераклаша барган туган авылына бакты, сүзсез генә күз яшьләрен эченә йотты. Ләйлә кырын күз белән кечкенә юлдашына карады һәм, йөрәген чеметтереп, аны — житлегеп кенә килгән кызны Ширваншаһ хәрәменә алып килүләре исенә төште. Туган йортыннан аерылу сагышы кабат баш калкытты. Ләйлә кызчыкны жәлләп куйды. Нәрсә бу? Кызганумы, әллә бәби тапмаган хатынның ана булырга теләү хисләренең уянуымы? Ул Тай-туглы янына көчте дә иркәләп башыннан сыйпады. Әлегә кадәр таныш булмаган бу икәүнең баш өстендә ниндидер иркә яктылык таралды, йөрәкләрендә жылылык хасил булды. Баланың башы Ләйләнең күкрәгенә авып төште һәм кызчык назлы кочакка чумды.

Үзбәк алда бара иде, иярендә тирбәлеп барганда: «Самир хажи, хатын-кызлар Коръәннең хакыйкатенә төшенергә комачаулык итәләр, дию белән хаклы булган», — дип уйлады.

Яшь ханның йөрәгенә Ләйләнең карашындагы гажәпләнү, шом, кызчыкны куралмавы тынгы бирмәде. Ул ир-атын беркем белән дә бүлешергә теләми иде. «Жәза бирергәме? Ныклап кулга алыргамы? Хакимлекне күрсәтергәме? Тик ул бер сүз дә әйтмәде бит. Шәрык хатын-кызларына хас булганча, аның өчен күзләре сөйләде». Егетнең башын шундый уйлар биләп алды.

«Кем тормышны аңлый, шул ашыкмый» дигән акыллы нәсихәтне исенә төшерде Үзбәк. Ул, арбаны алга уздыру өчен, атын тыя төште һәм ана белән кыз шикелле кочаклашып утырган Ләйлә белән Тай-туглыны күрде. Ханның йөрәге шатлыктан чәнчеп-чәнчеп алды, ул атын әйдәкләп, әкрен генә, әмма ышанычлы рәвештә чиркәс тауларына якынлашып килгән сафлар тезмәсенең алдына чапты.

***

Алтын Урда ханы Туктай пошаманга төште: бәкләр бәге Нугай белән каршылыклар иң югары ноктасына житте. Алтын Урда икегә аерылды диярлек. Хәрби көчләр тигез, берсе дә көндәшенә беренче булып һөжүм итәргә базмады. Туктай, бик оста эш йөртеп, көнчыгыш чикләрен ныгыту белән шөгыльләнде. Ул баш иеп, Бөек каһан — Тимер янына китте, һәм Алтын Урда кабат Чыңгызхан төзегән зур дәүләткә кушыла, дип белдерде. Ханның карусызлыгына сөенгән Тимер, Хубилай тарафыннан гасыр уртасында ук Бәркәдән тартып алынган Пиньян өлкәсен Туктайга кайтарып бирде һәм табышы Алтын Урда казнасына китәчәк Цзиньчжоу белән Юнчжоу өлкәләрен дә өстәп язды.

Йола буенча, Туктай үз чиратында башка Олысларның хакимнәренә зур бай шәһәр йә өлкәне бирергә тиеш иде. Барысын ди бизмәнгә салып үлчәгәч, ул күршеләре хозурына тапшырыр өчен Кырымдагы Нугай үзенеке дип санаган Судак шәһәренә тукталды. Бәкләр бәге бу турыда ишеткәч, тәмам ярсыды, Кырымга сугышырга оныгы Ак-Тайжины жибәрде. Кырымлылар бик нык каршы торуы сәбәпле, максатына ирешә алмады. Нугайның оныгы Кафеда сәүдә иткән генуялылар тарафыннан үтерелде, кырым шәһәрләре исә Туктайга ярдәм сорап мөрәжәгать иттеләр, һәм мәкерле карт шым булды.

1299 елның ахырында Нугай үз гаскәрен Сарайга таба кузгатты, Туктай бу турыда белгәч, аңа каршы китте. Гаскәрләрнең юлы Көньяк Бугада кисеште.

Ханның көч ягыннан үзен күпкә узуын күреп, мәкерле карт хәйләләргә кереште. Ул кабат авыруга сабышты, арбага ятып, ыңгырашты, Туктайга, килешик дип үтенеп, хат артыннан хат яудырды, янәсе ул сугышырга түгел, үз гаскәрен ханның кул астына тапшыру өчен килгән.

Нугай сугышчыларының күпчелеге ханга каршы барырга теләмәде һәм алар әкренләп аның ягына чыга башладылар. Күчүчеләрнең берсе, бәкләр бәге, үзенең хатлары белән Туктайның уяулыгын йомшартып, сиздерми генә елга аша кичәргә дигән әмер бирүе турында житкерде. Әмма Туктай үзе беренче булып елга аша чыкты һәм канунсыз туган чыңгызыйның гаскәрен тар-мар итте.

Нугайны ханга хезмәт итүче урыс сугышчысы әсирлеккә алды. Бәкләр бәге үзен Туктай янына илтергә боерды, тик сугышчы аның башын чапты һәм ханга китерде.

— Менә Нугайның башы, — дип, ханның аяк астына ташлады.

— Каян чыгып аны Нугай башы дип уйлыйсың? — дип кызыксынды хан.

— Ул үзе әйтте, үтерməвемне үтенде, әмма мин, житәр бу картның безгә бәла китерүе, дидем дә башын чабып өздем.

— Ә син минем карт бабам Бөек Чыңгызханның аны канунлаштырганын беләсеңме? Гади халык патшаны үтерергә тиеш түгел! Аның язмышын бары тик без, аның туганнары гына хәл итәргә хаклы.

Туктай сакчыларына борылды:

— Канун бозучыны җәзаларга һәм хәзер үк, минем күз алдымда!

Туктай җиңелчә сулыш алды. Алтын Урданың бар халкы, кыйбатлы бүләкләргә күмеп, үзенең ханга тугрылыгын күрсәтергә ашыкты. Әмма тынычланырга иртә, аны Нугайның елгыр балалары һәм оныклары борчый иде. Мәрхүм бәкләр бәгенең олы улы берничә тапкыр Туктайга каршы чыгып карады, тик файдасы булмады. Шуннан ул, илдә барган үзара низаглардан файдаланып, Болгариягә бәреп керде, Тырново тәхетенә ия булды, әмма анда бер ел да утыра алмады. Җирле боярлар баш күтәрделәр һәм төрмәдә аны буып үтерделәр.

Нугайның икенче улы Тури кайчандыр ханга тугры булган Сарай-Буганы абыйсына каршы үгетләде, тик аларның ниятләрен белеп, Туктайга чын күңелдән бирелгән ир туганы Бөрлек икесен дә үтереп ташлады. Әкренләп мәкер-хәйләләр тына төште, Нугай Олысына ханга тугры чыңгызыйларны күчерделәр. Шуларның берсе Туктайның яшь улы Илбасар иде.

Тынычрак булган саен, Туктай да җанлана барды, ул Урданың эчке төзелеше белән шөгыльләнә башлады. Инде җиде елдан артык бөлгенлеккә төшми хан казнасын табыш белән тулыландырып торган урыс кенәзлекләренә чират житте. Туктайның күңеле тыныч, шат, ул кабул итү мәҗлесләре оештырды.

Бар да яхшы, сөенеп-куанып кына яшисе дигәндә, ханга бер үк төш керә башлады. Башта сирәк кенә, аннары ешлаганнан-ешлады. Төшендә янына үзе канын койган мәрхүм Тогрыл абыйсы килде һәм дәшми генә каршына утырып, күзләренә бакты, хан салкын тиргә батып уянганчы шулай дәвам итте. Төннең калган өлешен ул уяу уздырды, шуңадыр, көннәрен үзен кыйнап ташлангандай сизде. Түзәр чамасы калмагач, ул үз янына күк белгечләрен җыйды. Күк белгечләре Туктайдан:

— Үтерелгән абыең синнән ни тели, белмисеңме? — дип сорадылар.

— Юк. Аны ничек белергә соң?

— Төшеңдә килгәч сора, әгәр җавап бирми икән, димәк, аннан башка тагын берәү белә дигән сүз.

Туктай бик сорарга теләсә дә барып чыкмады, төшләр ханга буйсынмыйлар, күрәсең.

Кичләрнең берсендә, алдагы йокысыз төннән соң нервларын тынычландырырга

теләп, Арибахны үз янына чакырып алды. Хатыны ханны иркәләде-назлады да, сихер көченә ия куллары белән башын да дәвалады. Хәле жинеләеп китте, әмма исенә төшендәге серне белүче кеше төшүгә, кабат башы түнде.

— Нәрсә булды сина, ханым? Ник боектың? Зәңгәр күк синен белән булсын, ярдәм итсен һәм бар шик-шөбһәләренне куып таратсын.

Туктай яраткан хатынына барысын да сөйләп бирде.

— Абый миннән нәрсә теләгәнен кем белә, ул кайда яши икән? — Үз-үзенә сорау бирде Алтын Урта хакиме.

Арибах та уйларынын очына чыгарга тырышты: «Хәзер үк яки беркайчан да! Вакыт сукты! Күктә йолдызлар да бүген әйбәт урнашкан. Бик әйбәт, минем файдага. Тәвәккәллә, Арибах, тәвәккәллә!»

— Ачуланма, әфәндем, тик синең соравына жавапны мин беләм. Хәтерендәдер, мин Тогрылның хатыны идем һәм аңа Үзбәк атлы ул тудырдым.

— Үзбәк исемле иде, — берникадәр ярсуланып Туктай аны төзәтте. — Күптән юк бит Үзбәк, син бит аны үзең күмдең. Мин хәтта аның каберен дә беләм.

— Үзбәк исән, патшам! Исән һәм сау-сәламәт! Тогрыл аны үз янына чакыруынны, яраткан энен һәм фикердәшең итүенне тели. Шуннан соң мәрхүм абыең синең янга килүеннән туктар.

Туктай шундук тәнендә жинеллек тойды, башы сафланды, колаклары шаулаудан туктады, аяк-кулларына көч йөгерде. Хан аягына басты, уйларының очына чыгарга теләп, бүлмә буйлап йөренде: «Әгәр дә шулай икән, ник Арибах әйткәнчә эшләмәскә? Зәңгәр күк абыйларны жәзалаган өчен үч ала. Бәлки ашыкмаска, сабыр итәргәдер?»

Ләкин Туктай кинәт Тогрылның йөзен күрде, ул үткен күзен аңа төбәгән иде. Ул шунда ук Арибахка борылды:

— Йә, кайда яшереп тотасың инде улынны?

— Бу бары тик абыем Айдарбәккә — синең тугры хезмәтченә генә билгеле. Мин Үзбәкнең бары ышанычлы кулларда гына икәнен беләм. Ул сау-сәламәт, акыллы һәм сугышчы буларак әзер, — Арибах хәйләләде.

Ханнын кәефе күтәрелде. Нигә күтәрелде — үзе дә аңламады. Ул хәзер хужадан шундый серне яшергәннәре өчен ачуланырга, дуларга тиеш иде.

— Бәлки миннән тагын кемнедер яшерәләрдер? Бәлки яшерен генә сүз куешалардыр? — дигән уй үтте ханның башыннан, тик сәламәтлеге әйләнеп кайтуы һәм кәеф күтәренкелеге бу уйларны басып китте.

Мәңге сулмас гүзәл Арибах белән ул искиткеч төн уздырды. Туктай аны кичерде, чөнки ул ханны бәйләнчек-бастырылулардан, хан Арибахны куркыныч сердән коткарды. Икесенә дә рәхәт иде.

Иртән Туктай Итил белән Дон арасында үзенә ышанып тапшырылган хан гаскәре белән күченеп йөргән Айдарбәк төмән артыннан атчабар жибәрде. Арибах ышанычлы хезмәтче шул иртәдә Котлыгъ Тимергә Арабахның бүләкләрен дә илтә китте һәм аңа апасының, Котлыгъ Тимер абыйсы Айдарбәкне Сарай янында каршылап, аңа «Жылы жил ишекне ачты» дигән бер жөмләне тапшырсын, дигән үтенечен житкерде. Котлыгъ Тимернең анасы Мәрьям — Арибах белән Айдарбәкнең кыз туганы булганга, егетнең тамырларында Чыңгызхан каны ага, әбисе атасы ягыннан Бату ханның оныгы иде.

Ханбикә апасының әмере яшь, киләчәге өметле төмән бәге өчен үтәлергә тиеш сүз иде. Яшенә карата бик акыллы, сак эш йөртүче егетнең тәхеткә якынрак торасы килә. Ул монда ниндидер яшерен сер булуын, озакламый әһәмиятле вакыйгаларның куерасын сизенде. Озата килүчеләрнең күнелендә, энесе ни сәбәпле абзасын каршыларга уйлаган, дигән шик тумасын өчен, ул нишләргә дип баш ватты.

Иртәгесен Котлыгъ Тимер Сарайдан Актүбәгә таба бер көнлек юлга кузгалды һәм абзасын шунда лаеклы итеп каршы алырга әзерләнде. Айдарбәк исә, җавапларнын төрледән-төрлесен уйлый-уйлый, хан янына ашыга иде. Теләсә нәрсә булырга мөмкин, тик начаррагы гына түгел, дип уйлады ул. Энесе белән очрашканнан сон, абзасы, ашыгуын сәбәп итеп, туганынын күчмә торагына кереп тормаска булды. Әмма акыллы егет үз дигәнендә торды:

— Юл тузаннарын юмыйча йокылы күзләр белән хан янына килеп керү яхшы түгел, — диде ул.

Айдарбәк шунда ук ялдан мөһимрәк нидер барын сизенеп, төн куну өчен тукталырга әмер бирде.

Күптән көтелгән: «Жылы жил ишекне ачты», — дигән яшерен сүзне ишеткәч, ул жинел сулап, каты йокыга талды.

Айдарбәк хан алдына тезенә төште, мактау һәм данлау сүзләрен житкерде.

— Яле, ханыннан нәрсә яшерәсен, сөйлә?

— Теләсән жәзалый аласын, хакимем, тик Зәнгәр күк күрә, бары таулылар каны гына хатынынның улы һәм энекәшемнен кайдалыгын белгертмичә сине билгесезлектә тотарга мәжбүр итте.

— Ин әүвәл, Үзбәк — минем энекәшем! Хәзер син мен сугышчы аласын да аны минем янга китерәсен, элек күрермен һәм синен жүнсез канынны агызыргамы, әллә сабыр итәргәме икәнен хәл итәрмен. Бәлки тагын яшерен серләрен бардыр әле?

— Әй ханым, минем башка серем юк. Бар гомеремне сина, бары тик сина гына хезмәт итәргә багышладым, падишаһым өчен гомерем дә жәл түгел.

— Күп сөйлисен, түмән башы. Үзбәкне кайда яшерәсен, шуны әйт?

— Ул Чиркәс тауларында, минем атамда тәрбия кылына.

— Энекәшемнән башка сине күрәсем килми, Айдарбәк, юлга кузгал һәм ашык.

Айдарбәк, башын иеп артка чигә-чигә, тәхет залыннан чыкты. Анын күнеле канат какты. Хан янында озак булу сәбәпле, ул аны өйрәнгән иде инде, шуна хакимнен сүзләре күбрәк тәхет тирәсендәгеләргә юлланганын белде. Туктай һичкайчан сөекле Арибахынын кәефен жибәрә алмас иде.

***

Елбаздукка биш түбәле тау янында менләгән сугышчынын төн кунарга тукталганын хәбәр иттеләр.

— Кичүләрдәге сакны көчәйтергә, мен башынын кем булуын ачыкларга, — дип боерды кенәз.

Иртән сугышчыларнын Айдарбәк житәкчелегендә икәне билгеле булды һәм атасы улын каршы алырга чыкты. Бийчесын жәйләве итәгенә житеп килгәндә, Айдарбәк ерактан ук атасын танып алды — ат өстендә шундый дәрәжәле һәм үзен эре тотып бары ул гына утыра ала иде. Аттан төшеп, сәлам бирештеләр. Икесе, читкәрәк тайпылып, хуш исле үләнне таптап атладылар.

— Ни белән килден, улым?

— Яхшы хәбәр белән, атам. Туктай хан Үзбәкнен исән икәнлеген белгән һәм аны үзенә китерүне таләп итә.

Елбаздукнын йөзен кара болыт басты:

— Яхшымы бу хәбәр, әллә начармы — хәзергә билгесез.

— Яхшы, атам, яхшы! Синен кызын Арибах ханнын хис-тойгылары белән идарә итәргә өйрәнгән. Туктай Үзбәкне яхшылык белән көтә, үзенә якынайтмак була.

— Хакимнәргә якынаю —яхшы дигән сүз түгел әле.

— Үзең күрәсең, атам, Үзбәкне озата йөрергә Туктай нинди сак җибәрде, әсир өчен егерме сугышчы да җитә. Андый хөрмәт белән хан янына Урданың бары тик югары катлау түбәннәре генә килә ала.

— Ул турыда әйтмим мин, алга таба сезнең һәм аның эш-гамәлләре турында борчылам, — дип үзенекендә торды әле дә икеләнүе кимемәгән Елбаздук. — Кешеләреңне монда калдыр, ял итсеннәр, без исә өйгә кайтыйк.

Кенәзнең утарына кайтып җитәрәк, аларның юлын саф токымлы байтал өстендә ярыйсы шәп утырган җайдак бүлде. Айдарбәк шунда ук кылычына үрелде, янәшәсендә баручы Елбаздукның кулы улының уң кулына төште.

— Ашыкма, улым, моңа отылуың бар. Ул бик көчле, акыллы сугышчы, аның белән дуслашырга кирәк, чөнки ул — синең энекәшең.

Кылыч, күз ачып йомган арада, кынына кереп утырды. Ике ир-ат бер-берсенең каршына киттеләр һәм, гадәткә кергәнчә, ат өстеннән төшми генә кочаклаштылар.

— Менә син нинди булгансың! — дип сокланды Айдарбәк, аңа карап.

— Мина инде егерме бер, абзам. Туган җиргә рәхим ит!

— Сине күрүемә мин бик шат, ханым. Хәзер без ешрак очрашырбыз. Сине алып китәргә килдем.

Үзбәк артык сораулар биреп тормады, чөнки ул белә: Сарайга юл якын түгел, агасы үзе вакытын чамалап сөйләр.

Йортның бусагасында Айдарбәкне анасы, аның сөекле Гайшә анасы каршы алды. Ул Елбаздукның бердәнбер хатыны, аңа ике кыз, бер угыл табып бирде.

Анасы улын кочагына алды, ә тегесе тезенә төште:

— Кичер, анам, озак күрешә алмадык, хан хезмәтеннән китеп булмады, менә мин синең янәшәңдә, туган йортымның исен тоям, кадерле кешеләремнең тавышын ишетәм, һәм сине сагыну-яратудан йөрәгем өзгәләнә.

Айдарбәк анасы алдына бүләкләр: кытай ефәгеннән яулыклар, кыйммәтле көмеш коштабаклар, савыт-сабалар, бизәнгечләр чыгарып тезде.

— Болар синең Урдадагы кызларың ханбикә Арибах белән Мәрьямнан, алар синең кулыңны үбәргә куштылар, анам.

Гайшә балаларының игътибарыннан куанып, түзмәде — елап җибәрде. Хезмәтчеләр ишегалдындагы зур өстәл тирәсендә кайнаштылар, алар белән зифа буйлы, гаҗәеп ягымлы йөзле тере-җитез кыз җитәкчелек итә иде.

— Бу нинди сөйкемле зат безнең йортыбызда? — дип сорады Айдарбәк Үзбәктән.

— Тай-туглы ул, әбием тәрбиясендә, кунак бабай — осетин кенәзе Хетәгнең оныгы.

— Шәп кызчык, кияүгә бирерлек, — дип елмайды абзасы.

Үзбәк дәшмәде.

Көн кичкә авышканга, төшке аш кичкесе белән кушылды.

— Кичер, атам, мин Үзбәкне ашыктырырга тиеш. Туктай көтәргә яратмый. Иртән без кузгалырбыз.

Елбаздук улына карап куанды. Чын ир-ат, яхшы сугышчы булып җитлеккән! Ата кешенең хыялы шул түгелмени? Шулай да бер уй аңа тынгылык бирмәде: «Айдарбәк чынлап та Туктайның Тогрылны үтерүен онытты микәнни? Туктайның бу мәкерен кичерде микәнни? Бәлки аның улы тау ир-аты булудан туктагандыр, канлы үчнең ни икәнен оныткандыр? Тик ул акыллы һәм хәйләкәр, мөгаен, унайлы вакыт җиткәнен көтәдер. Әйе, әйе, нәкъ шулай! Алар Арибах белән икесе Туктай ярдәмендә Үзбәкне тәхеткә утыртырга уйлыйлардыр!»

Елбаздук тынычланды. Ул җир йөзенә акыллы, төпле балалар тудырган.

Үзбәкне төрле уйлар чолгап алды, шуна керфегенә йокы эленмәде. Күпме төннәр житез ат үзен Урдага алып китәсен көтте, ниһаять, анасын күреп, сөекле, ягымлы, кадерле, яраткан кешесен кочагына алырын күз алдына китереп, хыял дингезләрендә йөзде. Иртән торгач, нурлы кояш, даланың хуш исе кайгысын читкәрәк куа иде. Менә иртәгә ул көн туар, ә яшь хан нәрсәдәндер шүрли, дулкынлана иде. Урдада аны ни көтә? Туктай тозак әзерләп куймасмы? Урда ханы үзенен варисы итеп улы Илбасарны игълан итте. Көндәш кирәк микән аңа? Монда нәрсәдер бар. Башында бөтерелгән уйлар егетне тәмам йөдәтте, ул бер яктан икенчесенә әйләнде, торып, йөреп килде, утырды, әмма йоклап китә алмады.

Кайчан күзен йомгандыр, төшендә янына анасы белән инде төс-бите хәтердән җуела барган атасы килде. Балачактагы кебек, атасы аны көчле, нык кулларына күтәрде һәм тыныч, әмма катгый гына әйтте:

— Улым, син инде зур, акыллы, елдам булып үстең. Тизрәк өйгә кайт, тик беркайчан да ашыкма, берничә кат уйла, шул вакытта һәрвакыт өстен чыгарсың.

Анасы улының башыннан сыйпады, Үзбәкнең тәне буйлап татлы рәхәтлек йөгерде, әкрен, ягымлы таныш тавыш ишетелде:

— Мин сине көтәм, улым! Бар да яхшы булыр.

Төшендә Туктай да күренде, Үзбәк анын йөзен шәйләп бетермәде, әмма Алтын Урда ханыннан җылы бөркелә иде.

Яшь хан күзен йомып кына алса да, ял итеп, күтәренке кәеф белән уянды. Ишегалдына чыкты, тәнен язды, елга буена, гадәттә иртәләрен бабасы белән юына торган урынга йөгерде. Көнчыгыштан, таулар артыннан, сыек кына яктылык сирпелде, иртәнге салкынча һава тәнгә үрмәләп, җинелчә чеметеп алды. Үзбәк, уйнаклап-сикергәләп, су буена төшкәндә, кинәт кенә сукмакта Тай-туглы пәйда булды, ул тезләнеп:

— Кичер мине, хакимем, сүз әйтергә бирче, — диде.

— Башта торып бас, кызчыгым, һәм әйт.

— Мин кызчык түгел инде, ханым! Мин теләсә кайчан хатын булырга әзермен, тик синең белән генә. Минем гыйффәтемне син генә алырга хаклысың. Мин сине яратам, Үзбәк, яратам!

Тәҗрибәле, ярату-яратылуда остарган ир-егет көчле кулы белән Тай-туглыны үзенә тартып алды, кыз анын кайнар кочагында калды һәм ирennәре бер-берсен табышып кушылдылар. Сулышка капкан кызулык дәртне уятты, әмма Үзбәк үзен вакытында тыеп калды, сөйгәнен кочагыннан ычкындырмый, колагына иркәләп пышылдады:

— Һичшиксез, сине алырга килермен, син минем хатыным булырсың! Сабыр бул һәм көт. Күпме көттерәсемне белмим, тик шикләнмә — көт. Ә хәзер йөгер, сөеклем.

Тай-туглы сукмак буйлап югарыга таба чапты. Бәхетеннән канатланып, сакляның хатын-кызлар ягына очып керде һәм шатлыгыннан сикерергә тотынды.

Ләйлә күптән уянган иде. Берәр сәгатьләп элек Тай-туглы белән сөйләшергә теләде, әмма кыз ятакта күренмәде. Озак кайтмый торгач, Ләйләнең башын «Чынлап та, Үзбәк кызчыкны үз янына чакырды микәнни?» дигән уй бөтереп алды. Ул буй тарткан көндәшенең инде күптәннән иренә гыйшык уты тулы күзләре белән караганын, тегесенең дә ерактан гына аңа сокланып йөргәнен сизә, күрә иде. Ләйләнең каны кайнады, әмма ул үзен кулда тотарга өйрәнгән иде.

Бәлки барысы да яхшыгадыр. Үзбәк — мөселман, аңа берничә хатын фарыз,

ә Тай-туглыны Ләйлә тәрбия кыла. Шулай булгач, ни телисең син? Шатлан, исәр! Тай-туглы белән идарә итәргә өйрәндең, ә ирең Урдада тагын берәүне тапкан очракта, икәүләп сагыш утында яну — җиңелрәк.

Тай-туглының бүлмәгә атылып керүен ишетеп, Ләйлә йоклаганга сабышты. Шатлыгыннан исергән кызый үзе аның ятагына килеп утырды.

— Син нәрсә, кәҗә кебек сикерәсең? — яңа уянган кыяфәт чыгарып, сорады Ләйлә.

— Үзбәк миңа өйләнергә вәгъдә бирде!

Гүзәлкәй Ләйләнең йөрәге, читлектәге кош кебек, күкрәгеннән чыгардай булып типте.

— Бүген төнлә чакырдымы?

— Юк, ул мине алырга киләчәк һәм өйләнәчәк. Үзе шулай диде.

— Сине алырга килер, ә безне — мин һәм кызың нишләтә?

— Билгеле инде, сине дә һәм безнең кечкенәбезне дә алып китәчәк.

Ләйләнең йөрәге тынычланып калды. Димәк, әлегә мин Үзбәкнең бердәнбер хатыны, вакыт дигәнең исә күп суларны: чистасын да, шакшысын да агызып китә. Шунда Ләйләнең башына бик матур бер фикер килде: кичекмәстән Тай-туглыга өйлән дип, ирен үгетләргә кирәк.

Аерылышкач, ул яшь бикәчен сагыначак, очрашуны көтәчәк һәм тизрәк безнең янга кайтачак.

Үзбәк иртәнге аштан соң ук хатын-кызлар белән хушлашырга килде. Әбисе алдында ул тезенә чүкте һәм кулын үпте. Гомере буе ирләрне озатып калырга күнеккән Гайшә, оныгының башыннан сыйпап, чәчләрен тузгытты:

— Син көчле ир-егет, Үзбәк. Син акыллы ир-егет, оныгым. Беркайчан да хатыннарыңны онытма, аларны кайгырт. Бәхетле бул! — диде дә, күзенә тулган яшьләрен оныгына күрсәтергә теләми, үз эшләре белән китте.

Йөзе сагышлы Ләйлә Үзбәкне үпте, ул аерылуның нинди газап икәнен белә, әледән үк иренең әйләнеп кайтуын көтә башлады, аның тизрәк үзен басып торган таулардан котыласы килә. Ләйләнең күңеле күкнең җир белән тоташкан урынына, иркенлеккә, шаян җил җанны иркәләгән якларга омтыла. Аны, ире ничек тизрәк китсә, шулкадәр иртәрәк кайтыр, дигән уй тынычландыра. Азактан ул Үзбәктән Тай-туглы белән ягымлы итеп хушлашуын үтенде:

— Кызчык сине ярата, ханым, кайда гына булсаң да аның сагышы сине табар, борчуга төшерер. Кара ана, хакимем, ул күптән хатының булырга әзер.

Ләйләнең хәйләкәр күзе җавап көтте, әмма ире дәшмәде. Бары тик эченнән: «Әй хәйләкәр дә инде бу гүзәлләр, әй хәйләкәр! — дип уйлап, көлемсерәде.

— Сөеклем, мине уйлап сагышланма. Ничек булса да сезнең белән тизрәк очрашу ягын карармын, — диде ул хатынына.

Тай-туглы ишек янында көтә иде. Хан аны каты итеп үпте.

— Мин әйткәнне онытма, көт!

Бабасы белән ишегалдында саубуллаштылар. Җыйнак, күтәренке күңелле Елбаздук гадәттәгечә, хәрби киемнән иде.

— Хатын-кызларны сакла, бабам. Рәхмәт сиңа барысы өчен дә!

— Сиңа да рәхмәт, оныгым! Син минем гомеремне ким дигәндә ун елга озайттың, җанландырып җибәрдең. Нәрсәгә өйрәттеләр — берсен дә онытма. Иң беренче нәүбәттә, күз-колакларны томалый торган, хәйләкәр һәм ялагайлар җырлый торган ялган дан турында уйла, аларга күңелеңнең нечкә кылларына кагылырга рөхсәт итмә. Шуны аңла: дөреслек — халык ягында!

Бабасы белән онык бер-берсенең куенына елыштылар. Үзбәк Елбаздукны кочагыннан ычкындырды һәм борылып: «Атларга!» — дип боерды.

Иярenә сикереп менде дә, артына карап-нитеп тормый тауга таба ыргылды, аның артыннан кузгалган Айдарбәк һәм аның кешеләре кемнен баш икәнен шунда ук төшенделәр.

***

1302 ел бара. Туктайның көнеле тыныч. Алтын Урда бер йодрыкка тупланды, монголлар арасындагы эчке ыгы-зыгылар туктатылды. Хан дәүләтне төзү һәм ныгыту, Иран белән араларны көйләү эшләре белән мәшгуль булды. Күк Урда хакиме Баян ханга, кардәшләре белән үзара низагларын җайга салу өчен, гаскәр белән ярдәм итте. Табигате белән кунакчыл Туктайның мәҗлес, уен-мәзәкләр өчен вакыты барлыкка килде, әмма идарә дилбегәсен кулыннан бушатмады.

Сарай үсте, төзелде, анда бердәм урда акчасы суга башладылар, төрле-төрле булган искеләре әкренләп кулланудан төшеп кала барды. Туктай урыс кенәзләренә «мөлкәтне кабул итәргә», бер-берсе белән сугышчан тәртипсезлекләрне туктатырга, бәхәсләрне кинәшмәләрдә хәл итәргә дигән боерыклар белән ярлыклар җибәрде. Хан Православ чиркәвенә бар хокукларын калдырды һәм алардан ясак алынмый дип белдерде.

Патшаның күңелендә тынычлык хөкем сөрде, куркыныч төшләрдән арынды, варис дип игълан ителгән улы Илбасар әкренләп буй тартты.

Үзбәк матур итеп бизәлгән зур каекларда яраннары озатуында Итил елгасын кичте. Актүбә белән Итилне тоташтырып торган агымны күбекләндереп, ишкәкләр хәрәкәт итте. Еракта Сарай, мәчет манаралары шәйләнде. Бераздан хан сараенын биек корылмалары ачыграк күренде, шәһәр үсте, матурланды, халык әкренләп утрак тормышка тартылды.

Каеклар балчыклы ярга килеп төртелделәр. Үзбәк белән Айдарбәк җинел генә җиргә сикереп төштеләр, кечерәк кенә текә ярга күтәрелделәр, анда аларны Котлыгъ Тимер каршы алды. Туганнан туган абый-эне кочаклаштылар, балачакларын искә төшереп алдылар.

— Синең белән, Үзбәк, бөек чыңгызыйлар нәселе дәвамчысы белән, туган җирендә күрешүемә шатмын.

— Сине күрүемә мин дә шат, Котлыгъ Тимер туганым! Син бик үскәнсең, чын сугышчы һәм ата-ананның лаеклы улы булгансың.

— Хөрмәтле абзам, данлыклы хәрби җитәкче Айдарбәк, безне бүген нәрсә көткәнен сөйләргә рөхсәт итче.

— Бөтен игътибарыбыз синдә, энем.

— Бөек Туктай ханыбыз абыйсының улы Үзбәкне лаеклы каршы алырга әзерләнә, ул бүген кич, эсселек кимегәч башлана.

Үзбәк шунда гына якты җәйге кояшның бик нык кыздыруын сизде. Көн шундый эссе, хәтта сирәк кенә утырган агачларның яфраклары яктыга кире яклары белән әйләнгән, кайберләре исә бөтерелеп килгәннәр. Яшь ханның чигәләреннән бите буйлап тир тамчылары йөгерешә, ул аларны сөртеп алды һәм учына дала тузанының пычрагы ябышканын күрде.

— Ә хәзергә, абзам,— дип дәвам итте Котлыгъ Тимер , — хатыннарың, хезмәтчеләрең ашарга һәм озак юлдан соң ял итү өчен кирәкле бар нәрсәне әзерләделәр. Мунча да әзер.

— Шундый эсседә нинди мунча булсын! — Үзбәкнең кәефе кырылды.

— Тылсымлы мунча, арганны юып ала, тәнне пакьлый, — дип каршы төште аңа Айдарбәк. — Алга, энекәшләр, минем өемә. Синең атаң салган өйгә, Үзбәк.

Ишегалдына керделәр. Үзбәк тирә-ягына караштырды. Әллә ни үзгәрешләр

күренми, әнә бер почмакта чыгыр, икенчесендә арба, менә эт оясы, янында йоны коелган хуҗасы шыншып тора.

— Нәрсә булган аңа? — дип сорады яшь хан.

— Игътибар белән кара һәм аңларсың. Бу бит син сөт эчергән көчек, — диде абзасы.

Үзбәккә күңелсез булып китте. Ун елдан аз гына артып китте, ә эт инде көчен югалткан. Ул элеккеге дусты янына килеп, аның сыртын сыйпады, үзен ипи кыерчыгы белән сыйлады. Яртылаш сукыр эт яратып аның битен ялады. Хан тәмам күңелсезләнде, йөрәген чеметтереп, балачак истәлекләре калкып чыкты.

— Абзам, әйләнеп чыксам ярыймы?

— Ярый гына түгел, кирәк, без сиңа комачау итмәбез.

Йорт хезмәтчеләре, хөрмәт белән башларын иеп, бусага янында катып калдылар, бары чал кергән чәчле хатын башын имичә, күз яше аша Үзбәккә карап тора иде. Ул боларның шатлык яшьләре икәнен аңлады, җыерчыклы йөзгә төбәбрәк күз салды. Бу бит ул! Әйе, нәкъ үзе — аның караучысы! Аңа кыпчак телендә ягымлы, матур җырларны ул көйләде, борынын сөртте, чебиләгән аяк-кулларын дәвалады, бер җирдән икенчесенә күчкәндә җил һәм яңгырдан ышыклады. Үзбәк аның янына килеп, тезен чүкте һәм кулын үпте.

— Сез нәрсә, сез нәрсә, ханым, — өлкән яшьтәге хатын каушап калды, — бер мескен кол хатынга хан тарафыннан якты чырай була аламы, мин андый зур хөрмәткә лаек түгел.

Тәрбиячесенең кулыннан тоткан килеш, Үзбәк аягына күтәрелде һәм Айдарбәккә:

— Абзам, син миңа күп игелекләр кылдың, тагын берне эшлә: караучымны миңа җибәр. Янәшәмдә булуын һәм калган гомерен хөрмәттә яшәвен телим, — диде.

— Ничек әйтәсез, ханым!

Тәрбияче хатын елап, Үзбәкнең кулын үпте, мактау сүзләре яудырды.

Ул бусаганы атлап, өйгә керде. Монда бар да таныш, якын һәм кадерле. Үзе яшәгән бүлмәгә үтте, үз ятагына ятты, теге соңгы көннәрдәге дәһшәтләр исенә төшеп, йөрәге кысылды. Аның ачуы котырды, үч алу теләге баш калкытты, тик хан, Елбаздукның: «Ашыкма! Үлчәп эш ит!»— дигәнен хәтерләп, бу тойгыларны баса алды. Үзбәк үз-үзен тотарга өйрәнде, кинәт сикереп торды да ныклы адымнар белән ишеккә атлады.

Айдарбәкне күреп:

— Нәрсә, абзам, башта мунча, аннары төшке ашмы? — дип сорады.

— Син хаклы, мунчага ашагач кермиләр.

Үзбәк тиз генә чишенде, элгечкә якасыз җиләнен, каракүл бүреген элеп куйды һәм Котлыгъ Тимер артыннан яхшылап эссе салынган чабыну бүлмәсенә үтте. Алар киң ләүкәгә утырдылар, тәннәре буйлап, юл пычрагын ияртеп, юл-юл тир акты. Ишектә кулына зур имән себерке тоткан озын ак күлмәк кигән ир-ат күренде. Ул ләүкәнең өске катындагы печәнне төзәткәләп, яшь ханга менеп ятарга кушты. Үзбәк уттай кызган ташларда ни чыжлаганын күрмәде, әмма тәнен рәхәт кайнар дулкын чорнап алды, тәненә тияр-тимәс себерке орынуга, ул икенче дөньяга күчте. Аннары ханның өстенә салкын су койдылар, тагын чаптылар, бөтен тәнен бал белән сыладылар һәм тагын чаптылар. Ул хәлдән тайды, тукымага төренеп мунчаның алгы ягындагы сәкедә ятып алуга, көче әйләнеп кайтты һәм аның һавага күтәрелеп очасы килде. Теш сындырырлык салкын куас Үзбәкне тәмам тәртипкә салды һәм ул киемнәренә үрелде.

— Җиләненне кияргә ашыкма, ханым, — дип туктатты аны Айдарбәк,

— анаң сина монгол киеме, бүреге һәм итекләре жибәргән. Туктай янына минә шушыларны киеп барырга тиешсең.

Үзбәк киенде, киемнәр күнегелмәгән булса да, Аллага шөкер, үлчәме туры килде.

Мул итеп әзерләнгән төшке аштан соң, Алтын Урда хакиме каршында лаеклы күренү өчен, ятып торырга булдылар.

Туктай ханның зур сарае биек нык койма белән әйләндереп алынган, капка төбенә ышанычлы сак куелган. Айдарбәк белән Котлыгъ Тимер озатуында Үзбәк ишегалдына җәяүләп һәм коралсыз керде. Чәчәкләр һәм үләннәрнең хуш исеннән баш әйләнә. — Ишегалдының буеннан-буена тезелеп зур бассейн-күлгә таба төшкән фонтаннардан, һавага салкын бөркеп, өзлексез су агып тора, яхшылап төеп тапталган сукмаклар кырыеннан яшел тигез чирәмлек сузылган.

Хан түрәсе Үзбәкне зур илтифат күрсәтеп каршы алды һәм, башын ия-ия, кунакларны кешеләр җыелып торган урынга таба алып китте. Килеп җитәрәк яшь хан кечерәк кенә күтәренке урын күрде, аны күләгәләп, биек түгәрәк зиннәтле чатыр корылган иде.

Озатып йөрүче:

— Сезгә монда, — диде, фарсы келәме түшәлгән юлны күрсәтеп.

Келәм буйлап хан яраннары янына атлаганда ул чатыр астында күркәм тантаналы кыяфәттә утырган хаким гаиләсен, һәм аларны әйләндереп алган сакчыларны күзәтергә өлгерде. Уртада тәхеттә сынын мәһабәт тотып Туктай калкып тора, уң ягында — өлкән хатыны Баялун, сулда — сөекле хатыны Арибах. Кырыйда — тагын ике хатыны, унда, өлкән хатыныннан аз гына алдарак ун яшьләр чамасындагы улы — тәхет варисы Илбасар утырганнар. Арттa дистәләп түрә җәй азагында чыккан әрсез чебеннәрне куа һәм кулларындагы зур җилпәзәләр ярдәмендә әфәнделәренә саф һава җилпи иделәр.

Аскуймага биш адымнар кала, Үзбәк ике тезенә төште.

— Әй зирәкләрнең зирәге, Зәңгәр күк сакласын үзеңне! Әй акыллыларның акыллысы! Әй көчлеләрнең иң көчлесе! Әй мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе! Синең алда, озак еллар ачуыннан куркып түгел, лаексыз булып күренүдән куркып, укуга бирелеп, карашына лаек булырга теләп озак еллар адашып йөргән үзеңнең энекәшең. Аны кичерә алырсың микән? Мине синең бар нәрсәне күрә торган гадел күз каршына китереп җиткерергә дигән әмереңне ишетеп, ничек куанганымны Аллаһы Тәгалә, ана дан булсын, белә. Мин синең алдыңда, падишаһым! Хөкемеңне көтәм, барысын да: дәрәҗәне дә, әрләүне дә тиеш дип кабул итәм.

Үзбәк башын иеп, мангаен келәмгә тидерде. Башын күтәргәч анасының үткен карашын тойды. «Анам нәрсә уйлый? Үземне дөрес тотаммы?» — дип уйлады ул, әмма анасының күзенә төбәп карамыйча, аны аңлый алмый иде.

Үзбәк Туктайның тәхетеннән торып, аскуймадан төшүен һәм энекәше янына килүен дә күрмәде. Ханның беркайчан болай эшләгәнен күрмәгән тирә-янындагылар катып калды. Үзбәк көчле кулларның аны тотып, җирдән аеруын тойды. Туктай елмайды:

— Ниһаять, мин сине күрдем, кадерле энекәшем. Тор, гади сугышчылар кебек, син минем алда алай түбән иелергә тиеш түгелсең. Син минем янымда утырырга лаексың, син — минем гаилә әгъзасы.

Хакимнән мондый мөнәсәбәтне берәү дә көтмәгән иде. Арибахның күңеле нечкәреп, әзлән генә күз яше чыгармады. Улының баскычлар буйлап күтәрелгәнен күреп, ананың йөрәге сөенеч белән тулды. Нинди сын, нинди көч! Зифа буй, монголларныкына охшамаган туры аяк. Әмма йөз-бите гел атасыныкы (әй Аллаһ, улы ничек Тогрылга охшаган), чыңгызый икәнен әйтеп тора.

Арибахның менә хәзер үк улын барып кочасы, иркәлисе килде, тик йоланы бозарга ярамый иде. Бөек һәм мәрхәмәтле Аллаһка дан, Туктай Үзбәкне анасыннан әз генә алгарак, сул якка утыртты. Анасы сиздерми генә улының аркасыннан сыйпады, тегесе артка борылмый ягымлы итеп чиркәсчә:

— Мин сине яратам, анам! — диде.

Бәхетеннән Арибахның йөрәге урыныннан купты. Ул рәхмәт тулы карашын Туктайга төбәде.

Мәҗлес башланды. Ит, сыр, ипи, куас, кымыз, каты сөт аракысы, бузамантый, токмач бик күп иде, шулай ук кытай чәе бирделәр. Тәгам җыйганнар җай гына гәп куерттылар. Бер почмакта Туктайның кин күңелле булуы, икенчесендә — хатын-кызларның мәкер-хәйләсе, хакимне дә үз кубызларына биетүләре хакында сөйләштеләр, хан энекәшенең буй-сынын, аның акыллы нотыгын мактадылар. Күбесенең аның нинди сугышчы булуын беләсе-күрәселәре килде, алар өчен иң мөһиме шул.

Төп сөйләшү мәҗлеснең уртасында барды. Туктай игътибар белән Үзбәкнең өйдән читтәге тормышы турында тыңлады, аның белеменә, әңгәмә кору осталыгына шаккатты. Энекәшенең дөнья төзелеше турында фикер йөртүе ханны хәйран калдырды, ул диннәр тарихын да әйбәт белә иде. «Монысы бик яхшы, — дип уйлады хан, — сугышчы буларак нинди, әлегә билгесез. Гадәттә акыллылар корал белән эш итә белмиләр».

Туктай үзе янына мәҗлес белән җитәкчелек итүчене чакырып, иртәгесен надам[25] булачак дип, игълан итәргә боерды. Бу бәйрәмне уздырганга айдан артык кына булса да, ул кабатларга булды һәм анда яраткан энесе дә катнашачак иде.

Үзбәккә хәйләкәр генә карап:

— Ярышларда катнашырга телисеңме? — дип сорады хан.

— Ихтыярыгыз, падишаһым!

Мәҗлес, Туктай барысына ял итәргә әмер биргәнче, төн уртасына кадәр сузылды. Үзбәк анасы белән бары бер-ике сүз алышырга өлгерде, аерым үзләре генә сөйләшә алмаганга көенде.

— Бар, улым, ял ит. Иртәгә хан сине сугышчы буларак тикшермәкче була. Юлдан соң йокыңны туйдыр. Мин сине, улым, бик озак көттем, тагын көтәрмен. Сөйләшер өчен алда вакытыбыз күп әле.

Яшь хан надам өчен өч төрле ярыш: көрәш, җәядән ату һәм ат чабышы кирәклеген белә иде. Үзбәкне аттан башка берни борчымады, әмма Айдарбәк белән Котлыгъ Тимер унайсыз хәлгә куймаслар, дип ышанды.

«Иртә кичтән хәерлерәк» дигән мәкальне кабатлап, йокларга ятты.

Иртәдән Актүбәнең Сарайга якын яры буендагы ике озын калкулык арасындагы тигез зур мәйданга бик күп халык җыелды һәм түземсезлек белән ярышларның башлануын көттеләр.

Бәйрәм ат чабышы белән башланып китте. Караучыларга ике дистәләп катнашучыны тәкъдим иттеләр. Хан энесенең ияре астында түземсезләнеп саф токымлы җирән чабышкы биеп тора иде. Кузгалырга әмер бирелде. Ат шунда ук ыргылып алга чыкты, әмма Үзбәк Елбаздукның, ашыкма, атны тый, дигән киңәшен исенә төшерде. Көндәшләре атларын бар көченә куды. Хан энесе алдагыларны күз уңыннан ычкындырмый өченче-дүртенче булып барды. Беренче булырга ияләшкән айгыр авызлыгын йолкыды, әмма җайдак бирешмәде. Бәйгенең әкренәя төшүен сизеп алгач, йөгәнен бушатты һәм җинелчә генә кагып алды. Ат, көндәшләрен тузанга күмеп, ук кебек алга атылды. Сызыкны беренче үткәч, Үзбәк атны кинәт туктатты, тегесе тар юл буйлап,

[25] Монголчадан «күңел ачу», «ирләрнең өч уены» мәгънәсендә.

икенче булып киләчәк җайдакны көтеп, горур гына атлап китте. Халык гөж килде. Туктай шатланды, ул Айдарбәкне үз янына чакырып алды:

— Энекәшкә айгырны син бирдеңме?

— Юк, Котлыгъ Тимер .

— Ул малай аны каян алган?

— Үз көтүендә колыннан үстергән. Атасына гарәп сәүдәгәрләре бүләк иткән булган.

— Ярар, бар әйт, мин канәгать.

Айдарбәк барысын да аңлады. Җиңүчегә бүләк тапшырганда, меңбашы атны йөгәненнән тотып, Туктай утырган чатыр янына алып килде һәм кычкырып әйтте:

— Ханым, бу ат синең араңда гына булырга лаеклы.

Туктай икеләтә канәгать калды, борылып үзенең бабасы-бәкләр бәге Сәлҗидәй гүргәнгә карады, тегесе уйга калган иде.

Кыска гына ялдан соң җәядән ату бәйгесе башланды. Һәр укчыга берәр тәмек[26] куелды һәм унар ук файдаланырга рөхсәт ителде. Вакытны чикләмәделәр. Бәйге тәмамлангач, хөкемдарлар унар ук кадалган унбер тәмекне генә сайлап алдылар. Аларны ханның санаучылары хөкеменә китерделәр. Тәмекнең нәкъ уртасында уклардан тигез әйләнә ясаган укчыны җиңүче дип атадылар. Тәмекнең кемнеке икәне берсенә дә мәгълүм түгел иде. Төп хөкемдар җиңүченең исемен хәбәр итте — ул Үзбәк булып чыкты.

Көрәштә дә Туктай энесе Чыңгызхан нәселен лаеклы күрсәтте. Ул азакка чыкты, әмма, күпме генә тырышмасын, эш үгезе кебек алагаем Борханны җиңә алмады. Теге таш кыя кебек тора һәм, акылы киткән аю кебек, кулларын болгый иде.

Гомуми исәптә Үзбәк җиңүче дип игълан ителде һәм ана төп бүләк тапшырылды. Нык тарттырылган җәя бик матур бизәлгән, көреше кыл кебек яңгырап тора иде.

Туктай үзе үтергән мәрхүм абыйсының улын кочаклады, тынычланырга боерды һәм кычкырып:

— Тогрылның улы, Мәңгүтимернең оныгы, Бөек галәмне таң калдырган Чыңгызхан нәселе дәвамчысы энем Үзбәкне Алтын Урда тәхетенә яраткан улым Илбасардан кала икенче варисым итеп игълан итәм, — диде.

Кичен Туктай белән Сәлҗидәй гүргән икесе Кырым мәсьәләсен хәл кылдылар. Ахырдан бәкләр бәге болай диде:

— Үзбәккә карата ярату хисләреңне бүлешмим, тик син хан, ихтыярың. Аның кул астына берәр ерак Олысны бирергә мөмкин һәм карарга —ерактагы яхшы күренә.

Туктай бабасының сүзләрен игътибарга алмады, бары: «Тәмам картайды, шикләнүчәнгә әйләнде!» — дип кенә уйлады.

Бу кичтә аның тизрәк Арибах белән очрашасы, ана улының яхшы сыйфатлары турында житкерәсе килде: сөеклесе куаныр һәм үзенең ханын тагын да ныграк яратыр.

***

Иртәнге яктылык тыгыз киерелгән болытлар арасыннан үтеп чыгарга тырышты-тырмашты. Таң җиле дала үләннәре өстеннән йөгереп узды да Чулпан йолдызны сүндерергә һәм җир астыннан кояшны тартып чыгарырга дип өскә күтәрелде. Шаян җилкәйгә ярдәмгә әтәчләр кушылды: алар да, кычкырып, кояшны чакырдылар, нишләптер ул гына ашыкмады. Үзбәк кояштан алда кузгалды, үзенең галәтләнгән җиләнен киде, атына сикереп атланды да Актүбә

[26] мишень.

ярына таба юыртты. Соңгы тапкыр тау елгасында коенуына ун көн узган, бөркү төннән соң аны салкынлык тартты. Ул суга керде, әмма ул иртәнге һавадан да җылырак булып чыкты, бераз абалангач, ярга күтәрелде һәм шунда гына коенуның ләззәтен тойды. Су өстеннән сыек томан күтәрелә. Үзбәктән ерак түгел ике малай кармаклы ятьмә өстери, һәр кармакта берәр зур балык тыпырчына иде. Даладан килгән кипкән әрем, янган учак исе аны тәмам исертте. Хан үлән өстенә ятып, төн буена җылылыгын саклаган җиргә сыенды. Аның күнелен нечкә хисләр урап алды: «Менә ул — минем җирем, менә ул — минем далам, елгам, йортым һәм янәшәмдә анам. Ничек кысып кочасы килә анамны!»

Үзбәкнең колагында балачактагы бишек җыры, анасы җыры чыңлады.

Кояш офык артыннан күтәрелеп, кыздыра башлаганда, Үзбәк бар көченә чапкан җайдакны күреп алды. Котлыгъ Тимер, атын тыеп, сикереп төште:

— Син авырмыйсыңмы, туганым? Аллаһ сакласын үзеңне!

— Син нәрсә турында, кайгыртучан туганым? Бөек һәм мәрхәмәтле Аллаһ сине калдырмас! Төнлә бөркү булды, менә елга янында ял итәм.

— Арибах илчеләре эзли чыккан сине, ханым. Ул үзеңне ак юртасында, кизләү янындагы салкынча сызада[27] көтә.

— Озатасыңмы? — Үзбәк сөенде.

— Әгәр теләсәң, һәрвакыт һәм һәркайда ияреп йөрермен, ханым.

Ир туганнар сикереп атларына менделәр дә далага чабып киттеләр.

Текә тар сызаның икенче башын вак яфраклы карама һәм куаклар баскан, аларның ботаклары арасыннан кечерәк кенә инеш агып чыга да салкынча суы ярымбуш далага китеп югала. Ә киңәеп киткән бу башы, һәрдаим дала тигезлеге белән кушыла барып сөзәкләнгән. Җайдаклар ак юрта янына килеп туктадылар.

Арибах улын ишек янында каршылады, шатланып кочты, аналарча якын итеп үпте һәм Котлыгъ Тимергә борылды.

— Энем, хезмәтчеләрне берәр эшкә кушчы, безнең сөйләшү алар колагы өчен түгел.

Алар юртага үттеләр. Анасының яңагыннан шатлык яшьләре коелды, улының да күзе дымланды, йөрәкләре исә бергә кушылып типте, күңелләре парлап бәйрәм җырын көйләде. Үзбәк тезенә чүгеп анасының кулын үпте һәм ана җылы ярату сүзләре әйтте.

— Син, мөгаен, иртәдән валчык капмагансыңдыр? — дип кабалана башлады анасы.

Үзбәк башын какты. Арибах улын мендәрләр арасына иплäп утыртты да ризыкны аның алдынарак этте һәм баласын үзе сыйларга тотынды.

— Анам, җитте, анам, күп булды! — дип үтенде Үзбәк. — Гуҗ буласым килми, мина зифа, сыгылмалы, җитез булырга кирәк. Үзең беләсең, алда күп эшләр тора.

— Ашыйсың килмәсә — ял ит, эшләр турында соңрак сөйләшербез.

Арибах улының башын тезенә салды һәм бала чагындагы кебек сыйпап, чиркәс бишек җырын көйләде. Яшь ханның күңелендә әйтеп аңлата алмаслык бәхет тулып ашты, тәне йомшарды һәм ул йокымсырап китте. Анасы эченнән генә догалар укып, кымшанмый улына карап утырды.

Үзбәк ничек тиз йоклап китсә, шулай тиз уянды да. Җинелчә җил, юртаның күтәртелеп куйган киезе астыннан үтеп, һаваны сафландыра, кизләү суының чылтеравe күңелен күтәрә иде. Хан җайлабрак утырды да анасына карады.

— Ә хәзер безнең алдагы тормыш турында сөйләшик, улым. Сине юк итүләреннән куркып, бабаң янына җибәргәндә, Аллаһка синнән хан ясарга,

[27] Коры елга.

исем өчен генә түгел, хан итеп билгеләнүең өчен тырышырга ант иттем. Гомеремне туган йортына кайтарту максаты белән Туктайны көйләп үткәрдем, хыялым тормышка ашты. Син хан алдында үзеңне белемле ир-егет, кыю сугышчы, телләр һәм фәннәр белүче укымышлы буларак, гомумән бар яктан килгәнлегеңне күрсәттең, һәм шуның белән аның янәшәсендәгеләрдә көнчелек хисе уяттың. Тагын да яманрагы, Туктай сиңа варисларның берсе дип игълан иткәндә, ачудан кечкенә Илбасарның күзеннән очкыннар чәчрәде. Ай-һай, күз алдыма китерәм, малайга аның яклылар, тәрбиячеләр ниләр генә әйтеп бетермәгәннәрдер, алар бит, атаңның үлеменә төп сәбәпче мәкерле Нугай кебек, гомерләренең соңгы көннәренә кадәр аның янында булып, аның белән идарә итәргә маташучылар. Очрашу шатлыгыбызга менә шул нәрсә күләгә төшерә. Аңладыңмы, улым? Безгә Туктай исән вакытта синең тәхеткә ничек хезмәт итәчәгең хакында уйларга кирәк. Аннан соң син, бары тик син генә Урданың ханы булырга тиешсең.

Үзбәк дәшмәде, ул моны күз алдына китерә иде, әмма шулай тиз буласын уйламады.

— Синең берәр тәкъдимең бармы, анам?

— Әйе, улым, әмма бу минем өчен бик авыр юл, кабат синең белән аерылырга туры киләчәк. Әгәр риза булсаң, Туктайдан сиңа берәр ерак Олыс белән идарә итәргә җибәрүен сорармын. Син Сарайда һәм күчмә тукталышларда елына өч-дүрт тапкыр була алачаксың һәм без күрешербез. Никадәр еракта булсаң, үзең өчен шулкадәр тыныч булыр. Еракта хәбәрләр сирәк килә. Әгәр сиңа кирәкле хәбәрләр, өстәвенә кыйммәтле бүләкләр белән килсә, югарыда булачаксың, улым. Иң кирәкле вакытта ым кагармын, менә шунда бар да тизлегеннән, зирәклегеннән торачак. Әгәр без уйлаганча барып чыкса, бөтен кешегә яхшы булачак.

— Бөтен кешегә — кемгә ул?

— Улым, кан кардәшләреннән һәм безгә чын күңелдән бирелгән туган-тумачалардан тыш минем сердәшем, якын дустым, Туктайның өлкән хатыны Баялун-хатун да безнең белән. Тиздән ул монда киләчәк.

— Анам, кадерлем, минем синнән аерыласым килми, тик мин барысын да аңлыйм һәм шулай ук тәшвиш-шом сиздем. Төн бөркүлеге генә йокларга комачауламады. Мин китәргә әзер, газизем, кешеләр белән әйтеп торучыларсыз идарә итәргә, хәрби башлык белемен үзләштерергә, Коръән һәм фәннәрне белүне камилләштерергә кирәклеген төшенәм. Мине Хәрәзмгә җибәрергә Туктайны үгетли алырсыңмы? Күптәннән күренекле шагыйрьләр һәм фәлсәфәчеләр иленда булырга хыялланам.

— Тиз аңлавыңа куанам, улым. Туктайны күндерә алырмын дип уйлыйм. Бар да яхшы булыр. Әмма, улым, кая гына барсаң да үзең белән Котлыгъ Тимерне алырга кинәш итәм, сез кан буенча туганнар гына түгел, фикер йөртүләрегез дә уртак. Туганың күзең һәм колагың булса, үзең баш белән уйларсың.

Икесе дә сүзсез торганда, юртага озын зифа буйлы, байларча киенгән, бизәнгечләр таккан хатын килеп керде. Аның борынгы юнан, ассирия һәм әрмән каны катышкан ханбикәләрчә горур йөзе балкып тора.

— Комачау итмәдемме? — илле тирәсендәге чибәр хатын, җавап көтмәстән, Үзбәккә, үптерер өчен, кулын сузды. Ул үпте һәм Баялунга урын тәкъдим итте. Хатын кулы белән таянмыйча җинел генә миндәрләр арасына урнашты.

— Нигә тынып калдык?

— Барысы да диярлек әйтелде, — дип җавап кайтарды Арибах.

Баялун-хатун шаркылдап көлде:

— Ана белән ул арасында барын да әйтеп бетереп буламы соң! Үлгәннән

сон да әйтеп бетермәгәннәр кала. Дустым, әз генә архи[28] салчы, эчеп куярга кымыз да бир. Ә син, Үзбәк, безнен архины тәмләп карыйсың килмиме?

Яшь хан каршы килеп, башын селкеде.

— Әйе бит әле, Аллаһ сезне исерткеч эчүдән тыя. Безнең Гайса пәйгамбәр бу әйбергә гадирәк карый, шулай да чама белмәгәннәргә җәза биреп куя.

Туктайның өлкән хатыны аракы салынган касәне яртылаш бушатты, аның бит очлары кызарып чыкты.

— Улына барысын да әйттеңме, Арибах?

— Әйе, апам. Үзбәк Хәрәзмгә китәргә әзер.

— Ә син ник авызына су капкандай утырасың?

— Мин ике бөек ханбикә сөйләшкәндә кысыла алмыйм.

— Без сиңа рөхсәт итәбез, булачак ханыбыз, — Баялун көлде. — Яхшы, шаяртуны куйыйк. Синең көчле, житез, зирәк булып үсүеңә куанам, Үзбәк. Гомеремнең калган көннәрен Туктайдан үч алуга багышлыйм, ул минем улларымның — Алтын Урда һәм Византия тәхетләре варисларының жанын кыйды. Мин бик озак Аллаһка гыйбадәт кылдым, аннан ник үчемне кабул итмисең дип сорадым, тик ул файда өчен жан кыюны да кабул кылмый. Үзенең бер дини канунында Гайса: «Үтермә!»— дип әйтә. Мин дә, анаң да үтерү турында карар кыла алмыйбыз. Шуңа ниндидер бәхетсезлек очрагы килеп чыкса, аннан соң ханыбыз һәм безне саклаучыбыз син булсаң, без бик шат булыр идек. Шулай итеп, уйла, зирәк ханыбыз!

Жинелчә жил дала ягыннан кипкән үлән исләре алып килде, һәм авыр сөйләшүдән басылган күңелне тынычландырып жибәрде. Анасы хакына Үзбәк бар нәрсәгә әзер иде. Ул, һичшиксез, нидер уйлар, һәм ул, һичшиксез, Алтын Урда ханы булыр.

***

Туктай эссе кулдан карар чыгарырга яратмады. Әле уйлаганнан соң да ашыкмады — вакыт нәрсәнедер үзгәртер яисә әйтеп жибәрер дигән фикердә булды. Ул берничә тапкыр тирә-юнендәгеләрнең Үзбәкне ераккарак жибәрергә, серләрен белү өчен үз кешеләрен куярга дигәнне тыңлады. «Ә нәрсә төпченергә? — дип уйлады Туктай. — Кемнең хан буласы килми? Үзбәк тә тели, әмма ана тәхеткә ерак. Үземә утыз тулмаган, аннары яна варислар үсеп өлгерә, бар, яшьләр белән көндәшлек итеп кара. Шулай да аны күз уңыннан ычкындырырга ярамый.»

Хан күзәткәләсә дә, шикләнерлек нәрсә тапмады. Ачык күңелле, хөрмәткә лаек егет белем буенча теләсә кемнең авызын томалый ала, шәп сугышуын әйтеп торасы да юк. Барыбер Туктай кардәшләре һәм якын түрәләренә Үзбәкне ешрак кунакка чакырырга, аны ачы бал һәм аракы белән сыйларга, бүләкләр бирергә, күңеленә вәсвәсә салучы әнгәмәләр корырга боерды. Яшь хан һәрвакыт уяу торды, кымыздан башканы эчмәде, агасы турында гел яхшы яктан гына сөйләде, бүләкләрне теләп кабул итте һәм үзе дә бүләкләр бирде. Аны берничә яна хатын белән бәйләргә теләделәр, әмма ул шома гына котыла алды.

— Мин акыллы һәм барын да күрүче агамның бирәр Олыс биргәнен көтәм, ә бүгенге көндә икедән артык хатынны асрый алмыйм. Аллаһыбыз, бөек һәм зирәк Тәгаләбез, хатыннарны хаерчелектә, сагыш-хәсрәттә тотарга кушмый.

Каршы килеп булмый, бу очракта яшь хан хаклы. Үзбәккә хөрмәт көннән-көн арта барды. Ялгыш дип санаган очракта кыерсытылганнарны яклаудан курыкмады, һәм шуның белән күпләрне үз ягына аударды. Мөселманнар Үзбәк өчен жаннарын да жәлләмәделәр, ул алар белән бергә намаз укыды, ашау-эчүдән тыелып торды һәм бәйрәмнәрдә юмарт кыланды. Бер сүз белән әйткәндә, Мөхәммәд Пәйгамбәр (ана Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) кушканча

[28] Сөт аракысы.

яшәде. Бары Илбасарның кардәш-туганнары гына кинәттән генә пәйда булган варисны өнәмәделәр. Аларга Үзбәкнең көннән-көн үсә барган дан-шөһрәте һич ошамады. Шулай ук бар җирдә кысылып йөрүче астыртын, туганының болытлы көндә дә күләгәсенә әверелгән Котлыгъ Тимер дә кәефләренә ярамады.

Туктайга энесе турында берәү дә яман сүз әйтә алмады, ул хәтта бу акыллы яшь кешене, карт бабасын ялга җибәреп, аның урынына бәкләр бәге итәргәме, дигән уйларга да килгәләде. Бервакыт хан бу фикерен Арибахка да җиткерде.

— Иртә әле, падишаһым, иртә! Улым бик яшь, беркатлы, ялганнан дөресне аера алмый, — дип каршы төште сөекле хатыны.

Ике көн дә үтмәде, таләпчән Баялун кырыс кына сорап куйды:

— Син нәрсә, ханым, бу малайны үз янында озак тотаргамы исәбең. Инде бар Сарай, якын-тирәдәге күчмәләр ана соклана. Бөтен Урданың хәйран калуын телисеңме? Ераккарак җибәр аны, әнә, Хәрәзмгә ку.

— Үзбәк турында әйтәсеңме? Ник бик ачулысың ана?

— Бу илтифатсыз яшь кеше үги анасына игътибар да итмәде! Бер бүләк бирмәде, күңелем сизә — бирмәячәк тә, алама малай.

Баялун уйный белә иде, менә аны балачакта, сарай театрында өйрәттеләр.

Озакламый Үзбәк үзе дә агасыннан кабул итүен үтенде:

— Әй бөек ханым, миңа Актүбә буйлап өскә күченергә рөхсәт итче, утрак тормыш, туганнар корган мәҗлесләр ялыктыра башлады. Яшермим, изге Богдо тавын да күрү теләгем бар, бабабыз Бәркә ханның яраткан урынында, Урдада беренче мәчетне салган җирендә буласым килә.

— Әйбәт уйлагансың, кайчакларда урыңда утырып чыдар хәл калмый, әмма хакимлек вазифалары авыр йөк кебек — үзеннән җибәрми. Бар, йөр, салкында уйларыңны тәртипкә сал, язын исә Хәрәзмгә кадәр юл тотарсың. Анда Олыс белән идарә итәрсең. Кайткач, тәфсилләбрәк сөйләшербез.

Туктай белән Үзбәк төрле темага гәп куерттылар. Агасы энесен анасы белән ешрак күрешергә үгетләде, аның улын бик яратуы, сагынуы турында әйтте, аңа карата ягымлы һәм рәхмәтле булуын теләде.

Далада кыш хакимлек итә, ул кар өермәләрен уйнатып, озын чокырларны, уйсу җирләрне кар белән күмә иде. Төньяк җиле битне чеметте, рәхимсез рәвештә тәнгә үтеп керергә маташты, әмма монголларның ата-бабалары акыллы булган: алар яннан төймәләнә торган халатлар уйлап чыгарганнар. Түзем, бар нәрсәгә күндәм тәбәнәк монгол атлары үҗәтләнеп, пошкыра-пошкыра алга таба бардылар да бардылар. Көнгә унбиш чакрымнан артык юл үттеләр.

Ике көн үткәч, Котлыгъ Тимер Үзбәк янына килде:

— Озатып йөрүчеләр сиңа су буйлап барырга тәкъдим итәргә куркалар, елга борыла, шуңа юл озыная төшә. Аның каравы бозга кар аз яткан, шуңа тизлек артачак. Мондый суыкта боз ышанычлы.

Иртән атларны бозга ярашлы итеп кабат дагаладылар һәм елгага төштеләр. Актүбәдә җил бераз тынды, кыска аяклы монгол атлары, танауларыннан кайнар бу чыгарып, җәһәтрәк атладылар.

Боз буенча берничә көнгә сузылган сәяхәт Үзбәкне тизлеге белән сөендерде, атларга җиңеллек китереп, чаналар үзләреннән-үзләре шугандай барды. Боз астына китүдән куркасы юк: хезмәтчеләрнең төнгә ятьмә салу өчен боз чабуларын күрде, катлам терсәктән биегрәк иде.

Бәркә чокырына килеп җиткәндә, караңгы төште. Хан өчен юрта әзер, уртада учак яна, казаннан чыккан бәрән итенең тәмле исе үзенә тарта иде. Үзбәк салагы белән бил каешын да салырга өлгермәде, урындагы Тули бәкнең юртага кертүен үтенгән хәбәрен җиткерделәр.

Тули җылы сәфәр торагына үрмәләп диярлек керде һәм башын идәнгә орып:

— Әй ханнардан ин күренекле ханның кодрәтле варисы! Әй курку белмәс сугышчы Үзбәк-хан, башымны чап минем, чап тизрәк. Сине иртәгә генә көткән андый карт һәм тиле башның кирәге юк. Сарай-Бәркәгә кергәндә, синең аягыңа орынырга насыйп булмады, — дип тәкърарларга кереште.

— Аягына бас һәм такылдавыннан тукта, — дип боерды Үзбәк.

— Басмыйм. Башымны чап яисә бүләкләремне кабул кыл.

— Үзең әйткәнчә, синең исәр башыңнан ни файда, бүләкләрең кайда?

Тулиның хезмәтчеләре көмеш, кыйммәтле кытай ефәге, балчыктан ясалган савыт-сабалар белән тулы подносларны кертте. Үзбәк авыл хакименә торырга кушты һәм табын янына чакырды.

— Син нәрсә, син нәрсә, ханым! Кунак хужаны сыйлый димени? Хатыннарым бик житезләр, Бәркә ханга, әй мәрхәмәтлем, осталар салып биргән жылы өйдә өстәл әзерләделәр инде.

Агач өйдә, чыннан да, жылы иде. Ярты гасыр узуга карамастан, яхшы сакланган. Ин зур бүлмәдә урынның өчтән бер өлешен алагаем зур ак мич алып тора. Аннан рәхәт жылы бөркелә, тәрәзә янындагы зур өстәлгә эчемлек һәм кабымлыклар куелган.

— Елбаздук бабадагы кебек диярлек, — диде Котлыгъ Тимер һәм, күнеле күтәрелеп, Үзбәкне кичке ашка чакырды.

Агач савытларга балдан коелган тәмле эчемлек агыздылар. Мичтә пешкән жылы ипи зур-зур кисәкләргә турап куелган. Кайнар ит белән тәмле әчетелгән кәбестә юлчыларның ашыйсы килү теләген тагын да арттырды. Бераздан жылылык һәм ачы бал үзенекен итте, барысын да йокыга тартты.

Салкын иртә. Офыкта шәфәкъ алсулыгы. Кинәт тынлыкны бүлеп, мөәзиннең иртәнге намазга чакырган азан тавышы яңгырады. Үзбәк атына атланып мәчеткә ашыкты. Агачтан салынган мәчет манарасының алтынланган гөмбәзе, күккә ашкан һилал ай белән төрле төстәге күпләгән юрталар арасында балкып утыра. Үзбәк, аяк киемен ишек төбендә калдырып, мәчетнең намаз укый торган иркен жылы залына керде, анда йөзләгән ир-ат, Аллаһы Тәгалә белән әңгәмәгә керү өчен, намазга әзерләнә иде. Иртәнге намаз ислам таләпләренә туры китереп укылды, чөнки Мөхәммәд Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) болай дип өйрәтте: мин намазны ничек кылам, сез дә шулай кылыгыз.

Үзбәк канәгать калды. Аның ыруы торган саен күбрәк исламга тартыла, әй Аллаһ, дан сиңа! Яшь ханның күңеле жырлады, ул үзенең ата-бабаларына һәм дин кардәше Бәркә ханга мактау сүзләре күндерде. Бу — аның мәчете һәм карт бабасы да шушында намаз кылган!

Хан артында кемнеңдер карашын сизеп, борылды һәм олылап баш иеп торган мондагы мулланы күрде.

— Безнең мәчеткә шундый олуг кунак китергәне өчен мәрхәмәтле һәм кодрәтле Аллаһка дан! Әй Үзбәк хан, Аллаһ бакчаларында йөрүче һәм аның чишмәләренең изге суларын эчүче Бәркә ханга мәңгелек хөрмәт булсын.

Үзбәк мулла белән ихтирам күрсәтеп исәнләште. Алар озак кына исламның әһәмияте, кешеләрне саклап калу өчен кирәклеге, аның кешене чистарак, шәфкатьлерәк итә алу сәләтенә ия булуы турында сөйләштеләр. Мәчеттән чыккач, хан, Аллаһны хөрмәтләп, болай диде:

— Иманыбызның изге чыганагын саклаучы, сабыр ит, килер вакыт, монда бер генә мәчет тормас, аларның манаралары Бөек Аллаһы Тәгалә һәм Мөхәммәд Пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) хөрмәтенә күккә ашар.

Үзбәк озатып йөрүчеләре белән Сарай-Бәркәдә егерме көнләп яшәде, шул арада тирә-якны карап чыкты, Актүбә белән Итил арасындагы урынны өйрәнеп, бабасының урын сайлауда үткен акыллы булуына тагын бер кат инанды. Билгеле, моны Мәккәгә яисә Мәдинәгә хаж кылу белән чагыштырып булмый,

әмма бу Алтын Урдада исламның беренче адымнары башланган изге урынга барып баш ию иде. Монда Үзбәк иркен сулады, рәхәтләнеп намазларын укыды, ул Аллаһ аларны ишеткәндер дип ышанды һәм ана монда — Итилнең түбәнге агымында ислам терәге булган шәһәр төзергә кушкандыр.

Яшь хан 1261 елда кенәз Александр Невский тарафыннан нигез салынган чиркәүдә дә булды. Бәркә ханның рөхсәт язуы буенча, гыйбадәтханәнең зиннәтле җиһазын карады, руханилар белән әңгәмә корды, аларның тәкъвалыгына һәм игелекле теләкләренә иманды, күп кешенең монда гыйбадәт кылганын күреп, православиегә ышану йөрәкләрендә ныклы урын алган дигән фикергә килде. Ирексездән үзенең мәңге онытылмас укытучысы Самир Озан Ибн Хөсәен Шәкәви белән, Аллаһ кешеләргә, һәркем үз йөрәге кушканын сайлап алсын, дип юкка гына берничә динне җибәрмәгән, дип сөйләшүләрен исенә төшерде.

Үзбәк үзенә, тәхеткә утыргач, Урдада ике генә дин — ислам һәм православиене генә калдырырга сүз бирде, һәм алар һәр икесе дәүләткә терәк булырлар! Варис янә Бәркә ханның үткен акыллы булуына хөрмәт белдерде.

Язгы кояш нурларыннан кар күзгә күренеп кимеде. Эрегән кар сулары чокырларга, уйсу җирләргә юл тотты. Җил исә үз эшен эшли, даланы киптерә. Вакыт! Хәрәзмгә җыенырга вакыт!

Үзбәк һәм Котлыгъ Тимер мең ярым сугышчы чолганышында Итил аша кичтеләр һәм бүленделәр. Яшь ханның йөзлеге таныш юл буйлап чиркәс тауларына юнәлде, аның дусты һәм туганы көньякка — Нугай даласы килеп терәлгән Каспий диңгезенә карап юл тотты. Котлыгъ Тимернең бурычы гади дә, шул ук вакытта катлаулы да: зуррак кораб яллап, Кара-Бугаз-Гол култыгы ярына чыгарга, аннары Үзбәк һәм аның гаиләсен алып килергә һәм сәяхәтне кабат дәвам итәргә кирәк иде. Беркайчан да корабларда су буйлап йөргәне булмаган Котлыгъ Тимер башта дулкынланды, әмма яналык кызыксынучан, бер урында таптанырга яратмаган егетне бик тиз үзенә тартып, куркуын таратты.

Үзбәк ашыкты. Аның тизрәк үзенекеләр янында буласы, Елбаздук бабасын, әбисен кочагына аласы, Ләйләнең татлы иреннәреннән орынуын тоясы, Тайтуглыны күрәсе килеп, күңеле ашкынды. Хан аны хатынлыкка алырга карар кылды. Төшләрендә бу кызый аның янына еш килә, ымлап чакыра, ниндидер алсу төскә төренгән ераклыкка алып килә дә үзе каядыр китеп югала иде. Уянгач, Үзбәкне сагыш баса, төшне кабат күрәсе, иң яхшысы — өнендә кочып аласы килә.

Биш түбәле тау артта калды. Тауларда ханны дуслары каршы алды һәм күңелле итеп кенәз ишеге төбенә озатты. Өйдә Үзбәкне көтәләр иде. Туганнары белән күрешеп, ул алар арасында Ләйләнең юклыгын абайламады, ә инде хатынын күрмәгәч, борчуга төште. Әмма барын да сизеп торган Гайшә әбисе аны тынычландырды:

— Хатыныңның тулгагы башланды, бар, кайтуың белән сөендер үзен.

Үзбәк хатын-кызлар ягына атлап түгел, очып диярлек керде. Ләйләнең күзеннән шатлык яшьләре тамды.

— Кичер мине, сөекле ирем, синең каршыңа чыга алмадым.

Шунда аны кабат тулгагы тотты. Ләйләнең бите кызарып чыкты, маңгае вак тир тамчылары белән капланды, ыңгырашты. Ире иелеп хатынын үпте һәм кемнеңдер йомшак кына итеп билбавыннан тартканын сизде. Кендек әбисе ирне йөзе белән ишеккә борды да җинелчә генә алга таба этәрде:

— Хатын-кыз эшенә комачаулама, хан, үз эшеңдә бул, озакламый белерсен.

Үзбәк юллан соң юынды һәм бабасы белән ишегалдындагы ташка утырдылар. Әмма сүз ялганмады. Ханның уйлары бәбиләп яткан хатыны тирәсендә әйләнде. Елбаздук оныгын борчымады, сугышчылар йок бушаталар, ә вакыт үтми дә үтми.

Тиздән кендек әбинең шат авазы яңгырады:

— Сөен, хан! Улың туды, таза, нык малай!

Алсу-кызгылт тәнле юеш баланы һавага алып чыктылар. Бабайсы канәгать елмайды, шат Тай-туглы сикергәләде, әбисе күз яшьләрен сөртте, хезмәтчеләр ыгы-зыгы килделәр. Бәхетле ата Елбаздуктан:

— Кенәзем, берничә сарык чалырга боер, Тимербәк туган хөрмәткә мәҗлес җыябыз, — дип үтенде. — Минем улым Тимербәк атлы булачак!

Әмер бирелүгә, бар да хәрәкәткә килде. Үзбәк кабат хатын-кызлар бүлмәсенә керде. Арган, әмма бәхетле Ләйлә ятакта ял итә иде.

— Син канәгатьме, хакимем?

Җавапны көтеп тормастан, ул кулын иренә сузды. Яшь хан аны әкрен генә сыйпады һәм назлы итеп хатынын үпте:

— Акыллым минем, кадерлем! Син барысын да булдырасың, мин бәхетле!

— Бик яхшы, сиңа бик тә бер малай табасым килгән иде. Син аңа исем бирдеңме инде?

— Әйе. Тимербәк булачак аның исеме!

Ләйлә янында мышнап яткан улын назлап сыйпады.

— Без Тимербәк белән ял итәбез, син Тай-туглы янына бар, ул акылыннан яза бугай инде. Ашык, аңа күптән хатын булырга вакыт, Аллаһ сакласын, гыйшкыннан янып үлүе бар.

— Синнән дә акыллырак хатын юк, кадерлем! Ял итегез.

Ләйлә күзен тутырып ире артыннан карап калды, күңелендә исә кабат көнчелек уты кабынды. Әмма янында яткан нәни кыйпылчыгының дөп-дөп типкән йөрәге күңелсез уйларны читкә куа иде.

Күрше-күлән тиз җыелды. Кенәзне оныкчык, Үзбәкне улы тууы белән котладылар. Мәҗлес шәп үтте, Елбаздукның саклясы өстендә шатлык дулкыннары йөзә, үзе исә горур иде.

Кич таулардан әкрен генә салкынча һава алып төште, кунаклар таралышты, йортта тынычлык урнашты. Үзбәк елга янына барып юынды, күңеле тулы шатлык, куаныч иде. Хан өстенә халатын капларга да өлгермәде, Тай-туглы селәүсен кебек аңа ташланды. Ирнең көчле кулы кызны эләктереп алды һәм өскә күтәрде, әйләндерде, аннары, сак кына төшереп, кочаклап бүлмәгә алып керде. Бу төндә Тай-туглы дәртле яратышуның ни икәнен белде һәм ханның хатыны булды. Ул иренә аның үлеменә кадәр дә, аннан соң да тугры булачак, ул бу дөнья хакименең зирәкләрдән зирәк һәм хөрмәтле хатыны буларак беренче адымын ясады.

Иртән Үзбәк атчабарларны Сарайга һәм Каспий ярына — Котлыгъ Тимергә җибәрде, ул дингезгә бер айдан да иртәрәк килә алмасын, улы һәм хатынына ныгырга кирәклеген әйтеп хәбәр салды. Елбаздук оныгына:

— Ханым, Сарайга ат чаптырып ашыкмадыңмы? Варисның улы тууы турындагы хәбәргә бар да шатланмаска мөмкин.

— Мин бу турыда уйладым, хөрмәтле аталык. Анамны оныгы тууы турында искәртми булдыра алмадым. Туктай белән ачыктан-ачык булырга кирәк, хыянәтче һәм астыртын дип шикләнмәсен. Улымны исә үзем сакларммын.

Вакыт сизелми дә үтте. Китәргә әзерләнделәр. Үзбәк тә бабасы кебек озын-озак хушлашуны яратмый иде. Кәрван Нугай далаларына карап юл тотты.

Котлыгъ Тимер Кара-Бугаз-Гол култыгына барып өлгереп, Үзбәкне каршыларга әйләнеп килде. Шулай итеп, алты көне юлда узды. Ханның ышанычлы дусты һәм туганы, коры җирне күрергә теләп, офыктан күзен алмады, тирә-якта әз генә дулкынланып торган су, кояш та күккә сибелгән йолдызлар һәм ай гына иде. Кораб алга барамы-юкмы икәнен дә тәгаен генә әйтеп булмады. Бары салкынча җил һәм нык итеп тарттырылган җилкәнгә карап кына хәрәкәт иткәннәрен чамалады. Җирдә барыбер катылык тоясың.

Озак көтәргә туры килмәде, туганнар шатланып кочаклаштылар, сәяхәтне кичектермәскә булдылар, корабка вак-төяк мөлкәтне, кешеләрне, атларны төйи башладылар. Ишкәкчеләр ишкәкләрен суга батырдылар, матрослар җилкәнне көйләделәр һәм җилдә киерелгән җилкән корабны көньяк-көнчыгышка таба кузгатты.

Иртәгесен Үзбәк җилкәннәрнең салынып төшкәнен күрде.

— Җил юкмы? — дип сорады ул капитаннан.

— Әйе, ханым.Тынлык! Начар ырым! — капитан баш артын кашыды.

Көндезге намаздан соң, җил чыгып, җилкәннәр әкренләп киерелде. Озакламый тагын да көчәеп, тыныч кына яткан дулкыннарны уятты һәм алар, күбекләнеп, өскә күтәрелделәр. Кояш түбәнәйде, көн кичкә авышты. Капитан җилкәннәрне җыярга боерды. Ишкәкчеләр ишкәккә утырды, кораб бер дулкыннан икенчесенә сикерде, бер яктан икенче якка чайкалды.

Хатын-кызларның күзендә курку чагылды, сугышчылар да тынып калды. Алар өмет белән башлыкларына карады. Тегеләре исә сер бирмәскә тырышты, сеңерләре тартышса да сер бирмәделәр.

Дөм караңгы, диңгез өстенә кара, усал төн канатларын җәйде, диңгез дулады-үкерде, корабны як-якка чөйде, юлчылар үзләрен тәмугка эләккән кебек тойдылар. Үзбәк үз-үзен кулда тотарга тырышты, иманлыларның барысын да догага чакырды, үзе мулла урынын алып, курку догасы — Хәвефне кычкырып укыды. Тай-туглы сиздерми генә корабның борынына килеп басты һәм кулын күккә сузып, Ходайдан Ләйлә белән аның кечкенәләрен булса да саклавын үтенде.

Ләкин капитан рульне кулында нык тотты, ара-тирә бар көчләренә ишкәкләре белән суны кыйнаган ишкәкчеләргә, матросларга кычкырып алды. Төн уртасы җиткәндә, капитан Үзбәктән ишкәкчеләрне ял иттерер өчен сугышчыларның чиратлап аларны алмаштыруларын сорады. Кораб иртәнгә кадәр котырган дулкыннарга каршы торды. Ниһаять, давыл әкренләп тынды, капитан җилкәнне тарттырырга боерды һәм Үзбәккә, дулкын аларны аллан билгеләнгән юлдан читкә алып китүе, югалтканны торгызу өчен ярты көн кирәк булачагын белдерде.

Бары бер көн узгач кына, алар Кара-Бугаз-Голны диңгез белән тоташтыручы тар бугазга килеп җиттеләр. Көчле агым корабны зур тизлек белән бугазга алып керде һәм дүрт чакрымнар тирәсе алга таба куды, аннары су әкренләп күтәрелде һәм җилкәнгә генә түгел, ишкәкчеләргә дә бик нык тирләргә туры килде.

Нинди бәхет! Кичке шәфәкъ алсуында бугазның аксыл ярлары күренде, һәм дала ягы кешеләренең күнелләре бермә-бер күтәрелде. Кораб борыны белән йомшак комны кисеп керде, ярда юлчыларны күптәннән көткәннәр, шатланып каршы алдылар. Хуҗаларны алдан әзерләнгән юрталарга ял итәргә озаттылар.

Ләйлә диңгезнең чайкалуын бик авыр кичерде, күңеле болганды, башы әйләнде, йөзе киндер кебек агарды, ул дерелдәп торган аяклары белән җиргә басарга курыкты. Тай-туглы, хезмәтчеләр, бала караучылар — барысы да, булышырга теләп, Үзбәкнең өлкән хатыны тирәсендә бөтерелде. Курку, кот очулар артта калды, каты сахра җире үзенең ярлы гына үсемлекләреннән килгән исләр белән кешеләрне сөендерде. Ләйлә әкренләп үз хәленә кайтты, нәни Тимербәкнең генә дөньяда гаме юк, ул тәрбиячесенең кулында мышнап ята бирде.

Гадәти булмаган сәяхәттән арган, талчыккан юлчылар шунда ук йокыга талды.

***

Көнчыгыштан таң туып килә иде. Үргәнчкә кул сузымы ара калды.

— Үргәнеч, Үргәнеч, сиңа ничә яшь? — дип уйлады Үзбәк. — Кытай мәктүпләрендә искә алуларына караганда, сиңа инде бик күп еллар. Ә

Кырыкмулла ныгытмасы? Аны төзегән вакытта византийларның ата-бабалары Олимп аллалары белән аралашкан, дигәннәр иде. Укымышлы затлар монда ниләр генә тудырмаган! Бу җиргә алып килүең, камиллеккә ирешергә мөмкинлек биргүең, күп сандагы кешеләр белән идарә итәргә әзерләвең өчен рәхмәт сиңа, бөек һәм мәрхәмәтле Аллаһ!

Үзбәк Котлыгъ Тимер белән бергә аның бертуганнары Сарай-Тимер һәм Мөхәммәд-хуҗаны да алып килде. Монда кеше сүзенә колак салып йөрергә, икеләнеп караучыларның шикләрен таратырга кирәк иде. Ләкин Хәрәзм аксөякләре арасында зур хөрмәт казанган шәех — Имад әд Дин әл Мәскари белән еш аралашуы һәм әкренләп аңа якынаюы яшь ханның абруен күтәрүгә, хакимлеген ныгытуга китерде.

Үзбәк беренче көннәрдән үк эшенә чын-чынлап тотынды, вазифаларны бүлде: Котлыгъ Тимер яудан соң җимерек хәлгә килгән Хәрәзм шәһәрләрен торгызырга тиеш булды, Сарай-Тимергә Олыс гаскәре белән җитәкчелекне тапшырды һәм аларны кирәк-ярак белән тәэмин итәргә кушты. Үзенә, Олыс бәгенә, гомуми җитәкчелектән тыш, сәүдә, мәдәният, фән, бигрәк тә суфыйлык үсешен торгызудагы кыенлыкларны чишәргә кирәк иде. Мөхәммәд хаҗи чираттагы тапкыр Мәккә белән Мәдинәгә хаҗ кылырга уйлады, аңа өстәмә йөкләмә итеп, онытылмас укытучы Самир Озан Ибн Хөсәен Шәкәвины эзләп табарга кушылды.

Бик яхшы хәтергә ия Олысның яшь хуҗасы бар нәрсәне исендә тотты. Аның үткен күзеннән бер нәрсә дә качып кала алмады. Аннан тыш, кызыксынучан, күп белергә тырышучан акыл иясе буларак, Олысның көнкүрешен яхшырткан шактый гамәлләр кылды. Иң беренче чиратта Котлыгъ Тимергә Үргәнеч белән Хивада кәрван-сарайларны торгызырга боерды, кәрваннардан ясакларны киметте, кәрван юлларында сакны көчәйтте һәм юлбасар өерләрен рәхимсез рәвештә тар-мар итте. Туктай хан ризалыгы белән Хәрәзмгә төзүчеләр, сугару белгечләре, кирпеч яндыру һәм балчыктан бизәкләр ясаучылар яллау өчен монголларның Юань[29] империясе башкаласына илчеләр юллады. Монгол империясенең Бөек ханы Тимергә, аның зирәклеген мактап, дөньяның хакимнәре арасында зур урында торуын әйтеп, мәңге аңа бәйле булырга ант итеп язылган хаты белән бергә бик күп бүләкләр җибәрде. Илчеләр җавапка бүләкләр һәм күп сандагы осталар белән әйләнеп кайтты.

Котлыгъ Тимер үзенә хас зур көч-куәт белән төзелеш эшен җәелдереп җибәрде. Моннан йөз ел элек Хәрәзм шаһы Манун тарафыннан нигезе салынган мәчет манарасы күккә үрләде. Тиз арада тагын берничә мәчет күтәрелде, «Кубра» суфый мәзһәбен оештыручы Нәҗметдин Кубра корылмасын гаҗәеп матур итеп бизәде. Үргәнеч тирәли Амударья мул суы белән сугарылган бакчалар шау чәчәккә күмелде, кырларда башаклар чайкалды. Шәһәргә берсе артыннан берсе исәпсез-сансыз кәрваннар тартылды, халык җанланды, байлык тулы базарда кайнашты, осталарның чүкеч тавышлары катырак ишетелде, Олыс казнасына, шул исәптән Туктай ханны да баетып, акча агылды.

Сарайга килеп чыккан кәрванчылар Хәрәзмнең яшь хакименең зирәклеге һәм киң күнеллелеге, юмартлыгы турында сөйләделәр. Туктай энесе хакындагы мактау сүзләрен канәгатьлек белән тыңлады һәм бу нәселне булганга санап, сөеклесе Арибахның кардәш-туганнарын үзенә якынайтты. Айдарбәк Алтын Урда ханының шәхси сак башлыгы итеп билгеләнде, һәм тегесе аяз көндәге күләгә кебек аның артыннан бер адым калмады. Матурдан-матур мәчетләр төзелгәнен ишетеп, диндәгеләр бик куандылар. Бары Илбасар яклылар гына тагын да берләшә төштеләр — аларга көчле, данлы көндәшләр кирәк түгел иде.

[29] Монголия һәм Кытайда империя династиясе.

Амударья суы кебек, вакыт та гөрләп акты. Үзбәк анын узганын бөтенләй сизмәде. Көненен беренче яртысы төзелештәге эшләрне барлап үтте яисә икътисадка багышланды, икенчесе исә — гыйлем, сәнгать һәм дингә. Олыс хакиме исламны шулкадәр тирәнтен өйрәнде, хәтта белеме белән суфыйчылык юлына басарга әзер иде, тик ул очракта ул хакимияттән китәргә тиеш иде, чөнки суфый фәкыйрьлек һәм тәкъвалыкны вәгазьләргә, бу дөньяны хыялда дип кабул итәргә, бары Аллаһ иркенә генә таянырга тиеш. Кичләрен еш кына Имад әд Дин әл Мәскири шәех белән әңгәмә корулар Үзбәкне үзен суфыйчылыкка багышларга дигән уеннан кире кайтарды.

— Кем ул суфый? — шәех Олыс бәген өйрәтте. — Ул — мөселман диненен бар кануннарын тел-теш тидермәслек итеп үтәү. Ләкин син бар нәрсәдән ваз кичеп, мөрит булырга әзер микән? Юктыр, дип уйлыйм. Бөек һәм кодрәтле Аллаһ сина икенче юл билгеләгән: син олы бер дәүләтнен тәхет варисы. Ә мөрит булсаң, Аллаһны акылын белән түгел, йөрәген белән аңларсынмы? Юк! Матди як жанынны газаплар, гаиләң, патшалык турында кайгырту Аллаһны аңларга, жанынны яманнан чистарту юлына басарга, мактаулы сыйфатлар күңеленне аңар ялгарга ирек бирмәс — суфыйлыкның асылы менә шулардан тора.

— Ә син, зирәк шәехем, гыйсави дәрвишләрен үз диннәренен суфыйлары дип санамыйсынмы? — дип сорады Үзбәк.

— Бу бик якын. Алар ыгы-зыгылы тормышны онытып, тәкъва булалар, үз тәннәре өчен азга гына риза булып, Ходайга якынаер өчен жаннарын бушаталар. Тик бар да файдасызга, аларның тәгълиматы искерде. Аллаһтан башка алла юк!

— Бөек укымышлы зат, ә син неоплатонизм суфыйчылыктан чыккан тәгълимат дип уйлаганыгыз юкмы? Бу бөек Платон эшен дәвам итүче даһиларнын тәгълиматы, шулай ук тәнне һәм жанны матдилектән чистартуны тараталар.

— Мактау яусын сезгә, хакимем, мактау яусын! Күрәм, сез борынгыларны һәм Әбугалисинаны жентекләп өйрәнгәнсез! Билгеле, неоплатонизм кинрәк төшенчә. Мәгәр анын барышы — беренчел бердәмнән күпләп сату өчен билгеләнгән дөньяга күчү матдә никадәр сонрак ваклана, безне тудырган динилектән шулкадәр сонрак ераклашуны күрсәтә. Матди яктан үсеп, без жаныбызны ваклыйбыз. Байлыкны арттырып, без жаныбызга караганда, анын турында күбрәк кайгырта башлыйбыз. Жан ваклана һәм Тудыручыга омтылмый, тән байлыкка төренеп хозурлана, һәм шунын белән үзенен башлангычы турында әкренләп оныта бара. Андыйлар арткан саен, кешелек Аллаһтан ерагая бара. Шулай булгач, Әбугалисина фикеренчә, жан белән тән бердәм нигез тәшкил итә, ул чагында минем карашымча, анда рух белән матдә арасында өзлексез көрәш бара. Кемнен кайсы жинеп чыга, шулай яши, бу көрәштә исә төп хөкемдар —Аллаһ Тәгалә.

— Алай булганда, тегесен дә, монысын да тигезләп, үзара ярашып яшәргә була, — дип каршылык күрсәтте Үзбәк.

— Син хаклы, әмма тулы хакыйкатькә төшенү сина бирелмәячәк.

— Әйе, барыннан да бигрәк, моны аңлап, үз тормышынны гына түгел, дәүләт тормышын да акыл белән жайга салырга мөмкин.

— Шул ук вакытта кешелек дөньясында бик акыллы, бик зирәк хакимнәр була, әмма халык аларны яратмый, чөнки алар халыкны, халык аны аңламый кебек. Гавам андыйларны йә куып жибәргән, йә жанын кыйган. Сина, әй бик яхшы әңгәмәдәшем, игътибар белән Әбү Насыйр әл-Фараби хезмәтләрен укырга кинәш итәм. Ә хәзер, әй бөек хаким, әңгәмәбез ахырында Гомәр Хәйям робагыен мисалга китерергә рөхсәт итче. Тик аны аңлап укырга кирәк:

Үзең бит инде туфрактан яраттың,
Йә оҗмах, йә тәмуглы исме productивny?

Андый әңгәмәләр Үзбәкнең күңеленә сары май булып ягылды, ул күп укыды, шәехләр әйткән хакында озаклап уйланды. Шәехләр дә үзара сөйләшкәндә яшь хан турында еш искә алдылар. Дөрестән дә, Үзбәктән менә дигән суфый чыгар иде. Андый сәләтлеләр аз, һәм алар арасында тәхетнең бер генә варисы да юк иде. Алар зур илдә яшиләр, әмма көньяк-көнчыгышта яшәүчеләр генә ислам динендә, төньякта — православие, ә киң кыпчак далаларында барысы да нигездә мәҗүсиләр. Кешеләргә аң-белем бирү, дингә, иманга, Аллаһка, аның җирдәге пәйгамбәре Мөхәммәдкә (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) инандырыр өчен менә кайда иркенлек. Аллаһ безгә Үзбәкнең Алтын Урдада патшалык итүе өчен бар мөмкинлекләр тудырырга фатиха бирсен, булачак ханга үзенең патшалыгында исламны кабул итәргә кирәклекне аңларга ярдәм итсен.

Фәлсәфи әңгәмәләр көн дә диярлек булып торды, ә фәлсәфәче булсын да инандырмасын, имеш. Хәрәзм шәехләренең берсе — сүзе үтемле Алла әд-Дин ән-Нуман, тартынып-нитеп тормый, Үзбәккә туп-туры:

— Туктайдан соң син хан булачаксың! — диде.

Шәехләр Олыс бәгенә якынаер өчен барын да эшләделәр. Алар аның дуслары, туганнары белән дуслык элемтәләре суздылар. Нәкъ менә алар Котлыгъ Тимергә хатынлыкка Үргәнечнең кади Садра Әбу-Хафса Гомәр әл Бакрый хатынының бертуган сеңлесе Торабәкне димләделәр. Котлыгъ Тимер үзе бу вакытта үрнәк булырлык мөселман булып, аны хатынлыкка алырга шатланып ризалык бирде. Шәехләр шулай ук халык арасында исламның изге урыннарына хаҗ кылуы турындагы хикәятләре белән танылган Мөхәммәд хаҗи турында да онытмадылар. Ул барысын да, кешелекне коткару Коръәнне тирәнтен төшенү юлы аша гына һәм теләсә кайсы дәүләтнең хакиме, әгәр ул Аллаһка инанса, үзенең халкын, аңа рухи азык биреп коткара ала, дип ышандырды.

Үзбәк эше һәм уй-фикерләре белән ләззәтләнеп, хатыннары һәм балаларының яратуын тоеп яшәде. Кызына алты яшь тулды, ул атасы белән күңелле итеп уйнарга яратты, аның өчен курчаклар ясады. Кечкенә Тимербәк ат өстенә утыра башлады һәм җәя тартырга маташты. Соңгы төннәрне үзе белән генә уздырганга, Ләйләнең күңеле шат. Тай-туглы бәби көтә иде.

Ләйлә ятакта иренә зур канәгатьлек китерде. Тай-туглы да гыйшык мәсьәләләрендә калышмады, әмма ул Үзбәк өчен дус, фикердәш һәм киңәшче дә булды. Тай-туглы Тәүратны, Инҗилне бик әйбәт белә, берничә кат Коръәнне укып чыкты, гомумән, Үзбәк укыган-белгән белән танышып барды. Аның вакыты иренекенә караганда иркен иде. Ә менә хаким белән фәлсәфәгә бик сирәк кенә керде. Аллаһка шөкер, аның сөйгәне фәнни әңгәмәләрне бик ярата иде. Хәзер бәби табарга санаулы көннәр генә калгач, ире аның янына ешлады һәм Тай-туглы галәм, дөнья буенча җыелып килгән мәсьәләләрне хәл итәргә тырышты.

Бервакыт Үзбәк хатыны белән уйларын уртаклашты:

— Тәхеткә утыруга, дәүләтебездә халыкка исламны мәҗбүри итеп куячакмын.

Тай-туглы елмайды, ул беркайчан иренә, күп сөйләшергә яратучы такылдык хатыннар кебек, уйламый, ашыгып каршы төшмәде. Ул матур күзләреннән хәйләкәр очкыннар сибеп:

— Сездә эзлеклелек юк, ханым! — диде.

— Нәрсәдә? — дип гаҗәпләнде Үзбәк.

— Әле кайчан гына мина онытылмас укытучын Самир хажи, Аллаһ Тәгалә кешеләргә, күнелләре һәм гадәтләре кабул иткәнен сайлап алсыннар дип, берничә дин индергән дип әйтте дигән иден. Син мине дә ислам кабул итәргә мәҗбүриләрсенме?

— Син аны кабул итмәденмени? Син бит Коръәнне теләсә кайсы яхшы мулладан ким белмисен.

— Мин шулай ук Инҗилне дә бик әйбәт беләм, хөрмәтле ирем, һәм ул минем күнелемә якынрак.

— Анын искергән тәгълимат икәнен беләсен бит.

— Анын каравы мин үзем яшь! — дип чыркылдады Тай-туглы.

— Житди сөйләшкәндә шаярмыйлар, — Үзбәкнен йөзенә күләгә ятты.

— Ә мин шаярмыйм. Илендә ислам яклылар күпме икәнен исәплә дә, буддачылар, шаманчылар һәм башка мәҗүсиләр, тагын православие нык тамыр җибәргән урыс кенәзлекләрен өстәп, аларны каршы бизмәнгә сал. Хәзер үлчәү угына кара. Дәүләтеннән генә түгел, Аллаһ сакласын, башыннан да колак кагарсын.

Үзбәк дәшмәде.

«Хатын-кыз димәссен! Эссе көндә таудан агып төшкән салкын агым кебек, шунда ук суындырды. Әйе, Елбаздукнын: ашыкма, жиде кат үлчә, бер кат кис, дигән киңәше башымнан чыккан».

Шул арада яшь хан, шәехләр белән фәлсәфә корырга гадәтләнеп, жирдән читләшкәнен сизде. Исламны кертүне нәрсәдән башларга икәнен яхшылап уйларга кирәк. Ә анын кирәклеге турында һич кенә дә икеләнмәде.

Тай-туглы уйга баткан ирен борчымады. Үзбәкне өйрәтергә кирәкмәсен, анын зирәк икәнен ул күптән аңлаган иде. Хатын сабыр гына ятакнын почмагында, сөеклесенә комачауламас өчен, тын алырга да куркып утырды.

Үзбәк, ниһаять, уйларыннан айныды, Тай-туглынын маңгаеннан үбеп, кулын кабарып торган корсагына куйды. Нарасыйнын тибенүен тоеп елмайды.

— Улы атасы белән исәнләшә! — диде Тай-туглы да, елмаеп.

— Каян беләсен, бәлки кыздыр?

— Беләм, без анын белән гел сөйләшәбез, ул сина охшаган — акыллы һәм батыр. — Бу юлы Тай-туглы житди иде.

— Ят, ял ит, сөеклем, улыма да хәл жыйдыр, бүген-иртәгә якты дөньяга киләсе бар. Ә мин киттем, эшләр көтә...

Атна да үтмәде, Хәрәзмнен Олыс бәгенен яраткан хатыны дөньяга малай китерде. Бала тыныч иде, әйбәт ашады һәм йоклады. Үзбәк улына Тәнбәк дип исем кушты. Үргәнеч яшь ханнын тагын бер варисы тууы уңаеннан зур мәжлес корды.

Соңгы вакытларда Үзбәк үзенен остазы Самир Озан Ибн Хөсәен Шәкави белән сирәк күреште. Карт айлар буе манара төзелешендә югалды, яктырткычларны күзәтеп-барлап торды. Күккә ашкан манаранын мәйданчыгыннан ватык-жимерекләрдән арчылып, янарган Үргәнеч бар матурлыгы белән күренә иде. Самир хажи төннәрен шәкертләре белән өстә ясмык пыялалар куелган торбадан иксез-чиксез галәм киңлекләрен күзәтте.

Тиздән укытучы укучысы-хакимнән үзен кабул итүен үтенде. Үзбәк галимне шунда ук чакыртып алды. Анын яңа ачышлар турында тизрәк ишетәсе килде.

— Жирнен түгәрәк булуы хакында сүзебезне хәтерлисенме, сәләтле укучым?

— Әйе, исемдә, хөрмәтле остазым бу турыда сөйләшүне гел чигерә килде.

— Бүген мин ул сөйләшүгә әзер, өстәвенә көннән-көн көчем кими, Аллаһ үз янына чакырыр көнгә ерак калмады. Менә нәрсә, сәләтле Олыс бәгем, мин Галәм гел хәрәкәттә дигән нәтиҗәгә килдем. Салкын планеталар безнен кояшка

охшаш кайнарлары тирәсендә әйләнәләр, бер үк вакытта яктырткычка әле бер, әле икенче яклары белән борылалар. Шунын белән бергә алар түгәрәк рәвешендә. Минем хәзергә әйткәннәремне расларлык дәлилләрем юк, тик минем фикер йөртүемне тынла. Шулай итеп, мин кояш сәгатьләреннән башладым. Ни өчен күләгә өчен тамгаларны без әйләнә, дөресрәге ярым әйләнә буенча ясыйбыз? Әгәр аларны туры сызык буенча эшләсәк, без дөрес вакытны күрмибез.

Үзбәк аны бүлде:

— Кояш та дуга буенча йөри бит.

— Без кояш тирәли әйләнәбез, дөресрәге безнең Жир. Синең уйлап караганың юкмы, ни өчен җәй, көз, кыш, яз була? Без яктырткычтан йә ерагаябыз, йә ана якынаябыз — менә шуның өчен. Дөрес булмаган әйләнә буенча...

— Якынайсак — җәй, ерагайсак — кыш, шулаймы? — дип ачыклык кертте Үзбәк.

— Бәлки, киресенчәдер. Мин ясмык пыяла белән тәҗрибә үткәрдем. Аңа кояш нурлары җыеп, аларны кәгазьгә юналлердем, алар аны яндырып тишек ясады. Ясмык пыяланы өскә күчердем — тәэсир итми, аска күчердем — нәтиҗә юк. Димәк, җәен без кояштан шундый ераклыкта торабыз, аның нурлары Жирдә туплана.

— Сез ни өчен без кояш тирәли әйләнәбез, дип саныйсыз, әй зирәк укытучым?

— Чулпан йолдызын күп мәртәбәләр күзәттем. Ул кояшка да, Жиребезгә карата да күчеп йөри. Без аның белән кояш тирәли, әмма төрле дөрес булмаган әйләнәләр буенча хәрәкәтләнәбез дигән фикер туа.

— Яхшы, алайса нигә көн һәм төн була?

— Шунын өчен, чөнки жир үз күчәре тирәсендә әйләнә, яктырткычка йә алды, йә арты белән борыла.

— Бу бик катлаулы. Без көн саен үз күчәребездә әйләнәбез һәм шул ук вакытта елга бер мәртәбә кояш тирәли әйләнеп чыгабыз. Шулаймы, сезнеңчә?

— Нәкъ шулай!

— Ә ни өчен әйләнгәндә без егылып төшмибез?

— Белмим, җавап бирә алмыйм. Минем әлегә юрамаларым юк. Бәлки, әйләнү тизлеге исәбенәдер, ә бәлки, Жир эчендә нindидер өслегендәге бар нәрсәне тотып тора торган көч бардыр.

— Әгәр Жир түгәрәк икән, нишләп сулар агып төшми?

— Суны да шул көч тота.

— Ә Ай, ул да әйләнәме?

— Шулай дип уйлыйм. Ай безнең тирәли әйләнә. Жир Айны да шул ук көч белән үзенә тарта, һәм аның өстендәге бар нәрсәне тотып тора. Ә менә Ай үз күчәрендә әйләнми, чөнки мин аның бер ягын гына күрәм.

— Әгәр Жирнең нindидер көче тартып тормаса, Ай безнең өскә егылып төшәр идеме?

— Белмим, белергә өлгермәм дә. Көчем кими бара, хакимем, менә шуның өчен синең янга килдем: шәкертләремне ташлама, юрамаларымны раслар яки кире кагар өчен барган тәҗрибәләремне тәмамларга ярдәм итче.

Яшь хан бернигә карамастан остазына эшен дәвам итәргә сүз бирде.

Укытучысы әйткәннәр буенча Үзбәк озак еллар фикер йөртте. Күп нәрсәдә ул икеләнде, Самир хажиның шәкертләре исә күпме генә тырышмасыннар, остазларының юрамаларын раслый алмады. Олыс бәге бу бәхәсле фикерләрне дөньяга чыгарырга ашыкмады, югыйсә, хаким акылдан язган диярләр иде. Ә үзе бу фәнни сорауларга җавап эзләргә һич вакыт таба алмады. Эш күп, барысы белән дә идарә итәргә кирәк. Өстәвенә, Туктайдан да төрле йөкләмәләр килеп торды.

***

Туктай бер вакытта да кул кушырып утырмады. Ул әле яу чапты, әле Иран белән килешү төзеде, әле Чыгытай Олысына, Күк Урдада әледән-әле алышынып торган ханнарга ярдәм итәр өчен сәфәр чыкты. Әмма анын өчен ин мөһиме булып үз дәүләтен кайгырту торды. Урыс кенәзлекләре һәрвакыт мәшәкать тудырдылар. Кенәзләр бертуктаусыз әле җир аркасында, әле кайсы башрак дип, гел үзара низагка керделәр.

Андрей Городецкий бакыйлыкка күчкәч, кенәзләр җыелышы Бөек кенәз итеп мәрхүмнең туганнан туганы Михаил Тверскийны сайлады. Әмма Городецкийның бертуганының улы Юрий Данилович Московский, моңа ачуы килеп, Урдага юл тотты.

— Урыс тәхете Александр Невскийның нәсел дәвамчыларыныкы булырга тиеш, — дип белдерде ул ханга.

Туктай Юрийның башка дәлилләрен дә тыңлады, тик аларда тәхетнең чираттагы кешегә яше буенча олырагына күчүен исәпкә алып, Михаил Ярославович Тверскийның хакын раслады һәм ана ярлык тапшырды. Юрий Урдала калды, монда бик күп дуслар һәм үзенә карата яхшы мөгамәләдә булучыларны тапты. Кунак булгач, иленә — Бөек кенәзлек өчен көрәшне дәвам итәргә кайтып китте. Башта, ханга каршы барырга батырчылык итте дигән булып, Василий Рязанскийга яла якты. Туктай гаепсез кешене үлем җәзасына тартты, сугышчылары исә, кешеләргә шактый зыян салып, үтерелүченең бар кенәзлеген таптап үттеләр.

Туктай дәүләтне ныгыту эшләрен дәвам итте, акча реформасы кертте, иске акчаларны әйләнештән алып, яна, бер авырлыктагы тәнкәләр суга башлады. Урдада ханга тел кайтарудан куркалар иде, һәм ул үзенен хаклы булуына ышанды, яңа акча тиз арада әйләнешкә кереп, чит ил сәүдәгәрләрендә ышаныч уялады. Туктайга бар да берсүзсез буйсынды, халык арасында йөргән сүзләрне ул белмәде, хәтта башына да китермәде.

Җәй бик эссе килде, бигрәк тә Итилнең түбәнге агымында кызу иде. Җәй уртасына дала ярымчүлгә әйләнде. Туктай гаиләсе белән төньякка — Болгар ягына күченде. Биредә төннәрен булса да түзәрлек, дала буйлап салкынча җил йөгереп үтә иде.

Күчмә тормыш ханны һәрвакыт үзенә тартты, ул бер урында утырырга, анынча итеп әйтсәк, үз тиресе исен иснәргә яратмады. Күчмә тукталышларда анын хатыннары һәм хезмәтчеләре үләннәр җыйдылар, тамырлар казып алдылар, балаларны күчмә тормышның хикмәтләренә төшендерделәр. Шундый көннәрнең берсендә Баялун белән Арибах, даланың хуш исенә мөкиббән китеп, хезмәтчеләрнең күз уңыннан читкәрәк тайпылдылар.

— Бу үтерүчегә тагын күпме түзәбез? — диде Баялун кискен генә.

Арибах иңнәрен җыерды.

— Вакыт, — дип дәвам итте өлкән хатын. — Ул инде үзенекен эшләде, Үзбәк тә хан булырга өлгереп җитте.

— Син миңа Туктайны суеп үтерергә кушасыңмы? — диде ачуы чыккан Арибах.

— Анысы — иң авыр юл. Илбасар безне шунда ук эләктерер дә, Үзбәк Хәрәзмнән килеп җиткәнче, җәзалап та куяр. Мин сиңа берничә тапкыр әйттем инде, безгә бәхетсезлек очрагы әйбәтрәк.

— Белмим... белмим... — Арибах икеләнде. — Мин инде Туктайга ияләштем һәм Тогрылны онытгым диярлек, Туктай миңа якынрак.

— Йә-йә, елап та җибәр тагын, — сердәшенен йөзендә сагыш күреп, Баялун зәһәрләнде. — Син беләсен, безнең иребез саналган адәм бүген-иртәгә Илбасарын бәкләр бәге итәчәк. Менә шуннан соң бу кәтәнә җәллап-нитеп

тормаячак, Үзбәкне дә, безне дә юк итәчәк. Син бит башсыз түгел, Арибах! Уйла! Туктай бөтенләй йөзә белми. Әгәр ул сине якын күргән кебек, мине үз янына якынайтса, күптән ком таптап йөрүеннән туктатып Итилгә алып кереп китәр идем. Үзләрен хөрмәт итүчеләр дингез, елгаларда үз корабларында йөзә, ә безнекенең рәтле-юньле бер каегы да юк.

Бер айдан хан ставкасына урыс җирләренең Бөек кенәзе Михаил Тверский чакыртып алынды һәм аңа Алтын Урда ханына лаек булырлык ике кораб төзү эше тапшырылды.

***

1310 елда (һиҗри буенча 710 елда) Тай-туглы Үзбәккә тагын бер угыл — Җанбәкне тудырды. Бәхете ташыган ата, анасы белән агасын шатландыру өчен, атчабар җибәрде, әмма әле ул вакытта Арибахның каты авырып китүе турындагы авыр хәбәр белән үзенә дә атчабар юлга чыкканын белми иде. Үзбәк үзе белән Котлыгъ Тимерне алып, кечерәк отряд озатуында, дистәләгән ат куып, Донның урта агымында урнашкан Туктайның күчмә тукталышына килеп житте.

Улы ашыгып юртага килеп кергәндә анасы саташып бәргәләнә иде. Аның тирәсен им-томчылар, шаманнар сырып алган, хезмәтчеләр исә такмаклап елыйлар. Үзбәк анасының ут кебек кайнар кулларыннан тотты. Авыру хатынның мангаен салкын тир каплаган. Улының орынуы бәхетсезне бераз тынычландырды, ыңгырашуы басылды, бераз тынып торгач, күзен ачты, битараф карашын бушлыкка төбәде, бераздан Үзбәкне табып, җанланып киткәндәй булды, көч-хәл белән иреннәрен селкетеп пышылдады:

— Улым, килдеңме... Бәхетле бул, улым, үзенне сакла, балаларыңны... Хуш, улым... Бетте... мине Аллаһ һәм атаң чакыра...

Арибахның карашы кабат томанланды, ул тирән итеп сулады да җан бирде.

Җан ачысыннан нишләгәнен анламаган Үзбәк Туктайны аздан гына бәреп екмады. Тегесе туганының улын кочаклап алды, аның да күзе тулы яшь иде. Күчмәләргә кайгы-ыңгыраш килде. Арибахны бар да ярата иде.

Өч көн буе Үзбәк беркем белән аралашмады, сөйләшмәде, бары анасының җаны тынычлансын дип, тырышып, догалар кылды.

Атна узды, Олыс бәге Хәрәзмгә китәргә рөхсәт алу өчен хан янына килде. Хан мөлдерәмә яшь тулы күзен күтәреп аңа карады да кулын селкеде:

— Күз алдымнан кит, сине күрүгә күз алдыма сөекле Арибахым килеп баса. Кит, ялгыз-ялгыз кайгырсак, җинелрәк булыр.

Үзбәк башка бернинди күрсәтмәләр алмады. Айдарбәк агасы белән хушлашты, үги анасы Баялунны кочаклады, тегесе шул чакта:

— Миннән хәбәр көт, алуга, Сарайга килеп җит, — дип пышылдады.

Ике ел узып китте. Үзбәк даими рәвештә Сарайдан хәбәрләр алып торды, тик Баялуннан гына берни ишетелмәде. Ул Туктай янындагы ышанычлы кешеләреннән барысын да белде. Дин кардәшләре Олыс бәгенә ханның яңа башлангычлары хакында хәбәрләр җиткерделәр, алардан Үзбәк атасы янәшәсендә булган Илбасарның күтәрелүе, беренче варисның хәйләкәр тәрбиячесе Калакның явыз ниятләре турында белде. Үзбәк Туктай ханның кайда булуы, кем белән сөйләшүе турында белеп-ишетеп торды һәм аның үзенә карата суынуын анлады. Яшь ханның да Хәрәзмнән күнеле кайтты. Үзенең киләчәге турында көн-төн уйлады, борчылды: тәхет аны үзенә тарта, чакыра иде.

Үзбәк тирәсендә элеккечә укымышлылар күп иде, күк белгечләре дә артты, алар үзләренен хуҗасы өчен берсеннән берсе яхшы йолдызнамәләр төзеде. Әмма Алтын Урда тәхетеннән читләштерелгән диярлек варисны берни

шатландырмады. Хәтта балачактагы үзен хәтерләтеп акыллы, таза-нык булып үсеп килгән малайлары да. Үзбәк түземсезләнеп Баялуннан хәбәр көтте, әмма ул күренмәде дә күренмәде.

***

1312 елның көзе җылы һәм яңгырлы килде, яңа туган айдан икенче яңасына кадәр кояшны күрмәделәр диярлек. Көннәр кыскарганнан-кыскарды. Дала тәмам изрәде, атлар балчыкка батты, Туктай исә сугышчыларын куалады да куалады. Аңа ашыгыч рәвештә Сарайга кайтып җитәргә кирәк иде. Коры җирдән тиз генә кайталмасын белгәч, хан корабка төялергә әмер бирде. Итилдән җитмеш чакрым тирәсе өстәрәк, зур елгадан Актүбә агып киткән төштә, Бәлҗәмин шәһәре янында утырдылар. Айдарбәк төне буе салкын яңгыр астында төяү эшләре белән җитәкчелек итте. Таң беленгәндә, Бәлҗәмин тукталышыннан кузгалдылар. Кораб җил унаена Итил буйлап түбәнгә төшеп китте.

Берничә сәгатьтән җил кисәк кенә юнәлешен үзгәртте, агымга каршы зур-зур дулкыннар күтәрелә башлады. Ишкәкчеләр тиреләреннән чыгардай булып тырышсалар да, кораб урынынннын кымшанмады. Җил тагын да көчәя төште, боздай салкын су палубага кадәр күтәрелде, көймәне йомычкадай як-якка ыргытты. Чираттагысы зур корабны шулкадәр янтайтты ки, су борт аша ургылып керде, ә борчактай тирә-якка сибелгән кешеләр көймәне тагын кыйшайттылар. Мачта канатын эләктерә алмый калган Туктай, аның артыннан Айдарбәк суга очтылар. Җылы халатлары шунда ук манма суга батты, боздай салкын судан мускулны көзән җыерды, йөзеп чыгарга тырыштылар — әмма файдасызга. Батып баручы Айдарбәк Туктайның итегеннән эләктереп, үзе белән төпкә өстерәде, киявен үтергәне өчен әллә атасының үч алырга кушуын җиренә җиткердеме, әллә соңгы вакытта аеруча якынаеп киткән ханының үлем алдыннан газабын җиңеләйтүе булдымы? Шулай итеп, алар икесе бергә тирән ләм төбенә яттылар.

Батып баручы корабтан котылучылар саны бармак белән генә санарлык иде, нигездә алар — салкынны кичерергә өйрәнгән һәм йөзә белгән ишкәкчеләр иде. Алар шашынган суга берничә бүрәнә ыргытырга өлгерделәр һәм сулъяк ярга чыктылар, анда исә ярымүле яткан бу кешеләрне һәр җиргә борын тыгарга яраткан малайлар табып алды.

Туктайның үлү хәбәре Сарайга өч көннән соң гына килеп иреште.

Кадак тиз генә Илбасарны тәхеткә утыртты һәм башкалага гаскәрне күбрәк китертергә боерды. Яшь хан яраннары башларын югары күтәрде һәм үзара вазифалар бүлешергә тотындылар.

Мөселманнарны кыйнап, Сарайдан куып җибәрергә дигән тавыш күтәрелде, әмма тәхеткә яңа утырган хаким ашыкмады.

— Дошманнар арттыруның кирәге юк, башта атам вакытындагы кебек буйсынуларын таләп итәргә кирәк. Барлык нойоннар, Олыс бәкләре Сарайга килсеннәр һәм миңа тугры булулары хакында ант итсеннәр.

Баялун Хәрәзмгә җибәрәчәк атчабарны үз янына аударды һәм Үзбәккә атап язылган хатны кулына тапшырырга кушты, анда ул үги улына язмышына буйсынырга, Илбасарга ант итәргә кушкан. Атчабар шунда ук үзенең җитәкчесенә хәбәр итте, тегесе исә хатны яшь ханга күрсәтте.

— Һе, мондый хатларны уку күңелле. Карт убырлы үзе өчен курка. Бар да җайга салынгач, аны иленә — Византиягә җибәрәм, алайса барыбер соңрак ниндидер мәкер уйлап табар. Илбасарга атасының өлкән хатыны атчабары бер тәүлек элек Үзбәккә башка әчтәлектәге хат белән ук кебек очканы хакында мәгълүм түгел иде. Хәтта берничә генә сүз язылган иде: «Бәркә ызанында кинәшер өчен көтәм». Өч ханның хатыны булган зирәк хатынның хәрәмнән ничек чыгып киткәнен берәү дә сизмәде.

Хәер, ул ыгы-зыгы, буталышта бераудә дә хәрәм кайгысы юк иде. Үзбәк белән Котлыгъ Тимер гаиләләрен Сарай-Тимер карамагына калдырып, ике мең сугышчы озатуында Бәркә ызанына килеп җиттеләр. Ярый әле, юл азагында суыклар башланып, юллар бераз үтә алырлыкка әйләнгән иде. Баялун аларны каршылады һәм, юлдан соң аз гына ял итәргә дә ирек бирмичә, җитәкчелекне үз кулына алды.

— Малайны ант иткән булып йомшартырга кирәк. Сугышчыларны, шик тудырмас өчен, монда калдырыгыз. Озата йөрүче итеп ике-өч дистәне алыгыз, алары да кирәк булмас дип уйлыйм, сез үзегез җитез егетләр. Илбасар өчен бүләкләр хәстәрләп куйдым, сезнең дә кулыгыз буш түгелдер. Мин Сарайга үземә тугры менбашны якынрак китердем, тәхет залына керүегез сугышчыларым өчен сарай сагын юкка чыгарырга фәрман булыр. Манка малайны шунда ук юк итегез. Сәнәктән көрәк булганны үтерүгә, сезгә андагы ишле дин кардәшләрегез ярдәмгә килер. Әйе, Кадак турында онытмагыз, ул үзенең карап үстергән кешесеннән бер генә минутка да читтә калырга тиеш түгел.

Ант бирү йоласы яна гына бәкләр бәге вазифасы алган Кадак тарафыннан эшләнде. Ул, бу югары урында төпләнеп калыр өчен, хакименең өметен акларга тырышты, ул бу турыда бер ай элек, үзенең чыгышы начар булу сәбәпле, хәтта хыяллана да алмый иде. Барлык саклану чаралары күрелде. Сарайга керүчеләрнең барысын да сакчылар инәсеннән җебенә кадәр тентеп керттеләр. Залга артык кешене үткәрмәделәр, анда бары ун зур түрә, Олыс бәкләре, хәрби җитәкчеләр һәм руханилар гына чакырылды. Баялунга, залда Котлыгъ Тимер булсын өчен, сак башлыгын сатып алу бик зур чыгымнар китерде.

Ант бирү Калакның әйтеп торуы буенча башкарылды. Яна ханга бүләкләр тапшыру башланды. Кардәшлек буенча Үзбәк бүләкне беренчеләрдән булып бирде. Хәрәзм осталары кыйммәтле ташлар бизәп ясаган кылыч яткан подносны кулына тотып, Үзбәк тәхет янына китте. Шундый ук поднос белән Хәрәзм Олысы бәгеннән чак кына калышып Котлыгъ Тимер атлады. Алар икесе дә, ханның күзенә карамаска тырышып, башларын түбән игәннәр. Тәхет аскуймасының басмаларына җиткәч, Үзбәк көтмәгәндә подносны Илбасарга томырды. Теге иелеп бәхетсез подностан качарга маташканда, көндәше кылычны кыныннан тартып чыгарды да ике сикерүдә янына барып басты. Кылычны айкауга, тәхеткә утыра алмый калган ханның йокы артериясеннән кан сиптерә башлады. Шук ук минутта Котлыгъ Тимер Кадак белән дә нәкъ шуны кабатлады. Ике мәет тәхет кырыенда ятып калды.

Залдагылар анышканчы, Үзбәк Урданың хан тәхетенә менеп тә утырды. Коралсыз хәрби җитәкчеләр, Олыс бәкләре, зур түрәләр күзләрен ачып йомарга да өлгермәде: залга дистәләгән сугышчы озатуында Баялун аяк басты:

— Мин, арабыздан көтмәгәндә вакытсыз китеп барган Туктай ханның хатыны, Алтын Урда тәхетендә аның дәвамчысы — мәрхүмнең туганының улы Үзбәк утыруын игълан итәм!

Тәҗрибәле ханбикә көтелмәгән хәлдән каккан казыктай катып калган зал өстеннән без кебек үткен карашын йөртеп чыкты да сүзен тәмам итте:

— Кем каршы, чыгыгыз, сезне анда мина тугры сакчылар көтеп тора.

Бар да сүзсез тынып калды.

*Русчадан* **Рөстәм ГАЛИУЛЛИН** *тәрҗемәсе.*

*Ахыры киләсе санда*



Рафис
Корбан

# ӨЧ ҖЫРЫ БАР БУ ГОМЕРНЕҢ

## Урыс капка

Урыс капка татар авылында.
Ясагандыр үзен чын оста!
Киләсенә хәтле чуклы бизәк,
Андый капка юк тик урыста!
Урыс капка татар авылында.
Мунчалары булган чакта сон,
Үскән чакта урыс каеннары,
Ник булмасын әле капкасы?!
Урыс капка татар авылында.
Капка корып Хода бәндәсе,
Ырыс дигән матур исем кушкан,
Бәхет-капка – асыл мәгънәсе.
Бәхет кенә ачып кертер капка!
Аһ бу дөнья, шук та, кырыс та.
Кышлар гына түгел, капкалар да
Әйләнәләр икән урыска.
Урыснын юк монда бер гаебе.
Тел алдында гөнаһ кылып без,
Капка гына түгел, үзебез дә
Беттек инде урыс булып без.

## Тукран

*Агачларны түгел,*
*Йөрәгемне*
*Чукый тукран.*
Ш.Гаделша

Урманда йөрим. Сокланып
Ислейтар урманына.
Кошлар тынган. Бер агачта
Тукылдый тукран гына.
Тук та тук килә, тук та тук.
Тукылдый туктап-туктап.

---

Рафис КОРБАН (1957) – *шагыйрь; «Алмалы төн», «Яра», «Минем туган көнемдә» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге әдәби бүләк иясе. Казанда яши.*

Тукранның эшләгәнен мин
Күзәтеп тордым туктап.
Сокланам шул тукранга мин.
Ничек итсә дә итә,
Агачны эчтән кимергән
Кортның башына житә.
Уйлыйм аннан: безнең дә, дим,
Жәмгыять бара череп.
Эчтән аны жиз башлы корт
Кимерә – ришвәтчелек.
Ничек безне тазартырга?
Башымда яңгрый оран.
Агачларны түгел, гүя,
Миемне чукый тукран.

## Туган як үрләренә

Биектауның биек таулары юк,
Калкулык та монда, үр генә.
Юллар монда һәрчак сикәлтәле –
Үр төшә дә янә үр менә.
Бормаланып Ашыт агып төшә,
Урый-урый үрләр арасын.
Әй, Ашытым, үрләр кичә-кичә,
Син диңгезгә агып барасың!
Күпме кичтем мин дә гомеремдә
Туган якның шушы үрләрен.
Үргә менеп, үрдән төшкәнемне
Төшләремдә хәтта күрәмен.
Мин гашыйкмын якташ Ашытыма,
Үрләренә туган якларның!
Үлгәч тә мин шушы үр өстеннән
Ашытымны тыңлап ятармын.

## Өч жыр

Өч жыры бар бу гомернең.
Бишек жыры – беренчесе.
Әнкәң жырлаган ул жырны,
Син тиз йоклап китсен өчен.
Әнкәң жырлаган ул жырны,
Әткәсе кебек булсын, дип.
Туган телен, туган илен
Яклардык егет булсын дип.
Икенчесе – тормыш жыры.
Күп аһәнле, күп көйле ул.
Тормыш буйлап ахыргача
Озата бара сине ул.
Япан кырга алып чыга,
Алып менә биек тауга.
Йөртә озын юллар буйлап,
Һәрчак була синең янда.
Утка керсәң, ул да керә.
Синен белән төшә суга.

Авыр сүздән өшегәндә,
Сине жылытыйм дип туна.
Әле дәртле, әле шаян
Йә гел сагыш-моннан тора.
Бу жырынныңниндилеге
Үткән тормышыңнан тора.
Өченче жыр жырланачак
Үз чираты житкәч кенә.
Бәхилләшеп дөнья белән,
Бакыйлыкка киткәч кенә.
Ул жырлана жансыз гәүдән
Ләхетенә ингән чакта.
Бәхилләшеп, дус-ишләрен
Башын аска игән чакта.
Жырланмаска да мөмкин ул!
Онытма син шушы хакта:
Тик ул жырны һәрбер кеше
Үзе яза исән чакта.
Ул языла һәр кешенең
Газиз хәләл көче белән,
Милләтенә мирас итеп,
Калдырасы эше белән.

## Мәңгелек сәфәр

Учак яна, жилфер-жилфер,
Ялкынланып, жилпенеп.
Очкыннарның йолдызларга
Житәсе килә менеп.
Чишмә ага, чылтыр-чылтыр,
Ашыга, кабалана.
Барып житәргә тели күк,
Ерак диңгезгә таба.
Жилләр исә, үләннәрнең
Башларын иеп алга;
Алар да каядыр чаба —
Әйтерсең, чыккан юлга.
Бар да каядыр ашыга,
Бар да мәңгелек юлда.
Күкрәктә йөрәк ашкына —
Тәкъдирен эзләп ул да
Чыккан мәңгелек сәфәргә.
Бер гомер дигән ара...
Утка керә,
Суга төшә,
Жилләргә каршы бара.

## Миргазиян Юныска

Без диңгезне күргәнмени?!
Безне хәтта зур судан
Кырык чакрым читкә куган
Урыс атлы зур туган.

Без диңгезләр күргәнмени?!
Бездә кыр да дала тик.
Мингазиян Юныс бар дип
Юаныргa кала тик.
Без диңгезне күрмәсәк тә,
Шәп беләбез диңгезне.
Диңгез белән таныштырып
Торгач шулай син безне.
Син диңгезне күп күрсәң дә,
Кырда яшәгән халкың
Синең өчен бар нәрсәдән
Кадерлерәк һәм якын.
Синең бөтен язганыңа
Чын бәя бирсәң әгәр,
Син – татар өчен җан аткан
Патриот-милләтпәрвәр!
Юлыгырга мөмкин бүген
Тик сине укып кына
Милләт хакында хисләрнең
Тугызынчы валына.
Син татар әдәбиятын
Диңгезгә чыктың алып.
Шул диңгездә бер кораб син,
Әдәбиятта – Алып!

## Хәким урамында өмә

Казансуның уң ярында,
Сибгат Хәким урамында
Яшь юкәләр утыртабыз.
Урам гөрләп тора монда.
Өмәчеләр – язучылар.
Каләм түгел кулда – көрәк.
Шагыйрь урамын ямьләргә,
Яшелләндерергә кирәк.
Ә юкәләр гади түгел,
Бу юкәләр – Ауропадан,
Ерак Алман җирләреннән –
Солдат Сибгат эзе калган.
Алман җирен фашистлардан
Азат иткән чакта, бәлкем,
Озынторык юкәләрне
Күп күргәндер Сибгат Хәким.
Әле көз, зифа юкәләр
Кичкәч кышның кар-буранын,
Яшәрерләр, яшәртерләр
Сибгат Хәким урамын.
Сибгат Хәким урамында
Алмания юкәләре –
Кислород фабрикалары –
Казаныбыз үпкәләре.
Ә сугыштан Сибгат-солдат
Кайта чирле үпкә белән,
Ярым тере хаста булып,
Немецларга үпкә белән.

Без кичердек алманнарны,
Яшәп булмый үпкә белән.
Алманнар шагыйрь үпкәсен
Бәхилләтә юкә белән.

## Сөю киткәч

Сөю китте миннән,
Сөю китте.
Жаным калды торып
Буш зал кебек.
Яңгырамый хәзер анда жырлар,
Яңгырамый анда хәзер көлү.
Сөю китте миннән,
Сөю китте.
Сусыз ваза кебек
Калдым торып.
Бер яме юк хәзер ул вазаның –
Чәчәкләре күптән беткән корып.

## Нидер кала

Башта күкрәп сөю килә безгә.
Көткән сөю килә!
Чәчәк ата язгы бакча булып –
Күңел уйный, көлә.
Гомер үтә, сөю бездән китә.
Бакча корый, сула.
Тик хәтердә мәңге сулмый торган
Хатирәләр кала.

## Муза килгән иде

*(Шаяру)*

*Зөлфәткә килсә Муза,*
*Шундук шигырьгә уза.*
Л.Лерон

Төн уртасы. Хатын йоклый иде,
Килгән иде Муза яныма.
Үталмады илһам булып жанга,
Әүрелмәде сөйгән ярыма.
Язалмадым яңа шигыремне.
Язалырмын микән иртәгә?
Канәгатьсез Муза китә инде,
Белмим инде ни хәл итәргә?
Канәгатьсез Муза китә инде,
Ул шигырьгә уза алмады.
Ахры, янда жиденче төшен күреп
Яткан хатын комачаулады.



Әмирҗан
Моталлапов

# ГАМЬ

РОМАН

***

Исхак атны алыштырды да юлга чыкты. Районга бару-кайту юнәлешендә ышыкланып туктардай урын бер генә төбәктә, ул — авылдан ике чакрым тирәсендәге куаклык. Авыл халкы «Чәмәй» чокыры дип йөртә бу урынны. Сафетдиннең тукталышы нәкъ шушында булгандыр сыман тоелды Исхакка.

Куаклыкка якынлашкач, Исхак атны туктатты, ешлыкка таба каерылган тәгәрмәч эзләрен күзәтә башлады. Илле-алтмыш адым китмәгәндер, куаклык арасыннан бәрелә-сугыла чыккан тарантас эзенә тап булды. Атны читтә калдырып, Исхак эз буйлап эчкә керде. Берничә адымнан җигүле ат туктаган ачыклыкка килеп чыкты. Тарткалашудан таптала төшкән урынны күреп, коелып төште. Якында гына ике якка чөелгән хатын-кыз туфлие дә аунап ята иде...

— Бәреп кенә үтерәсе мәхлук, кызның башын шөйлә очладың микән? — дип, сүзләрен теш арасыннан сыгып чыгарып, каты гына сүгенде Исхак.

Кызның исәнлегенә ышанасы килә иде аның. Эчкәре кергән эзләр булмаганлыктан, Рәлия ниндидер жай табып, Сафиның кулыннан ычкынгандыр да туфлиләрен салып йөгергәндер. Йөгерсә, әлбәттә, аксак Сафи аны тота алмаячак, дигән уй Исхакның ярсуын күпмедер йөгәнләп тора иде. Ычкына калганда, һичшиксез, Шомыртлы авылына таба чабачак.

Гатин ялгышмады. Рәлияне Шомыртлыда тапты. Шушы авылдагы укытучы кызга сыенган. Исхак килеп кергәндә кыз, фажигадән котылуына ышанып житмичә, дер калтырап утыра иде. Сизмәстән ачылган ишек тавышына да сискәнеп китте. Керүченең Исхак икәнлеген танығач, жинел сулап куйды. Урыныннан күтәрелеп, аның янына килде дә:

— Абзыкаем, үлемнән чак калдым бит... — дип үксеп еларга кереште. Гатин кызны күкрәгенә кысты, тынычландырырга теләп, аркасыннан сөйгәндәй итте.

— Тынычлан, үскәнем... Сине исән-сау күрүемә мин бик шат, — диде ул, «өметемне өзә язган идем инде», — дип әйтүдән чак-чак тыелып калып.

*Ахыры. Башы 7, 8 саннарда*

— Көч-хәл белән котылдым бандиттан, — дип, сүзләрен өзеп-өзеп әйтеп, яшь сыгуын дәвам итте кыз.

— Әйдә, кайтканда сөйләшербез, — дип, рәис Рәлияне өйдән алып чыкты.

— Теге ристан кайда соң? — дип сорады Рәлия, бераз тынычлангач.

— Качкан ул. Капса, нәрсәгә тарыйсын чамалый бит. Әмма озак йөри алмас, койрыгына басарлар...

«Сафетдин кызны көчләмәде микән?» — дигән икеләнү борчый иде Исхакны. Ачыклыйсы килде, ләкин ачыктан-ачык бу хакта сорау бирә алмады. Юлдашының фикерен сизенгәндәй, кыз хәлнен ничек килеп чыгуы турында кыскача үзе сөйләп бирде.

— Булдыргансын, сенлем. Ярый, югалып калмагансын, — дип Исхак аны мактап алды.

Алар кайтып җиттеләр. Басу капкасын ачып, авылга керделәр...

Берничә көннән Рәлия авылларына кайтып китте...

***

Аланбашта отчет-сайлау җыелышын башка колхозларга караганда алданрак үткәрделәр. Хәлимә Һашимованын рәислектән җибәрүләрен сорап биргән гаризасын канәгатьләндерү көннәрен артык озакка сузарга теләмәде район җитәкчелеге.

Җыелышта райкомнын беренче секретаре Хәмзин үзе катнашты. Клуб халык белән шыгрым тулы иде. Урынга сыешмаганнар стена буйларында, ишек катында баскан килеш җыелыш барышын күзәтергә мәҗбүр булдылар. Ике ел эчендә башкарылган эшкә йомгакны Хәлимә ясады. Ана сүз биргәндә беренче секретарь:

— Хөрмәтле колхозчылар, доклад өчен сүзне менә каләр колхозны Һашимова фамилиясе астында җитәкләгән, хәзер Әмировага әйләнгән Хәлимә ханымга бирәбез, — диде ул елмаеп. Халык дәррәү килеп кул чабарга кереште, Хәтта түшәм ярыкларыннан туфрак коелды, тәрәзә пыялалары зенгелдәп куйды.

Кулыннан власть китәсе җитәкченен тетмәсен тетү — гадәти күренеш. Ләкин Хәлимәне «тешләргә», «чеметергә» ниятләүче табылмады. Ул җитәкчелек иткән дүрт ел эчендә, чоры авыр булуга карамастан, колхозның аягында ышанычлы тора алуын басымлап күрсәттеләр, Хәлимәнен хезмәтенә югары бәя бирделәр чыгып сөйләүчеләр.

Чыгыш ясаучыларнын күпчелеге хатын-кызлар иде. Алар Хәлимәнен эш оештырудан гайре, эчүче ирләргә көн күрсәтмәвен аеруча мактадылар, яна җитәкчегә дә бу яктан корылык күрсәтергә куштылар. Сонгы сүзне хисапчы Салих Баянов алды.

— Җәмәгать, мин озын-озын, яп-яссы сөйләп тормыйм, бары шуны гына әйтәм: һәркайсыгыз беләсез, Хәлимә белән Хаҗи шыр буш ихатада яши башладылар. Әллә шуларга бер теше бозау бирәбезме? Колхозның туй бүләге булыр. Иптәш Һашимованын хуҗалыкта куйган хезмәтен бәяләү кебегрәк тә килеп чыгар, — диде ул, сораулы карашын залга ташлап.

— Бер бозаудан колхоз таралмас, бирәбез-бирәбез, — дип бертавыштан ризалашты зал.

...Беренче секретарь Һашимованың гаризасын укыды, тавышка куйды.

Хатынның үтенече канәгатьләндерелде. Хәкимҗан кандидатурасына да каршы килүче булмады, ул бер каршылыксыз колхоз рәисе итеп сайланды.

Аланбаш авылы елъязмасына бер яна сәхифә өстәлде...

***

Рәсим — тулы хокуклы белгеч. Балаларга физика һәм математика фәннәренең серләрен төшендерәчәк. Кем булып һәм кайда эшләячәген институттан ук белеп кайтты. Тимәк мәктәбе директоры Фаяз Саттаровның анын кайтып күренүен көтеп кенә торуын да аңлый. Беренче май бәйрәмендә очрашкач, остазы:

— Кайту белән менә дигән мәктәп тапшырам үзенә... Ял кирәк мина, артык арыдым, — дип әйтеп үк калды.

Гади укытучы булып эшләргә бишкуллап риза егет, ә директор йөген тарта алуына икеләнеп тора. Бу хакта Саттаровка яшерми әйтте. Ләкин остаз кырт кисте:

— Тарихта хәзер сезнен буын бите ачыла. Институт дипломлы директорлар районда санаулы гына. Институт тәмамлап, урта белемле директорларга буйсынып йөрмәссен бит. Ул ягын да уйларга кирәк, — дип орышкандай итеп өстәп куйды.

Директор итеп билгеләделәр Рәсимне. Үзе белем алган, күпмедер вакыт укыткан мәктәп, һәрхәлдә, анын күнеленә якын иде. Сенлесе белән кияве дә шушында эшли. Туган авылы янәшәдә генә. Бу якларын искә алганда, Тимәккә урнашуына канәгать иде Рәсим.

Яшь егетне түбәнсетеп карарга уйлаучы юк иде. Санлаштылар анын белән. Институт тәмамлаган белгеч ләбаса! Хәер, бередә укытканда да төшеп калганнардан түгел иде ул. Тәҗрибәле мөгаллимнәрдән калышмый эшләде...

— Абзыкай, бездә яшәрсен. Директор башың белән авылга кайтып йөрмәссен бит, — диде Рәсимгә сенлесе Хамия, килеп урнашуының беренче көнендә үк.

— Ялгыз карчык табылыр, сезне мәшәкатьләп йөрмәм. Икегез дә эшлисез, кеше карау кайгысымыни сездә, — дип Рәсим тәкъдимнән баш тартты.

— Чит кешеләр түгел лә! Ничек тә укмашып яшәрбез. «Бертуган абыйсын да сыйдырмаган», — дип, мине халыкнын каһәрләве бар. Директор өчен фатир салынгач, бер сүзем булмас... Әллә өйләнеп тә куярсын...

— Өйләнү мәсьәләсе кичегер, ахыры. Киләсе елда безнең елгыларны армиягә алачаклар дигән сүз йөри. Мине генә калдырмаслар, — дип Рәсим икеләнеп әйтеп куйды.

— Оксана белән язышасыздыр? — дип сүз агышын бора төште Хамия.

— Әйе.

— Укыймы?

— Быел икенче курста.

— Укысын, институтын бетерсен инде.

— Ничек булыр? — диде Рәсим, үз бизмәненнән чыгып уйлап. Армиядән калдырсалар, Оксанага өйләнмәкче ул. Кызнын да каршылыгы юк сыман. «Син кайда — мин шунда», — дип язмышын анын белән бәйләүдән башка күз алдына китермәвен хат саен сиздереп тора.

Рәсимнен Тимәккә урнашуына Сафа да, Фәния дә канәгать иделәр. Ике баланың бер төбәккә укмашуы сөендерде аларны. Аралашып, ярдәмләшеп яшәрләр, кинәшләшеп эшләрләр, дигән караштa иделәр алар. Барып-кайтып йөрергә ара ерак түгел... Оныклар дөньяга килер. Алар ике араны бер итеп йөреп үсәрләр, дип өметләнә ата белән ана...

Тормышында булган үзгәрешне Оксанага житкерергә ашыкты Рәсим. Кичке якта кызга хат язарга утырды...

«...Үзем укыган мәктәпнең директоры мин хәзер. Ул мәктәп сина да чит түгел бит. Анда йөреп укыган чакларынны онытмагансыңдыр, шәт...

...Алдагы жәйгә корган планнарым зурдан. Жәйге каникул вакытында сезнен тарафка сәфәр кылырга ниятлим... Аерылышуыбызга өч ел тулды бит. Ничек

түзеп үткәрдек икән бу гомерне?! Уйлыйм да үзебезнен чыдамлылыкка аптырап куям. Күрешү көннәрен канатланып көтеп торам...» — дигән юлларны тезде егет. Беренче эш көннәрендә алган тәэсирләре, гаилә хәлләре турында да язды, соңгы яңалыкларны житкерде...

Хатны конвертлагач, Оксананың үзен күреп сөйләшкәндәй жиңел булып китте Рәсимгә. Өйдә кеше юклыктан файдаланып, көйләп тә куйды:

...Айга менеп, түбән карап,
Сине күрәсем килә...

Хисапчы Салихны иртәгә районга бара дип ишеткән иде Рәсим.Тизрәк китсен өчен, хатны аның артыннан биреп жибәрүне мәслихәт күрде.

— Синең арттан хат жибәрмәкче идем, районда почта тартмасына салмассың микән? — диде ул, утынлыкта протез кулына кыстырып казык очлап торучы Салих белән исәнлек алышкач.

— Хахул кызына сәлам озатуны? — диде хисапчы, уң күзен хәйләкәр кысып.

— Кемгә булсын тагын! — Яшермәде Рәсим. Оксана белән ике арадагы бәйләнешне авыл белә. Сер саклаган булып кылануны урынсыз саналы егет.

— Китүенә шактый булды, бер карасаң. Шул сары маржаны тәки онытмыйсың, — диде Салих, бу юлы житди төс белән.

— Сары түгел иде бит, Салих абый. Үзебезнең татар кызларына тарткан: соры күзле, кара чәчле, ак йөзле...

— Болай гына әйтүем. Украин кызларын беләм мин. Ул тирәдә сугыштым бит. Күрдем аларны, — диде хисапчы, аркасын турайту өчен инсәләрен киереп.

— Хатны салырга вакыт табарсың, шәт?

— Табармын. Йомышым күп түгел, Галәвиевне күрәсем бар.

— Андый кешегә дә йомыш төшәмени? — диде Рәсим, көлемсерәп.

— Вакыты белән төшә икән. Урман очы урамдагы Хәйрулла агайның лапасыннан сарыгын урлаганнар. Ишетмәдеңмени?

— Юк. Урлаучысын беләсең әллә?

— Белмим. Шулай да шигем бар. Күрмәгән-белмәгән кешенең эше түгел. Урманга казыклыкка баргач бер шәүлә күргән идем. Ныклап танымадым, әмма күңелгә шик йөгерде.

— Кем булырга мөмкин инде?

— Сиңа сер итеп әйтәм: Сафетдин түгел микән? Икеләнебрәк, билгеле... Авылга ныклап зыян сала башлавы бар. Укытучы кызга ухталганны, башкага ябышмас, дип кем әйтә ала?

— Ышанып булмый, әлбәттә. Шигеңне районга житкерү хәерледер, минемчә.

— Мин дә шул фикердә, — дип яшь директорны озатып калды Салих...

Сафетдин озак яшеренеп йөри алмады, аны Шомыртлының ферма каравылчысы Кашшафетдин абзый «тотып бирде»...

«Кашшафетдин абзый каравыллаганда бур түгел, бүре дә фермага якын килә алмый», — дип Шомыртлы халкы тынычланып яши иде. Менә ничә еллар колхозның терлек торакларыннан эре мал түгел, сарык бәрәненен дә югалганы булмады.

Каравылчының мылтыклы булуын белгәч, урлашырга килергә куркырлар, дип, Кашшафетдин каравыл өендә йокы кабартып яту ягында түгел. Төн чыкканчы ихата тирәсен берничә кат әйләнеп чыга, тораклар эченә колак сала, малларның үз-үзләрен тотышларын күзәтә.

Чираттагы тикшерүен Кашшафетдин сарыклар лапасыннан башлады. Бу юкка түгел иде. Каравылчының сизгер колагы абзар эчендәге сарыкларның өркүдән тынгысызлануларын абайлап алды. Утар капкасыннан кереп, берничә адым атларга өлгермәде, торакның теге башындагы капкасыннан кемдер сарык сөйрәп килеп чыкты. Кашшафеттин шул якка ашыкты, мылтыгын җайлап тотып, сөрән салды:

— Тукта, иблис! Атам!..

Кая туктау! Бур, хайванны ташлады да, арт капкага таба йөгерде.

Каравылчы әмерен янә кабатлады:

— Тукта, диләр сина! Югыйсә, берсүзсез атам...

Бу юлы да анын боерыгы бурга тәэсир итмәде. Түземсезлеген югалткан Кашшафетдин бер көбәктәге патронны һавага атты. Файдасы тимәде. Угры йөгерүен дәвам итте. Менә ул капкага ук якынлашты. Аны ачарга өлгергәнче, каравылчы икенче көбәктәге патронны бурның билдән түбән өлешенә төбәп атып җибәрде.

Егылмады карак. Алпан-тилпән килеп, капкага асылынды. Бераз якынаю белән, каравылчы бурнын кемлеген абайлады. Качкынлыкта йөрүче Сафетдин иде ул.

— Харап иттен, абзыкаем, — диде Сафетдин көч-хәл белән.

— Ә нигә качасың? Әйткәч, туктарга иде. Юньле бур була белергә дә кирәк. Минем кулдан ычкына алмасынны чамаламадынмыни?

— Чамаламаганмын инде. Мылтыгың бардыр дип белмәдем шул, — диде Сафетдин, ынгыраша төшеп.

— Ярый, түз. Бүлнискә илтү ягын карарбыз, — диде аңа каравылчы.

— Юк, юк, кирәкми, — диде Сафетдин.

— Кирәкми дип, синең арттагы тозны мин чүпләмәм бит инде. Бүлнистә жылы суга утыртырлар, даруларлар да аякка бастырыр, — дип Кашшафетдин китеп барды. Колхоз идарәсенә кереп, авыл советында кизү торучы хатынга шалтыратты. «Мин Сафины тоттым, Исхакка әйт, ат жигеп, тиз арада килеп житсен», — диде.

Ике сәгать узмагандыр, Исхак белән Хәкимжан Шомыртлыда иделәр. Кояш офык өстеннән шактый күтәрелергә өлгергән иде инде. Сафетдиннен хастаханәгә кадәр утырып барырлык рәте юклыгын чамалап, тарантасны туарып арба жиктеләр. Шул арада орган вәкиле Габсаттар Галәвиев тә пәйда булды.

— Эләктенме, бандит? — диде Габсаттар, беренче сүзе итеп.

— Эләгүен эләкте дә... Катырак эләккән шул әле. Кашшафетдин абзый арт ягын тозлаган бит, — диде Исхак, эшнен бераз чамасызракка китүен аңлатып.

— Тоз белән аттынмыни? — диде Галәвиев, карашын каравылчыга юнәлтеп.

— Шулайрак шул...

— Бер көбәгеннән генә аттынмы?

— Әйе.

— Икесеннән берьюлы тондырасың калган, — дип хуплады милиционер каравылчынын гамәлен.

... Сафетдин яткан арбаны озатып, Габсаттар районга китеп барды...

***

Рәсим кайтырга жыенганда гына бүлмә ишеген шакыдылар.

Ишектә элекке директор Фаяз Саттаров күренде.

— Тәрәзәдә ут күреп, керәсе иттем. Көне-төне эшләсәң дә эшнен беткәне юк, егетне кайтарып жибәрим, дип кагылдым, — диде ул, гадәтенчә кет-кет көлеп.

— Дөрес әйтәсең, Фаяз абый, эш бетә торган түгел, — дип килеште Рәсим остазы белән.

— Әлбәттә, шулай, — диде өлкән мөгаллим дә, — берәүләр үзләренә үзләре эш табалар, икенчеләрне кушып та эшләтеп булмый. Төрле характердагы бәндәләрдән торган коллективны җитәкләүнең кыенлыгы да шунда инде. Өч конверт турындагы анекдотны юкка чыгармаганнардыр...

— Нинди өч конверт ? — дип кызыксынып сорады егет.

— Үзе киткәндә, урынына билгеләнүчегә өч конверт калдырган директор турындагы мәзәкне ишеткәнең юкмыни?

— Юк.

— Аның эчтәлеге менә шулай... Директорны алыштырганнар. Ул алмашчысына өч конверт тапшырган. «Тырышып та хикмәт чыкмаса, беренче конвертны ач, анда язылган киңәшне тотып кара. Алай да булмый икән, икенчесен ач. Һаман үзгәреш ясалмаса, өченчесен ачарсың», — дигән... Тырыша яшь директор, әмма хикмәт чыкмый. Аптырап, беренче конвертны ача. Анда: «Кадрларның урыннарын алыштырып кара», — дип язылган икән. Шулай кылана директор. Бераз файдасы да күренә, тик көтелгән нәтиҗәгә ирешелми. Икенче конвертны ача ул. Монысына: «Бөтен гаепне мина сылта», — диелгән икән. Җыелыш саен иске директорны сүгә яна хужа, тетмәсен тетә, ләкин барыбер алга китеш күренми. Аптырап, өченче конвертка тотына директор. Ә анда: «Өч конверт әзерлә», — дип язылган. Менә, бөтен эчтәлеге шул аның, — диде Саттаров, җинелчә елмая төшеп. Рәсим рәхәтләнеп көлде.

— Акыллы мәзәк бу. Мина сабак өчен сөйләвеңдер, Фаяз абый. Рәхмәт акыл бирүенә, — диде егет, тынычлана төшкәч.

— Гаепле күрмә мин картлачны. Якын итеп сөйләвем генә. Син конвертларга мохтаҗ егет түгел.

— Берниндн гаеп-үпкә юк. Һәр мәзәкнең төбендә хикмәт ята. Аны кабул итә белергә генә кирәк.

— Килешәм. Тик ул һәркемнең гадәтеннән килми.

— Бу ягы бар...

— Сөйләштек-аңлаштык, дигәндәй, әйдә, алып кайтам, — дип Саттаров урыныннан күтәрелде.

— Бүген мин сезнең якка түгел, авылдан урап килү исәбендә идем.

Алар урамга чыктылар. Кул кысышып саубуллашып, икесе ике якка китеп бардылар. Бүген Рәсимнең күнеле хат көтә. Авылга кайтырга уйлавының да бер сәбәбе шул иде.

***

Салих районнан байтак яналык ишетеп кайтты. Хастаханәдә яткырганнан соң, Сафетдинне кулга алганнар. Элекке көяз офицер Алтаф Хажиев районнан киткән. Хисапчы бу хәбәрләрне колхоз идарәсе бинасына килгән ирләр алдында сөйләде. Алтаф, Хажиның аерган хатыны Гашиягә өйләнгәнлектән, аның турындагы яналык тынлаучы ирләр арасында кызыксыну уятты.

— Үзе киткәнме, әллә куып җибәргәннәрме? — Әүвәлге сорау шул иде.

— Икесе бер чама кебек. Бюрода каты шелтә чәпегәннәр, этлеге булган бугай, — диде Салих, белгән кадәресен әйтеп.

— Төп сәбәбен белмәденме?

— Каян белим? Бюрода катнашмадым бит. Сөйләүләренчә, хатын-кыз белән мәрәкәләнгән бугай.

— Хактыр. Кәнтәйләнергә ярата торган бәндә. Сугыш елларында да кимен куймады...

Көтмәгәндә Хәкимҗан килеп керде. Куерып барган әңгәмә тынып калды. Рәис алдында гайбәт куертып утыруны урынсыз санап, ирләр идарәдән берәм-берәм чыгып киттеләр.

— Нинди йомыш белән йөриләр иде? — дип сорады рәис, идарә тынып калгач.

— Алтаф белән кызыксыналар.

— Нәрсәсе белән кызыксынасын инде анын? Киткән — беткән, — диде Хәкимҗан, кул селтәп. Бу яналыкны ул телефоннан сөйләшкәндә Салихка кадәр үк ишеткән иде. — Ә син үзен кайчан кузгаласын сон?

— Аптыраган. Аяк тартмый тора. Нигездән кубарыласы килми, — дип җавап кайтарды хисапчы.

— Әллә ничә тапкыр шалтыраттылар. Әйтерсен, мин җибәрмим сине. «Ихтыяр үзендә, минем тарафтан каршылык юк», — дидем инде.

— Дөресе шул инде...

— Ризалашу хәерледер, Салих. Күтәрелүгә каршы килмә син. Колхозга кайтырга кайчан да житешерсен. Районнын барлык хисапчыларына башлык булачаксын бит.

— Анысы шулай. Күченү мәшәкате жиксендерә.

— Акрынлап жае чыгар. Шуны уйла: балаларын үсә, аларны укытырга кирәк. Институтка керәм, дисәләр урысча укыту хәерле бит. Үзәктә монын өчен жай бар.

— Хатын да шулай сукалый.

— Тынла аны. Китү ягын кара, — диде Хәкимҗан, сонгы кинәшен әйтеп...

...Салих Баяновны район жир бүлегенә инструктор-бухгалтер итеп эшкә чакыралар иде...

**Өченче кисәк**

Күпләр ышанырга теләмәгән, шулай да халык арасында телдән-телгә күчеп сөйләнелгән яналыкны гамәлгә ашырырга керештеләр — колхозларны эреләндерү матавыгы башланды. Берьялгызы бер колхоз булып яшәгән авылларны кушудан тотындылар бу мәрәкәгә. Халык теләгенә каршы килеп, өстән житкерелгән күрсәтмә нигезендә алып барылды мондый әвеш-тәвешлек. Күп еллардан килгән бердәмлекне жимерү — тату гаиләдә көтелмәгәндә килеп чыккан аерылышу белән бер булачак. Ләкин түрәләр алай уйламый. Алар өчен халык фикере барни-юкни. Берләштерү күрсәтмәсен әштер-өштер үтәп, өстән бурыч төшерү, сүзгә менмәү, әрдән котылу — алар өчен ин мөһиме әнә шул...

...1948 елнын язында Тимәк мәктәбе директоры Рәсим Нәбиевне армия хезмәтенә алдылар. Егерме сигезенче елда туганнарны кырып-себереп жибәрделәр. Аланбаштан бары Исхак кына калды. Анда ниндидер чир таптылар. Сугыштан сон хәрби хезмәткә беренче чакырылыш иде бу.

Республика хәрби комиссариатында карау үткәннән сон, Рәсимне авылдашларыннан аердылар. Кыска сроклы училищеларда укыту өчен институт тәмамлаучылардан махсус группа тупладылар. Андый егетләрнен саны дистәгә генә якын иде. Икенче көнне аларны поездга утыртып, Көнбатыш юнәлешкә алып киттеләр. Юлда барганда, аларны алырга килгән офицер училищенын Украина белән чиктәш Белгород өлкәсендә икәнлеген әйтте. Укытып чыгаргач запаска жибәрү өчен офицерлар әзерлиләр икән анда. Хәрби хезмәткә калдыру очраклары да була икән.

Училищенын Украинага чиктәшлеге Рәсим өчен сөенечле яналык иде. Оксана белән күрешү өчен көтелмәгән мөмкинлек туа түгелме сон? Аралар

якынаеп та очрашмый калсалар, гафу ителмәслек хәл булыр, билгеле... Ул көннен килеренә икеләнми хәзер егет. Күнелдә туган якты уйлар тәнгә жинеллек индергәндәй булды. Бу группага эләгүе өчен язмышына рәхмәт укыды ул...

Уку жинелдән түгел иде. Курсантлар бер ел эчендә өч елда үтеләчәк программаны үзләштерергә тиешләр. Алар авиация техниклары белгечлеге алып чыгачаклар, часть командирынын политик тәрбия эшләр буенча урынбасары дәрәжәсен биләргә дә мөмкиннәр.

Укулардан сон туган беренче буш арада Рәсим хат язу ягын карады. Әүвәлгесен Оксанага исемләде.

«...Безнен ара якынайды. Украинанын борын төбенә килеп хәрби белем үзләштерергә керештек. Офицер ясамакчылар безлән. Бер ел укыячакбыз. Күрешербез дигән өметтә торам... Сагынуымнын чамасын анлатыр сүзләр юк инде...»

Хатнын үзәк өлеше шушы фикердән гыйбарәт иде. Жавап көтү көннәре генә озакка сузылды. Анын сәбәбен ничек юрарга белмичә, зар-интизар булып йөргән көннәрдә, ниһаять, Оксанадан хат килеп төште. Киевта ике ай буена практика узган икән кыз. Хатны вакытында алып, жавап жибәрә алмаган. Хатны озын язган иде Оксана. Рәсим рәхәтләнеп укыды, сагынуы басыла төшкәндәй булды.

«...Рәсимкәем, укулар башланганчы, бер жай чыгарып, синен янга, һичшиксез, барам. Мондый унайлы мәлдә дә күрешмәсәк, тагын кайчан жай чыгар?..

Мине Франциядәге сәүдә вәкиллегенә тәржемәче итеп жибәрмәкчеләр. Читтән торып укуга күчәргәме, әллә шунда баргач укыргамы, дип торам. Әлегә төпле фикерем юк. Бу хакта очрашкач сөйләшербез...»

Хатнын калган өлеше сагыну, ярату хисләреннән торган юллар белән тулы иде. «Алдагы тормышымны синсез күз алдына китерә алмыйм...» — дигән сүзләр Рәсимнен йөрәгенә сары май булып ятты.

Ара якын булганлыктан, хатлар тиз йөрде. Оксана фоторәсемен жибәрде. Аны алган көнне Рәсим рәсемнән башын күтәрә алмады. Ул күргән-белгән Оксана түгел иде рәсемдә. Житлеккән, артисткаларга биргесез чибәр. «Менә ул мин!» — дип үз дәрәжәсен белеп басып тора иде кыз. Гүзәлләрнен-гүзәле, сихри матурлык иясе шул анын Оксанасы...

...Көтмәгәндә хат килү тукталды. Рәсим пошаманга төште. Киткән тәкъдирдә барыбер хәбәр салырга тиеш иде кыз. Нәрсә булды? Аптырашта калды егет. Билгесезлектә үткән бер ай бер ел тиненнән тоелды. Ярый, кош теле хәтле телеграмма китереп тоттырдылар үзенә. Оксана жибәргән.

«Гафу ит, көтмәгәндә китеп бардым. Кайттым. Бер ай өйдә торам, хат язармын», — диелгән иде кечкенә кәгазь кисәгендә.

Күпмедер тынычланды Рәсим. Оксанадан хәбәр килмичә торып, хат язарга уйламады. Жавапсыз калган хатлары болай да житәрлек иде. Шулай да анын кыз тормышында булган сонгы үзгәрешләр турында ныклап беләсе килә. Тик Оксана, нигәдер, алар турында житкерергә ашыкмый әле. Хат килү тагын тукталды...

Занятиедән чыгып, нигә тотынырга белмичә аптырап торганда, Рәсимне тышка дәшteләр — капка янындагы контроль-пропуск пунктына килергә куштылар. Билгесез шатлык тойгылары белән шунда ашыкты егет. Кереп-чыгып йөри торган аралыкнын тышкы ягында басып торган, хыялында фәрештәгә санаган кадерле затны күргәч, йөрәге сөенечтән туктап калгандай булды. Читят күзләрдән дә оялып тормады, йөгереп чыгып, Оксананы биленнән кочып күтәреп, күкрәгенә кысты, кызны бөтерә башлады.

— Житте, Рәсимкәем, башым әйләнә, — дигәч кенә, анга килеп, кызны жиргә бастырды. Кочагыннан чыгармады, анын битеннән, иреннән үбүен дәвам итте. «Курсант Нәбиевнен хатыны килгән», — дип, Рәсимнен шатлыгын уртаклашкандай, сөйләнеп алдылар тамашаны күзәтеп торучы курсантлар.

Оксананы кизү торучы солдат янында калдырып, күрешү өчен рөхсәт сорарга взвод командиры янына йөгерде Рәсим. Кабаланудан тыны кысылган егет килү сәбәбен көч-хәл белән анлатып бирә алды. Ярты ел тирәсе генә хезмәт иткән солдатны юллап йөрүләренә гаҗәпсенеп, командир сорады:

— Кемен килгән соң синен?

Тиз генә борылып чыгарга уйлаган егеткә хәлнең асылын анлатып бирергә туры килде.

— Тарихи очрашу икән шул. Ял мәсьәләсендә минем каршылык юк. Сиңа ике көн кирәк булыр бит?

— Ике көн эләксә, искитмәле чыгар иде, — дип сөенечен яшерә алмыйча әйтте Рәсим. Бу чаклысын көтмәгән иде ул.

— Командир белән килешергә кирәк инде. Аның янына кереп чыгыйм, — дип капитан урыныннан күтәрелде.

— Кызның чит илгә китәсен дә җиткерсәгез иде. Янадан күрешүнең тиз арада булмаячагын искәртеп инде, — дип үзенә калганда мөһим санаган сылтауны җиткерде Рәсим.

— Әлбәттә инде...

Капитан начальник яныннан тиз әйләнде.

— Булды, — диде ул, кереп килешкә, — ике көнгә рөхсәт итте.

— Рәхмәт, иптәш капитан.

— Ярар! Нәрсә ул чаклы... Старшинадан рөхсәт язуы тутырт та китү ягын кара, — дип взвод командиры Рәсимне озатып калды.

...Шәһәр кунакханәсеннән бүлмә алып, ике тәүлекне шунда үткәрделәр яшьләр. Көндезләрен шәһәр таптадылар, киногa керделәр, паркта йөрделәр, цирк карадылар, калган вакытлары бүлмәдә узды. Ике көн эчендә генә бушатып бетерерлек түгел иде аларның сүзләре...

Ике көн!.. Мәхәббәт ялкынында дөрләгән йөрәкләр өчен ике көн вакыт бер мизгел сыман үтте дә китте. Бу — аларның дүрт елдан соң беренче һәм озак елларга сузылачак аерылышу алдыннан соңгы тапкыр күрешүләре иде...

***

...Бер елга исәпләнгән укуларны ике айга кыскарттылар. Лейтенант дәрәҗәсе биреп һәм техник дипломы тоттырып, Ерак Көнчыгышка җибәрделәр.

Мәскәүдә яшь лейтенантларны бүлгәләделәр. Рәсим эләккән төркемгә Читага китү өчен приказ җиткерелде. Бу шәһәрнең соңгы нокта түгел икәнлеге дә мәгълүм иде. Йә Монголиягә, йә Кытайга чыгарачаклар аларны.

Чикне үткәнче кисәттеләр: чит илгә чыгу турында хәбәр итмәскә, айга бер тапкыр хат язарга, торган урынны күрсәтмәскә. Конвертта хезмәт иткән частьның номеры гына күрсәтелергә тиеш. Рәсим чикне чыкканчы якыннарына «Еракка озаталар, тиз генә хат көтмәгез», — дип хат салып өлгерде.

Рәсим истребительләр дивизиясендә хезмәт итә башлады...

Ара ераклашкач, Рәсим белән Оксана арасында хат алышу тукталу күрчегенә килеп терәлде. Кызның Франциядән җибәргән хатын, СССРның буеннан-буена үткәреп, чит илдәге хәрби частька кертү яки, киресенчә, Кытайдан анда хәбәр ирештерү турында уйлыйсы да юк. Яшь йөрәкләр шулай да аралашу җаен таптылар. Оксана Рәсимгә аталган хатларын әнисенә салды, ә Софья аларны егеткә озатты. Җавап хатлары да шул юнәлеш буенча йөреп торды.

Соңгы хатны Оксана әнисе янына кайткач язып җибәргән иде. Аларның гаилә тормышында үзгәреш килеп чыккан. Электән үк аралашып йөргән, Оксананың әтисенең дусты белән Софья никахка кергән. Кыз шул турыда хәбәр иткән иде.

«...Рәсим, безнен гаиләдә ишәйде, әни кияүгә чыкты. Әнинен никахка керүен хупладым. Кырык яшенә генә аяк баскан бит әле ул. Әти белән нибары дүрт ел торып калган. Үз бәхетен таба күрсен, дип кенә телим. Хәзер мин әни өчен тыныч. Хәтәр тату яшәп яталар...

Сина тагын бер сер ачыйм инде: сина ике тамчы су кебек охшаган малай үстереп ятабыз. Ренат атлы куйдык. Чорсыз үзе, чукынчык. Шулай да өзелеп яратабыз...»

Хатны укып чыккач, Рәсим гажәпсенеп уйлап куйды: Софья апа шул арада мина тартым малай да алып кайтырга да өлгергән икән ләбаса!.. Ике елдан армия хезмәтеннән бөтенләй котылам, дип хыялланып йөргән Рәсим бары тик чираттагы ялын гына ала алды. Жәйге көн иде. Хәрби форманы чемоданга салып, гражданский киемнән юлга чыкты. Биредә хезмәт итүчеләргә хәрби киемнән күренергә рөхсәт юк. Чикне чыккач нәрсә кияргә теләве офицернын үз иркендә.

Алган хатлары буенча Рәсим атасынын сәламәтлеккә туймавын белә иде. Әмма артык мөшкелләнгәндер дип күз алдына китермәде. Сафа нык бирешкән, ябыгунын чигенә чыккан — как сөяккә калган, алга нык сөрлеккән. Рәсим белгән-күргән кин жилкәле, тулы гәүдәле, йөгерешчеләргә хас житезлек белән хәрәкәтләнүче элекке Сафанын әсәре дә калмаган.

— Сине күрмичә китеп барам, ахыры, дип өметне өзгән идем, Ходай Тәгалә насыйп итте күрешергә, — диде ул, как сөяккә калган кулын яткан жиреннән улынын кин учына салганда.

— Китәргә ашыкма, әткәй, бергә-бергә яшәргә язсын әле, — диде Рәсим, атасын күнелсез уйлардан арындырырга теләп.

— Рәхмәт сүзләренә... Көннәрем санаулы инде, улым. Әжәл чире сугылды, — диде Сафа, өметсезлек пәрдәсе ябылган битенә әллә елмаю, әллә сызлану чаткысы чыгарып.

— Улым, озак сөйләштереп, атанны хәлсезләндермә. Бераз ял итсен. Сине күрүдән болай да нык дулкынланды, — дип, Фәния Рәсимне әтисе янынннан кузгатты. — Самавыр да кайнады, хәзер чәйләп алырбыз... Синен кайтуын хакында Тимәккә хәбәр жибәрдек, өчәүләп килеп тә житәрләр.

— Ничек өчәүләп? — дип уйлап бетермичә сорады Рәсим.

— Өчәү булганга өчәү. Син барда тәпи генә баскан Гүзәлебез зур кыз инде хәзер, — дип горурланып жавап кайтарды ана.

— Аларнын хәле ничек? — Кияве һәм сенлесе турында соравы иде.

— Әйбәт. Камил синен урында. Хамия укыта. Гүзәл бакчага йөри.

— Безнен авылда бакча бармы?

— Бакча түгел, колхоз юкка чыкты инде. Авылларны кушкач, читтәгеләрендә рәт-чират гел бетте. Хәзер бөтен нәрсә колхоз үзәгендә, — дип көрсенеп жавап бирде ана.

Рәсим эндәшмәде. Сүз куертып, кәефе кырылган ананын яралы күнеленә тагын жәрәхәт өстисе килмәде. Авылнын бетә баруына сыкрануларын хатта язганнар аша да белә иде инде ул. Ярымпышылдауга күчеп, атасынын кайчаннан өзлегүе, табибларнын нинди карашта торулары турында сорашты. Сафа район хастаханәсендә дә яткан, Казанга да алып барганнар, әмма хикмәт чыкмаган. Ярдәм күрсәтүдән узган, дигәннәр табиблар. Фәния улынын соравына каршы шул сүзләрне әйтте.

Күрешүдән шатлыклы хисләр туар урында, әжәл белән тарткалашучы атасына ярдәм кулы суза алмаудан туган йөрәк сызлаткыч ачы тойгы биләп алды Рәсимне. Әтисенен көен көйләп, көне буе чабулаган әнисен дә кызганды.

— Үзенне сакларга тырыш инде, әнкәй. Аяктан егыла күрмә, — диде Рәсим, чәй өстәле артыннан кузгалганда.

— Сакланам, дип нишлисең инде? Чир сорап килми. Кагылганын сизми дә каласын. Әткән дә жир жимердәй булып йөргән килештән тәгәрәде дә китте. Зәхмәт сукты диярсең, — диде ана, күз төбеннән бәреп чыккан яшь бөртекләрен яулык очы белән сөртеп.

Күзләре дымланса да еламады Фәния. «Ялгыз калган чакларында өзгәләнеп елаудан күз яшьләре дә корып беткәндер инде», — дип анасын янә кызганып уйлап куйды Рәсим.

Кичке унайда, Гүзәлне ияртеп, Хамия белән Камил килеп житте. Өйдә бераз юанганнан соң, Рәсим белән Камил бакчага чыктылар. Кияү кеше бер шешә «зәмзәм» суы кыстырып килгән иде. Авыру янында авыз күтәреп эчеп утырудан кыенсынып, аулакта сөйләшә-сөйләшә «чеметкәләп» утыруны мәслихәт санадылар.

Рәсим мәктәп хәлләре турында сораштырды. Ул киткәннән соң байтак үзгәрешләр булган: кайберәүләр киткән, яналары килгән. Камил читтән торып институт тәмамлаган. Анын укуы хакында белә иде инде Рәсим.

— Хәзер районда шундый хәрәкәт бара: урта һәм жидееллык мәктәп мөгаллимнәре югары белемле булырга тиеш, дигән максат куелды. Мәктәптә эшләргә телисен икән — укыйсын. Укымасаң — китәргә мәжбүр итәчәкләр, — дип белем алуга карата таләпчәнлекнең артуы хакында әйтте Камил.

— Минемчә, начар таләп түгел, — дип хуплады Рәсим районда күтәрелгән бу башлангычны.

— Әлбәттә...

Элекке директор Фаяз Саттаров турында сораштырырга да онытмады Рәсим.

— Бирешә инде. Мәктәпкә сирәк кагыла. Элек көн аралаш диярлек килә иде, — дип жавап бирде Камил сорауга каршы.

— Килә алмаса, үзегез барыгыз. Ул күбебезнен укытучыбыз бит. Остазны онытырга ярамый. Ярдәмне дә кызганмагыз, — дип басымлап әйтте Рәсим.

— Ташламаска тырышабыз инде...

...Камилләр каранңы төшәр алдыннан кайтып киттеләр...

Иртән улы уянганчы Фәния иренә дарулар эчереп, тамагын туйдырырга житешкән иде. Рәсим торып чәй эчте дә районга барырга жыенды. Учетка керү өчен хәрби комиссариатка керәсе бар. Офицер формасын киде. Иненә хәрби кием салгач, егет бөтенләй үзгәрде, олпат кыяфәт алды. Ата кичәге килештән кыймылдамаган төсле ята иде, берара тамагын кырды, нәрсәдер әйтеп куйды. Көзге алдында чәч тарап торган килештән Рәсим атасы ягына күз салды. Сафа, ун кулын күкрәк өстенә куеп, хәлсез бармакларын селкеп, улын үз янына чакыра иде.

— Хәерле иртә, әткәй. Тынлыйм сине, — диде Рәсим, атасы ятагына якынлашкач.

Ата сүз катмады, бары тик баш бармагын югары күтәреп, елмайгандай итте. Малае белән горурлану, анын өчен шатлану һәм соклану билгесе иде бу. Рәсим иелеп әтисенең кулын учына алды, аны кат-кат үпте. Ата хәлсез кулы белән улының башыннан берничә кат сыпыра алды. Шушы тамашаны күзәтеп торган Фәниянең йөзенә дә жан керде. «Сафа әллә хәлләнүгә барамы? Бүген даруны да эчте, тамагына да капты», — дигән өмет биләп алды аны.

Рәсим капылт күтәрелде дә ашыгып чыгып китте. Менә-менә бәреп чыгарга житешкән күз яшьләрен ата-анасы алдында күрсәтәсе килмәде анын...

Рәсим авылда бер айга якын торды. Ул ялга киткәндә аларнын частен күчерү турында сүз йөри иде. Төгәлен өзеп кенә әйтүче булмады. «Утсыз төтен чыкмый», — дигән гыйбарәне искә алып, Рәсим, Оксананын хатларын жибәрми

торырга кушып, Софья Петровнага хәбәр җибәрде, частьның адресы үзгәрү ихтималы барлыгын искәртте...

Рәсим авылда чакта могҗизага тиң хәл килеп чыкты. Табиблар кул селтәгән, хәтта хатыны да терелеренә өмет өзгән Сафа утырып тора башлады. Бераздан аягына басып, өй эчендә атлаштыра, кешеләр ярдәмендә ишек алдына чыга алды.

— Улыкаем, алданрак кайтсаң, атаң әллә кайчан аякка басасы булган икән. Синең күзгә-башка күренүеңне генә көтеп яткан, — диде ана, сөенеченнән нишләргә белмичә.

— Минем катнаш юк монда, әнкәй. Сихәтләнә башлау вакыты җиткән, — дип Рәсим анасының өметен кочәйтергә тырышты.

Рәсим киткәндә Сафа капка төбендәге утыргычта утырып, кул болгап озатып калды. Егет Казанга самолет белән очты. Почта йөртүче аэропланның кайтышлый бер пассажир алу гадәте бар иде, ул шул җайга эләкте.

...Атналар буена поездда җилгәрелеп, талчыгып барып җитте Рәсим хезмәт урынына. Куерган сүзләрдә хаклык булган икән. Частьны тулысынча күчермәсәләр дә, бертөркем офицерларны каядыр җибәрергә әзерлиләр иде. Кемнәрне сайлыйлар, кая җибәрәчәкләр — бу кадәресе әлегә мәгълүм түгел.

Билгесезлек озакка сузылмады, группаны тупладылар. Ана төрле чиндагы хәрбиләр кергән иде. Рәсим Нәбиев тә шулар арасына эләкте. Җыенырга вакытны кыска бирделәр. Гражданский киемдә юлга кузгалдылар. Поезд Урта Азия юнәлеше белән теркелдәде. Союзда калмаячакларын тиз чамаладылар. Шулай килеп чыкты: хәрби йөк самолеты белән аларны икенче континентка — Африкага очырдылар...

...Өч айдан соң Аланбашка һәм бераз соңрак Софья Петровнага коры сүзләрдән генә торган хатлар килеп ирешә. «Хезмәт әйбәт бара, исән-сау, ашау муллан... Көннәр бик эссе, безнең халык чыдый торган түгел...» — дигән сүзләрдән башка әһәмиятле яңалык юк иде. Оксанага аталган хат та ике гашыйк арасында йөргән язмага тартмаган иде. Софья Петровна хатның ахырына: «Таләп каттыйдыр, югыйсә, Рәсим гомердә булмаганча язмас иде. «Эссе» сүзенә игътибар ит, шуннан да аның кайда икәнлеген чамаларга мөмкиндер», — дип өстәде...

***

Ике айдан соң Сафаның гәүдәсен җир куенына иңдерделәр. Улы кайткач хәлләнеп киткәндәй тоелса да, сәламәтләнү түгел иде ул, үлем алды исереклеге кереп аякка басу иде. Кабат урынга ятмады, кыштырдап йөргән җиреннән җан тәслим кылды.

Тышта көзнең матур көннәре тора иде. Аяз, җылы булуга карамастан, иңсәсенә кыска тунын салып, Сафа капка төбенә чыкты. Улын озатканнан бирле ул көн саен бирегә утыра. Күңеле белән улын көтә. Эре адымнар белән урам буйлап атлап, затлы хәрби кием кигән Рәсиме менә-менә кайтып килер шикелле.

Сөйләшергә маһирлыгы гел бетте Сафаның. Соңгы вакытта сүзгә күренеп саранланды. Үзе сүз әйтми, башкаларны гына тыңлый ул. Сөйләгәнне ничек кабул итүен аның йөзеннән чамаларга мөмкин. Әгәр кайсыдыр фикерне кабул итми икән, кашларын җыера, йөзен читкә бора, күңеленә якын алган сүзләргә елмаерга тырыша.

Капка төбеннән кергәч, Сафа ятагына утырды, Фәнияне үз янына чакырды. Һич көтмәгән көр тавыш белән:

— Сөйләшик әле, сиңа җиткерәсе сүзләрем бар, — диде.

— Сөйләшмәгән кая ул! Тынлыйм сине, карткаем, — дип Фәния, иренең кәефе күтәрелгәнгә сөенеп, анын янәшәсеннән урын алды.

— Соңгы сүземне житкерәсем килә... Бүтән әллә сөйләшеп була, әллә юк... — диде Сафа, карашын идәндәге бер ноктага текәгән килештән. — Синең киләчәк язмыш турында борчылам...

— Нинди соңгы сүз? Яшибез бит әле! Минем хакта да кайгырасы юк, — дип, хатынның ир күңелендәге яман уйларны куасы килде.

— Әлегә шулай... Көннәрем санаулы. Үзем беләм... Шуны әйтәсем килә: мине жирләгәч, берьялгызың өй саклап, дөнья куам, дигән булып газап чикмә. Рәсим кайтканчы Хамия янына күченеп тор. Ул сине арттырмас. Оныкларны карарсың. Камил кияү дә тар күңелле түгел... Өйне нишләтү хакында бер киңәш тә бирә алмыйм. Рәсим кайтканчы үз урынында торсын... — Сафа тынып калды. Бераз хәл алгач, телгә килеп әйтте: — Үзенә иш табып, соңгы көннәреңә чаклы бергә яши алсаң, шәп булыр иде дә...

— Кая инде хәзер андый бабка керү!

— Мин дә шулай уйлыйм. Рәтле ирләрне сугыш йотты. Ялгыз ирләрнең күбесе аракы күленә кереп батты...

— Бу яшькә житкәч, кабат парлану хакында уйлану урынсыз. Синең кебек кешене каян табасың хәзер?

— Икенче әйтәсе килгәнем шул, — диде Сафа хатынының йөзенә туры карап, — бик рәхмәтле мин сиңа. Ир итеп, сиңа сугып яшәдең. Эчеңдәге борчуларны тышка чыгарып, мине борчымадың... Беренче мәхәббәтең түгел икәнлегемне дә белә идем. Тегүче Фаяз белән ике арада булган мөнәсәбәтеңне дә ишеттерделәр. Көнләшмәдем. Шөкер, матур яшәдек. Балаларыбыз белән мактана алабыз. Кеше алдында кимсенерлек, хурланырлык сәбәп юк... Рәсим теге кызын алам ди икән, каршы төшмә. Улыбыз акыллы, нишләргә кирәген үзе белер... Балалар синең тәрбияңдә үсте. Чын кеше итә алдың аларны... Шуның өчен рәхмәт...

Сафага сөйләшү авырайды.

— Миңа ятарга ярдәм ит, зинһар. Калганын иртәгә сөйләшербез, — дип Сафа урынына сузылды. Стена ягына карап ятты да тынып калды...

Иртәгәсен әңгәмәне дәвам итә алмадылар. Төн уртасында Сафа жан тәслим кылды. Авыл халкы аны соңгы юлга зурлап озатты.

Әтисенең жидесен үткәрү белән, Хамия әнисен үзләренә килергә әйдәкли башлады.

— Үземне карый алганда, ике аягымның берсен дә атламыйм, — дип Фәния тәкъдимнән катгый рәвештә баш тартты.

— Юкны сөйләмә! Көрәк белән казып бәрәңге утыртыр, аны чокып хәлдән таеп яшәр чагың түгел. Һәр көн килеп без дә ярдәм итә алмыйбыз. «Бер ананы сыйдыра алмыйлар», дип, халык безгә рәнжер, — диде Хамия, соңгы дәлилен китереп.

— Тора-бара күз күрер, кызым. Бу кышны шушында чыгам. Әткән рухы рәнжемәсен. Хужа вафатыннан соң нигезне ел үтмичә ташларга кушмыйлар. Ата-бабадан калган гореф-гадәтне үтәргә кирәк, — диде ана, кузгалу турында сөйләшүнең әлегә урынсыз икәнлеген аңлатып.

— Ярый, синенчә булсын. Кыенлаша башласа, күз күрер, — дип кыз анасы әйткәннәр белән ризалашты...

***

Алты егет чыктылар алар урамга. Шәһәрдә берән-сәрән йөрергә рөхсәт ителми. Баштарак ике-өч солдатны берьюлы чыгарып караганнар. Сирәк очракта гына исән кайта алганнар, күбесе хәбәрсез гаип булган. Хәрбилекне

сиздермәү өчен формадан күренү тыела. Гомумән, бирегә килгәннән бирле бер генә хәрбинен дә солдат формасыннан йөргәне юк.

Жирле халык сизгерлек ягыннан эт белән бер: нинди хәлдә дә үзенеке белән читне аера. Кара каргалар арасына юлыккан ак карга шикелле, безнен бәндәләр әллә каян аерылып тора.

Совет хәрбиләренен монда интернациональ бурыч үтәү йөзеннән, ягъни жирле халыкнын азатлыгын, илнен бөтенлеген саклау өчен жибәрелүләрен анларга тиешләр, югыйсә. Андыйлар азрак шул. Күпчелек ярдәмгә килүчеләрне баскыннарга саный, жан дошманы күрә, жае чыкса — үтерә яки әсир алып кол итә...

...Алтау иде алар: ике офицер дүрт солдат. Офицернын берсе — Рәсим. Урам тулы халык — ул кырмыска оясы шикелле кайнап тора. Кемнен кая барганын, нәрсә кылганын анламалы түгел. Каршы килүчеләр белән юл сабышу читен хәтта.

Төркемнен куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен, юлнын аулаграгын сайларга кирәк иде. Алар базар юлыннан читләшеп, штабка пакет илткәндә бара торган тыныч урамга борылдылар. Биредә дә үткән-сүткән житәрлек. Шулай да төп урамдагы шикелле болгавыр түгел. Дингез ягыннан ара-тирә искән дымык жил эсселектән тиргә баткан тәнгә күпмедер рәхәтлек бирә иде.

Штаб урнашкан бинага каләр, күп булса, йөз адым тирәсе ара калгандыр. Анда кергәч, эчтәге жиләс һавада бераз тын алырбыз, дигән өмет белән атлаучы төркем хәвефсез саналган тыныч урында төзәлмәслек фажигагә дучар булды....

Егетләрнен берсе дә чамаламый калды: бер-беренә терәп диярлек салынган ике йорт арасындагы тар аралыктан яшен тизлегендә килеп чыккан озын чапанлы, кара тәнле бәндәне абайларга өлгергәнче колак төбендә автомат тавышы янгырады. Алдан атлаган бишәү шундук жиргә ауды. Арттан атлаган Рәсим пистолетын тартып алырга һәм тәтегә басарга өлгерде, аннан, күкрәген тотып, иптәшләре янәшәсенә тәгәрәде...

Билгеләнгән вакытка пакет килеп житмәгәнлектән, штабтагылар часть белән элемтәгә керделәр. «Алар сездә булырга тиешләр иде инде», — дигән жавапны ишеткәч, гражданский киемдәге бертөркем солдатны килүчеләрне каршыларга чыгардылар. Тышта аларны алты мәет каршы алды. Как жиргә тәгәрәшеп жан тәслим кылганнар. Үтеп-сүтеп йөргән жирле халыкнын алар турында гаме дә юк: яннарына килеп кызыксыну түгел, үләт чиреннән шикләнгәндәй, читләтеп урап үтәләр.

Каршыларга чыгучылар егетләрне таныдылар, аларнын штабка беренче тапкыр гына килүләре түгел иде. Мәетләрне тикшерделәр. Бишесендә жан-тын юк, ә берсенен йөрәге сизелер-сизелмәс кенә тибә иде. Аны дәвалау өчен туган илгә жәһәт кенә жибәрү чарасын күрделәр.

Житез кыландылар, яралыны истребитель белән Бакуга озаттылар, әзерләп куелган икенче самолет аны алып, Мәскәүгә очты. Алты сәгать үтүгә, ни тере, ни үле түгел гәүдә операция өстәленә салынды. Күкрәк читлеген ачып, дүрт ядрә алдылар. Ярый, берсе дә йөрәккә эләкмәгән иде. Шунлыктан гына егет исән калган...

Бер атнадан сон гына егет үз-үзен белешә башлады. Күзен ачуга, ап-ак палатада ятуын шәйләп, аптырап калды: кайда ул, ана ни булган?

Күкрәк ярасынын сулкылдап-сулкылдап сызлавы Рәсимне чынбарлыкка кайтарды. Ут чәчеп торган урамда меннәрчә халык арасыннан бәрелә-сугыла баруы, ике өй арасыннан озын чапанлы бәндәнен пәйда булуы, үзләренә төбәлгән мылтык... бер-бер артлы күз алдыннан үтте.

— Мин кайда? — дип сорады ул, үзеннән ерак түгел караватнынында ни беләндер мәш килүче ак халатлы кыздан.

— Госпитальдә, — дип җавап бирде кыз.

— Кайсы шәһәр?

— Мәскәү. Операция ясау өчен сезне монда кайтардылар.

— Операция кайчан булды?

— Бер атна элек...

Тагын нәрсәдер сорамакчы иде егет, «Сезгә сөйләшергә ярамый», — дип шәфкать туташы бүлмәдән чыгып китте.

Бер атна элек!.. Атна буена һушына килә алмыйча ятканмы ул?

Калку гәүдәле, ак халатлы ир килеп кереп, егетне уйларыннан бүлдерде. Рәсим янына якынайгач, ул:

— Хәлләр ничек, герой? — дип аның кәефе белән кызыксынды.

— Ярыйсы, — диде табибтан күзен алмыйча. Табиб, аның йөрәк тибешен тикшергәч, көлемсери төшеп, әйтте:

— Болай булгач, алга...

— Бүтәннәрнең хәлләре ничек соң? — дип сорады Рәсим, үзе белән бергә штабка барган егетләрнең язмышы белән кызыксынып.

— Әйтә алмыйм. Безгә башка яралыларны китермәделәр, — дип кабаланып чыгып китте табиб.

— Мина операцияне шушы табиб ясадымы? — дип сорады Рәсим, хирургка ияреп кергән баягы кыздан.

— Әйе.

— Ә мин аңа рәхмәт тә әйтмәдем.

— Өлгерерсез. Ятасыгыз күп әле.

— Хирург ни атлы?

— Подполковник Сергей Иванович Колосов...

Госпитальдә ятуына ике ай тулганда Рәсимнең күңелендә яшәүгә өмет уянды. Каләм тотарлык хәлгә килү белән, сөйгәненә хәбәр салды. Җавапны бер айдан соң алды. Озын язган иде Оксана хатны. Кат-кат укыды егет, әмма кызның төп фикерен аңышып бетмәде. Күңелендә сорау артыннан сорау туды.

«...Дүрт айдан артык хат килми торгач, синең исәнлегенә дә икеләнә башлаган идем. Аптырадым-йодәдем дә беразга Франциядә калырга булдым. Бер сәүдә компаниясе белән ике елга килешү төзедем. Аның вәкилләре озакламыйча Мәскәүгә барачаклар. Алар төркеменә, бәлки, мин дә эләгермен. Синең белән очрашуга өметләнеп торам әле...

...Синең нинди фаҗигагә таруың хакында төпченмим, күрешкәч сөйләрсең яки хатта язарсың...

Кызларның күбесе офицерга кияүгә чыгарга хыяллана. Минем өчен дәрәҗә түгел, яраткан кешем булу әһәмиятле...Сине кая җибәрәләр бит әле! Алган белемне файдалана алмыйча офицер хатыны гына булып яту да мактаулы гамәл түгел... Әйдә, бу хакта соңрак сөйләшербез, син чыгып, ныклап урнашкач фикерләшербез...» — дигән юллар Рәсимне аптырашта калдырды, кызның ихласлыгына икеләнә төште.

Оксанага хәбәр җибәрүдән тыелып торуны кулай күрде Рәсим. Билгесезлек томанының таралуын көтте. Сабырсызланып әлләни язып ташлавыннан, төзәлмәслек хата эшләвеннән шөлләде. Шулай да Софья Петровна белән элемтәгә керүне кирәк санады. Ана белән кыз арасында сер уртак, Оксана тормышындагы үзгәрешләрне ана белми калмас, дигән фикердә иде ул. Язып җибәрде егет. Госпитальдән чыккач, үзен нинди язмыш көтүен белмәве турында әйтте. Отставкага җибәрү ихтималы барлыгын да язды. Хатның төп

өлеше Оксанага карата туган икеләнүләрне ачыкларга теләгән сораулардан тора иде...

...Аякка баскач, көннәр акрын үткәндәй тоела башлады. Якын-тирә шәһәрләрдә таныш-белешләре, туган-тумачасы булган яралылар янына килештереп кенә торалар. Аларның вакыты тиз үтәдер сыман Рәсимгә. Кем килсен соң аның янына! Оксаналар белән өйдәгеләрдән башка аның бирелә икәнлеген белүче дә юк. Рәсим беркемне дә көтми. Шуңлыктан, сестра кызның, палатага кереп:

— Иптәш капитан, сезнең янга килгәннәр, — дигән сүзләре аны аптырашта калдырды.

— Кемнәр? — диде ул, кыз әйткәннәргә ышанып житмичә.

— Хәрбиләр. Сезне баш табиб бүлмәсенә чакыралар...

«Бергә хезмәт иткән егетләрдер», — дигән уйга килеп, баш табиб бүлмәсенә юнәлде егет. Ишектән керүгә гажәпсенеп калды: килгән ике хәрбинең берсен дә танымый иде ул.

— Әйдәгез, әйдәгез, — дип гадәттәгедән гайре ачык йөз күрсәтеп чакырды аны баш табиб. Офицерлар өчесе дә аякка бастылар. Полковник дәрәҗәсендәгесе Рәсим белән ике куллап исәнләште.

— Сәламәтләнүегез белән, — диде ул.

— Рәхмәт, иптәш полковник...

Полковник белән килгән майор да, нидер мыгырданып, Рәсимгә кул бирде. Полковник егетне каршысына утыртты.

— Бәхетегез бар икән, йөзлек белән тугансыз... Сезнең алтыгызга да дәүләт бүләге бирү турында указ чыкты. Ул биш мәрхүмнең якыннарына тапшырылачак, ә сезгә бирүне миңа йөкләделәр... Рөхсәт итегез, иптәш майор, сезгә Кызыл Йолдыз ордены тапшырырга, — дип Рәсимнең түшенә орденны беркетте.

— Советлар Союзына хезмәт итәм! — дип үрә катып җавап кайтарды Нәбиев, үлгән биш иптәше турындагы уйлардан көч-хәл белән арынып. Полковник ялгыша, дип уйлап, төзәтмә бирәсе килде: — Иптәш полковник, гафу итегез. Мин капитан...

— Хәзер сез майор. Госпитальдән чыккач, приказ алырсыз, — диде хәрби, көлемсерп төшеп.

Полковник ашыга иде. Рәсимнең тизрәк сәламәтләнүен теләп, урыныннан кузгалды. Табиб Сергей Ивановичка ияреп, Рәсим дә килгән хәрбиләрне озата чыкты...

***

Колхозларны эреләндерү Аланбашны Шомыртлыга кушу белән генә тәгәлләнмәде. Аларга Калмаш, Ызанбаш, Наратлы авылларын өстәп, зур бер хуҗалык барлыкка китерделәр. Колхоз идарәсен, берәүнең дә фикеренә колак салып тормастан, Аланбаштан ундүрт чакрым ерактагы Наратлыга урнаштырдылар. Биш авылны берләштергән җирле совет та шушында күчерелде. Хәзер Аланбаш һәм Шомыртлы кешесе барлы-юклы йомышы белән колхоз идарәсенә яки авыл советына бара икән, озын бер көнен юлда исраф итә.

Аланбаштан авыл советы алыну белән ясле ябылды. Якын-тирә кешеләренең ихтыяҗларын күп еллардан бирле үтәп торган «ут» тегермәнен сүтеп, такта ярдыру өчен, колхоз үзәгенә көйләделәр. Көнозын авылга җан кертеп торган алачык ябылды, авыл күрке булып кукраеп утырган каланча череп ауды. Авылның табыш чыганагы саналган алма, яшелчә бакчалары көтүлек урынга әйләнде.

Берләшү башланганнан соң Аланбаш бер дистә хуҗалыкка кимеде. Өч

гаилә колхоз үзәгенә күченде, икесе районга китте, башкалары, өйләрен сатып, якын-тирә шәһәрләргә авыштылар.

Аланбашта сарыктан башка терлек калмады. Бу фермада дүрт хатын-кыз эшли, ике ир-ат каравыл тора. Авылда ирләр хезмәте бетеп бара. Хәер, хатын-кызларга да урын тарайды. Батырып эшләрдәй егетләр көнлекче хәленә калдылар. Кайда ашап-эчәрдәй эш бар — шуны гына хәстәрләп йөри башладылар. Сугышка кадәр һәм яу барган елларда да аракыга исләре китмәгән ирләр тәҗрибәле эчкечегә әйләнеп бара. Тыныч тормыш башлангач рәхәт яшәргә өметләнгән авыл халкы бетү, бозылу, әхлак нормаларыннан тайпылу юлына басты.

Авылда яшәүнең мәгънәсе вагайды. Эш юклыктан, авылда кызлар кимеде. Кызларсыз җирдә егетләр каламыни?! Алар да шәһәр тирәсенә елышу җаен карадылар. Армия хезмәтен тутырганнарның күбесе авылдан читләште.

Кичләрен тәрәзәләрендә ут балкытып, олыны да, кечене дә үзенә җыя торган китапханә бар иде. Китап укучылар саны җитми, дип, аны да яптылар, чират мәктәпкә килеп терәлде...

Кыскасы, авыл сәясәт томаны арасына кереп югалды — күренмәс һәм кирәкмәс хәлгә төште...

Хәкимҗан авыл хуҗасы булып калды. Шомыртлы белән берләшкәннән соң бригадир итеп сайланган иде, биш авылны кушкач та ул шушы хезмәтен башкаруны дәвам итте. Сугыштан кайткач, ике ел буйдак йөргән Хәкимҗанның өйләнүенә әле генә кебек иде, карасаң, вакыт үткән дә киткән: зур кызы башлангычта укып йөри. Шунысы яман, башлангычлар да хәзер Тимәккә баралар, авылда мәктәп ябылды. Уртанчы малай биш яшькә чыкты, кечесе өч белән бара.

Гаилә ишәя. Яшәү урыны кысан. Аркылысы-буе бишәр адымлы өйдә алты җан кайнашалар. Төннәрен түзмәле. Балалар йоклагач, идәндә йөрер урын табыла. Көндезләрен генә болгавыр — бер-беренә юл сабу читенләшә.

Кысанлыкта гел болай болганышып яшәп булмас дигән исәптән чыгып, Хәкимҗан иркенрәк өй салу ниятенә керде. Бура күтәреп, башка кирәк-яракларны тергезгәч, өйне кайда салу мәсьәләсе борчуга әйләнде. Хуҗага һәм хатынына урын талымлауның кирәге юк. Хәкимҗан өчен ата-баба нигезен ташламау хәерлерәк. Балаларның киләчәге турында уйланганда, Аланбашта калуның мәгънәсе күренми. Урта белем алганчы алар өч мәктәпкә йөреп укырга мәҗбүр булачаклар.

Кечкенә авыллар тиздән гел бетәчәк икән дигән сүзләрнең йөрүе дә Хәкимҗан күнеленә шом сала. Мондый әйтүләргә икеләнергә урын да юк төсле: авыл болай да үзеннән-үзе юкка чыгып бара бит инде. Аланбашка өй салып, ахыргы чутта, берьялгызың утырып калуың ихтимал. Тик барыбер Хәкимҗанның Аланбаштан китәсе килми.

Сеңлесе Тәлига анның күченүен кулай күрә. «Син өй салу белән генә Аланбаш тернәкләнеп китмәс», — диде.

— Китүен китмәс тә, әмма ата-баба нигезен, нәсел-ыру күмелгән җирне калдыру әрвахларның рухын рәнҗетү кебек, — диде Хәкимҗан, икеләнү сәбәбен.

— Бер синең башка төшкән хәсрәт түгел. Бүтәннәр китәләр бит. Дөрес эшлиләр. Керосин лампасы яндырып, утын ягып яшәргә җиксенмәгәннәр генә кечкенә авылларда калырга мөмкин, — дип заманча итеп аңлатты сеңлесе.

— Дөрес сәясәт түгел бу. Көнбатыш илләрдә иген игүчеләр, терлек асраучыларның байтагы хуторларда яши, әмма безнең сыман көн күрми. Халыкның үз ихтыярына куярга кирәк: авылның эресе дә, кечесе дә булсын,

хуторлар да корсыннар, — дип Хәкимжан үз дәлилен китерде. Өстән житкерелгән күрсәтмә нигезендә алып барылган әвеш-тәвешне Хәкимжанның күнеле кабул итеп бетерми иде.

— Кечкенә хужалыкларда хезмәтне механикалаштыру мөмкин түгел. Авыл хужалыгына техника үтеп кермичә торып, азык-төлек муллыгы булмаячак. Муллык тудырмыйча торып, коммунизмның материаль-техник базасын ныгыту турында сүз алып бару урынсыз, — дип аңлатты Тәлига, партия мәктәбендә ятлап кайтканнарын абыйсына житкереп.

— Үскәнем, мин сине аңлыйм. Китапча сөйлисең. Миңа тормышча кирәк. Минем бүген үк кешечә яшисем килә. Балаларымның хәерчелек баткаклыгында быгырдауларын теләмим... Әнә шул хуторлы жирләрдә халык бездәгегә караганда, беләсеңме, ничә мәртәбә әйбәтрәк яши? Белмисең, ә мин беләм, күреп кайттым. Хәтта сугыш вакытында да ачлык күрмәделәр алар... Шулардан өйрәнергә кирәк, — диде Хәкимжан, канәгатьсезлек белдереп.

— Бәхәсләшмик, абзыкай. Ил барыбер алга атлый. Соңгы вакытта гына күпме уңай үзгәрешләр булды! Нибары ун ел үтәр — коммунизмда яши башларбыз, — дип рухланып әйтеп куйды Тәлига, абыйсы белән килешмичә.

— Өй салуны мин коммунизмга чыкканчыга кадәр кичектереп тора алмыйм инде, — диде Хәкимжан, авыз чите белән кинаяле елмаеп.

— Өй салу — синең шәхси эшең. Ана жәмгыятьнең катнашы юк...

— Әнә шул яклары яман шул...

***

Госпитальдән чыккач, Рәсимне Кара диңгез буена бер айга санаторийга жибәрделәр. Килеп урнашу белән ул Софья Петровнага хат язды. «Бәлки, Оксана да кайткандыр. Әгәр Украинада икән, килеп чыкмый калмас», — дигән өмете дә юк түгел иде.

Ни хикмәт, дүрт көннән Рәсим җавап хаты алды. Ул артык озын түгел иде. Бүгенге хәл-әхвалләре турында кыскача әйткәннән соң, кызы турында түбәндәгеләрне житкергән иде:

«Рәсим, Оксана турында аптырап калдым дип язгансың. Мин дә синең хәлдә. Бер хатында ул: «Миңа монда яшәү ошый, жай чыкса, әллә калырмын да. Ир-ат затына да кыргынлык юк», — дип язган иде. Мин жибәргән жавабымда: «Андый уйны башына китермә. Бердәнбер кыз була торып, бердәнбер ананны тилмертеп яшәрсеңме? Бәхиллегем юк», — дип орыштым. Нинди нәтижәгә килгәндер тагын. Бер ай элек кайткан иде, мин үстереп буй житкергән малайны алып китте. Малайны калдырырга күзен кайтмакчы. Әллә үзе дә калыр...»

Элек мондый хәбәр алса, кая барып сугылырга урын тапмас, яшәүнең мәгънәсен югалткандай тояр иде Рәсим. Йөрәге дә жилкенмәде, дулкынлану хисләре дә тоймады. Шулай да эчтә ниндидер бушлык барлыкка килде. Сөйгәнен югалтудан гайре, кызның чынбарлыкны турыдан-туры әйтеп язмавына үртәлде.

Тиңдәшсез көчкә ия булса да, сөю тиз сынала, нәзберек шул ул. Ике якның да ихласлыгы булмаса, сынап кына калмый, чәлпәрәмә килә. Бер-береннән ничәмә-ничә еллар аеры яшәп мәхәббәтне саф килеш саклау — тиңдәшсез батырлыкка тиң. Аның олы йөрәкләрнең ихтыярыннан гына килә торган изге хис икәнлегенә янә бер тапкыр инанды Рәсим. Элек тә бу хакта кат-кат уйланганы бар иде.

Оксана энесен ни өчен алып киткән? Дөнья күрсәтү өченме, әллә чит тел өйрәтергәме? Бу сорауга анык жавап таба алмады Рәсим. Софья Петровна да ачыклап язмаган.

Санаторийдан соң Рәсим Мәскәү янындагы авиация дивизиясе карамагында калырга тиеш иде. Поезддан төшү белән туры шунда юнәлде. Аның документларын байтактан бирегә җибәргән булганнар. Штаб начальнигы, сейфны ачып документларны алды да, күз йөртеп чыккач:

— Иптәш майор, сез Татарстаннан икән, — диде саф татар телендә.

— Сез дә әллә шуннанмы?

— Әйе. Без күрше районныкылар гына. — Ул үзенең туган җирен атады...

Штабка кереп-чыгып йөрүчеләр юклыктан файдаланып, алар үз телләрендә рәхәтләнеп сөйләшеп утырдылар, ныклап таныштылар, аңлаштылар. Рәсим үзенең хәрби хезмәттә калу-калмау мәсьәләсе белән кызыксынды.

— Сезгә хезмәт итәргә туры килмәячәк инде. Госпитальдә бер ай ятып чыгарга туры киләчәк.

— Ни өчен?

— Группа биреп, отставкага җибәрү өчен. Бу хакта сезгә госпитальдә үк әйтергә тиешләр иде... Гражданкага китәргә каршылыгыгыз юктыр бит?

— Җибәрсеннәр генә! Икеләнүсез китәм! — дип сөенә төшеп, җавап бирде Рәсим.

— Минемчә дә дөрес буладыр. Сез — институт тәмамлаган педагог. Эш мәсьәләсе проблема булмаячак. Хәрби пенсиянең күләме югары булыр. Яшәргә мөмкин дигән сүз.

— Җае чыгар. Туган җир үги итмәс, — дип җавап бирде Рәсим, авыр йөктән арынгандай, җиңеллек белән...

...Туган якка кайтырга атлыгып торган Рәсимнең планнары кинәт үзгәрде. «Дөнья әйләнеп кайту» хәстәренә керде ул. Хәрби пенсиясен саклык кассасына күчереп баруны җайлаштырды да, поездга утырып, Ерак Көнчыгышка юл алды.

Оксананы югалтуына ышана башлаган иде ул. Күңел бушлыгын тутыру өчен яңа мажаралар табып, шулар белән мавыгу омтылышы аны ерак сәфәргә әйдәкләде. Өйдәгеләр дә аның хәлен аңларлар, дип фикер йөртте Рәсим. Күңелендәгесен бәйнә-бәйнә тезеп, Хамиягә хат язды...

***

Кыргынлык кылә башласа, туктата торган түгел. Узган җәйдә ун хуҗалык, ихатамилкен корытып, Ырынбур далаларында яңа укмашкан колхозларны тернәкләндерү өчен кумәк төстә уткәрелгән күчерү хәрәкәтенә кушылып, авылдан китеп барды. Бу язда яңгын чыгып, бер урамдагы җиле өй көлгә әйләнде. Уттан зыян күрүчеләрне колхоз үз канаты астына алды, аларга үзәктә өй салып бирде. Җәй үзәгендә ике гаилә Сарапул шәһәре янәшәсендәге совхозга күченде. Тагын икесе Башкортстанның Нефтекама шәһәренә китеп урнашты. Аланбашта илле бер өй утырып калды. Шуларның кырык өчендә кеше яши, ә сигезе, сатып алучы көтеп, буш тора...

Хәкимҗанның таралып барган Аланбашта өй салырына берәү дә ышанмады. Күпләр: колхоз үзәгендә генә калмас, районга ук күченер, дигән караштa тордылар. Авыл тутырып йөргән имеш-мимешләрне юкка чыгарып, Олы күлгә аяк сузып утырган төп ихатасына яңа өй салып керде Хәкимҗан.

— Кешеләр белми күченми торгандыр, әллә без дә дәрт итәбезме? — дип караган иде хатыны, Хәкимҗан андый сүзне ишетергә дә теләмәде.

— Балалар үсеп таралышкач, без кайда да икебез генә калачакбыз. Чит-ят җирдә яшәүгә караганда, туган төбәктә көн күрү күпкә отышлырак булыр, минемчә. Бу хакта күп уйландым инде, уйлардан чәчләрем агара төште... Без монда теләгән кадәр мал асрап яши алабыз. Күлдән көч китсә, Олы күлдән балык тотып та тамак туйдыра алабыз. Авыл кешесенә тагын ни кирәк? Бөтен кеше китеп бетеп, берүзебез калганда да яши алачакбыз, диясем килә, — дип тагын бер кат ныклы

фикерен житкерде Хәкимҗан карчыгына. Аның хуторларда яшәүчеләргә кызыгып кайтуы турында күп тапкырлар сөйләвен ишеткәнгә күрә, Фәриха сүз көрәштерүне урынлы санамады, ире белән ризалашырга мәҗбүр булды.

Хәкимҗан белән Фәриханың өч баласы да Тимәккә йөреп укыйлар. Аланбашта башлангыч мәктәпне кире торгызу буенча ата-аналар хәтәр хикмәт чыгарырдай булып йөреп караганнар иде, берни кыла алмадылар. «Киләсе елда балалар саны нык кими, мәктәпне быел ачып, алдагы елда ябуда хикмәт юк», — дип рөхсәт бирмәделәр.

Шулай да халык Аланбашның яшәренә өметләнә. Совет власте колхозларны тарату ягында түгел бит. Өстәге житәкчелек алышындымы, тормыш тагын элекке эзенә төшәр, дигән карашта яши. Чөнки Мәскәүдә баш түраләр әвеш-тәвеш килдеме, үзгәреш булмый калмый... Элек икенче бригадага житәкчелек иткән Хафиз да, мөгаен, шундый фикердәдер. Югыйсә, Аланбашта өй житкерергә керешмәс иде...

...Кече авылларны бетүгә дучар итү генә житмәде, халык күнеленә тозлы яра салырдай хәбәр килеп иреште: якында гидростанция төзелү нәтиҗәсендә, су басу куркынычы туганлыктан, түбәнлектәге авыллар күчереләчәк. Шундыйлар исемлегенә Аланбаш та кергән, имеш...

Соңгы вакытта алып барылган үзгәрешләргә битараф карарга күнегә төшкән, ярдәмчесез, саклаучысыз калган авыл халкы, чарасызлыктан гажизләнеп, чираттагы шомлы хәбәргә дә кул селтәде...

***

Төне буе яуган яңгыр иртәнгә дә туктамаган иде. Юл лычма лыбырдыкка әйләнгән. Аякка ябышкан ләпекне бәргәләп-селкеп кенә төшермәле түгел. Олы юлга чыккач кына атлавы бераз жинеләя төште. Жәяүләп барыбер ерак китәрлек түгел: урыны-урыны белән күлләвекләр хасил булган, төнозын койган яңгыр юлның комын юып, кызыл балчыгын чыгарган.

Рәсим юл унай туры килүче машинаны көтәргә ниятләде.

Ниһаять, миһербанлы бер бәндә машинасын Рәсим янына туктатты. Шофер кабинада үзе генә иде. Чемоданын арткы урындыкка куеп, аны үзе белән янәшә утыртты.

— Сезне күргәнем бар инде... Кем дип әйтергә хәтергә генә килми тора... Кая кайтасыз, абый?

— Аланбашка. Аннан Тимәккә.

— Хәкимҗан абыйларгамыни?

— Түгел. Үзебезгә.

— Рәсим абый, сезме соң?

— Әйе.

— Аланбаш таралганга өч ел инде. Ишетмәдегезмени? Халык китеп бетте аннан, — дип аңлатты егет.

— Хәкимҗан абый күченмәдеме?

— Яна йорт житештереп калды. Кузгалуда исәбе күренми. Аннан күрепме, Хафиз абый да Аланбашка йорт күтәреп куйды. Әлегә анда яшәми.

— Хәкимҗан абый ни хәлдә соң?

— Ул кулак сыман яши.

— Энем, син үзең кайсы авылныкы? Мине дә беләсең...

— Белмичә! Мин Тимәкнеке бит. Сез директор чагында мин беренче класста укый идем. Сез мине белмисез инде...

— Күпләрне оныткан мын инде.

— Китүегезгә байтактыр...

— Хәтсез шул...

Рәсим сенлесе Хамия белән Камил турында сораштырды. Егет аларның тормыш-көнкүреше турында белгән кадәренчә сөйләде.

— Мин шуларга кайтам.

— Чамаладым. Хамия апа сезнең сенлегез бит.

— Әйе, сенлем...

Машина хуҗасы Рәсимне Хамияләрнең капка төбенә үк китереп төшерде. Рәсим егеткә акча сузган иде, тегесе үпкәли язып әйтте:

— Сездән акча алсам, Ходай сугар. Таныш түгел бәндәләрдән дә алганым юк, — дип кузгалу ягын карады егет.

Капка төбенә туктаган машина тавышын ишетеп, Камил белән Хамия чыкты. Алар Рәсимне көтәләр иде инде. Хуҗалар кунакны ике яклап кочаклап алдылар. Сагынышканнар иде туганнар. Соңгы күрешүләреннән соң да ун елга якын вакыт үткән иде.

— Әнкәй мәрхүмә генә сине күрә алмыйча китеп барды. Теле белән әйтмәсә дә, күнеленнән сине көтте, — дип яшь сыгып алды Хамия өйгә кергәч.

— Минем өчен икесенең үлеме дә үкенечле. Әткәйнең вафаты вакытында чит илдә идем, әнкәйнең үлеме хакында дингез эчендә ишеттем. Көне-сәгате белән кайтып житмәле түгел, — диде Рәсим, авыр уфтанып...

Хәрби хезмәте елларында башыннан кичергәннәрне ачыктан-ачык әйтеп яза алмады ул. Рәсимнең чит илләрдә адым саен үлем куркынычы туып торган хәлләрдә хәрби бурыч үтәвен, каты яраланып, үлемнән чак калуын Камил дә, Хамия дә белмиләр иде. Чәйдән соң Рәсим башыннан кичкәннәрне кыскача сөйләп алды. Ул туктап калгач, өйне авыр тынлык биләде. Хатын-кыз күңеле тиз эрүчән — Хамия күз яшьләренә манчылды.

— И-и-и, абзыкаем, бу хәлләргә төшеп йөрүенне белмәдек бит. Хәтта уйга да китермәдек. Җәһәннәм газаплары кичкәнсен икән, — дип, абыйсын кочаклап, елавын дәвам итте.

— Йә-йә, житте, тынычлан, — дип абыйсы аны аркасыннан кагып күпме кабатласа да, сенлесен ярсудан туктата алмады. Бераздан үзеннән-үзе тына төште Хамия. Елау жинеллек бирде, күпмедер җиңеләеп, бушанып калды хатын. Тирән сулап, урыныннан кутәрелде дә табынны жыярга кереште.

— Мин бит сезнең хатта «Аланбаш бетте», дип язган сүзләрегезгә ышанып житмәдем. Күпләр китсә дә, барыбер утыз-кырык өй калгандыр, дип уйладым, — диде Рәсим, Камил белән икесе утырып калгач.

— Хәкимжан абый гына калды шул. Фәриха апа белән тиң икесе яшәп яталар. Иркен яшиләр. Мәжбүри кусаң да Хәкимжан абыйны кузгатып булмас. «Бермәлне киткәннәрнең исенә төшәр, бик кире кайтырдай булырлар, ләкин чамаларыннан килмәс. Ә акыллырак яшьләр шушында төпләнерләр. Авыл янәдән терелә башлар», — дип хыялланып ята Хәкимжан абый, — диде Камил, Рәсим юлда ишеткән яналыкны үзенчә кабатлап.

— Хәкимжан абый балык тотадыр? — дип әңгәмәдәше көтмәгән сорауны бирде Рәсим.

— Күл буенда яшәп, ансыз буламыни! Балык кирәк булганда якын-тирә кешеләре аның янына йөгерә.

— Алпавытларча яши, диген.

— Аермасы шунда — хезмәтче тотмый.

— Рөхсәт юктыр, — диде Рәсим, көлемсерәп.

— Ихтимал...

— Абзыкай, син бер хатыңда: «Бәлки өйләнермен дә», — дип язган идең. Аннан соңгы хатларында ул хакта сүз булмады. Барып чыкмадымы соң? — дип көтелмәгән сорауны бирде Хамия, ашарга әзерләп йөргән жиреннән.

— Мин өйләндем, ул ташлады, — диде Рәсим, житди генә. — Бер-беребезне анлый алмадык... Хәер, башка сәбәбе дә булгандыр.

— Язмыштыр.

— Бәлки...

— Оксана белән күптән өзелдеме? — дип Хамия абыйсының беренче мәхәббәтен искә төшерде.

— Бишбылтыр инде.

— Жиде-сигез ел элек анын бер хаты килгән иде. Үзләренә бөтенләйгә кайтып эшли башлагач язган иде. Әлбәттә, синең белән кызыксынган. Мин, жүләр: «Абзыкай өйләнгән», — дип язып жибәрдем. Оксана яңадан хат салмады, — дип Рәсим көтмәгән яңалыкны ирештерде сенлесе.

Күрешмәүләренә, язышмауларына ничә еллар үтсә дә, зифа буйлы украин кызын оныта алмады ул. Оныта да алмас, мөгаен. Әллә хат язып караргамы? «Юк-юк, күптәннән тормыштадыр. Чибәр кыз иясез тормас. Хәбәр салып, аларның тормышларын бозуда ни мәгънә бар?» — дип, уеннан бик тиз кайтты ул...

Икенче көнне, Камилнең әрхәрәй мотоциклын кабызып, Рәсим Аланбашка юл тотты. Ярык торбадан чыккан үкерү тавышын ишетеп, Хәкимжан капка төбенә чыкты.

— Чит ил техникасы икән. Безнеке бу тиклем чәрелтәмәс, кем йөри микән, дип гажәпсенгән идем, син икәнсен, иске күрше, — дип каршылады аны Хәкимжан. Алар кочаклашып күрештеләр.

— Иномарка алып кайттым, Хәкимжан абый. Шуны котлатырга синең янга килдем, — дип шаярту сүзләре белән жавап бирде Рәсим дә.

— Хәзер карчыкка эндәшәм, ике-өч йомырка чыгарып бирсен, — диде авыл хуҗасы, җорлануын дәвам итеп.

Гадәттә, очрашу вакытында була торганча, исәнлек-саулык турында сүз алыштылар, хәл белештеләр. Хәкимжан иске күршесенең бу тикле гомер күзгә башка чалынмыйча кайда йөрүе турында төпченде. Һәркайсына басымлап тукталмаса да, жир шарының төрле почмакларына кылган сәяхәтләре турында кыскача бәян итте Рәсим.

— Белмәгән-күрмәгән жирең калмаган икән, борынгай, — дип гажәпсенеп тыңлады аны күршесе.

Алар өйгә керделәр.

— Икәү генә яшисезме? — дип сорады Рәсим, аларның ялгызлыкларын белеп торса да.

— Кошлар язмышы хәзер бәндәләргә күчте бит. Ярый, кошлар китәләр дә кайталар, ә күпчелек балалар кирегә юлны оныталар, — диде Хәкимжан, мондый хикмәтне үзең дә беләсең дигәндәй, кул селтәп.

— Кайда да шул хәл, — диюдән башканы әйтмәде кунак.

— Үзеңнең төпләнү кайда соң?

— Утраклыкка күчмәдем әле. Шул хакта уйланып кына йөрим.

— Гомер буена алай яшәп булмас, төпләнергә кирәк.

— Әлбәттә!.. Чын сүзме, Хафиз абый кире кайта, дип ишеткән идем.

— Дөрес сүз. Әнә, өе өлгергән инде, — дип Хәкимжан чапырышрак утырган ихатага күрсәтте. — «Мал тотып, синең кебек яшисем килә», — ди.

— Аңлаган кеше шулай уйлар. Эштән курыкмасаң, ким-хур булып яшәрлек урын түгел бит.

— Без аңлыйбыз да... Шуны белмәгән кешеләр күп бит. Тамырың нигә корытасы иде авылның? Ун-унбиш өй калса да авыл булып исәпләнеп йөртелер иде әле Аланбашыбыз, — диде Хәкимжан, йөрәк сызлавын баса алмыйча.

— Хәзер тормыш шулайрак бит: ваталар-жимерәләр дә аннары пыр тузып

шуны торгызырга керешәләр. Батырлык эшлиләрмени!.. Кем белә, берничә елдан биредә дә кечерәк бер матур авыл барлыкка килергә мөмкин.

— Амин иде әгәр...

— Транспортың бармы? — дип кызыксынды Рәсим, ансыз бай дөньяны сөйрәү жинел түгеллеген чамалап.

— Ат тотам. Малайдан калган бишекле матай бар. Мина житә. Кирәге чыкса, машина да сатып ала алам. Акча бар, шөкер. Ит, балык, печән сатам... Зарланырлык түгел.

— Иген иксән, гел алпавыт буласы икәнсең, — диде Рәсим, көлемсерәп.

— Анысы да кулдан килә. Рөхсәт кенә итсеннәр, — дип икеләнмичә жавап бирде хужа.

— Синең янга киңәшкә килдем, Хәкимжан абый, — диде Рәсим, күршесен аптырата төшеп. Хәкимжанга килгәндә, ил гизгән егет аның киңәшенә мохтаж түгелдер сыман иде.

— Мин ни генә әйтә алырмын соң сина?

— Башка берәүдән дә килми ул, иң дөрес киңәшне син генә бирә алачаксың.

— Ышанып килгәч, әйтеп кара инде...

— Кайтып, шушында төпләнсәм, дим...

Ышаныргамы-юкмы, дигәндәй, Хәкимжан Рәсимнең күзенә хәтсез карап торды. Ләкин кунак йөзендә шаярту чаткысы тоймады. Шулай да икеләнеп:

— Саташып кына әйтүең түгелме? — дип сорамый кала алмады.

— Кайтуымның максаты шул теләктән. Каралты-кура тергезү генә читенгә туры килмәгәе, дип икеләнәм. Шул хакта сораштыру өчен синең янга киңәшкә килдем, — дип төп фикерен житкерде егет.

— Туганкаем, кесәңдә рәт бар икән, үзең читтән карап торсаң да була — бөтенесен житештереп бирәләр.

— Акча бар-барын.

— Өй сатучы күп хәзер. Су басачак авылларда өр-яңа өйләрне дә арзан гына бәягә жибәрәләр. Алучы гына табылсын. Сүтеп торасы да түгел, трактор белән тарттырасы гына. Мәшәкате аз, диюем... Мин шуны гына төшенеп житмим: нишләп монда төпләнергә уйладың? Интеллигент башың белән, диюем...

— Шушында туган өчен, Хәкимжан абый. Әткәйнең нигезне корытмаска кушып әйткән васыяте бар иде. Аны үтәргә кирәк. «Әгәр исән калсам, туган жиремә кайтып тынычлап яшәр идем», — дип үз-үземә биргән нәзеремне дә үтәргә кирәктер... Мин дә тормыш куа алырмын бит әле...

— Әлбәттә. Шөйлә атаң каны кайный икән каныңда. Мәрхүм, ул да әллә кайларда йөреп кайтып, авылга төпләнеп гомер кичерде... Язмышларның кабатлана торган хикмәте бар шул. Хәерлегә булсын! Энекәем, кайт кына! Ялкауланмасаң, рәхәтләнеп яшәячәксең. Яшь бит әле син, гайрәтле чагың.

— Иртәгә үк районга барам. Кирәк-ярак артыннан чабулау өчен транспорт кирәк. Тиз арада кулга төшереп булмасмы әле...

— Матай-мазар аласынмы?

— Автомобиль юнәтүдә исәп.

— Машинага чират күп, диләр. Сина, бәлки, жае чыгар.

— Ихтимал. Минем армия льготасы да бар...

Сүзләрне туктатып, өстәл артына утырыштылар. Тәмләткечләр өстәп, парда жылыткан, олы таба чүмәкәй тулы итне авыз иткәннән соң, иркенләп чәй эчтеләр. Табын урыныннан кузгалганнан соң да дөнья тергезү турында хәтсез озак гәп корып утырдылар.

***

Ашыгыбрак килгән Рәсим. Район үзәгендә рәтле-башлы хәрәкәт тә башланмаган. Эшкә кузгалучылар берән-сәрән генә күренә.

Шулвакыт Рәсим көтмәгәндә күптәнге танышын очратты. Урта мәктәптә бергә укыган сабакташының эшкә барышы иде.

— Надил, син түгелме соң? — дип эндәште ул, аның ягына карамыйча үтеп баручы иргә.

— Рәсим дускай, күктән төштеңме әллә? Ничә еллардан бирле сине күргән юк, — дип колачын җәеп килеп кочаклады Рәсимне сабакташы. — Хезмәт итәсеңме?

— Юк. Отставкага чыктым. Ә син кайларда?

— Сәүдәгәр мин. Райсоюзда товар белгече.

— Минем өчен бик кирәкле кеше булып чыктың бит әле.

— Ни белән ярдәм итә алам?

— Башта кинәшең белән, аннары күз күрер.

— Әйтеп кара соравыңны?

— Машина алырга кирәк миңа.

— Дускай, соравың җиңелләрдән түгел... Сиңа хутлысы кирәк инде?

— Әлбәттә.

— Кайчак җае чыгыштыра. Бигрәк тә квартал ахырларында... Районның сәүдә планы үтәлмәү куркынычы туа икән, ашыгыч рәвештә бер-ике автомобиль бүлеп бирәләр. Чират карап торыш юк: кемнең кулында акча бар — шуңа бирәбез... Сине хәзердән үк чиратка төртеп куярга кирәк.

— Кем «төртә» инде?

— Мин.

— Син шундый зур түрә үкмени?

— Райсоюз рәисе юк чакта мин хуҗа. Урынбасар саналам бит.

— Сабакташым шундый урын биләгәндә, мине машинасыз калдырмас, шәт?

— Калмассың. Акчаң әзер торсын... Син бөтенләйгә кайттыңмы соң?

— Әйе.

— Алайса, проблема тумас. Югыйсә, машинаны район кешеләренә генә сатарга кирәк, дип чәйнәнгән булалар... Кичкә кадәр монда буласыңмы?

— Юк. Ә ни өчен?

— Иркенләп утырырбызмы әллә, дигән идем.

— Житешербез, дускай. Бергә яшисе бит.

— Дөрес!..

***

Хәкимҗан сүзендә торды. Бормалы Күл авылыннан өй белешеп кайтты. Кар төшү белән өйне сөйрәтеп алып китәргә килештеләр. Эш бер унга китсә, җае чыгып кына тора. Сабакташ Надил да вәгъдәсен үтәү вакытын озакка сузмады. Сөйләшүдән соң ай тулганчы ук, районга килергә кушып хәбәр салды. Бүлмәсенә килеп керү белән яңалыкны җиткерергә ашыкты:

— Сабакташ, бик шәп «Волга» кайтты. Синең ише офицерлар гына йөри торган. Алып җибәр, үкенмәссең, — диде.

— Миңа авыл пычрагына бирешми торганрагы булса әйбәт булыр иде дә...

— Шәхси кулга сатарга икене генә җибәрделәр. Берсен җайлаштырып райбашкармага алдылар, берсен сиңа дип калдырдык. Ия күп аңа. Колхоз

рәисләре алырга атлыгып торалар. Әгәр телисең икән, «Волга»ны җаның теләгән машинага алыштыра аласың. Хет танкка... — дип көлеп куйды Надил.

Сабакташының киңәшен ошатты Рәсим. Сатып алып китте «Волга»ны. Атна үткәнче «кода»лар да килеп җитте. Алышырга кыстыйлар. Авыл кешесенә тормыш «тарту» өчен иң кулае — алгы күчәре тарта торган машина, дип «ГАЗ»ик тәкъдим итәләр Рәсимгә. Акча да өстәмәкчеләр. Ризалашты Нәбиев. Автомобильгә ияртеп арбасын да бирделәр. Урта кул йөк ташу өчен кемгәдер ялынып йөрүдән котылды егет.

Аланбаш авылы тирәсе элек-электән киек җанварларга бай иде. Хәзер дә алар ишле күренәләр. Табигать кочагында яшәгәч, корал кирәк булыр дигән максаттан, Рәсим ау мылтыгы да тапты. Калай көймә сатып алды. Күлгә терәлеп утырып, балык та тотмасаң, харам булыр төсле иде аңа.

Тормыш йөген тарту исәбенә керде Рәсим. Үз көченә ышана. Ихата әйләндереп, урам якка торба багана утыртып, тимер капка эшләтеп куйса, ата-бабадан калган нигезгә җан керер сыман. Өйне генә түгел, әзер мунчаны да Бормалы Күлдән сөйрәтеп кайтармакчы.

Өй кайтып утыргач, ничек яши башлау мәсьәләсе турында аның басымлап уйлаганы, күз алдына китергәне юк әле. Берьялгызы гомер кичермәсен белә. Ныклап төпләнгәч, үзен аңлаган, бередә беркеп яшәрдәй хатын-кыз тапмый калмас...

Никахлашу турында чак кына уй тудымы, күптән онытылырга тиешле кешесе күз алдына ялт килә дә баса. Юллар әллә кайчан аерылышкан, югыйсә. Шушы көнгә чаклы ни өчен күңелдән китми торгандыр... Сагыш сүрелә төшә инде, дип тынычланырга өлгерми, төшкә кереп булса да хисләрне яңарта. Чиргә сабыштырырлык сихер көченә ия микәнни соң ул беренче мәхәббәт?!

Шушы уйларга бирелеп кайта торгач, капка төбенә килеп терәлгәнен сизми калды Рәсим. Машина тавышын ишетеп, Хәкимҗан чыкты.

— Эчкә керәсеңме? Капканы ачам, — диде күрше агай.

— Тимәктән урап киләсе бар. Мине югалтып торалардыр... Районнан кайбер кирәк-ярак алып кайткан идем, сараеңа кертеп торып булмасмы? — диде Рәсим.

— Нигә сорап торасың? Алып кайткан бер әйбереңне керт тә куй, — дип үзенең ихата капкасын ачты...

Тимәктә Рәсимне көтәләр иде. Кичке ашны да ашамый торганнар. Рәсим сонару сәбәбен Аланбашка кагылуы белән аңлатты. Өй эчендә кирәкле тауар сатып алуы турында да әйтте.

— Кола яланга төпләнгән кешегә кирәкнең чут-чамасы юк. Ярый, хәзердән үк ташый башлагансың, — диде Хамия, төртмә телләнеп.

— Ниятләгән эшне ахырына җиткермичә ярамый. Югыйсә, яшәүнең мәгънәсе юк. Тотынганмын икән — кире тайпылмыйм инде, — диде Рәсим, ниятенең катгыйлыгын сиздереп.

— Тәгаенләгәнсең икән — кылан. Үкенечкә калмасын. Кулдан килгәнчә мин дә булышырмын, — дип Камил кайнагасын яклау ягына басты.

— Үзегез карагыз. Сез эшләүдән миңа көч килми, — дип Хамия кул селтәде. Тышка чыгарга җыенып ишек катына атлаган иде, кинәт туктап калды. — Беләсеңме, абзыкай, берәүдән хәбәр алдым бит...

— Кемнән?

— Уйла әле.

— Шуңа гына баш ватасым калган икән! Минем башта уйлар болай да җитәрлек, — диде Рәсим, сеңлесе сүзенә исе китмәгәндәй. Тик, барыбер, күңеле нидер сизенеп, йөрәге җилкенеп куйды.

— Украинадан килде, — дип турысын әйтте Хамия.

— Алай икән, — диде егет, Оксананың ниләр язуы турында беләсе килсә дә, дулкынлануын сиздермәскә тырышып.

— Укыйсыңмы?

— Сина язган хатны ничек укыйм ди?

— Кайдалыгыңны сораган. «Бер барып чыгасым килә. Рәсимгә сюрпризым бар», — дигән.

— Авыл таралганын беләме соң?

— Каян белсен?! Күптәннән хәбәрләшкән юк бит. Җавап язасыңмы соң?

— Мин андый эшкә әзер түгел әле.

— Ярар, үзем язармын. Синен Аланбашта хыялый коммунизм төзеп йөрүенне дә әйтермен. Килергә чакырырмын, — диде Хамия, абыйсының хисләрен укыгандай. Абыйсының Оксананы онытмавын белә ул. Ясалма тәкәбберлек күрсәтүен дә чамалый.

— Яз-яз, — диде Рәсим, сеңлесенең сүзләренә игътибар итмәгәндәй. Ә күнеле Оксананың килүен тели һәм бик тә көтә...

* * *

Рәсим белән Хәкимҗан озак көтмәделәр, буран уйнатып юл ачып килүче тракторлар да күренде. Рәсим юл бүлегенә барып, өй тарттыру өчен трактор белешкән иде. «Сезнең якта юл ачучы тракторлар белән тарттырырсың», — дип рөхсәт биргән иде бүлек хуҗасы.

Ирләр янына якынаю белән тракторлар туктады. Алдагысының кабина ишеген ачып, тракторчысы сәлам бирде:

— Әссәламәгаләйкүм, авылдашлар! Исән-саулармысыз?

— Сау-сау, — дип Хәкимҗан аңа таба атлады. Рәсим дә иярде. Якынайгач, тракторчыны таныды.

— Хаҗи абый, син түгелме соң? — дип, ике кулын сузып, күрешергә үрелде. Хаҗи, җиргә төшеп, Рәсимне кочаклады.

— Мин бу, Рәсим энем...

— Үзгәрмәгәнсең әле.

— Үзгәрүне кем белгән, әмма мәгәр картайта, — диде Хаҗи, елмая биреп.

— Ә син коеп куйган Сафа абзый инде. Көрәшчеләр кыяфәте кергән үзенә. Атаң мәрхүм дә көч-куәткә ия бәндә иде.

— Нишлисең? Чир барыбер бәреп екты.

— Берәгәйлесе эләксә, кемлегенне сорап тормый, әйләндереп кенә сала, — дип килеште Хаҗи Рәсим белән. Сүзне икенчегә борып, егетнең гамәлен хуплады: — Изге гамәл кылып йөрисең, энем. Эт олаккан җирләрдә йөреп тә туган иленне онытмавыңа рәхмәт. Үзем җүләрлек эшләдем — шушындагы әзер милекнең тамырын корыттым. Пенсиягә чыккач, кайтып кына керәсе иде бит. Хафизның шушында өй житкерүен ишеткәч, төн йокымны югалттым, күңелем авылга тарта башлады.

— Кайт син, Хаҗи. Әле дә соң түгел. Бер өйлек урынны ничек тә табарбыз, — диде Хәкимҗан, кет-кет көлеп.

— Алып бетермәсеннәр, минем өчен берәр урын тотыгыз, — диде тракторчы, шаяруны кабул итеп.

Тракторлар юлга кузгалды. Рәсим белән Хәкимҗан, машинага утырып, алар артыннан иярделәр.

Кузгатасы өй янына Бормалы Күл авылының ир-атлары байтак җыйналган иде. Авылның тарала башлавы шаһиты булып, беренче өйнең нигезеннән кубарылуын үз күзләре белән карап калу өчен килгәннәр иде. Берәүдә дә дөнья көтү гаме күренми. Яна урынга урнашкач, төпләнеп китәргә

## БАШКАЛАЛАР ЙӨЗ БУЛСА...

**Татарлар бердәмлек булмау белән аерылып тора. Мәскәүгәме, Уфагамы, бүтән бер шәһәргәме килү белән, бер-берсеннән зарлана башлыйлар. Фәлән кеше, төгән кеше белән очрашмаска үгетлиләр, кулга шуңа кагылышлы ниндидер гаризалар, мөрәҗәгатьләр тоттыралар. Таркаулыгыбыз борчуга салган милләтләр дә аз түгел үзе, бу уңайдан күз яшьле мәкаләләр дә язылгалый. Әмма бердәмлеккә омтылыш, гадәттә, үтәү һәркем өчен мәҗбүри булган, бертөрле уйларга буйсынуга өндәүдән әлләни ерак китми торган карар, документ-фәлән кабул итүгә әйләнеп кала.**

**Революциягә кадәр яңа идеяләр җәдитчеләрдән чыккан. Кадимчеләр исә әләк арты әләк язган, арада охранка хезмәтендәгеләр дә булган. Гаҗәп хәл: җәдитчеләр төрле фикердә торганнар, аларның бердәнбер башлыклары-остазлары да, мәзһәпләре дә, бердәм тәртип-йолалары да булмаган. Алар ничек киенергә, нинди фиркагә (партия) керергә кирәклеге турында сүз куертмаганнар, бәхәсләшсәләр, халыкның дәрәҗәсен, абруен ничек итеп күтәрергә кирәклеге турында бәхәсләшкәннәр. Эшмәкәрләр исә милләттәшләренең тормыш хәлен яхшырту, гыйлем дәрәҗәсен күтәрү юллары турында фикер алышканнар. Мондый плюрализм, фикер төрлелеге табигый дип саналган. Әгәр дә бөтен ислам дөньясы шул юл белән барса, мөселманнарның үзара сугышының әсәре дә булмас иде. Әгәр дә хәзер үткәннән нәрсәне дә булса тергезергә кирәк икән, бу һич кенә дә мәзһәп-фәлән түгел — киресенчә, фикер төрлелеге һәм моңа карата түземлелек. Кызганыч ки, совет идеологиясе системасы кешеләрдә бүтәннәр фикеренә карата сабырсызлык тәрбияләде. Шуңа күрә бүген, бердәмлекне җимерә дип уйлап, тәнкыйть сүзен һич сөймиләр. Ләкин болай без ерак китә алмаячакбыз.**

**Татар иҗтимагый оешмаларының күплегеннән дә куркырга кирәкми. Революциягә кадәр дә, беркадәр хөррәк чакта, татар мәдәнияте үзәкләре барлыкка килгән. Казан гына түгел, Уфа, Оренбург, Троицк, Җаек (Уральск), Әстерхан белән Бакчасарай да татарның милли үзәкләре булган энә. Тагын әле Петербургта, Мәскәүдә һәм Төмәндә дә шактый гына милли көч тупланган. Күпертебрәк әйткәндә, татарның башкалары йөзәү булган. Һәм бу һич тә көенеч түгел, сөенеч кенә.**

**Себер һәм Кырым татарларының, керәшен һәм мишәр татарларының, Буа, Минзәлә ягы татарларының үз үзенчәлекләре белән горурланулары һич тә куркыныч түгел. Ул үзенчәлекләр безгә бердәм булырга комачауламый. «Төрлелекләр бердәмлеге» — төрле карашлар һәм мәнфәгатьләргә бәйле уртак максатлар — бер-береңне баету һәм үстерү тирәсендә ялгаучы шәп принцип бу.**

**Хәзер татар дөньясында йөз башкала пәйда була икән, без моңа сөенәчәкбез генә. Халкыбыз мәнфәгатьләре шәхси амбицияләрдән югарырак кына куелсын. Бу безне ясалма түгел, чын, табигый берләшү белән берләштерәчәк.**

**Рафаэль ХӘКИМ**

жинелрәк булсын өчен, терлекләрен, өйләрен сатып акчага әйләндерү уе белән генә яшиләр.

Алып китәсе өй көздән күтәртелеп, ике ягына бүрәнә кыстырып куелган иде. Як-якларына такта сугып, стеналарны ныгыткач, чана хезмәтен үтәү өчен тыгылган аскы бүрәнәләрне тракторга тагу өчен көйләделәр.

Тракторлар кузгалгач, бертөркем халык аларны авыл башына кадәр озата барды. Бормалы Күл кешеләренен хәлен анларга мөмкин иде — мәетне соңгы юлга озаткандагыдай хис белән карап калдылар алар тракторлар артыннан.

— Берүләр авыл тарата, икенчеләр таралган авылны корыштырырга йөри, — диде озатып калучылар арасыннан берәү.

— Хәзер тормыш шулай көйләнгән бит: төзиләр дә җимерәләр, җимерелгәнне тагын кора башлыйлар, — диде икенчесе, ачу белән җиргә төкереп.

...Рәсимнең өен үзләренең иске ихатасына, бабасы корган нигезгә кайтарып утырттылар.

— Мунчасын киләсе атнада сөйрәтербез. Ана кадәр ихатадагы барлык корылмаларны сүттер. Аларын икенче тракторга төярбез, — дип ышандырып китте Хажи. Авылы тернәкләнә башлавын күрү сөенеченнән Рәсимгә ярдәм итәсе килә иде өлкән тракторчынын.

Җәй урталарына Рәсимнең өе генә түгел, ихатасы да күптән оешкан ныклы хуҗалыкны хәтерләтә иде.

— Дөньяны бергәләп корсан кадерлерәк була. Өйләнергә иде башта, — дип берничә кабатлады күрше Фәриха, Рәсимне күргән саен.

— Көздән калмам инде, Фәриха апа, язганы очрадымы — тотам да өйләнәм, — диде ул, апасын да, үзен дә ышандырасы килеп. Әмма күнеле барыбер икеләнә иде. Булдыра алырмы?...

...Өйләнеп карады ул. Аерылыштылар. Хатын хыянәткә барды. Беренче тапкырын Рәсим гафу итәргә дә риза иде, ләкин хатын алай уйламады — үзе китеп барды...

...Поездда таныштылар алар. Урыннары кара-каршы туры килде. Икесе дә Мәскәүдән утырганнар иде. Яшьләр арасында әңгәмә тиз куерды. Кыз Ирина исемле. Ул Рәсимнең сәфәре белән кызыксынды.

— Сахалинга кадәр житмәм микән, — дип икеләнеп әйтте егет.

— Сез офицер түгеллер бит?

— Нигә алай дисез?

— Кыяфәтегез хәрбиләрнекенә тарткан.

— Әле генә хәрби идем, хәзер — юк. Отставкага чыгардылар.

— Бик яшь килеш җибәргәннәр.

— Шулайрак туры килде шул.

— Сәфәрегезнең максаты нинди? — дип төпченә бирде кыз.

Рәсим дөнья күреп кайту, җай чыкса, бераз эшләп алу нияте белән юлга кузгалуы турында әйтте. Үзе турында ачылып сөйләргә теләмәвен сизенеп, Ирина сораштырудан туктады. «Барасы юл озын, танышырга өлгерербез әле», — дип уйлап тынып калды.

Төнгә каршы вагон эче тынычлана төште. Тәне кызыша башлагач, йокларга ятканда Рәсим күлмәген салды. Бүген шактый арыган иде ул. Башы мендәргә тию белән йокыга китте. Ул күзен ачканда кояшның иртәнге нурларыннан вагон эче балкып тора иде.

Ирина күптән уянган. Челтәрле калай аслыкка кертеп утыртылган сырлы стаканнан чәй эчеп утыра иде. Каты йоклаган Рәсим, хәтта чәй таратып йөргәнне дә ишетмәгән.

Алар хәерле иртә теләштеләр. Рәсим хәрбиләрчә житезлек белән киенде дә

юынып килде. Юл озынлыгын чамалап, ашамлыкларны муллан алган иде. Ул да чәй эчәргә утырды. Күршесен дә кыстаган иде, илтифатлы гына итеп, кыз тәкъдимнән баш тартты.

— Сез кайларда хезмәт иттегез? — дип көтелмәгән сорау бирде Ирина, егет ашап туйгач.

— Күп урында булырга туры килде.

— Мәскәүдә дәме?

— Юк. Анда икенче эш белән булдым.

— Алай икән, — диде кыз, сузып кына. Тәрәзә читенә беркетелгән өстәл өстендә нәфис бармакларын биетеп алды. — Еракларда йөргәнсез, димәк...

— Каян чыгып әйтәсез? — дип сорады егет.

— Сезнең күкрәктәге яра эзләрен күреп, — дип көрсенеп әйтте кыз.

Рәсим эндәшмәде. Чынбарлык турында сөйләргә ярамый иде...

Озын юл егет белән кызны бер гаилә кешеләредәй якынайтты. Рәсим Иринага институтта укуы, мәктәп директоры булуы, армиядә хәрби училище тәмамлавы, майор дәрәҗәсенә күтәрелүе хакында сөйләде. Кыз да үзе белән таныштырды. Ул Новосибирскида туган, шунда укыган. Институттан соң Владивостокка эшкә билгеләгәннәр.

Ирина кай ягы беләндер Оксананы хәтерләтә иде. Югыйсә, кыяфәттә дә, йөзендә дә ана тартымлыгы юк. Оксананы югалтудан, сагынудан, юксынудан туган хисләр генә ике кыз арасында охшашлык эзләми иде микән?

— Әйдә Владивостокка. Синең өчен барыбер түгелмени? Мин шәһәрне беләм, урнашырга ярдәм итәрмен, — дигән тәкъдим ясады Ирина, сәфәрләренең соңгы көне якынлашып килгәндә.

— Белмәгән-күрмәгән кеше ияртеп кайтып, мәшәкатькә уралуың гына бар. Янадан үкенергә туры килмәсен, — дип кисәтте аны егет.

— Ул хакта кайгырган юк, житәккә калган мескен бер бәндә түгел лә син.

Алар күптән «син» гә күчкәннәр иде инде.

— Ирләргә хатын-кыз житәге кирәк, диләр, шулай да.

— Житәкләшергә риза, — диде кыз, елмая төшеп.

...Тиз арада «житәкләштеләр» алар. Ике айдан бергә яши башладылар.

Рәсим балыкчылар артеленә кушылды. Дингезгә чыга башлады. Балыкчыларның эше шундый: онытканда бер генә өйгә кайтып кермәле. Елның яртысы диярлек су эчендә үткән чаклар бар. Икенче тапкырын рейстан кайтып кергәндә Рәсимне буш бүлмә каршылады. Өстәлдә ике бит кәгазь ята иде. Берсе — аерылышу турында суд карары, икенчесе — өч-дүрт җөмләдән торган хат...

«Рәсим, гафу ит, мин синнән китәм. Синнән генә түгел, шәһәрдән үк югалам. Пар таптым, аның белән никахлаштык...

Тагын бер кат гафу сорыйм. Ира. 28 нче август.»

...Иринадан аерылганга да биш ел вакыт үтеп китте. Хатын-кызга ышанычын югалтыпмы, Рәсимнең берәү белән дә житди мөнәсәбәткә кергәне юк...

Ә барыбер өйләнергә кирәк...

Машинасын ихатага керткәнче, койма буендагы утыргычта утырган Хәкимжан янына килде Рәсим. Бүген күрешмәгәннәр иде алар. Рәсимгә иртүк китәргә туры килде.

— Хәлең ничек? Нинди уйларга чумып утырасың, Хәкимжан абый? — дип кул биреп исәнләште Рәсим.

— Хәлләр рәтләнә бара, энем. Өченче өйнең дә эше бетәргә тора, — диде ул, каршы яктагы Хафиз ихатасына күрсәтеп.

— Шулай булырга тиеш, Хәкимжан абый. Өйләрнең дүртенчесе дә,

бишенчесе дә калкып чыгар, — диде егет, ниндидер бер ышаныч белән. Әйткәннәренә иманы камил булмаса да, күнеле шуны тели иде анын.

— Минем гомердә бер урам барлыкка килсә иде, дип хыялланып утырам. Урам башына: «Аланбаш авылы» дип эре хәрефләр белән язып беркетеп куяр идек. Авылнын тамыры корымаганлыкны белеп-күреп торсыннар иде, — диде Хәкимжан, эчендәгесен әйтеп.

— Озак көтәргә туры килмәс. Өч өй — бер авыл ул. Хафиз абый яши генә башласын, һичшиксез, язуны кадаклап куячакбыз... Авыл булыр! Без юкка тупланмәгән монда, Хәкимжан абый.

...Юл тузанын күтәреп, алар ягына мотоцикл килә иде. Рульдә килүчене ерактан ук таныдылар, авыл советы рәисе Исхак Гатин иде ул.

— Ничек киләсе иттен? — дип сорады Рәсим аннан, бу тирәгә түрәләрнен аяк басканы булмаганга күрә аптырап.

— Сез төзи башлаган урамны күреп китим, дип килдем, — диде Исхак, көлемсерәп.

— Урам белән генә туктамас әле ул, — диде Рәсим, житди генә.

— Син үз әйткәненә ышанасынмы? — диде рәис, житди төскә кереп.

— Кайчан гына бер өй утыра иде, ә хәзер өчәү. Алдагы җәйдә тагын икәү өстәләчәк, — диде Рәсим, рухланып.

— Кем килсен монда тагын?

— Хажи белән Салих кайта, — диде Хәкимжан, гәпкә кушылып.

— Ышанасы килми.

— Без бәләкәй чакта: «Сезнен күз алдында Аланбаш таралачак», — дип әйтсәләр, ышаныр иденме?

— Юк, билгеле... Ярый, пенсионерлар жыелыр, ди. Яшьләр нишләр?

— Анысы сездән тора. Эш урыны кирәк.

— Мин аны каян алыйм?

— Башны уйлатырга кирәк. Хәзер үк биредә куян фермасы, умарталык булдырырга мөмкин. Куяннарны без өчәүләп карый алырбыз, ә умартачыны табып жибәрергә туры килер.

— Дөрес, — дип хуплады күршесенен сүзен Хәкимжан.

— Жәйлектә шушында нигә пионер лагере ачмаска? — дигән сорау куйды Рәсим совет житәкчесе каршына.

— Киләчәктә бу хакта уйлашырга ярый, — дигәннән башканы әйтмәде Исхак. — Мин жалу тикшерү өчен килгән идем. «Колхоз жирен законсыз басып алып, кулак хужалыклары төзүчеләр бар», дигән шикаять керде. Сез шуна ничек карыйсыз? Килешәсезме?

— Юк. Бу жирне безнен бабаларыбызнын бабалары үзләштергән, ә без аларнын нигезендә генә утырабыз, — диде Рәсим.

— Энем Исхак, жалу язучы үзе бирегә килеп, кычыткан-курадан жир арындырып, өен салсын да алпавытка әйләнсен. Күрербез, нәрсә кыла алыр микән? — диде Хәкимжан, кыза төшеп.

— Андый гамәл кулыннан килгән кеше шикаять язу белән шөгыльләнми, — дип Исхак үзе дә Хәкимжан фикерен куәтләде.

— Ярый, Галәвиевкә зарланмаганнар. Ул әллә кайчан котырып килеп житәр иде, — диде Хәкимжан, бу чаклысы белән ризалашкандай.

— Габсаттар эшләми инде. Башына операция ясаганнар. Хәле шәптән түгел, диләр. Ялгыша да башлаган бугай.

— Ялгышыр инде... Буш башны нигә ачканнардыр тагын, — диде Хәкимжан, кул селтәп.

Тынып калдылар. «Кеше рәнжеше тотмый калмый торгандыр. Күпләрне

кыерсытты шул теге чакта», — дип уйлады Рәсим, Габсаттарның әнисенә карата кылган юньсезлеген искә төшереп. Галәвиев турында сүз катуны кирәк санамады, электр линиясе сузу турындагы фикерен Исхак белән уртаклашасы килде.

— Ризалашмаслар, — дип җавап бирде Исхак, яшьтәшен тыңлаганнан соң.

— Эш сездән тора. Мәсьәләнең мөһимлеген аңлата белергә кирәк. Аланбашта ферма булачак, дип күтәрелгәндә, каршы килүче табылмас.

— Бу фикерне күтәрергә ярый.

— Озакка сузмагыз. Тимерне кызуында сугу хәерле, — дип озатып калдылар совет җитәкчесен.

— Молодец, энем Рәсим, сөйләшә беләсең. Син монда яшәгәндә авыл терелми калмас, Алла боерса! — дип канәгатьлек белдерде Хәкимҗан...

* * *

Сабантуй көннәрендә Аланбаш тирәсе ыгы-зыгыга күмелде. Туган-үскән җирен сагынып, җирсеп кайткан элекке авылдашлар күбәйде. Бәйрәм көннәре булуга карамастан, аларның йөзендә моңсулык. Табигый халәт иде бу. Чөнки кайберләре хәтта ата-бабасы яшәгән, үзләре якты дөньяга килгән нигезләренең төбәген дә чамалый алмадылар. Якыннары күмелгән каберләрнең кайдалыгын онытучылар да бар иде. Ничек үкенмәссең? Үкенәләр, билгеле. Элек ел саен кайтып йөрмәүләренә үкенәләр алар. Өлкәнәя башлагач, изге туган җирнең кадере исләренә төшкән. Авылның соңгы казыгын суырып алгач та үз нигезеннән кузгалмаган Хәкимҗанга, илнең теләсә кайсы шәһәрендә төпләнерлек мөмкинлеге булган Рәсимгә карата кайтучыларның ихтирамы, рәхмәте зур иде.

— Сез биредә яшәгәндә без авыз тутырып: «Авылыбыз исән!» — дип әйтә алачакбыз, — диделәр алар киткәндә.

— Ел саен кайтыгыз. Яшел чирәмен таптап үскән туган җирегез барлыгын онытмагыз. Аланбаш терелергә тиеш, — диде Рәсим, кунакларны озатканда. Киләчәккә булган планнар турында да сөйләде. Кайтырга теләүчеләр була икән, колач җәеп каршы алачакларын әйтте: — Кешелек дөньясы авылга бурычлы: авыл ашата, авыл киендерә. Таза беләкле, олы йөрәкле егетләр никадәр күбрәк, авыл шулкадәр нык һәм бай булачак.

Кунак авылдашлар кузгалдылар. Алар утырып киткән машиналар артыннан кара тузан күтәрелеп калды. Шушы тузаннар корытты инде Аланбаш халкын элек-электән үк. Аланбаш белән Тимәк арасыннан узучы юлга нибары бер чакрым ара — ирләр адымы белән барлы-юклы мең атлам. Әнә шул арага асфальт салганда елның теләсә кайсы вакытында теләгән җиргә барып кайтырга булыр иде.

«Авылны корытучы төп сәбәп — юлсызлыктыр, мөгаен», — дигән карашта Рәсим. Көнбатыш илләрдә урамнарда гына түгел, урман сукмакларына да таш түшәлүен күреп-белеп кайткач, бу фикере тагын да көчәйде. Аларда кечкенә авылларның, хуторларның сакланып калуында елның теләсә кайвакытында йөрерлек ышанычлы юлларның булуы төп роль уйнавына икеләнми иде ул...

Кинәт ишетелгән трактор гөрелтесе Рәсимне уйларыннан бүлде. Арба таккан «Белорусь», урта юлдан каерылып, Аланбашка туп-туры килә башлады. Гаҗәпләндергәне шул: трактор арбасында трансформатор кукраеп утыра иде. Сөенеченнән кул чабып куйды Рәсим. Авылны торгызу турындагы хыялы шушы трансформаторны утыртып куюдан башланыр кебек тоелды аңа. Ул тракторны юлга чыгып каршылады. Өйләрдән илле-алтмыш адым тирәсе ераклыкка туктагач, тракторчы кабинадан башын тыгып:

— Сезгә трансформатор китерергә кушканнар иде, кем алып кала? — диде.

— Мин, — диде Рәсим, ике дә уйламыйча.

— Күз-колак булыгыз, ботарлый күрмәсеннәр, — дип кисәтте егет Рәсимне.

— Курыкма, күз карасы кебек саклarбыз.

— Кран килеп төшергәч, арбаны алып китәрмен, — дип тракторчы трансформаторны арбада килеш калдырып китте. Чәй эчәргә керергә кыстаган иде Рәсим, ашыгуын сылтау итеп, егет керүдән баш тартты.

Аланбашта электр уты кабынды. Кичләрен дүрт өйнең тәрәзәләреннән һәм Хажи белән Хафиз йорты арасына утыртылган багана башындагы лампочкадан таралган яктылык, ерак-ераклардан күренеп, бу төбәктә тормыш башланып китүен хәбәр итә кебек иде. Куян фермасы урнашачак урынга кадәр баганалар утыртылып, чыбык тартылды. Аның ихатасы әйләндерелеп, дистәдән артык куян оясы ясап куелды инде. Озакламый куяннар кайтартылачак.

Ферма мөдире дә табылды. Бу хезмәт Хажи бичәсе Хәлимәгә йөкләнде. Өйләренең эше беткәнче үк хатын биредә хәрәкәтләнә башлады. Аланбаш беткәннән бирле Хәлимәнең монда булганы юк иде. Беренче аяк баскан көнне күзенә ташланган тамаша төштә күргән мизгелләр кебек тоелды ана. Күптән гомәме гөрләп утырган авыл урынында бары дүрт өй кукраеп утыра. Аның да берсе — үзләренеке.

— Үзеңнең кайтасын киләме, Хажи абый сүзенә карап кынамы? — дип сорыйсы итте Рәсим, Хәлимәнең уйга батып йөргән бер мәлендә.

— Икесе дә бар: беренчедән, ир кайда — хатын шунда булырга тиеш; икенчедән, үземнең дә мал тотып, иркенлектә яшисем килә; өченчедән, бу авыл мина чит түгел ләбаса! Аның язмышы өчен мин дә җаваплы. Ниһаять, Хәкимҗан абый белән синең үрнәкнең йогынтысы да булды. Авылны терныкләндерүдә без дә өлеш кертергә тиеш, дигән карашка кердек без Хажи абыең белән, — диде хатын, тәфсилле җавап биреп. Куянчылык белән шөгыльләнгәне булмагач, эшкә кереп китәренә икеләнүен дә әйтте.

— Фәриха апага таныш хайван алар. Без яшь чакта ук Хажи абыйлар куян асрыйлар иде. Куян карау тәртибен онытмаганнардыр әле, — диде Рәсим аның икеләнүенә каршы.

— Яшьләр килеп төпләнгәнче хәрәкәтләнергә туры килер инде, — диде Хәлимә, башка чара юклыгын чамалып. — Килергә теләүчеләр табылса инде...

— Эш күрсәтә башласак, кызыгып китеп, кайту ягына кермәсләрме? Симертү терлекләрен монда күчергәч, өстәмә эшче көч булдыру турында колхоз түрәләренә дә уйланырга кирәк булачак бит. Безнең янга тагын берничә өй өстәлер, дигән өметтә торам әле мин, — диде Рәсим ихласлык белән. Күнеле шулай тели аның. Үзе дә хәллерәк гаиләләрне кире кайтырга өндәп йөри бит, тәэсире тими калмас сыман тоя.

Аланбаш өйләрендә ут яна, радио сөйли, телевизор күрсәтә. Авыл кешесе өчен тагын ни кирәк! Кайтып, ата-бабасының ташландык нигезенә тамыр җибәрүенә Рәсим тамчы да үкенми. Сугыштан соңгы елларда гына да районда егермеләп кече авыл юкка чыккан. Ни кызганыч, Аланбаш та шулар исәбенә керә. Әгәр туган авылын кабат торгызуга өлеш кертә ала икән, Рәсимнән дә бәхетле кеше булмаячак...

Велосипедка атланып, Тимәк ягыннан томырылып килүче малайны күреп, Рәсим аптырашта калды. Таныды килүчене, ул Хамиянең кече малае иде. Капка төбенә чыкты Рәсим, энесен шунда каршылады.

— Ут капмагандыр бит, нигә шулкадәр томырылып куасың? Егылып имгәнүең бар, — дип битәрләп алды ул малайны.

— Әни ашыгырга кушты. Сина язу җибәрде, — дип абыйсына кәгазь кисәге тоттырды малай. Рәсим язуга күз салды.

«Абзыкай, Оксана шалтыратты. Казаннан районга кайтучы машина белән безгә киләләр. «Караңгы төшкәнче Тимәктә булырбыз», — диде. Ана кадәр бездә булырга тырыш. Ул бит синең өчен килә. Хамия...»

Укып чыкты да аптырап куйды. «Киләләр», дигән. «Кем белән килә соң ул? Софья Петровна да михнәт шулпасы чөмергән җирен күреп китәргә уйладымы?»— дип уйланып алды.

— Үскәнем, кайтып әйт, кичкә таба барып җитәрмен, — дип малайны кайтарып җибәрде.

Шатлыгын уртаклашу өчен Хәкимҗаннарга керде Рәсим. Аның кәефе күтәренкелекне чамалап, күршесе сүз катканчы ук сорау бирергә ашыкты.

— Куанычлы хәбәр-мазар бармы әллә?

— Бар, Хәкимҗан абый. Миңа кунаклар килә. Ерак-ерак җирләрдән...

— Марҗаң кайтамы әллә? — диде Хәкимҗан, көлемсерәп.

— Әйе.

— Бик хуш. Башта кая киләләр?

— Хамиягә тукталалар.

— Туры шушында алып кайт. Карчыкка аш салырга кушам. Иртәнгә мунча ягарбыз... Менә дигән итеп хөрмәт күрсәтәбез, — дип, үзенә килгән кунакка сөенгәндәй, тезеп алды күрше.

— Рәхмәт, Хәкимҗан абый, бүгенгә мәшәкатьләнмәгез. Хамия әзерләнми калмас. Кунакларны ул да көтә. Иртәгә монда кайткач күз күрер, — диде Рәсим, күршесенең олы җанлылыгына сөенеп.

— Килештек. Иртәгә сез кайтканчы бәрән чалам.

— Нигә ул чаклы?

— Шашлыкка.

— Мәшәкатьләнмә, үзем җаен чыгарырмын.

— Синең кунак — минем кунак. Вәт, шул! Күп сөйләнмә. Нишләргә кирәген үзем беләм, — дип кырт кисте Хәкимҗан.

— Сине чыгымга тарытасым килми.

— Ха! Нинди чыгым? Син безнең сарыклар чутын беләсеңме?

— Юк.

— Мин дә белмим. Шулай булгач, син бәхәс кубарма.

— Яхшы, күндерден... Бәясеннән тормам.

— Менә сиңа бәя! — дип Хәкимҗан, йодрык төйнәп, Рәсимнең борын төбендә уйнатып алды.

— Биреләм, Хәкимҗан абый, — дип Рәсим ике кулын күтәрде. Икесе дә җинелчә көлешеп алдылар...

Тәкатьне корытканы — көтү һәм куып җитү. Тимәктә дә көтәләр. Рәсим кая барып орынырга урын тапмый. Утырып торып та тынычлана алмый, йөрештергәндә дә йөрәк ашкынуы кимеми. Тыштан никадәр сабыр кыланырга тырышса да, эчке халәтен яшерә алмый. Камил дә, Хамия дә аның кичерешләрен аңлый. Өй хуҗасы ара-тирә тышка чыгып, кайтыр юлга күз салып керә. Кичкелеккә табын әзерләп йөргән Хамия абыйсын тынычландырырга тырыша.

— Машинаны артык кызу кумаганда да якты күздә кайтып элгәшергә тиешләр. Хәзер көннәр озын бит, — ди.

— Исән йөрсеннәр, килми калмаслар, — дип Камил хатынының сүзен җөпли...

Җәйге кояш офык артына тәгәрәде. Җир өстенә акрынлап карангылык пәрдәсе җәелде. Күз бәйләнер вакыт җитеп килә, бер-бер хәл булмагае, дип кунак көтүчеләр ныклап торып борчыла башлаганнар иде инде, кинәт капка төбенә туктаган машина тавышы ишетелде. Өчесе дә урамга ашыктылар. Кунак көтү манзарасы белән чын-чынлап мавыга башлаган балалар — Хамиянең кызы белән малае да өлкәннәргә иярде.

Автомобильнең дүрт ишегеннән дүрт кеше чыкты. Өчесен шундук таныдылар: Тәлига, аның ире һәм Оксана. Дүртенчесе — чандыр, калку гәүдәле яшь егет. Карангылы-яктылыда аны төсмерли алмадылар. «Оксананың малае түгел микән?» — дигән уй йөгерде Рәсимнең башына. Кул бирешеп күрештеләр. Оксана белән Хамия бер-берләренә чат беркеп кочаклаштылар. Рәсим Оксананың иненә кул салырга кыенсынды. Вакыт арасы аларны күпмедер читләштергән иде инде. Кунакның кулын кысып, аркасыннан сөеп куйды.

— Кунакларны кабул итегез, — диде Тәлига, күрешү йоласы тәгалләнгәч.

— Итәбез, итәбез, — диеште көтеп торучылар. Алып кайтуларына рәхмәт әйттеләр.

— Ничек очраштыгыз? — дип кызыксынды Хамия.

— Көтмәгәндә! Үзебезнең якка борылган юл чатындагы кибеткә сугылырга дип туктаган идек, шунда очраштык. Оксана танып алды мине, — диде Тәлига, күрешү вакыйгасы турында.

Хамия барысын да өйгә керергә әйдәкләде. Тәлигалар ашыктылар. Аланбашка абыйсы Хәкимҗан янына кагыласы барлыгын, районда да аның кайтуын көтеп торулары хакында әйтеп, кузгалу ягын карады.

Өйгә керделәр. Рәсимнең йөрәге урыныннан кузгалды. Беренче мәхәббәтен белдерергә ниятләнгән яшь егетләрнеке төсле дулап тибәргә кереште. Оксанага ияреп килгән егет үзенең яшь чактагы рәсеменә тарткан иде. Оксана бер хатында: «Синә охшаган малай үстерәбез», — дип язган иде. Ул чакта Рәсим: «Кияүгә чыгып, Софья Петровна малай тапкандыр», — дип уйлаган иде. Ул баланың ни өчен үзенә охшавына гына гаҗәпсенеп куйган иде.

Рәсимнең фикерләре чуалганын аңлагандай, Оксана телгә килде:

— Улым белән таныштырыйм әле сезне. Белеп торыгыз: бу егет — Ренат Рәсим улы Нәбиев булыр...

Бер мизгелгә тынлык урнашты. Барысыннан да алда Хамия телгә килде:

— Ренат үскәнкәем! Абзыкайның чатлап торган күчермәсе икәнсең бит! Шушындый энебез барлыкны бу көнгә кадәр нигә яшереп йөрдегез? — дип ул егетне кочакка алды, аркасыннан бәпләп сөяргә кереште.

Рәсимгә икеләнергә урын юк иде. Үз канынннан баш тартырга җыенмый. Оксанага да үпкә сүз җиткерүне кирәк санамады.

— Исәнме, улым, — дип, гомерендә беренче тапкыр үз баласына үз аты белән эндәшеп, Ренатны килеп кочаклады.

Тамак төбенә төер утырды. Бермәлгә телдән язды Рәсим. Стена буендагы урындыкка көч-хәл белән барып утырды да тезләренә кадәр сыгылып төшеп, үксеп еларга кереште. Еллар буена йөрәгендә йөрткән кайгы-хәсрәтләрен күз яшьләре белән юып агыза иде ул. Бу тамашаны күреп, барысы да тынып калдылар. Оксана бераздан аның янәшәсенә килеп утырды. Шуны гына көткәндәй, Рәсим хатынның иненнән кочып, күкрәгенә кысты.

— Рәхмәт, Оксана... Шушындый егет үстергәнең өчен рәхмәт... Мине онытмыйча монда килүең өчен рәхмәт, — дип ихлас хисләрен җиткерде.

Үзен белә башлаганнан бирле беренче тапкыр елавы иде Рәсимнең. Күргән-кичергән газаплар өчен язмышын каһәрләп, иң якын кешеләре белән егерме ел аеры торырга мәҗбүр иткән тәкъдиргә рәнҗеп елавы иде аның.

— Тынычлан, Рәсим, үткәнне яшь белән кайтарып булмый. Алдагы көннәр якты, бәхетле булсын. Сәламәт яшәргә язсын... — Бу сүзләрне Оксана саф татарча итеп әйтте. Нәкъ элеккечә — унике-унөч яшьтә чакларында бергә уйнап, сөйләшеп йөргәндәгечә итеп.

Рәсимнең тәне жиңеләеп китте, жаны тынычлана төште. Оксананың башын күтәрде, хатынның ике битеннән тотып, күзләренә томырылып карады. Хатынның карашыннан нидер белергә тели сыман иде ул.

— Шөйлә синме соң бу? — дип аның иреннәреннән үбеп алды.

— Мин, мин, Рәсим...

— Татарчаны да онытмагансың.

— Ничек онытыйм! Без Ренат белән икәүдән-икәү калганда гел татарча сөйләшәбез. Янәшәбездә татар гаиләләре тора, алар белән аралашабыз... Шулай бит, улым?

— Шулай, — дип татарча җавап кайтарды Ренат.

— Әтиеннән туган теле ул. Гомерең эчендә барырга туры килсә, рәхәтләнеп татарча сөйләшерлек бул, дип өйрәттем, — дип аңлатты хатын, яшь вакытында өйрәнгән телне күп еллардан соң да онытмау сәбәбен...

Сүз куерган арада кичке аш-су әзерләнде, өстәл өсте нигъмәт белән тулды.

— Безнең дә күчтәнәчләр бар, табынга чыгарыйк, — дип Оксана кузгалмакчы иде, Хамия ана кузгалырга ирек бирмәде.

— Күчтәнәчкә вакыт житәр. Бүген хуҗалар әзерләгәнне авыз итәрсез, — дип кырт кисте...

Алар өстәл артыннан кузгалганда таң беленеп килә иде. Хамия һәрберсенә аерым-аерым урын җәйде. Бүген күзенә йокы кермәячәген әйтеп, Рәсим ятудан баш тартты.

— Мин дә Рәсим хәлендә. Без кояш чыкканчы сөйләшеп утырырбыз, — диде Оксана да.

— Бәлки, мин дә әти белән әни янында төн үткәрермен, — диде Ренат, Хамия ана түр бүлмәдән урын күрсәткәч.

— Энем, син йокла. Алар бүген серләшеп бетерсеннәр, ә иртәгә өчәүләп гәпләшерсез, — дигән кинәш бирде ана Хамия.

— Ярар. Алар белән бераз утырам да кереп ятармын, — дип килеште Ренат хуҗабикә белән.

Өйдәгеләрне тынычлыкта калдырып, Нәбиевләр өчәүләп верандага чыктылар...

***

Аланбаш урынына житкәч, Оксананың ис-акылы китте: яшен сугып көйдергәнме, жир тетрәп барлык каралты-кураны жир упканмы — һич аңламалы түгел иде. «Югары оч», «Түбән оч», «Күл буе» дип йөртелгән урамнарның эзе дә калмаган. Өйләре юкка чыккан баз урыннарыннан чамалап кына элек урамның кай урыннан үткәнен белергә мөмкин. «Сугыш өермәсе кичергән Украина авыллары да мондый хәлдә түгел иде», — дип аптырап уйлап куйды Оксана.

Тимер капканы ачып, ишек алдына кергәч кенә Оксананың ямансулавы басыла төште. Ихатаның төзеклеге, ишек алдындагы чисталык һәм тәртип хатынны гажәпкә калдырды. Өйнең тышкы баскычы да аяк басарга жиксендереп тормалы — сап-сары итеп юылган. Агач бакчасы тергезеп жибәрергә дә вакыт тапкан яшь хуҗа...

Оксана Хамия хаты буенча белә: болар барысы да Рәсимнең кулы, аның тырышлыгы белән барлыкка килгән. Өлгерлегенә, тырышлыгына гажәпкә

калып, сокланмалы гына. Тормыш йөген тарту җинелгә туры килсен дип, өйләнү ягын да карамаган. Очрашкан көнне: «Күнелемнән сине берничек тә чыгара алмадым, кайчан да булса барыбер кушылырыбызга өметләнеп яшәдем», — диде бит. Сүзе хак, күрәсен. Ул да, минем кебек, язмышны каһәрләп, янган-көйгән икән, мескенем... Нишләдек сон без? Рәсимнең госпитальдән чыгуын көтеп алып, очрашкан булсак, безнен юллар аерылышмас иде бит... Анын яраланганын да белмәдем хәтта. Госпитальдә ятуын гадәти авырудан гынадыр дип санадым... Ә ул үлемнән чак-чак калган... Ренат белән минем бәхеткә түгел микән әле?..

Төп өйгә кайтып, рәтләп танышып та бетерә алмадылар, күрше Хәкимҗан килеп кереп, барысын да үзләренә әйдәкли башлады:

— Балалар, хәзер үк керәбез, аш-су әзерләнгән. Апагыз көтеп кенә калды, — дип кабаландырды.

— Тимәктән ашап кына кайттык бит, керәбезмени? — дип аптырап сорады Оксана Рәсимнән.

— Авылда өй саен ашка алыш инде. Тагын ике урынга керәсе булыр, — дип көлемсерәде ир.

— Мәҗбүримени?

— Түгел. Ләкин ата-бабадан килгән гадәт.

— Элек мин андыйны сизмәгән идем.

— Каян сизәсен? Ашатырга ризыгын булмагач, кунак чакырып буламыни?

— Анысы хак, — дип килеште хатын, көлемсерәп. Бергә ачыктылар бит, белә, бик белә ул заманны...

...Санаулы көннәр юри кабаланалар шикелле — үткәне сизелмәде дә. Оксана белән улын күрми дә калгандай тоелды Рәсимгә. Күзгә генә күренгәннәр иде, китәр көннәре дә җитте — иртәгә юлга кузгалачаклар...

— Рәсим, мин килүне озакка сузмам, җәй урталарында монда булырмын. Камилне кисәт, мине штатка кертүне онытмасын, — диде Оксана, анын юлга җыенуын тыныч кына күзәтеп утырган Рәсимгә.

— Ышандырды бит. Камил сүзендә тора торган егет. Әйткәнен үтәми калмас, — дип җавап кайтарды ир.

— Шулай да кызыксынып тор.

— Әлбәттә!..

— Әни, мин дә синен белән киләм, — диде өлкәннәр сүзенә читтән генә колак салып торган Ренат.

— Ә институт?

— Казанга күчертәм. Анда да электроника буенча белгечләр әзерлиләр бит... Сезнен янга кайтып йөрермен, ярдәм итәрмен, — дип тезеп алды Ренат. Күрәсен, бу хакта алдан уйланган булган инде ул.

— Син ничек уйлыйсын, әнисе? Мин килешер идем. Ул кайтып безгә ярдәм итәр, ә без ана булышырбыз, — диде ата, көлемсерәп. Студентка нинди булышлык кирәген белә бит инде ул.

Ризалаштылар...

...Иртәгәсен Рәсим хатыны белән улын үз машинасында Казан аэропортына озатты...

*Актаныш,*
*2005 — 2006 еллар.*



Фирүзә
Җамалетдинова

## ЧОРЫМ КАЛЫР ҮТКӘНДӘ

### Туган илем

Туган илем! Мин яраткан кебек
Тагын кемдер яратыр дип белмим.
Син өйрәткән сүзне сөйләп йөрим,
Бер иртәндә откан көйне көйлим.

Газиз Ватан! Синең өчен утка
Кергән бабаларым нәселе мин.
Шуңа бугай тоташ уттан торган
Сөю дигән илнең әһелемен.

Туган илем! Хаталарың жанда
Төзәтелә кызыл кара белән.
Төзәткәнне күпләр яратмый шул,
Тарих кичермәгәнен дә беләм.

Туган илем! Мин төзәтеп яшим,
Һәм төзәлеп яшим синдә һаман.
Һәр яхшыңа башым иеп яшим,
Яманнарың күргәч, хәлем яман.

Яхшың күпме, әллә яманыңмы? —
Туган илем, хәлең жиңел түгел.
Бар аклыгың сине алга этсә,
Каралыгы артка тарта бүген.

Алга атлыйм, илем, синең белән,
Фәрештәдәй ак канатлар индә.
Тик буталып йөрим булып чыга,
Ак һәм кара арасында мин дә...

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА – *шагыйрә, прозаик; «Толымлы ай», «Догалы корт», «Еллар кәрваны», «Хикәяләр» һ. б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге әдәби бүләк иясе. Казанда яши.*

Һәм яшәргә теләп ары китәм,
Бирешмә, дип, күңел алга дәшә.
Бирешмә син, илем! Җуелма син!
Яшә, илем! Яшә, илем! Яшә!

## Балта

Барларда, сыра янында
(Күбеге кайнап торган),
Синме, милләттәш, Җәлил, дип,
Кызгачтын гәпләр корган?

Синме, сөйләшкән Җәлил, дип,
Монда рәхәт яшәгән.
...Кемнәр килеп кагылса да,
Шагыйрь рухы дәшмәгән.

Бар халыклар таныганнар,
Алман иле таныган!
Дастан итеп сөйләрләр күк
Алар моннан ары да.

Татарның бөек улы! – дип, –
Халкының асылташы,
Киселсә киселгән, әмма
Һич сатылмаган башы...

...Моабитны эзли-эзли
Тирлиләр, пешәләр дә,
Диварларына сөялеп,
Фотога төшәләр дә,

Эндәшәләр бар гавамга:
– Җәлил рәхәт яшәгән!
Күкрәр чакта күкрәгән дә
Яшьнәр чакта яшьнәгән...

Аннан затлы сувенирлар
Юллый алар бүләккә.
...Ярый алмаган, һай, Җәлил
Башы белән түләп тә!

Илем, диеп, Халкым диеп,
Баш куелган... Балта бит...
Балта асларында милләт
Рухы өзелеп ята бит!

Юкса килә милләтемнең
Дастан булып калкасы.
...Үткенрәк әллә алман,
Әллә татар балтасы.

## Яшьлек

Яшьлеге — җуләрлегеме:
Җаны тоташ хис кенә.
Дулкыннарны күлмәк итеп
Кигән гүя өстенә.

Бер чума да бер калка ул,
(Гамәлен була аклап).
Аннан ары йөзеп китә,
Дулкыннарны кочаклап.

Аны күргән дәү диңгез дә
Әле шундый яшь кебек.
Аны күргән дулкыннар да
Һич түгел кебек җебек...

Яшьлеге — исәрлегеме,
Аңлап булмый һич кенә.
Дулкыннарны күлмәк итеп
Кигән гүя өстенә.

Шундый тын иде иртәләр,
Су ята иде көлеп.
Диңгезне дә кузгатты күк
Ул яшьлек алып килеп...

Аны күргәч, дулкын белән
Кояш шатлык бүлешә...
Аһ! Яшьлеккә күлмәк кебек
Исәрлек тә килешә!

## Замана ятиме

Уйнак суларга төбәлгән
Елганың ике яры.
...Күзләре дулкындай зәңгәр,
Чәчләре комдай сары
Нәни генә бер кыз бала
Уйный ярда су түгеп.
Кемнедер эзли... күңеле
Дулкын күк тыныч түгел.
Ярлар суны ташлый алмый,
Су белә ярлар холкын.
— Әнием, син кайларда соң?
...Үз ярын үбә дулкын.
— Әнием, син кайларда соң?
— Әтием, син кай якта?
Кычкыра бала — офыкны
Кайтавазы уята...

## Уен

Без икәү уенга кердек,
Бу бары уен менә.
Уеннардан бүген мина
Нигәдер кыен менә.

Хәрәмләшүләр юк инде,
Чип-чиста — уем кебек.
Читтән күзәтү җинелдер,
Уйнавы кыен кебек.

Без икәү уенга кердек,
Җинүне кем уйлаган?
Без генәме, уенны да
Чын иттереп уйнаган?

Чын иттереп ышанган да
Чын иттереп ялгышкан.
Нидер көткән, уеннарга
Этеп керткән язмыштан.

Тормыш — уен, яшәү — уен,
Адым саен алдый шул.
...Ә мәхәббәт, тик мәхәббәт
Уен була алмый шул...

## Бар да калыр

Сүзләрне оныту кирәк —
Һәм баш уйламаячак!
...Аквариумга салганнар
Кебек тоела кайчак.

Тынсыз гына, өнсез генә
Яшәп яткан бер мәлдә,
Бер сүз чыгып ычкына да
Дөнья баса сөялгә.

Аквариумдай тар дөнья,
Кысан — нәкъ аквариум.
Югыйсә, әйткән сүзем дә
Якты, ап-ак бар уем.

Ак сүз дә ярамый хәтта,
Дөрес итеп әйткәндә.
Гаделлек һәм намус җебе
Калган ерак үткәндә.

Якын-ерак бабайларның
Гомере белән өзелгән.
Намус урынына затлы
Машиналар тезелгән.

Яхшы йортлар житкерелгән
Әллә ничә катларда.
Ә үткәндә... ә үткәндә
Калган яхшы атлар да.

Яхшы атлар, дөрес сүзләр —
Бар да калган үткәндә.
Бәхетле елмая байлар,
Чор тәпиен үпкәндә.

Кешегә шәп бәтинкәнең
Очы белән типкәндә,
Һай, бәхетле елмаялар:
«Сезме кеше? Сез бәндә?!»

Безнең чордан яхшы йортлар,
Бәтинкәләр калыр күк.
Бөек Тарих битләрендә
Заман шулай яныр күк.

...Аквариум кебек дөнья,
Сулыш житми үпкәмдә.
Үз гамәле, йөзе белән
Чорым калыр үткәндә...
Җырым калыр үткәндә...

## Хыялда

Иярәсе килә кайчак болытларга,
Сүз кушасы килә дулкын булып ярга.
Кушыласы килә кошлар төркеменә:
«Сәлам илтим, чибәр егет, әйт кеменә?»
Күктән аклык, шуклык алам дулкыннардан,
Кошлардан — моң, кояштан — нур, ныклык — таудан.

Хыялларда кайчак ерак китеп барам,
Сызлый, әрни озын юлда тирән ярам.
Кая барам, уйдан аркан ишә-ишә,
Белмим кая җитәр идем тирли-пешә —
Мичкә куйган бәлешләрем искә төшә...

## Кулъяулыгым йөртәм

Рәнҗешләрне җил дә алып китмәс,
Нәселенә калыр, балана.
Күз яшьләре яңгыр юып бетмәс
Ташкын булып керер калаңа.

Көннәреңне болыт булып каплар,
Давыл булып күкрәү-яшенле.
Ул рәнҗешләр күзләреңнән тамса,
Кемнәр сөртер, илем, яшеңне?

Шуңа бераз игелек тә көткән,
Мәрхәмәт тә көткән көнебез.
Гасырлардан гасырларга күчеп,
Бүгенгегә җиткән көнебез.

Һава кебек ирек сулавыбыз
Ышандырып куя кайчакта.
Ярлылыкка без өйрәнгән инде
Ни кылырбыз икән бай чакта?

Бәлки шәфкать? Хәйриядер бәлки...
Байлар күргән барга — уй шикле.
«Бәлки»ләргә бүген булса да мин
Бикләп куйыйм әле ишекне.

Мин рәнҗемәм, илем, ни күрсәм дә,
Илдән аерым түгел күргәнем.
Белсәм дә мин мулла бабамнарны
Сөргеннәргә тиклем сөргәнен...

Үчем дә юк, бары кызгануым
Кала килә гел үз көчеңдә.
Кулъяулыгым түш кесәмдә йөртәм,
Күз яшеңне сөртер өченгә...



Кәрим Кара

# ИНГА МЕЙТАНЫҢ ҖИНАЯТЬ ЭШЕ

БӘЯН

Казан шәһәренең Мәскәү районы эчке эшләр бүлеге идарәсенә патруль посты хезмәткәре лейтенант Рудинның рапортыннан: «...Көндезге сәгать өчтә «Тандем» универмагында сак төркеменең игътибарын урта яшьләрдәге ханым үзенә җәлеп итте. Хатын үтеп-сүтеп йөргән кешеләргә бәйләнгән кебек тоелды. Ул үткәннәрнең җиннәренә асылынды, юлларына аркылы төште, артларыннан тагылып нидер таләп итте. Бераз күзәтеп торганнан соң, ханымның чыгышлары җәмәгатьчелеккә комачау тудыра дигән фикергә киллек. Универмагның беренче катында урнашкан полиция бүлегендә сорау алу, шәхси әйберләренә тентү үткәргәннән соң, түбәндәгеләр ачыкланды: ханымның үзе белән документлары юк иде, кул сумкасында бизәнү-төзәнү әйберләре, кульяулык, Мәскәү — Казан авиабилеты, өч мең тугыз йөз илле дүрт сум акча, Латвия акча берәмлеге булган биш йөз лат, бинт төргәге, берничә шоколад кәнфит һәм салкын корал исемлегенә кererлек, лезвие калынлыгы 2 мм, озынлыгы 9 см артык булган пычак табылды. Куелган сорауларга ханым аермачык җавап бирмәде. Аның белән контактка кергән гражданнар түбәндәгеләр хакында хәбәр иттеләр. Ул гел ниндидер Сафин Шәфкать исемле кешенең кайдалыгын сорашып мөрәҗәгать иткән. Белмибез дип кистереп җавап бирүләренә карамастан, һаман үзенекен такмаклап, ул кичекмәстән Сафин дигән кешене табарга тиешлеге һәм аның җанын җәһәннәмгә олактырачагы хакында антлар иткән. Сез беләсез аны, әйтегез миңа, кайда яшердегез, әгәр ярдәм итмәсәгез, үзегез дә аяусыз хөкем корбаны булачаксыз дип янаган. Ханым сорауларга җавап бирүдән баш тартты, шуңа да аның шәхесен ачыклау мөмкинлеге булмады. Сөйләшү манерасы, тышкы кыяфәте аның чит яклардан булуына ишарә ясый. Тышкы күренеше: буй озынлыгы 165-167 см, зифа гәүдәле (яхшы сакланган яисә спорт белән шөгыльләнә), чәчләре аксыл, җилкәгә кадәр, күзләре ачык-зәңгәр, бите — овал, күзгә бәрелеп торган аерым билгеләре юк. Рус телендә акцент белән сөйләшә, һичшиксез, туган теле башка тел булырга тиеш. Куелган сорауларның эчтәлегенә төшенергә теләми, гел үзенекен тәкрарлый: аңа кичекмәстән, имеш, татар милләтеннән булган, Татарстанда яшәгән Сафин Шәфкать исемле кешене эзләп табарга кирәк. Югарыда телгә алынган гражданин, әлеге ханымның белдерүе буенча, күптән түгел коточкыч җинаять кылган, ике кешенең үлүенә сәбәпче булган. Шуннан артыгын өстәп ханым бертөрле дә мәгълүмат хәбәр итмәде. Шунысы да игътибарга лаек: ул яхшы киенгән булуына карамастан,

киемнәре каралган, төймәләре өзелгән. Тышкы кыяфәтенә игътибар булмаганы күренеп тора. Үз-үзен тотышы да шик уята, кылык-кыланышлары адекват түгел, сөйләгәндә бутала, бөтенләй кирәкмәгәнне сөйли башлый, фикере таркау, күз карашы — мәгънәсез. Әлеге ханымны мин янында булган әйберләре белән идарәнең дежур бүлегенә китереп тапшырдым...»

***

Мин, гомер буе погон таккан хәрби офицер, кырыс күңеллеләрдән саналдым. Бар тормышын тәртипкә буйсынып, еллар буе фәрман үтәп, язмышның рәхимсезлекләренә каршы торып, шулай кирәк дип яшәгән кешегә болай кәнфитләнеп утыру һич тә килешми кебек. Әлеге көндә Амур елгасы буендагы бер аучы өендә көннәр-төннәр үткәрә идем. Белмәгән кешеләр өчен әйтим: аучы өе гадәттә урман уртасында, хуҗаның белемнәре булган җирләрдә салына. Чит-ят кеше монда тыгылмый, беренчедән — ерак, монда килгән яшерен сукмакларны белгәннәр сирәк. Нииндидер могҗиза белән кемдер чикләрне атлап үтә икән, башына ядрә чәпергә дә күп сорап тормыйлар, шунда ук коры ботаклар арасына күмеп тә куялар, киек җанварлардан башка кемдер аны юллап табып йөрер диган сәер уй булуы да мөмкин түгел. Таныш аучылар, әшне сизсәләр дә (ә алар, гадәттә, хәбәрдар булалар), шул кирәк ана, йөрмәсен кирәкмәгән җирләрдә дигәнрәк йомгак ясап куярлар. Чөнки аучы үзе борын-борыннан килгән гадәтләргә тугры була, чит җирләргә кермәс, анда җәнлек ауламас, үзенә язганны Ходай бирер. Ул яктан тыныч идем мин. Митяй, минем служак, ышанычлы егет, без аның белән утлар-сулар кичкәнбез, нинди хәлдә дә теш агарта торган гадәте юк. Әлеге урманнар аның туган төбәге, судагы балык кебек йөзә бу җирләрдә. Тик бер ягы түзә алмаслык газаплар тудыра иде яшәешнең: мин бу аучы өендә — җәйге чиллә вакытында. Ә бит аучы өйләре кышкы чорларга исәп тотып салына. Бары кар төшкәч кенә аучы өеннән урманга ашкына һәм айлар буе кайтмыйча аучылык белән шөгыльләнә. Аучылык дигәч тә, безнең як кешеләре мылтыклар күтәреп шарт та шорт атып йөрүне күзаллый. Монда бөтенләй икенче төрле бу шөгыль. Ходайның һәр бирмеш көнендә аучы, таннан торып, үзенә билгеле булган җәнлек сукмагы буйлап китә. Ул урмандагы эзләрне китап укыгандай укый, һәр киек җанварның холык-фигылен яттан белә, бер үк җәнлекнең эзенә ике тапкыр рәттән тап булса, аны танышыдай күрә башлый. Әнә шул эзләр челтәрләренең кайсына ау кора, кайсысына капкын куя, башка төрле хәйләләргә бара. Чаңгысында көненә илле-алтмыш чакрымлап үтеп, кичкә генә алачыгына кайтып егыла. Икенче көн тагын ауларын барлый, эләккән җәнлекләрне җыештыра. Гадәттә, аучы кыйммәтле мехлы җәнлекләр ауларга хирыс. Кичкырын аучы, трофейларының салкыннан каткан саннарын эретеп, тиреләрен салдыра, җәяләргә тарттыра, итен капкыннарга тарата. Көнне төнгә ялгап айлар буе кеше күрми ята күпләре. Бары язга таба җәнлек тиреләренең сыйфаты китә башлагач кына, байлыкларын йөкләп өйләренә кайта. Уңышлы ел киләсе кышка кадәр ашап-эчеп ятарлык, өс-башка киенерлек, хуҗалыкка кирәк-ярак алырлык акча китерә. Әмма җәй көне, башында акылы булган аучы үз белемәсенә борылып та карамый. Урманга борын тыгарлыкмы ул вакытларда: кешеләрне, җәнлекләрне, йорт хайваннарын гаҗиз иткән дошман — сукыр чебен хакимлек итә анда! Аны безнеңчә вак черки дип тә йөртәләр, вәләкин бу дөреслеккә туры килми, урысча әйтелеше генә төп сыйфатын ачадыр бу җаһилның: мошкара, гнус. Әнә күзе зурлыгы гына нәрсәкәй бөтен тереклекне зар елата да инде. Кермәгән тишеге юк ул бәдбәхетнең, үзе утка да, суга да, агуга да бирешми. «Без-з-з» килеп, ул синең миеңне эчә, фигылеңне гарипли, тазалыгыңны какшата, акылдан яздыра, валлаһи. Анардан качып, пошилар урманнан китә, мал-туар как сөяккә кала, китергән зыяннарын әйтеп

аңлатырлык кына түгелдер. Кешеләр ничек яшиләр икән мондый шартларда дип гаҗәпкә калам мин. Яшиләр бит, үрчиләр дә әле, чукынмышлар... Алар, ни әйтсән дә, авылларында, каршы торырга җайлашканнар бу чиргә, ә мин урман уртасында көн күрәм. Аңлап карагыз инде минем хәлләремне...

***

Тикшерү бүлеге карарыннан: «Сак астына алынган билгесез гражданканың шәхесен ачыклау максатыннан, законга ярашлы рәвештә, җинаять эше кузгатырга. Шулай ук аның тарафыннан гаепләнгән Сафин Шәфкать шәхесенә карата тикшерү эшләре оештырырга. Бу эшне өлкән тикшерүче Сәетбатталов Винер Кәлиевичка йөкләтергә...»

***

56-68 нче җинаять эше папкасыннан: «Билгесез ханым судмедэкспертиза тикшерүен үткәннән соң, терапевт Иванов В.В., психолог Адрианов К.А., психиатр Колыванов С.М. түбәндәге нәтиҗәләргә килделәр: пациент Н. (алга таба да бу шартлы билгеләнелеш кулланыла) физик яктан сау-сәламәт дип табылды, барлык органнары яхшы торышта, тайпылышлар күзәтелми. Әмма пациентның психик халәте тотрыклы түгел. Сөйләме аңлаешсыз, үз-үзен тотышы-кыланышы сау кешегә хас түгел. Анда гиперактивлык күзәтелә, бер урында тыныч кына утырып тора алмый, игътибары мизгел эчендә үзгәрә, мания сызатлары төсмерләнә, болар барысы бергә шизофрения башлангычы икәненә ишарәли. Бирелгән сорауларга Н. анык кына җавап бирми, бер яктан, телгә булмаганлыгы сәбәп булса, икенче яктан, ул үз мотивларын аңлап җитми. Тирә-як дөньяга ориентиры югалган, кайдалыгын, кемнәр арасында булганлыгын аермачык белеп бетерми. Психикасы нык какшаган, курку фобиясе күзәтелә, нык төшенкелеккә бирелгән. Бүгенге көндә пациентны диспансерда күзәтү астында тиешле препаратлар белән дәвалаганда, уңай нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бар...»

***

«Билгесез хатыннан хастаханәдә врачлар күзәтүе астында өстәмә сорау алганнан соң, түбәндәгеләр ачыкланды: ханым Татарстан башкаласына күптән түгел генә Прибалтика илләренең берсеннән килгән, конкретрак әйткәндә, Латвиядән булырга тиеш. Моны Латвия акчасы да дәлилли, шулай ук ханым сөйләмендә еш кына латыш сүзләрен кыстырып җибәрә. Моны тәрҗемәче Сабитова Р.К. раслады. Сорау алу врачлар рөхсәте белән сәгатькә якын дәвам итте. Әлбәттә, алдан әйтелгәнчә, төгәл җаваплар алып булмады. Шунысы ачыкланды: ханым Сафин Ш. белән кимендә ике тапкыр очрашкан булырга тиеш. Ул бу хакта берничә тапкыр кабатлады. «Беренчесендә мин аны, ул мине күрмәде», — дигән төслерәк аңлаешсыз җөмләләр кулланды. Әлеге сүзләрнең нәрсә аңлатканлыгын ачыклау мөмкин түгел. Ханымның исеме Инга дигән версия бар, чөнки үзенә карата бу латыш исемен ул берничә тапкыр кабатлады. Факт өстәмә тикшерүне таләп итә. Ханым улын, ирен бик еш телгә алды, елап-сыктап, үзен аларның үлемендә гаепләде. Барысына Сафин Ш. гаепле дип, ана бәддога укыды. Ханым үткәннәрне исенә төшерә башлагач, тыела алмый еларга тотынды, урын-җирендә бәргәләнде. Сорау алу врачлар кушуы буенча шул урында туктатылды... Җыелган фактлардан чыгып, алда торган тикшерү юнәлешләре:

1. Рига шәһәренең Эчке эшләр бүлегенә, ханым турында мәгълүматлар сорап, юллама җибәрергә, фотосын салырга.

2. Сафин Шәфкать исемен йөрткәннәр хакында белешмә тупларга, кайсысының билгесез ханым белән элемтәдә булганлыгын ачыклау өстендә эшләргә.

3. Кайдадыр кылынган җинаять хакындагы хәбәрнен урынлы-урынсыз булганына ачыклык кертергә. Чынлап та кеше җаннары кыелганмы, әгәр кыелган булса бу җинаятьтә Сафин Ш. дип йөртелгән шәхеснең нинди катнашы бар икәнлеген исбатларга.

***

Минем дустым Митяй баштарак аяк терәп каршы килгән иде урманда төпләнүемә. Ятырсың авылда минем янда, эт белән дә эзләп таба алмаслар үзенне. Безнең авылны эзләп табудан Айда тереклек табу җиңелрәк дип көлгән иде. Сүзендә дөреслек тә бар кебек, якындагы тимер юл өч йөз чакрымда, район үзәгенә кадәр урман юллары буйлап җитмеш чакрымлап барасы, күрше авылның да иң якын дигәне — егермедән артык. Кеше монда утрак тормышта, үз гаме белән яши бирә. Зур җирдә нәрсәләр булганлыгы артык кызыксындырмый берсен дә. Иң мөһиме: вакытында кибеткә икмәген, аракысын китереп торсыннар, калганы барысы да үзләрендә бар. Чирли калсалар да үз урманнарында үскән сихәтле үләннәр белән дәваланырга тырышалар. Дарулар аяк астында, иелеп, кирәклесен ала белергә генә кирәк дип җибәрәләр. Буыннан-буынга тапшырылып җыелган белем ярдәм итә күрәсең үзләренә. Монда йомык халык, бер авыз сүз әйтми көннәре үткән кешеләр очраштыргалый. Артыгын күрмиләр, күрше эшенә тыкшынмыйлар, әмма үзләрен борчыганны һич тә яратмыйлар. Болар — эш кешеләре, озын көн буе хәрәкәттә барысы, авыр шартлар эшчәнлеккә өйрәткән. Килеп терәлсә генә, башка юл калмаган очракта, урыныннан кузгала алучы, авылын калдырып, кайдадыр юллана. Кайда барса да, тизрәк эшен бетереп, өенә кайтып егылырга ашыга. Шуна да Митяй калырга үгетләде, әмма мин сакланганны саклармын дигән әйтемне истә тотып, ераккарак китәргә карар кылдым. Җан дустымның тулы исеме — Дмитрий, без үзара Кандагарда шулай эндәшә идек аңа. Яшь чакта ук хуҗалыкчан, бар эшне җиренә җиткереп үтәгән, пөхтә, сабыр иптәш иде ул. Җыен яшь-җилкенчәк, орды-бәрде кылана яна хезмәткә чакырылган егетләр, минем дә яңа гына лейтенант погоннары таккан чагым, барысын да азагына кадәр уйлап бетермим. Митяй исә алдан күрә белә, киләчәген юнәтә, алдагы көн белән яши. Мәсәлән, ахмалга төшеп, дошман тылыннан унбиш чакрым үткәннән соң, зарыгып көтелгән привалда шап та шоп кесәләргә суккалыйбыз, үтереп тәмәке тартасы килә. Шул агу өчен ярты гомерне бирергә ризабыз. Яшь чакта бит алда торган гомерең очсыз-кырыйсыз булып тоела, җәлмени яртысы... Ярты сәгать элек без шашып аккан тау елгасын кичтек, өстәге әйберләрне ерткалап, текә кыяларга үрмәләдек. Кемдә сакланып калсын инде берәр бөртек сигарет? Ярамсыкланып елмаеп, барыбыз да Митяйга борылабыз, бәлки ул?.. Теге кашларын җыерып, өс-башын каккалый, кайдадыр төпкел кесәләренә кереп китә һәм могҗиза: аның көрәктәй кулларына шулай кыйммәтле булган кызыл пачкалы «Прима» сигареты тагылып чыга. Без аһ итәбез, кабаланып тәмәке токандырырга ашыгабыз, тәмләп тамакны ярырдай ачы төтен суырабыз. Яшиселәр килеп китә. Әлбәттә, бертавыштан Митяйга сокланабыз, рәхмәт сүзләре яудырабыз. Бар тән таралып төшеп бара, кузгалмас өчен әллә ниләр бирерсен, күзләр үзләреннән-үзләре йомыла. Ә Митяй, әйтерсен, безнең белән беррәттән чапмаган, шинел кузгалып, коры-сары җыештыра, учак тергезә, мае каткан тушёнкаларны утта җылытып ашасаң, күпкә туклыклырак. Мин барысы өчен җаваплы буларак, үземне йөрергә зур авырлык белән мәҗбүр итәм, шулай да Митяйнын чыдамлыгына сокланып туя алмыйм. Нинди генә кыенлыкларга очрасак та, взвод егетләреннән иң беренче аны ярдәмгә чакыра идем мин. Бер вакытта да каршылык күрсәтмәде, җебеп төшмәде, иң кулай юлларны таба белде, үзен аямый иптәшләре өчен утка керде. Анын соңгы

яралануына турыдан-туры мин гаепле идем, хәзер дә шуның өчен иптәшем алдында ниндидер унайсызлану кичерәм. Әмма ул фәрманны бирмәсәм, күпләр кайта алмаган булыр иде Әфган тауларыннан. Госпитальдән Митяй туры өенә кайтты, тик безнең аралар өзелмәде. Бер-ике тапкыр очраштык та әле. Миңа суд булганда, ул бар эшләрен калдырып, очып килеп житте, үз акчасына адвокат яллады. Ул адвокатының файдасы шулкадәр генә булды да соң, әмма янда жан дустың булу, аның ярдәмен тою бермә-бер ихтыяр көчен ныгыта. Менә тагын авыр хәлдә калгач, мин беренче итеп Митяйны исемә төшердем, ул гына ярдәм итә ала дип уйладым. Телефон аша зарларымны тыңлаганнан соң, Митяй, уйлап та тормастан: «Кил! — диде. — Без икәү чакта — таш кыя!» Тормышымда шундый кеше барлыгына рәхмәтләр укый-укый, мин саклык чараларын күреп, Рәсәйнең бер очыннан икенче очына сәяхәт башладым. Самолётларга утырырга шикләндем, чөнки үзем турында мәгълүматлар тиешле органнарга барып житкән булса, аларның жәтмәсенә эләгү куркынычы бар иде. Монысы инде минем планнарыма керми иде, шулкадәр вакытлар читлек аша күк йөзенә карап утырганнан соң минем иректә, кешеләрчә яшәп карыйсым килә иде әле. Хезмәт елларым, тәжрибә мине итәк-жиннәрне жыеп йөрергә беркадәр өйрәткән иде. Шуңа күрә хәвеф-хәтәрсез генә дустымның яшәгән авылына килеп життем. Үткәннәрне сагынып, сөйләшеп-гөрләшеп, без өч көн бергә булдык та Митяй мине үзенең аучы биләмәләренә китереп урнаштырды. Кирәк-яракны биштәрләрдә йөкләп килдек, кушкөпшәле мылтыгын калдырды ул, тамак ягына кайгырасы түгел иде. Сөйләшә-аралаша минем алдагы язмыш хакында без уртак фикергә килгән идек. Митяй шул уйларыбызны тормышка ашыру турында кайгыртырга тиеш. Моның өчен күпмедер вакыт кирәк. Нәрсә-нәрсә, ә вакыт минем житәрлек иде. Шуңа да тынычлап көтәсе генә кала иде миңа. Әлегә барысы да яхшы төсле, күз тимәсен, канэчкеч мошкараларны исәпкә алмаганда...

***

Латвия Эчке эшләр идарәсенең жавап хаты: «Сезнең тарафтан жибәрелгән фотода Латвия гражданкасы Инга Мейта белән охшашлык бар. Хәзерге вакытта Инга Мейтаның кайда икәнлеген без ачыклый алмадык. Эш урынында аның кайда икәнлеген төгәл генә әйтә алмадылар. Инга Мейтаның эш калдыруы житәкчеләрен борчуга салмаган, моны гадәти хәл дип кабул иткәннәр. Гражданка Инга Мейта — Латвиядә танылган шәхес, ул Спорт һәм туризм министрлыгында жаваплы вазифа башкара. Шулай ук Латвиянең сеймы депутаты, актив жәмәгать эшләре алып бара, еш кына үзенең сайлаучылары белән очрашулар оештыра, эше буенча ерак командировкаларда була, чит илләргә чыга. Шуңа күрә дә Инга Мейтаның министрлыкта булмавы беркемне дә шиккә салмаган. Төрле каналлар буенча аның белән элемтәгә керергә тырышу унай нәтижә бирмәде. Иртәгә сезнең шәһәргә, бу эшкә ачыклык кертү максатыннан, Эчке эшләр бүлеге хезмәткәре Янис Тынт жибәреләчәк. Ана мөмкин кадәр ярдәм итүегезне сорыйбыз. Хастаханәдәге пациент белән очрашу үткәрерсез дип өметләнәбез. Я.Тынт үз хезмәте буенча Инга Мейта белән берничә тапкыр очрашкан, якыннан белә. Шуңа күрә ул дөреслекне тиз исбатлар, сезгә дә ярдәме тияр.

P.S. Инга Мейтаның тормыш иптәше Андрис Мейтаның да Ригада юклыгы ачыкланды, улы каникул көннәрендә әти-әнисе янында булырга тиеш булса да, шулай ук шәһәрдә юк. Бәлки Мейталар гаилә белән кайдадыр ял итәргә киткәннәрдер дигән фаразлар бар. Бу өлкәдә эшләр алып барыла, соңгы араларда самолётта очкан, судноларда йөзгән, поездларда киткән пассажирларның исемлекләре тикшерелә. Башка төр оператив эшләр алып барыла...»

***

Паспортлар өстәле сводкасыннан: «Сафин Шәфкать исемле 79 кеше Татарстанда исәптә тора. Әтисенен исеме билгеле булмаганлыктан бар кандидатлар да теркәлде. Шулар арасыннан: 1 яшьтән алып 20 яшькә кадәрлекләр — 38; 60 яшьтән һәм аннан олыраклар — 14; калганнары — 27.

Тикшерүче Сәетбатталов В.К. өстәмәсе: 27 кандидатны ныклап тикшергәннән соң, күпләрен бу исемлектән төшереп калдырырга кирәк дип таптык. Хәзерге көндә кайсылары хәрби хезмәттә, өчесе диңгездә, урын өстендә ятканнары бар, гомер авылларыннан чыкмый яшәгәннәр бар, башка төрле сәбәпләр эзләү кысаларын тарайтырга тулы мөмкинлек бирә. Тикшерү өчен җинаять эшенә беркетелгән исемлек белән танышырга мөмкин. Шик астына алырлык дүрт фамилия кала:

1. Сафин Шәфкать Маратович (1967), хәрби, хөкем ителгән.
2. Сафин Шәфкать Сафич (1992), музыкант, Казанда яши.
3. Сафин Шәфкать Муллагалиевич (1980), фермер, Биектау районы.
4. Сафин Шәфкать Гайнанович (1977), шофёр, Мәскәүгә йөреп эшли, автобус йөртә.

Санап үтелгән гражданнарның өчесе белән очрашу үткәрелде, тәфсилләп сорау алынды, барысының алиби бар, берсе дә шик уятмый. Бары Сафин Шәфкать Маратовичның гына кайда икәнлеге ачыкланмады. Әлеге вакытка җыелган фактлар буенча аның турында түбәндәгеләрне әйтергә була: Сафин Ш.М. Әлки районының Карасу авылында туган, шул мәктәптә урта белем алган. 1985 елда военкомат юлламасы буенча Рязань десантниклар училищесына укырга кергән, аны уңышлы тәмамлаган. Оренбург өлкәсе Тоцк каласына хезмәткә җибәрелгән. Әфганда хәрби бәрелешләрдә катнашкан, «Кызыл Байрак» ордены белән бүләкләнгән, өлкән лейтенант дәрәҗәсенә күтәрелгән. Чечняда булган сугышларда катнашкан, ниндидер сәбәпләр аркасында хәрби трибунал тарафыннан хөкем ителгән, төрмәдә утырган. Төрмәдән өч ай элек азат ителгән. Хәзерге көндә кайда икәнлеге билгесез. Туганнарына кайтмаган, туган авылында күренмәгән, урындагы полициягә исәпкә басмаган. Санап үтелгән фактлар билгесез хатын кылган җинаятьләре өчен нәкъ менә аны гаепләп сөйлидер дип фаразларга мөмкин...»

***

Кешенең холкына кара да киләчәген юра, дигәннәре дөрестер ахрысы. Бәләкәйдән үк мине «пәри» дип йөрттеләр. Шундый да холыксыз, пырдымсыз, мин-минлекле, кызу идем үз-үземне белә башлаганнан бирле. Гел беренче булырга омтылдым, гел үз хакымны хакладым. Малайлар җыелышып сугыш уены уйный икән, мин, һичшиксез, кызыллар командиры булырга әрепләштем. Йөгереп ярышсак, телләремне чыгарып, җан-фәрманга чаптым — мин беренче килергә тиеш! Мәктәптә укыган елларда физкультура дәресләрендә гарык була иде миннән укытучы, тотып тыя алмый иде, бахыр. Нәрсә уйнасак та, бар көчем белән бирелеп, алга-артка карамый чаба идем мин, тирә-яктагыларны изеп-сытып. Ялгыш кына берәр кушылган күнегүне эшли алмый калсам, гарьлегемнән кара яна идем, укытучының җилеген суырып кат-кат кабатлый идем шул күнегүне, өйгә кайткач, өйдәгеләрне аякка бастырып, елый-елый үземнекен сүз итә идем. Әнә шундый бер ташбашлык хәтердә калган әле. Изге күнелле укытучыбыз Самат абый кулларга таянып, башны терәп, аякларны өскә чөеп торырга өйрәткән иде. Әлбәттә, күпләрнең килеп чыкмады бу күнегү. Аякларын ташладылар да түшәмгә төбәп, гөберт итеп аркаларына аудылар. Мин дә алар арасында идем. Ә чепек

кенә гәүдәле Әдһәм, миннән бар яклап җинелеп килгән малай, бу юлы җинел генә күнегүне эшли алды. Без унга тикле санаганчы, кәкре аякларын каештырып аумый торды әле. Шул минутта минем өчен дөнья бетте. Бер генә теләк белән яндым мин: ничек тә бу тынкыш танау кәләмәйне (анын кушаматы шундый иде, ул сүз ни аңлаткандыр — анысын әлегә кадәр белмим) куып җитәргә! Җитү генә түгел, уздырырга моны, кызлар алдында көлкегә калдырырга, үземнең шәплегемне исбатларга! Ни гаҗәп, әле барып үзләренә сүз кушканым булмаса да, кызларның мыскыллап ирен чите белән генә елмайганнары яисә сокланулы карашлары миңа тәэсир итә башлаган иде инде. Кич җитүгә, бүлмә идәненә мендәрләребез таратып ташланды, мин, булачак гимнаст, трусик-майкадан гына үҗәтләнеп башта торырга матавыклана башладым. Әти мәрхүм әнигә: «Җитәр инде, Мәстүрә, туктат шул җулигынны. Йокларга вакыт бит, иртәгә таң тишегеннән эшкә барырга, — дип зарлана башлагач кына, әни җенләнеп килеп мендәрләрне җыеп алды, ялтыраган очаларыма кулы белән чәпәп тә өлгерде. Безнең әти әнә шундый йомшак фигыльле адәм иде, әнидән узып бер адым атламады, урыны җәннәттә булсын. Мин кемгә охшап таштояк булганмындыр инде. Ә башта торырга тәки өйрәндем мин, остасына әйләндем, ике кулга таянып хәзер дә әллә күпме җир үтә алам. Бик тә кызмач булдым, хәзер килеп уйлыйм да ничек муенымны сындырмаганмын балачак елларында. Үзегез беләсез: малайлар сүз көрәштерергә ярата, батырлыкта, түземлектә көч сынаша. Кем буаның иң биек җиреннән сикерә ала? Әлбәттә, мин әйткәннәрен көтми, шапылдап елгага сикерәм, зуррак малайлар күреп, чак сөйрәп чыгарып калалар көчле агымнан. Кем көтү үгезенең каршына чыгып ирештерә дә койма артына качып котыла? Ул юлы да җинел котылдым, үгезнең колач киңлек мөгезләре зәңгәр ыштанны гына эләктереп алып калды, гәүдәм койманың икенче ягында котырып үскән кычытканнарга егылып кына котыла. Мин күргәннәрне чутлый башласаң, очына чыга алмассың. Малайлар күп батырлыкларга юри котырталар иде. Берсе тагын искә килә. Абыең булгач, барыбер рәхәт, өстенлекләрең күп тиңдәшләрең арасында. Мәсәлән, абыйлар мине дусларымнан алдарак тәмәке көйрәтергә өйрәттеләр. Үзләре качып-посып тартып маташа, мин барыбер эзләп табам бит инде аларны бу гөнаһлы суәттә. Әләкләшеп йөрмәсен өчен, үземә дә калдырып бирәләр. Чәчәп, тончыгып, мин аларга ияреп, егетләр һөнәренә өйрәнәм, тиңдәшләрем арасында мактанам. Әнә шулай рәхәт чигеп тотәтеп утырганда, бәхәс куба: кем кулына тәмәке төпчеге баса ала? Баса калса, кем озаграк чыдый? Озак чыдаганны иң түземле дип йөртәчәкбез. Сез чамалыйсыздыр инде кемнең иң түземле булганын. Минем сул кулдан озак вакытлар пешкән яра эзе китмәде. Күрше-тирә малайлары алдында гына түгел, клубка кинога барганда, авыл масштабында минем беренчелекне исбатларга алына торганнар иде дусларым. Клуб артына чыгып, ышык урында югары очтан, түбән очтан, урталыктан минем ише шәпле дүрт-биш малай җыела да тәмәке кабызып, кулларына баса. Ышанычлы судьялар төрле яктан билгеләнгән, еш-еш тәмәке суыргалап, дулкынланып карап торучыларның чуты-саны юк. Минем ул чакларда ниндирәк хисләр кичергәнемне беләсегез килсә, үзегез кабатлап карагыз. Әмма ләкин беренчелекне бирми идем мин, кунакка килгән-фәлән эре-эре яшүсмерләр дә, җиңелгәннәрен таныл, миннән алдарак кулларын селкергә тотыналар иде. Селкүен анысын мин дә селки идем, тик иң соңгы булып. Ни өчен дигәндә, селкеп торганда, артык ук әрнемәгәндәй тоела чи яра. Соңыннан безнең як малайлары үзләре нидер кылгандай кәпрәеп йөриләр, башкаларның борынына чиртеп мактаналар. Миңа да файдасы тия: бөтенләй таныш булмаган малайлар килеп, кул биреп күрешеп китәләр, яннарыннан урын бирәләр, гомумән, хөрмәт итәләр. Малай чакта үз сүзеңне сүз итүнең иң ышанычлы чарасы — йодрык, моны күпләр белә. Каршыңда берәрсе нәрсәгәдер ризалашмый ә-мә килеп торса, шалт бернe

монын янак төбенә, хәзер синең җырыңны җырлый башлый ул. Ә инде сыеграк булса, шар елап өенә йөгерә. Барыбер әйбәт, каршыда тормый ичмасам кояшны каплап. Бала чакта ук көчленеке — замана. Мин бу тәгъбирне иртә аңладым, гомерем буена шуңа яраклаштым. Бернинди килешүләргә килмичә, кагыйдәләргә буйсынмый, алга-артка карамый, үлгәнче сугышырга әзер булганыма күрә «пәри» дигән кушамат тактылар да инде. Күземә ак-кара күренми иде минем кем беләндер эләгешеп китсәм, тукта, бу миннән он-талкан ясый бит дип куркып кала белми идем. Кул астына нәрсә туры килә — агачмы, ташмы, ала идем дә ыргыла идем дошманыма. Бик тиз үз тиңнәремне тез чүктердем мин. Шуннан абый белән канга тузып сугыша башладым. Ул минем белән бәхәскә кермәс булды. Аның яшьтәшләре мине урыныма утыртып куярга тырышып карадылар. Әлбәттә, алар миннән күпкә көчлерәк иде, әмма миндә бетмәс-төкәнмәс үҗәтлек булды, кызып киткәч куркуның нәрсә икәнен белмәдем. Читтән караганда кызык та тоелгандыр мондый көч сынашулар. Тегеләрнең берәрсе мине сугып екса, мин сикереп торып тагын киләм, теге тагын эләктерә, мин акырып елап, танавымнан гөрләп аккан канны бит-башыма таратып, тагын алга омтылам. Ниһаять, тегенең түземлеге төкәнеп йөгерә башлый. Мин куып җитсәм, тагын борылып эләктерә дә чабуын белә. Капка төбенә кадәр озатып куям мин андыйларны. Бикле капкага типкәләп әллә күпме торам әле, дөньядагы иң әшәке сүзләр белән дошманымны сүгәм, чыгарга чакырам. Икенче очрашканда, бер сүз әйтмәстән тагын арыслан булып мона ташланам, тагын пыр тузып якалашабыз.

Бииюче бии-бии остара, ди, унынчыны тәмамлаганда, мин хәттин үк сугышырга өйрәнеп беткән идем, авыл урамнарында күкрәк киереп ялгызым йөри идем. Ә авылда ялгызың төн уртасында йөрүләре — шактый хәвефле гамәл. Кызмача өч-дүрт егет, берләшеп, читән таяклары белән коралланып, шундый итеп әлхәм сүрәсен өйрәтергә мөмкиннәр, гомер буе тернәкләнә алмый өй тирәсендә генә гомер кичерерсең. Район ярышларында чаңгыда, йөгерүдә гел алдынгы урыннарны яулый идем. Һәрвакыт та беренчелек эләкмәгәндер, әмма өчтән дә түбән булмадым дип ышанычлы әйтә алам. Шуңа да унынчы классны тәмамлар алдыннан, военкоматка хәрби уку йортына юллама сорап баргач каршы килмәделәр. Уку ягын йомшаграк икән дә, ну физик әзерлек югары кимәлдә синең, шансларың бар, дип өметләндереп озаттылар. Безнең эти-әниләр Гагариннар чорында үсеп, бар космонавтларның фамилияләрен яттан белеп, җиһан турында хыялланып яшәсәләр, минем тиңдәшләрем Брюс Лины илаһилаштырып, Шаолинь монахлары тормышына кызыгып, супермен булырга хыялланып үстеләр. Спорт белән шөгыльләнү егетлек булып саналды, һәр дистрофикның ишегалдында турник булды, шунда ук гер исәбенә кергән ике-өч тимер кисәге аунады. Мәктәптә озын тәнәфесләрдә без тәрәзә каршындагы турникка ашыга идек. Кем «кояш» әйләнеп күрсәтә, кем «подъём переворотом»ны ничә тапкыр ясый? Кыш көннәре спортзалда тыгылышып яттык. Читтә укыган авылдаш егетебез бокс түгәрәге дә ачып каңгырды әле. Үзе әллә бер-ике ай шөгыльләнгән, әллә башкаларны карап торган, мәгәр кызу тотынды өйрәтергә. Кесә тутырып вак ташлар китерергә кушты. Һәрберебезне берәмләп стена буена тезеп, әлеге вак ташлар белән бәргәләргә алынды. Имеш, чын боксёрның сугуының тизлеге шул ташлар очуына тиң була икән. Качып котылырсың өч-дүрт метр ераклыктан кисәк ыргытылган таштан. Без дәресләрдә маңгайлар күптереп, күз төпләре күгәртеп утыра башладык. Кызларыбызга күңелле булды, борылып карап хихылдап рәхәтләнделәр. Бераздан авыр бокс перчаткалары да табылды. Безнең ул иләмсез нәрсәләрне киеп басуыбыз бушка гына була иде. Киң җилкәле, озын буйлы тренерыбыз, каршы чыгып, «левый боковой... хук, правый прямой», дип сугуларының исемнәрен әйтеп, безнең барыбызны сузып сала иде идәнгә. Озаграк йөрсәк, әллә ул сүзләрне истә дә калдыра башлар

идек, сугарга да талпыныр идек, әмма ни сәбәпледер өйрәнүләр кисәк тукталды, остазыбыз китеп барды. Шунысын әстәп әйтү кирәктер, укытучыбызның ташлар турында сөйләгән сүзләре ялган булмаган, мина осталар арасында шундый тиз реакцияле кешеләрне очратырга туры килде, алар өчен бер секунд та ялыктыргыч озак вакыт берәмлеге булып тоела.

Хәрби уку йортларына комиссия үтүләр яз айларында башлана иде. Мин врачлар комиссиясен уңышлы үтеп, экзаменнардан соң документларымны Рязань десант училищесына тапшырып кайттым. Бары десантниклар гына телгә алып сөйләрлек эшләр майтаралар, алар арасына эләгү зур бәхет булып тоела иде безгә. Теория ягы йомшак булды анысы, чак-чак ерып чыга алдым сорауларын, өметләр киселергә тиң мизгелләр дә булып алды, шулай да мине укырга кабул иттеләр. Ул көннәрдә миннән дә бәхетлерәк кеше юк иде дөньяда! Әмма кеше киләчәгеннән гафил була. Әгәр сайлаган сукмагым кайларга китереп чыгарасын белгән булсам, мин аннан ваз кичкән булыр идем. Ләкин болары бүгенге көннен уйлары. Ул чактагы гаярь егет әллә һаман күзен дә йоммыйча, әйдә шулай булсын, мин риза, дип җавап бирер иде, кем белә...

***

Инга Мейта хакында оператив юл белән җыелган өстәмә мәгълүматлар: «Инга Мейта Рига шәһәрендә дәүләт хезмәткәрләре гаиләсендә туган. Гаиләдә бердәнбер бала. Әтисе Владис Озолиньш — озак еллар вагоннар депосында бухгалтер булып эшләгән, әнисе Лайма Озолиньш — Фәнни институтның лаборанткасы вазифасын үтәгән. Инга Мейта мәктәптә яхшы укучылар исемлегендә булган. Мәктәп елларында ук биатлон белән ныклап шөгыльләнгән, призлы урыннар яулаган. Мәктәптән соң физкультура институтына укырга кергән, бер елдан соң читтән торып укуга күчкән. Илнең җыелма командасына кертелгән. Күп вакытлары ябык тренировкаларда, ярышларда үткән. 1993 елда Европа чемпионатында икенче урынны яулаган. Соңыннан да әйдәүче спортсменнарның берсе саналган. Берара тренерлык хезмәте белән шөгыльләнгән, өметле укучылар тәрбияләгән. 2004 елда министрлыкка эшкә чакырылган, бүлек җитәкләгән, 2008 елдан — министр урынбасары. Әти-әнисе иртә вафат булган, турыдан-туры туганнары юк. Кияүдә, 2003 елда Америка эмиграциясеннән кайткан Андрис Мейта белән никахлаша. Бер уллары бар — Айвар. Уллары Айвар бүгенге көндә Англиядә Кембриджда укый, җәй көннәрен галәттә туган илендә үткәрә. Берничә тапкыр җинел наркотиклар белән шаяруы теркәлгән. Инга Мейтаның ире Андрис актив политиклардан санала, Европа илләренә йөз тота, Советлар системасының, бүгенге Рәсәйнең дә кан дошманы булып тора. Киләчәктә президент сайлауларына үз кандидатурасын куярга исәпли...»

Казан шәһәренең психик авыруларны дәвалау клиникасында үткәрелгән эксперимент нәтиҗәләре:

«Катнаштылар: тикшерүче Сәетбатталов В.К., психиатр Колыванов С.М., тәрҗемәче Сабитова Р.К., Рига шәһәреннән килгән Эчке эшләр бүлеге хезмәткәре Янис Тынт. Пациент Инга Мейта белән очрашу нәтиҗәләре хакында протокол алып барылды, ул җинаять эше папкасына теркәлгән. Очрашуның төп максаты — чит ил кешесе белән авыруның контакты нинди нәтиҗәләргә китерүен ачыклау, чынлап та билгесез ханым Латвия дәүләте гражданкасы Инга Мейта бер үк шәхесме икәнен билгеләү. Башта Инга Мейта кергән кешеләргә битараф тоелса да, тора-бара Янис Тынтка текәлеп карый башлады, соңыннан аермачык итеп «Мин сезне беләм бит, кайда очрашканыбыз булды икән ?» — дип ана инглиз телендә мөрәҗәгать итте. Бәхеткә каршы, Янис Тынт инглиз телендә җинел аралаша булып чыкты. Ул үзенең Ригадан икәнен, Инга ханым белән шул шәһәрдә берничә тапкыр очрашканнарын хәбәр итте. Шул урында латыш теленә күчеп, сөйләшү латыш

телендә барды. Я.Тынт уртак танышларын искә алды, бергәләшеп истәлекле вакыйгаларны хәтергә төшерделәр. Боларның барысы тәрҗемәче тарафыннан безгә җиткерелеп торды. Санап үтелгән фактлар чынлап та пациентның латыш милләтеннән булганлыгын, чынлап та билгеле шәхес Инга Мейта икәнен исбатлады. Сөйләшү барышында И.Мейтаның халәте күзгә күренеп яхшырды, сөйләме эзмә-эзлекле булды, кыланышларында тайпылу күзәтелмәде. Янис сүз арасында Мейтадан Рәсәйгә ничек килеп эләккәнлеге турында кызыксынды. Шул вакытта авыру белән истерия башланды. Ул тагын ниндидер үтерү, кан коелу турында кызып-кызып сөйләргә тотынды, тагын Сафин дигән кешене искә алды, кат-кат ире белән улының исемнәрен кабатлап, сез юк инде кадерлекәйләрем дип такмаклап, илереп еларга тотынды. Сестра килеп тынычландыргыч укол кадады, Колыванов очрашуны кичекмәстән туктатырга боерды...»

Латвия дәүләте эчке эшләр бүлегеннән тикшерүче Сәетбатталовка телефонограмма: «Ике сәгать элек Рига шәһәреннән ун чакрым читтәрәк, Даугава елгасы буендагы ташландык промзонада политик Андрис Мейтаның һәм аның улы Айварның үле гәүдәләре табылды. Үтерүче аларны, бетон баганаларга янәшә бәйләп куеп, спорт винтовкасыннан аткан. Пулялар икесенен дә нәкъ маңгай уртасына эләккән, тәннәрендә башка ату эзләре юк. Бу факт үтерүченең югары профессионал булуы хакында сөйли. Ни сәбәпледер атар алдыннан ул үзенең корбаннарын ак япмалар белән каплаган булган. Һәр япмада кечкенә пуля тишекләре калган. Үтерүчегә карата җинаять эше кузгатылды, төрле версияләр буенча тикшерү эшләре алып барыла. Безнең хезмәткәр Янис Тынт хәбәр итүенчә, дәвалау йортында булган хатынның Латвия гражданкасы Инга Мейта булуы ачыкланган икән. Сүз арасында аның ниндидер Сафинны телгә алулары, безнең уебызча, игътибарга лаек. Бу шикле адәмнең коточкыч җинаятьтә ни дәрәҗәдә катнашы барлыгын ачыклавыгызны үтенәбез. Я.Тынтның командировкасы озайтыла, кирәк кадәр сезнең карамакка калдырыла. Ул урындагы вакыйгаларны яхшы белә, бәлки Инга Мейта белән өстәмә контактка керә алыр, гомумән, аның файдасы булыр дип исәплибез. Яңа фактларны кичекмәстән безгә хәбәр итеп торуыгызны сорыйбыз...»

***

Бүген Митяй килеп хәл белеп китте. Рәхәт булып калды тере кеше күргәч, ни әйтсәң дә, ялгызлык авыр. Тагын бер атнадан аның таныш уйгуры килергә тиеш икән, ул чакта инде, әгәр барысы да без уйлаганча килеп чыкса, хуш, Рәсәй! Алда торган аерылу искә килеп төшсә, күңелгә моңсулык сарыла. Нинди кеше булдым инде мин, бер җирдә ныгып гомер иткәнем булмады, эзләдем дә эзләдем нәрсәдер. Юк, алай дип үз-үземне генә гаепләп калдырсам, хаклыкка килеп бетмәс. Хәрби кеше приказга буйсына бит, кая куаладылар, шунда киттем. Бары Шәүлия белән араларны өзгәч, үзем теләп Ямалга сорадым. Кушкуллап риза булды югарыдагылар, җәһәннәмгә үзе теләп баручы табылганына алар чиксез шат иде. Их, Шәүлиякәй-әүлиякәй, синең аркада булды барысы да. Башта бит ул чынлап та мина әүлиягә тиң җан булып күренгән иде. Авылыбыздан башкасын күрмәгән, шунда бәбкә көткән, бозау куган, ахирәтләре белән әйлән-бәйлән әйләнгән, унынчы классны чак тәмамлаган оялчан кыз иде ул. Ә мин отпускага кайткан бер дигән лейтенант, күкрәк тулы алтынланган значоклар, форма, коеп куйган кебек көр тавыш. Беренче көн озатканда ук кысып кочаклап суырып үптем мин аны. Мәлҗерәп төште кызын, телен әйләндереп, сүзен әйтә алмады. Икенче көнне кабыргасы белән куйдым соравны: барасыңмы? Әйе, — диде ул, уттай янып. Отпуска бетәргә тулы өч көн бар иде әле. Өлгердек, язылышып та кайттык, никах та укыттык, тиңнәребезне җыеп утырышып та алдык, зөфаф киче дә булды. Мина кадәр егетләр кулы кагылып та

карамаган саф күңелле бала гына иде әле кәләшем. Эзләгәнемне таптым дип алып киттем моны Самарага. Бу вакытта Оренбург өлкәсеннән күчергәннәр иде мине, яхшы хезмәтемне искә алып. Хәрбиләр шәһәрчегендә шунда ук бүлмә бирделәр, яшәп киттек ирле-хатынлы булып. Ошый иде мина гаилә тормышы, шайтан алгыры. Шәүлиягә дә клубта ниндидер эш табылды. Тик бер китек ягы булды, мине еш командировкага тарткаладылар. Икешәр атна югалып торган чакларым булды. Кайткач ни калганнарны куып житәргә жан-фәрман тырыша торган идек алай. Әмма бер кайтуда замполит үзенә чакырта мине. Түрәләрнен эше шул: алар чакырта, фәрман бирә, без барабыз, карышусыз үтибез дип уйлап киттем мин. Яхшы кеше иде ул болай. Ул чакта замполит дигән сүзне алыштыралар иде, бу олы кешене һаман элеккечә сукаладык без барыбыз да. Яшел чүпрәк ябылган өстәле артына утыртты бу мине, үзе йөри дә йөри. Хезмәт турында, иптәшләр турында сораша, яшәү шартлары белән кызыксына, ашау-эчү ничек, ди, урата бу, урата. Мин калкынып нәрсәдер әйтергә унайсызланам, монын төп мәсьәләгә житкәнен көтәм. Ин мөһиме: тиргәргә жыенмый шикелле, ул-бу булса, керүгә башлар иде. Кәләшен белән араларыгыз ничек, бигрәк яшь күренә ди. Мәйтәм, үзебезнең авыл кызы ул, дөнья күрмәгән, яши-яши өйрәнер, дим көр тавыш белән. Ә ул нәмәрсәкәй, күптән өйрәнгән, имеш, клубның ышык почмагында түгәрәк ачкан, теләге булганнар белән парлашып өйрәнәләр икән бер шөгыльгә мин командировкаларда йөргән чакта! Бу хакта замполит, әлбәттә, мина тупас формада анлатмады, төрлечә йомшартты. «Ин мөһиме, иптәш Сафин, — диде ул, — шуны анла: бу болганчык дөньяда төрле хәлләр килеп чыга. Дөрес анлап, кеше булып кала белергә кирәк. Әлеге сүзләрне мин сина сөйләми калдыра ала идем. Ләкин башка кемнендер авызыннан кырын мәгънәләр салынган хәбәрне ишеткәнче, башлап миннән, үзенен өлкән иптәшеннән белсен дигән карарга килдем. Тормыш дигәннәре кырыкка төрләнә. Үзенә генә әйтәм, минем дә гаилә тормышым ал да гөл түгел, хатынымның холкы тәмам бозылган, чиргә тин, һәр бирмеш көн анлашулар, каргашулар туып кына тора. Нишлисен, түзәм, гомер юлы үткән яртым, бәлки ипкә килеп китәр дип өметләнәм. Бу кызый белән тыныч кына араларны өз син, табарсын әле үз тиненне. Син бит әле яшь, тормышын чак башлана гына. Эх, кайда минем ул чаклар, кесә тулы борчаклар, эх, эх.. Ярый, бар, анлагансыңдыр дип уйлыйм... — Кузгала башлагач тагын туктатты. — Мотри, мөгез-фәлән чыгара күрмә. Ышан карт бүрегә: барысы да үтә, онытыла. Вакытында аерылышып калуыгыз да хәерлерәктер. Ятим калыр балагыз юк. Тагын кабатлыйм — чыгырдан чыкма, иртәгә үзем өенә барып тикшерәм, әйткән иде диярсен...»

Берни җавап кайтармастан, үрә катып чыгып киттем. Эчтә дөрләп утлар яна. Мин аны бит, мин аны учымда гына йөрттем, күзләренә генә карап тордым, ә ул сөйрәлчек минем өйдән чыкканны көтеп кенә торган, чалбар кигәннәрнен барысын чүтләп чыккан. Ул нинди туймаган уйнашчы язган икән мина? Жүләрлек белән монда тую-туймаунын кысылышы шулкадәр генә икәнлеген мин анлап житә алмый идем әле. Хатын-кыз бит хыялый кануннарны үзе уйлап чыгарып, үзе шуларга буйсынып яши, мантыйкның эзе дә юк анда, физик якынлык та кайчакта ин сонгы урында тора. Кем анласын аларны... Ә ул көнне баскан эзләремнән ут чыга иде минем. Бу вакытта инде өйгә кайткандыр, бүген пәрәмәч белән сыйлыйм үзенне дип икейөзлеләнгән иде сөйрәлчек, плитә янында мәш киләдер. Керәм дә, кызган май тулы табасын башына каплыйм хәшәрәтнен, аллә башка жирен көйдерергәме, теләге түгәрәкләнер. Толымыннан урап тотам да, чәче озын анын, куе, бөдрәләнеп торган карлыгач канатыдай кара чәчләр, гел чәчәк исе килеп тора үзеннән. Нәмәрсәгә мина хәзер чәчәк, төкерергә, тешләрен кырам мин анын, теге, ап-ак мәрмәр төсле тезелешеп торган тигез тешләрен.

Шулай үз-үземне кызыштырып, йөгерә-атлый өйгә ашыктым мин. Ярты юлда

кинәт башыма килеп алды, мөгаен, Ходай эшкәрткәндер. Туктап калдым хәтта, калтыранган кулларым белән тәмәке алып каптым. Нәрсә эшләргә җыенам соң әле мин болай?! Шул кош баласы төсле генә хатыныма кайтып кул күтәрергәме? Ачу-ярсу белән бер суксам, жанын җәһәннәмгә олактырам бит мин аның. Аны гына түгел, өрлектәй ирләргә суга калсам, җан тәслим кылачаклар. Укыганда ничә еллар мине нәкъ шуңа өйрәттеләр, мөмкин кадәр остарак җан кыярга, ә мин ин яхшы укучылардан саналдым. Йодрык белән генә сөю яулап була ди мени?! Тыныч кына кайтып кердем мин. Дөрес, йөзем каралган булгандыр, андый йөрәк эшләре белән очрашырга туры килгәне юк иде әле миңа. Ишекне ачып кердем, күбәләктәй очып килеп назлы куллары белән муеныма асылынды юха, берни белми-сизми әле бу дип уйлаган буладыр. Кырык өченче размер десант итегемне салып тормый, түргә үттем. Түр дигән урында безнең ике урынлы караватыбыз тора иде. Бердәнбер затлы саналган өй җиһазыбыз, кайчан гына ике арада булган кайнар хисләребезнең телсез шаһиты. Шәүлия, гаҗәпләнеп, күк йөзедәй зәп-зәңгәр күзләрен шар ачып, минем яныма йөгереп килде, плитә өстендә нәрсәдер яна иде шикелле, анда таба борылып та карамады, идәнгә чүгәләп, итекләремне кочаклады.

— Мин барысын да беләм, — дидем мин кинәт карлыгып киткән тавыш белән. — Җыен, өенә кайтып китәрсен. Мин белештем, бер сәгатьтән поезд. Мин көтмәгән идем синнән, балта чаптың тамырыма...

Шуннан нәрсәләр башланды! Бернәрсә дә булмады дип барысын кире кага бу, мин сине генә яратам дип антлар итә, мин синнән башка яши алмыйм дип ялына, үксепме-үкси, галәмәт инде читтән карап торган кешегә. Бу чеңләүләре озакка китә башлагач, үзем әйберләрен чемоданга тутырырга керештем, күлмәк, лифчик мазарларын, мин бик аңлап бетермим аларның купшы челтәрләрен, кулга нәрсә эләгә, барысын салам. Машина сорап шалтыраттым, килеп җитте, бу һаман идәндә ауный, миңа тагылып сөйрәлеп йөри. Антлар эчә, ялган барысы, гафу ит дип ялына. Кем дә кем мине карарын үзгәртә торган кеше дип уйлый, ул нык ялгыша. Мин тегене сөйрәп алып, өстендә булган күлмәге белән машинага чыгарып утырттым, янына парлап чемоданнарын куйдым. Тизрәк-тизрәк котыласым килде шул зобаныйдан, күңелемдә бары чиркану хисе генә иде. Вокзалга кергәч, бертөрле юашланып калды ул. Билет алып, вагонга кертеп утырттым, булган барлык акчаларны кулына йомдым да миннән башка бәхетле бул, дип теләк теләп төшеп калдым. Ышанасызмы, ярты йөрәгемне үзе белән алып китте шул орчык зурлык кына кызыкай. Бу аерылышудан соң башка бервакытта да мин туган авылыма кайтмадым. Ә Шәүлия турында хәбәрләр килеп ишетелде. Кайткач та ул хасталаган икән. Врачларга йөртеп караганнар, билгеле генә чирен дә тапмаганнар, көннән-көн ябыгып, хәлсезләнеп, өч айдан соң якты дөнья белән хушлашкан. Үлем исереклеге кергәч, гел синең исемеңне кабатлады, гел сине чакырды, гел синеке генә булганлыгына антлар итте, диделәр. Кем белсен, кем аңласын аларны... Башкача мин өйләнмәдем. Яшерен-батырын түгел, булды хатын-кызлар минем тормышымда, карасы да, сарысы да дигәндәй. Бер ишеләренә жае чыккан саен барып йөргәләдем, кайсы белән бер-ике ай уртак кыек астында яшәдек. Әмма ләкин йөрәк белән берегеп китәрлек башка гүзәл затны очратмадым. Әллә сихерләгән булган Шәүлия мине, әллә каргышы төште, белмәссен. Илнен төрле кыйтгаларында хезмәт итәргә туры килде, аннан соң Әфганда озакка гына тукталдым, илгә кайткач — Чечня, иң соңгы тукталыш — төрмә булды, анысы шактый озакка сузылды. Бер малай да табып бирмәде ичмасам дип Шәүлиягә үпкәләп тә куям, соныннан тагын кире уйлыйм, мин жил куып йөргән елларда аны кем карап үстерер иде? Бәлки, чит-ят җирләрдә үземнең куышымны корырмын, берәр кытай йә

негр кызына өйләнеп, малайлар-кызлар үстерермен, бу каһәр төшкән Рәсәйдә үткән елларымны саташулы төш кебек кенә итеп искә алырмын, оныкларыма гыйбрәт итеп сөйләрмен...

***

Ригадан — Казанга: «Рәсәй һәм Латвиянең Чит илләр министрлыгы килешүе буенча Латвия гражданкасы Мейта Инга, дәвалауны дәвам итәр өчен, үз иленә кайтарылырга тиеш. Бу килешүне тормышка ашыру өчен, хәлегездән килгән кадәр ярдәм итүегезне үтенәбез...»

Тикшерүче Сәетбатталовка экспертиза нәтиҗәләре: Хәбәр ителгәнчә, Андрис Мейта һәм аның улы Айвар спортта кулланыла торган винтовкадан атып үтерелгәннәр. Винтовкада калган бармак эзләрен тикшергәннән соң, анда ике кешенең бармак эзе беленде. Латвиядә саклаңган банк чагыштырулары нәтиҗәсендә, эзләрнең бер ишесе нәкъ Инга Мейтаныкы булганы ачыкланды. Тәтедә сакланган эзләр шәхсән Мейта И. аткан икәнлеген раслый. Ә менә Рәсәй криминологиясе икенче эзләрнең Сафин Шәфкать Марат улыныкы икәнен хәбәр итте. Шулай булгач, бу ике шәхес бер-берсе белән таныш, җинаять кылуда икесе дә катнашканнар дигән фикер туа. Әмма кайсысы ни дәрәҗәдә икәнлегенә җавап юк, бу сорау ачык кала. Инга Мейтаның адекват түгеллеге эшне катлауландыра, бары югарыда телгә алынган Сафинны кулга алып кына дөреслекне ачыкларга мөмкин. Шуна күрә тиз арада Сафинның кайда икәнлеген ачыклап, сак астына алсагыз иде...»

***

Чечняга безне 26нчы декабрьда китерделәр. Ул көнне чехлар белән бәрелешләр башланган иде инде. Чеченнарны безнекеләр үзара «чехлар» дип йөртәләр, тиз табыла солдат арасында шундый атамалар: духлар, тушкалар ише сүзләр. Әмма дә ләкин хәлләрнең кискен үзгәрүе дә көтелде, низаглар тыныч юл белән дә хәл ителер төсле тоелды. Мин монда штрафбатка килгәндәй килдем. Әлеге дә баягы, дөреслек эзләүләрем, телне тыя алмавым, алдын-артын уйламый башлап йөрүләрем күпләргә комачаулый иде. Тиз арада Чечняга командировкага җибәрү турында сүз кузгалгач, ике дә уйламый минем кандидатурага туктадганнар. Котылабыз дип кулларын уганнардыр инде, шуларның кәефләнеп елмайган йөзләрен үк күргәндәй булам. Мин карышмадым, сәбәпләр эзләмәдем, файдасы да тимәс иде, әмма мина яна килгән көзге призывтагы, танау аслары да кипмәгән малайларны тагып җибәрергә карар чыгаргач, аяк терәп карышырга булашып карадым. Бар, исбатлап кара син аларга үзеңнең хаклыгыңны. Гомере буе штабист булган, бер-урындыктан икенче урындыкка күчеп, чалбар төбе шомарткан, вакытлыча гына комполка итеп тәгаенләнгән хохол Черненко үз кабинетына чакырып алды:

— Сафин, давай тыныч кына хәл итик бу мәсьәләне. Яна гына хәрби техниканы парашютлардан төшергән өйрәнүләрдә тәртәгә типкәнең онытылмаган әле. Ну и что, синең сүзләрең дөрес булып чыкты. Ну и что, ике десант бронетранспортёры он-талкан булды. Шуна да исеме учение аның. Өйрәнәбез югалтуларсыз сугышырга. Житәр, менә монда синең шәплекләрең, во! — дип җәлпәк, йомшак куллары белән кат-кат муенына чәпәп күрсәтте ул. — Әби белгәнне бабай да белгән. Без уйламаган дисеңме последствиеләрен? Барысы да нормально анда. Молодойлар әзрәк поход тормышына күнексеннәр, сухой паёк белән туенып карасыннар, вообще, бераз иректә искән җил сугылсын танауларына. Барырлар да кайтырлар. Син карт бүре, вакытында туры юлга сал аларны, тормыш белән таныштыр. Озакка түгел, Яна ел бәйрәмнәре исән-аман үтсә, җырлап кайтып

керерсез. Ул чакта сиңа өстәмә ял — әйткән идең диярсең! Всё путём, Грачёв мышей не ловит, ушлый мужик, күрә торып конфликтка кермәс, ну оппозиция тик ятмый анда, оператив хәбәрләргә караганда. Ну, давай, удачи, Сафин!.. — дип күп сөйләп, йомшак төшәп, катыга утыртып чыгарып җибәрде мине карт төлке. Аның сөйләгәннәре сизгерлегемне томалады, ышанып та куйдым. Әнә шулай, бәйрәм алдыннан, бер төркем салага белән Грозныйда идем мин. Ике ай эчендә әлифне таяктан аерырга да өйрәнмәгән малайларны нәкъ Минутка мәйданы каршына алып барып салдылар. Дәүләт бинасы алдында урнашкан ул мәйдан турында күпләр хәбәрдардыр. Илне таркатканчы исеме аның Октябрь мәйданы булган, диләр. Килделе-киттеле исемнәр тагарга рөхсәт итмәсләр иде ул чакларда, билгеле. «Минутка» дип соңыннан йөртә башлаганнар. Имеш, аның аша тимер юл үткән, состав мәйданда нәкъ бер минут туктап торган, диләр. Бу исем йөрәгемә канлы хәрефләр белән уелган, каберемә кадәр озатып барачак мине. Тарихта мәгълүм булганча, төп фаҗига утыз беренче декабрь төненә каршы башланды һәм берничә көн буена дәвам итте. Мина шәхсән бер тәүлек булырга туры килде бу дәһшәтле сугыш кырында. Шулай кыска гына вакыт эчендә булсам да, мондый канкоешның тиңе булмагандыр кешелек тарихында дип гуаһлык бирәм. Соңыннан кабат-кабат уйландым мин бу башка сыймастай хәрби операциянең барышы турында. Нәрсәләр уйлап бәйрәм алдыннан шундый фәрман бирә алды икән хәрби җитәкчебез Грачёв? Энәдән-җептән киенгәндер әле үзе, көязләнгәндер, бәйрәм алды бит, ни гаеп. Әллә бәйрәм хөрмәтенә бә-әк кыйммәтле коньяк, виски каплап куйган булгандыр, тәрәзә аша кышкы башкалага күз салгандыр. Күрше бүлмәдә гаиләдәге хатын-кызларның чыр-чу килеп көлмәк сайлаганнары ишетелеп торгандыр, нәзакәтле хушбуй исләре таралгандыр бар почмакка. Бу көнне Грачёвны кул астындагы исәпсез-сансыз хәрбиләре котлагандыр, төрле министрлар, дәүләт эшмәкәрләре сәлам юллагандыр. Мөгаен, бу көндә аның кәефе күтәренке, уенчак булгандыр, гел шаярасы-көләсе, нindидер җиңелчә мотив көйлисе килеп торгандыр. Шулай да йөзендә чагылмагандыр хисләре, гомере буе каеш буган кеше үзен авызлыкларга өйрәнгән булгандыр тәгаен, нindидер көйләр көйләү дә шундый рангтагы кешегә килешеп бетми. Харап зур бүлмәнең йомшак келәме буйлап унлы-суллы йөри торгач, башына килеп калдымы икән ул гениаль план? Әнә шул Чечнядагы каршылык күрсәтүчеләр тамакка тыгылган таш булдылар лабаса. Тукта әле, кызык итим үзләрен, бәйрәм ясыйм мин аларга, дип дәртләнеп киткәндер. Бик нык сакланган канал буенча урынбасарларына фәрман биргәндер: «Немедленно! Сәгать уникене сугар алдыннан доложить!» Хәрби машинаның тәгәрмәчләре шатыр-шотыр әйләнә башлагандыр, минем колакка майор Дудканың приказы булып ишетелгәнче дәвам иткәндер. Нинди татлы уйлар дингезендә тирбәлде икән маршалыбыз... Менә ана төн уртасында Президент сараеның яулап алынуы турында хәбәр итәләр, ул ныклы адымнар белән Рәсәй президенты каршына басып честь бирә дә ил хуҗасының колагына шатлыклы яңалыкны пышылдый. Әлбәттә, Хуҗа урыныннан торып кочаклап ала үзенең тугры, талантлы полководецын, күңеле йомшарып, күзләренә яшь килә. Эчкән кешенең күңеле бигрәк тә йомшак була бит аның. Мондый күренештән Грачёвның кан дошманнары галстукларын чәйни, нишләргә белми таптаналар. Ә шулаймы әле, белдегезме инде Грачёвның кем икәнлеген, ә?

Әле артында туктамый гайбәтен сата идегез, анекдотлар уйлап чыгара идегез, туры килгән саен хурлап сөйли идегез, инде кадерлегә әйләндеме? Күрсәтә әле ул сезгә кемнең кемлеген?.. Кырык төрле итеп күзаллый идем мин ул адәмнең кичергәннәрен, уртларымны чәйнәп, бәддога укый идем, төрмә койкасында аунаганда. Читтән караганда, Мәйданда тынлык хөкем сөрә иде, тирә-яктагы күпкатлы өйләрдә җан әсәре юктыр төсле тоела иде. Бәлки анда күпмедер

боевик каршылык күрсәтергә жыенадыр, әмма куәтле танкларыбызга каршы алар ни кыла алсын дигәнрәк фикер йөрттеләр безнен командирлар. Мина Майор Дудка үз десантникларым белән танклар артыннан калмаска боерды. Президент сараена житүгә, кичекмәстән шунда юнәлергә, сарайны кулга төшерергә, әсирләрне тылга озатырга дигән бурыч куелды.

Күнел төпкелем белән, еллар буе тупланган тәжрибәм белән сизә идем мин бу тынычлыкнын алдавыч кына булганын. Борынынны төртеп кенә кара, туган жирләре өчен актык тамчы канга кадәр көрәшергә әзер булган, көн өчен түгел, дин өчен дип кулларына корал алган чеченнар аяусыз алышачаклар безнен белән. Аларнын күп еллар буе кулларыннан корал төшкәне юк, бот буе баласына кадәр сугышчы, «Аллаһы әкбәр» дип һич икеләнми шәһит китәргә әзер тора. Ә мина ияреп килгән, яна гына парта арасыннан чыккан малайларнын гомер дары исен иснәп караганы юк, белгәннәре — компьютер артында утыру, сыра эчү дә тиндәш кызлары белән гыйшык-мыйшык уйнау. Ил дигән төшенчәнен мәгънәсе шулкадәр генә, бер-берен аркаларга өйрәтелмәгәннәр, тәртип дигән нәрсә юк. Мондагы яшьтәшләре күзләре ачылуга иман тәмен белгәннәр, гаилә өчен утка сикерәчәкләр, әйт кенә, ата сүзе хәтта хәзрәт сүзеннән югарырак, аксакалларынын колы булырга ант иткәннәр. Син аларны корал белән, үлем белән, танк-танкеткалар белән куркыта алмаячаксын. Баскан урыннарында шатланып үләчәкләр, үлгәндә, үзләре белән әнә теге минем һушсыз малайларнын дистәләп алып китәчәкләр. Минекләр беренче ату тавышыннан кайда ун, кайда сул икәнен анламый башлаячак, котлары очып, әниләрен чакырып, берәм-берәм дөнья белән хушлашачаклар.

Ярый мин яшисен яшәгән, күрәсен күргән дигәндәй, артык ябышып тормыйм фанилыкка, бу балалар жәл. Гөрләп эшли башлаган танк двигательләрен уздырырга теләп мин боларны Дудкага анлатырга тырышып карадым.

— Иптәш майор, башта разведка боем оештырып карыйк,ниндирәк булыр икән жаваплары. Танклар бер-ике урасын, сарай тәрәзәләренә берничә снаряд очырсын. Мәйдан таба кебек ялтырап ята бит, чебен урынына кырачаклар пехотаны, — дип үз кузаллавымны житкердем. Иреннәрен чалшайтып, бу мина:

— Сез, өлкән лейтенант, трус, куркак жан, үз шкурагыз өчен калтырыйсыз. Ничек йөрисез һаман армия сафында? — дип мыскыллап жавап бирде.

— Иптәш майор, мин берничә ел Әфган чүллекләрен күкрәгем белән сөрдем, хәрби наградаларым бар. Андый сүзегез булса, алдагы танкнын бронясында барырга ризамын, тик бу балаларны күрә торып утка тыкма, — дип ялындым.

— Разговорчики, — дип акырды бу, кызарынып-бүртенеп, — сез, өлкән лейтенант, белмисезмени — приказы не обсуждаются, приказы выполняются! Барыгыз үз взводыгыз кырына, сигнал ракетасы очу белән, танклар артынан хәрәкәт итегез. Элемтә аша үз адымнарыгыз хакында хәбәр итеп торыгыз. Карагыз аны, әгәр паникага биреләсез икән, под трибунал жибәрәм мин сезне, өлкән лейтенант!

Калганы саташулы төшкә охшаш булды. Боевиклар жинел генә танкларны алга уздырды, урамнарга керергә мөмкинлек бирделәр. Артта калган десантниклар бар мәйданга жәелде. Шуннан башланды гарасат. Кайдан килгәндер боевикларга шулкадәр корал. Ин-ин куәтле йөзләрчә төр ату кораллары безгә төбәп ут ачты. Чирек сәгать үтүгә, мәйдан үлекләр белән тулды, һөжүм дигән нәрсә карга капланды. Танкларны да күтеп кенә торганнар икән, берсе генә дә үтә алмады. Кара-каршы өйләрдән аларга таба ракеталар очты, гранотомётлар шартлады, эре калибрлы пулемётлар тырылдады. Тере факел булып танкистлар сикереште, аларын да кыеп кына тордылар. Кайда карама ут чүмәләсе булып танклар яна иде, мәйдан яралыларнын ынгырашулары белән тулды. Минем күз алдымда взвод

егетләре ауды, кайсысы кирегә шуышырга булашып карады. Биналарда утырган снайперлар, һәр кузгалган нәрсәгә пуля очырып, кузгалырга да ирек бирмәделәр. Минем ауган урыным үзенә күрә унайлы иде: ни өчендер җайлаштырылган бетон күтәрмә сызгырып очкан пуляларга үтеп керергә ирек бирми. Шул бетонга капланып төшкән бер солдатның гәүдәсе урынымны тагын да ышыграк итә иде. Якынча бер-ике сәгатьтән атулар тына төште. Кырыласы кырылган иде хәрби техниканың, күпчелек солдатлар якты дөнья белән хушлашкан иде. Ара-тирә ишетелгәләп алган ату тавышлары кемнәрнедер озата иде әле бакыйлыкка.

Ниндидер кинәшмә төслерәк нәрсә булып алгандыр ахрысы. Безнең якнысылар тагын бер омтылыш ясап карады. Анысы күпкә сыеграк иде, тиз тәмамланды. Мина шушында ятудан башка чара юк иде. Әле кызулары бетмәгән боевиклар майданны оптика аша сөзәләрдер, хәзер җанымны җәһәннәмгә олактырачаклар. Танга таба, гадәттә, төннең караңгылыгы куерып ала. Мин, шул вакытны туры китереп, зур саклык белән кирегә хәрәкәт итә башладым. Моңа кадәр тәнгә суык үтеп кергән булса, хәзер инде шабыр тиргә төшеп, ин читтәге өйнең почмагына кадәр чыгып җитә алдым. Тешләремне шыгырдатып, килгән юлыма борылып карадым, тәмугның үзе иде минем күз алдымда: чабылган үлән төсле түшәлеп калган иптәшләремнең гәүдәләре, һаман янудан туктамаган президент сарае, каралып утырган танклар шәүләсе, суынып та өлгермәгән гәүдәләрне чинаша-чинаша ерткалаган берәзәк этләр... Тир белән аралашып, сөмердәп күз яшьләрем акты. Дошманына да мондый хәлдә калырга язмасын. Күпмедер шулай онытылып торгач, штабны эзләп киттем. Кайдадыр барып баш төртергә тиештер идем ич инде мин. Үзебезнекеләр очрый башлады, бер-ике урында туктаттылар да әле, ниһаять, кирәкле бинаны эзләп таптым. Ишеккә тотынганда, ике-өч офицер каршыга килеп чыкты. Араларында минем турыдан-туры хуҗам Дудка да бар иде. Мине күреп алуга кычкырыплар җибәрде бу:

— Оп-ля, явился ! Явился — не запылился! Кайда качып йөрисең син, өлкән лейтенант? Кайда синең десантникларың? Нигә син үзең генә монда?! Нигә куелган бурычны үтәмәдең? Измена! Башыңны төрмәдә черетәм мин синең!..

Ниләрдер кычкырып торган менә шул симез чучканың бер сүзе минем егетләремнең үлүенә сәбәп булуы канымны кайнатып чыгарды, күзалларым караңгыланып китте. Песи житезлеге белән аны маскахалатыннан тотып түбәнгә тартып төшердем дә бәреп ектым.

— Менә сине эзләп килдем мин монда, паскуда! Син анда ятарга тиеш идең, минем солдатларым түгел. Хәзер белерсең, — дип җан ачуым белән биргәләргә тотындым хәшәрәтне. Нәрсә, нәрсә, моның ишеләрне акылга ничек утыртырга кирәген беләм мин, баштан үткән. Туп шикелле очып кына йөрде ул ишек алды буйлап. Яндагы хәрбиләр мине тыярга теләп килеп ябешкәннәр иде, аларын да селтәп очырдым. Бер чыбыктан куылганнардыр, аларына да өлеш кирәктер әле. Кызган чакта мин ак-караны аермыйм, үчем басылганчы иләдем теге ит кисмәген. Ул арада кайдандыр кешеләр җыела башлады, чак аралап алдылар үземне. Билгеле инде, шул минутта ук илтеп яптылар. Дудканы да носилкага салып «скорый»га төяделәр, тере булгандырмы, юкмы. Мине озак тотмый Зур Җиргә озаттылар, элек үзем хезмәт иткән җиргә. Хәрби прокурор статья артыннан статья укыды: солдатларны калдырып, сугыш кырын ташлап чыккан дип гаепләделәр, үзеннән өлкәнрәк дәрәҗәдәге офицерга авыр тән җәрәхәте салган, үлем белән янаган, диделәр (бәхетенә, Дудка исән калган икән, шулай да тәмам гарипләнгәндер дип уйлыйм). Тагын нәрсәдер тактылар әле, аларның кулына бер барып эләксән, эч-бавырыңны актарып чыгаралар. Зурдан куптарып суд булды. Әлеге сугышта үзебезнең яктан булган гаепләрне дә табарга кирәк иде. Минем кандидатура таманга гына туры килде. Үзәк гәзит-журналларда яктыртып, югары трибуналардан

минем вәхшилегем турында тәфсилләп сөйләп, телевизорда диспутлар үткәреп, «Безнең хәрбиләр нинди булырга тиеш», — дигән кебегрәк темаларга тәмен белеп хөкем иттеләр дә төгәл ун елга таш капчыкка ябып куйдылар. Соликамскины узгач та, Кама елгасын чыккач, үзенчәлекле даирәләргә бик тә таныш булган Березники дигән шәһәр бар. Мин әнә шул шәһәрдә «от звонка до звонка», ун ел буена, тимер рәшәткә аша күк йөзенә карап утырдым...

***

Тикшерүче Сәетбатталовка — Ригадан: «Безнең шәһәр тирәлегендә кылынган жинаять эшендә катнашы булган Латвия гражданкасы Инга Мейта соңгы араларда үзәк дәвалау хастаханәсендә билгеле медицина белгечләре тарафыннан дәваланды. Әмма интенсив чаралар унай нәтижә бирмәде, авырунын хәле көннән-көн начарлана барды. Врачлар фикере буенча, хәзерге көндә Инга Мейта тикшерү эшләрендә катнаша алмый, алдагы көннәрдә дә аның сәламәтлегендә үзгәрешләр көтелми. Шуна күрә үзегезнең тикшерү эшләрендә бу фактны игътибарга алсагыз иде. Башка шаһитлар, гаепләнүчеләр ачыкланыр, тикшерү эше уңышлы тәмамланыр дигән өметтә калабыз. Ярдәм кирәк була калса, кичекмәстән мөрәжәгать итегез...»

Инга Мейтаның жинаять эшеннән: «Төп гаепләнүчеләрнең берсе саналган Сафин Ш.М. турында өстәмә мәгълүматлар юк диярлек. Самара хәрби трибуналы офицер Сафинны 1994 елда, Присягага хыянәт иткәне һәм үзенең командирына тән жәрәхәтләре салганы өчен, ун елга иркеннән мәхрүм иткән. Эшнең асылына төшенергә теләп, каза күргән Дудка фамилияле хәрбинең торган урыны ачыкланды. Дудка куелган сорауларга рәтле-башлы җавап бирә алмады, чөнки урын өстендә ята-ята балалар акылы кергән иде ул бичарага. Безнең куйган сораулардан бигрәк, төсле ялтыравык кәгазьләр аның игътибарын ныграк җәлеп итте. Сафинның кайдалыгын ачыклау өчен, полициянең төрле подразделениеләре эшкә тартылды. Туган-тумачалары, якыннары, аралашкан хатын-кызлары, хезмәттәшләре тикшерелде, әмма шик салырлык дәлилләр табылмады. Сафин Ш.М. суга төшкәндәй гаип булды. Тикшерү барышында башка төрле версияләр өстендә эш алып барылды, криминалистика хезмәткәрләре тикшерүдә актив катнашты, шаһитлар эзләү җентекле оештырылды. Югарыда саналып үткән эш төрләре бер унай нәтиҗә дә бирмәде. Житәкчеләр белән берлектә киңәш иткәннән соң, Инга Мейтаның жинаять эшен билгесез вакытка туктатып торырга дигән карар кабул ителде, җыелган оператив мәгълүматлар, тамгаланып, архивка озатылды...»

***

Төрмәдәге яшәү шартлары чыдап торырлык түгел иде дисәм, ялгыш булыр. Яши-яши мин төрлесен баштан үткәргән идем, фигылем буенча да артык нәзберек зат түгелмен: ни бирәләр — шуны ашыйм, нәрсә бар — шуны киям. Һәр гидайның якын дусты булган тәмәке житәрлек табыла иде, кышларын артык суык куырмады, җәйләрен таш дивар эсседән саклады, тагын ни кирәк адәм баласына? Дөрес, эч пошулар стенага сикерер хәлгә житкерә иде кайчакларда. Безне кайдадыр ереккә эшләргә-фәлән чыгарып йөртмәделәр, бары билгеле вакытта тар гына ишек алдына чыгып, саф һава сулап керә идек. Безнең бәхеттән кар яуса, йә булмаса яңгыр шыбырдаса, комсызланып шуларга каршы йөзебезне куя идек, ләззәтләнеп йота идек иректән яуган нигъмәтне. Ә тегеләй дүрт кешелек камерабызда барысы ташка басылган кебек. Бер үк йөзләр, бер үк сүзләр, озаграк бергә яшәсәң бит сөйләшергә сүз калмый, ә тере жанның беренче зарурлыгы — аралашу! Син икмәк бирмә кешегә, ә хәлен ничек дип сора, берәр тарих сөйләп күңелен күтәр. Бар гамәлләр алдан билгеле

булуы жанны яралый. Күзләренне ачасың шулай, хәзер ун як күршең кех-кех йөткеренгәләп икенче катыннан сикереп төшәчәк — нәкъ шулай була да. Хәзер ул өстәл өстендә утырган көл савытыннан зуррак төпчек чокып чыгарып авызына кабачак та тәмләп тәтен суырып, күрмәгән төшен уйлап чыгарып, бушлыкка сөйли башлаячак, аны барыбер тыңлаган кеше юк. Әмма бу гамәл ана нидидер рәхәтлек бирә... Минуты минутка туры килеп, ул шырпы сыза, һавага төтен өреп башлап китә:

— Бүген төштә үзебезнен полк ашханәсенә барып кергәнмен, имеш, дим... Повар Наташа ишектән ярты гәүдәсен чыгарган да мут елмаеп миңа ишарә ясый, кил монда янәсе. Ә Натаханың дәүләте теләсә кайсы ир-атны аяктан егарлык: буферлар — во!.. Задний мост — во! Шуннан...

Аның телгә салынуы башлануга, астагы урында яткан Корин одеял астыннан пеләш башын чыгара. Башы өши микәнни, томаланып йоклый ул, ничек тын ала торгандыр. Әнә шуннан башлана инде: кем башта барып клозетка утырыр, кем озаклап теш чистартыр, кайчан форточкада табаклар тезелер, бүген иртәнге ашка ни булыр — барысы-барысы алдан билгеле. Бу бертөрлелек миенне сыеклый, нервылар шартлап өзелер хәлгә житә. Көннең көне бит шулай, йа Ходай... Берәрсе китеп, яна кеше килсә генә бераз күңеллелек булып ала. Дөньядагы үзгәрешләр турында белеп каласың, яңалыклар ишетәсең, икенче берәүнең язмышын уртаклашасың. Китапханә дигәннәрендә ике-өч йөзләп китап бар иде. Мин еллар буена аларны, эчтәлегенә игътибар да итмәстән, әллә ничә кабатлар укып чыктым. «Красная звезда» гәзите аң-белемебезне күтәрде, өстәп «Физкультура и спорт» дигән журнал яздыралар иде. Бу журнал минем алдагы язмышымда бер төрле этәргеч роль уйнады.

Барысы да юктан гына башланды кебек. Сукырның теләге — ике күз дигәндәй, урый да кайта идем мин әңгәмәләремдә йөрәгемә канлы яра салган Яңа ел төненә. Бу хакта бар камерадашларым белән энәсеннән жебенә тиклем тикшерә идек. Һәр мизгелне янадан үтә идем үз хәтеремдә. Көчсезлегемнән уртларымны чәйни идем, артык иртә гомер белән хушлашкан яшь иптәшләрем өчен ничек тә үч алу тойгысы йокыларымны калдыра иде минем. Сирәкләп булса да кайберләребез ирекка чыкты, алар урынына озакка сузмый янасын китереп урнаштыра тордылар. Шулай берсе килгән чакта, мин, тагын хәтер сандыгын актарып, теге Минутка мәйданында булган фажигале төнне искә алдым, бик төз аткан, пуля артыннан пуля яудырып иптәшләремне аямаган снайперлар хакында бәян иттем. Теге иптәш ышанычлы итеп ярып салды:

— Латыш кызлары!..

Гажәпләнеп тегенә карап каттык. Уйлап сөйлиме бу, мин бит Чечня турында сүз алып барам, ә ул Прибалтикадагы чиста-пөхтә кызлар турында сөйли...

— Әх, бернәрсә дә белмисез сез. Анда бит нәкъ Прибалтикадан китерелгән кызлар зур өлеш керткән. Очраган берсе түгел, әлбәттә. Зур акчага ату төре белән шөгыльләнгән кызларны яллаганнар. Стендка ату, тәрилкәләргә ату, биатлон — күп бит ул төз ату күнекмәләре кушылган спорт төрләре. Чеченга нәрсә, акча күп, чит илдән агылып тора, кызлар да жинел юл белән акча эшләү мөмкинлегенә шатланып риза булганнар, валюта белән түлиләр бит.

Без барыбыз да яна күршебездән күзебезне ала алмыйбыз. Кеше ышанмаслык нәрсәләр турында сөйли бу...

— Уйлап чыгара дисезме әллә? Моның турында күпме тапкырлар матбугатта язып чыктылар. Берсенен сорауларга жаваплары да бастырылган иде әле. Башта кайсыдыр чит ил гәзитендә басылган шикелле, безнекеләр тәржемә иткәннәр. Почём зря мактанган кызыкай, күпме акча эшләгәнен дә әйткән, парлашып йөреп, дәртләре ташып торган чечен егетләреннән винтовка ярдәмендә генә

котылганнарын көлеп тасвирлаган. Кызык итеп, узышмактан прицелга эләккән яшь-жилкенчәкне үтерми, оят жирләренә генә төбәп атып, гарип ясаганнарын тәфсилләп анлаткан. Янәсе, тере калсалар да, нәсел дәвам итмәсеннәр, пычратмасыннар жир йөзен, кызыл империалистлар үрчетеп.

Во даёт, дип укып утырдым үзем, кояштыр менә...

Бу яналык мине чыгырымнан чыгарды. Башкалар берничә тапкыр телгә алдылар да оныттылар ахрысы, шулай инде: һәр яна көннен үзенен мәшәкатьләре. Мин үзем көннән-көн күбрәк уйландым бу хакта, күнелемдә бөреләнгән нәфрәт кайдадыр жир читендә булган латыш кызларына карата отыры көчәя барды. Латыш егетләре дип әйтсәләр дә ул кадәр ташмаган булыр иде хисләрем: ир кешенен вазифасы — яу кыры. Ә монда... Спорт белән шөгыльләнүнен нәрсә икәнен мин читләрдән ишетеп кенә белмим, үз башымнан үткән. Нинди төрендә үрләр яулыйм дисән дә, бар вакытынны шуна сарыф итәргә кирәк. Башкалар урам буйлап трай типкәндә, күнел ачканда, син үҗәтләнеп, ахмалга төшеп йөгерергә, сикерергә, шуышырга, үрмәләргә тиешсен, кабат-кабат, тиешле нәтиҗәләренә ирешкәнче. Болары бит кызлар әле, иркә затлар, нечкә күнелле жаннар. Ахирәте кибетләрдә кыйммәтле-затлы күлмәкләр сайлаганда, бу һәр иртә сикереп торып, жилме-янгырмы, чангыга басарга тиеш, колачлап суда йөзәргә,ябык беләкләре өзелер чиккә житкәнче авыр снаряд бәрергә тиеш. Санап бетерерлек түгел спорт китергән кыенлыклар.

Егетләр турында уйларга да вакыты калмый, серле мәхәббәт шатлыклары урап үтә аны. Бердәнбер максат аны алга әйди, бар тормышын үзенә буйсындыра — югары үрләр яуларга, беренчелекне алырга, ин яхшысы булырга! Шундый кызлар парлашып, бер-берсенә сыенып күзәткәннәрдер минем яугирләремне истәлекле төндә, өшегән бармакларын өреп жылытып, тәтегә басканнардыр, нәкъ төзәгән жирләренә эләккәндер ядрәләре. Шулай булмыйча, ничә еллар буе, бар осталыкларын биреп, ныгытып тырышканнар бит алар туры атарга өйрәнер өчен. Менә юкка китмәгән өйрәнүләре, төшкә кермәстәй акча эшлиләр ичмасам. Шулай бер-ике көн авырлыкларга түз дә соныннан жылы дингез буйларында арыган тәненә ял табарсын, күнеленә ошаган егетнен башын әйләндерерсен, яхшы өй алырлык та калыр әле акчан. Әти-әнисенә рәхмәт инде, ярый вакытында спорт түгәрәгенә язганнар әле балаларын, башкалар белән беррәттән трай тибеп йөрергә рөхсәт итмәгәннәр.

Төннәр йокламый газапланганда, төрле фигыльләрдә күзаллап, уйлап ята идем мин шул зифа гәүдәле спортчы кызлар турында. Салкын артык жәфаламадымы икән үзләрен? Яна килгән камерадаш әйтә бит: аларны «белые колготки» дип йөрткәннәр, ди. Ак колготкилары белән аерылып торганнар икән латыш кызлары. Шулай инде, яшь кызларнын килешле, чибәр күренәселәре килгәндер, хатын-кыз бит ул матурлык дип аһ итә. Көтмәгәндә теге журнал алыштыргысыз ярдәмчемә әйләнде минем. Мин бар спорт төрләренен азау теше чыккан фанатына әйләнеп киттем. Дөресен әйтергә кирәк, гел ир-ат өчен генә тәгаенләнгән спорт төрләрен мин исемлегемә кертмәдем, ә хатын-кызлар катнашканнарын йотлыгып, аерыла алмый укыдым. Мине бигрәк тә кайчандыр туганлаш булган Латвия спортчыларынын унышлары кызыксындырды, ату ярышлары очрый калса, аерата игътибар биреп укыдым. Тулы бер дөнья кайный икән лә алар арасында. Үз кайгылары-шатлыклары, үз хәйләләре, үз кыйммәтләре. Гажәп итеп укыдым һәр битен, ярыш төрләренен кануннарын үзләштереп бетердем. Спортчылар арасында яратканнарым, куралмаганнарым барлыкка килде. Басылган фотоларны ихласлап өйрәндем, кайсылары төшләргә кереп йөдәтте. Аралан берсе башкаларга караганда ешрак басыла иде журнал битләрендә. Басылмаслык түгел, Европа масштабында исеме янгыраган латыш чемпионкасы иде ул. Рәсеме дә бер

караудан әсир итәрлек: озын алтынсу чәчләре, якын килсәң, муенга уралырга тора, зәңгәр күзләрендә күк йөзенең төпсезлеге, кабарып торган чия иреннәре сизелер-сизелмәс кенә елмая, бит очлары чокырланып тора — гүзәлләрнең гүзәле инде менә. Мин ана гашыйк булдым дияргә була. Әмма дә ләкин үзенчәлекле иде сөю хисләрем. Нәфрәт белән мәхәббәт аерылмастай уралган иде бер-берсенә, мина бетмәс-төкәнмәс газаплар кичерүгә сәбәп була иде шул хисләр. Журналны кулга алуга, ашыга-ашыга битләрен актарырга тотына идем, таныш йөз чагылып калмасмы, бер-ике генә җөмлә булса да язмадылармы икән минем табынганым турында? Бу эшкә мин китапханәчене дә тарттым, озак елларга сузылган танышлык безне дуслаштырган иде. Ул, үз китапханәсендә актарынып, хәтта аның турында кечкенә китапчык та чокып чыгарды. Алтын кисәге алгандай шатландым мин ул бәһасез бүләккә. Хыялымда туган татлы уйларны кабатлый иде укыган битләрем. Гади генә гаиләдә туып-үскән, үз эченә бикләнгән, артык оялчан кызыкайның спорттагы беренче адымнары йөрәгемне кузгатты. Аның уңышларын үзем кичергәндәй кичердем, ил күләмендәге казанышларына шатландым, ул нәкъ мин уйлаганча уйлый иде шикелле, аны ныграк белә барган саен гел шулай тоелды миңа.

Исәпләүләрем буенча Инга да (аның исеме Инга Мейта иде), минем белән бер вакытта, бер урында 1994 елны каршы алган булуы бик тә, бик тә мөмкин иде. Соңгы елны утырганда минем бар фигылемне туктата алмастай бер теләк чолгап алды: бу гүзәл кызның шул елны кайда каршы алганын мин төгәл ачыкларга тиеш! Шул чакта гына ашым аш, эчкән суым шифа булачак, башкача яшәүнең яме юк. Ачылып киткән чакларымда бу торышның чир икәнен аңлап та кала идем, әмма берничек тә үз уйларыма баш була алмый идем инде. Башның кайсыдыр караңгы почмакларында туган бу уй минем кальбемне биләп алды, язмышым белән идарә итә башлады. Көрәшеп көрәшеп тә алдына чыга алмагач, агым унаена йөзәргә булдым, маңгайга нәрсә язылган — шул булыр...

Һәр нәрсәнең кайчан да бер азагы була. Ниһаять, минем дә иреккә чыгар көнем житте. Соликамскига килеп житкәнче азат тормышыма ышанып житә алмадым әле. Кемдер килеп туктатыр да: «Кулларны артка, стенага борылырга, тирә-якка каранмаска!» — дип, бу әкияти халәтемне челпәрәмә китерер төсле иде. Бу зур авылга тартым шәһәрчектә тукталыш ясадым. Гостиницада урнаштым да беренче эш итеп абыема шалтыраттым. Кайчандыр, буйдак тормышымда акчамның чуты югында, мин ана үз эшен ачарга шактый гына акча биреп торган идем. Тәки тернәкләнеп китте ул, сөт эшкәртергә алынды, каймагын, эремчеген, катыгын житештерә башлады. Тора-бара бизнесын ныграк җәелдерде. Гозерем анда иде. Исәнлек-саулык сорашкач, почтамтка до востребования минем фамилиягә зур гына күләмдә акча күчерүен үтендем. Ул нигә кирәклеген сорап тормастан, берсүзсез риза булды, туган якка кайтырга, яна тормыш башларга кушты. Эшебез уртак булыр, тапканыбызны бүлешербез, картайган көндә абыйлы-энеле ингә-иң терәп яшәсәк иде, синнән башка минем беркемем дә юк бит, дип зарланып алды. Форсат чыгу белән кайтырмын дип ышандырдым, хәзергә минем турыда теш агартмавын сорадым. Пружиналы караватта унга-сулга боргаланып төн үткәргәндә, алдагы көннәремә планнар кордым. Турыдан суктырып, башта Латвия чигенә барып житәргә кирәк иде мина. Анда якынайгач күз күрер: чик аша чыгарга йә берәр юлдаш табармын, соңгы чиктә ялгызым да тәвәккәлләрмен. Якын урнашкан рус һәм латыш авылларының бер-берсе белән алыш-биреш итеп яшәүләренә шигем юк иде минем. Кәгазьдә генә ул һәр адымын чутлап сызык сызганнар, ә тормышта чик дигәннәре бик шартлы нәрсә. Акчаның да могжизалы көче сакланып калгандыр шәт ун ел эчендә, кесәң калын булса иле белән сатып алырга була. Өч көннән мин адым саен

борынгы комарткылары сакланып калган, соклангыч Рига шәһәренен тар урамнарында йөри идем. Сәяхәт тәэссоратларым белән бергәттән, үз максатымны да онытмадым. Шул еллар эчендә кин колач алган интернет мина мизгел эчендә кирәкле мәгълүматларны эзләп табып бирде. Мин «якын танышым» Инга Мейтаның кайсы урамда, ничәнче йортта яшәгәнен төгәл белдем. Эш урынын күрдем, ирен җәмәгать эшләрендә виртуаль озатып йөрдем, улы яраткан төнге клубнын эш сәгате белән таныштым. Барыннан да озаграк Инганың сайтында булган фотоларны җентекләп карадым. Мин аны күбрәк спорт формасында күрергә күнеккән идем. Хәзерге Инга да баш әйләндерерлек затлы киемнәрендә искиткеч матур. Хәзерге тормышы анын башкаларга үрнәк булырлык иде. Яраткан хатын, иң яхшы әни, үз эшенә бирелгән талантлы хезмәткәр, халык ышанычын яулаган җәмәгать эшлеклесе. Бүгеннән бронзадан һәйкәл коярлык. Милләттәшләре дә нык хөрмәт итә икән үзен. Гәзит битләрендә — анын исеме, телевизорда чыгышлары яңгырап тора, латышларда иң популяр исем — Инга. Чынлап та үзгәргән микәнни шулай? Онытканлыр язмышынын кыска вакытлы теге вакыйгаларын. Кем белән нәрсә булмас. Ходай әнә Гайсә пәйгамбәрнен уң ягында дарга асылган җанкыярнын бар гөнаһларын гафу кылып, турыдан-туры оҗмахка керткән бит. Онытканлыр бу йөзеннән елмаю китмәгән чибәр хатынкай кайчандыр пуля артыннан пуля җибәреп, шаярып көлеп кенә, анын кебек үк кеше затыннан булган җан ияләренен җаннарын алганын...

Ходай — бөекләрнен бөеге, шуна да анын үз бизмәне, адәм баласы аңлый торган түгел. Мәгәр мин оныта алмый идем, онытырга хакым юк иде үткәннәрне. Унсигез-унтугыз яшьлек Витялар, Габдуллалар, Сембайлар мәңге гафу итмәсләр иде битарафлыгымны... Болар барысы тойгылар. Ә хәзер миннән барысыннан да артыграк салкын канлы булу таләп ителә, ярый әле вакыт белән чикләнмәгән идем. Әкрен-әкрен, һәр адымны исәпкә алып, үземнен хыялдагы җәтмәне үрергә тотындым. Бар очраклыкларны күзаллап еллар буе тегендә төзегән идем мин аны. Ләкин мондый эштә аеруча сак булу комачауламый. Ничек спорт винтовкасына ия булуымны, тиз генә эзенә төшмәслек итеп җинел машина куууымны, Инганын хөрмәткә лаек ире белән укымышлы малаен, җәтмәгә эләктереп, промзонага китереп урнаштырганнарымны тәфсилләп сөйләп тормыйм. Минем планнын икенче, иң мөһим өлеше башлана иде. Инганың бу тротуар буйлап эштән соң җәяү үткәнен белә идем, әлбәттә, гадәттә, кешеләр сирәк була бу почмакта. Тәмәкемне еш-еш суырып, югары көчләрдән тротуарнын буш булуы хакында ялвардым. Инга машина ишеге белән тигезләшкәндә, якын-тирәдә җан әсәре юк иде. Мин яшен тизлеге белән анын каршына чыгып бастым да борынына кызыл кенәгә терәдем:

— Инга Мейтамы? Куркынычсызлык комитеты. Сезгә берничә сорау бирергә теләгән идем. Капитан Лацис. Юрис Лацис...

Тышкы кыяфәтем белән мин коеп куйган латыш идем. Сөйгәнемне шаяртырга телим дип, бераз акча төрткәч, урындагы театрнын хезмәткәре шундый итеп бизәде мине, көзгегә күз салгач, үз-үземне танымый тордым. Кигән киемем, үз-үземне тотышым уйнаган ролема рас килә иде. Инга, күнелсезләнеп китеп, кулындагы кечкенә алтын сәгатенә күз төшереп алды. Кармакка капканына шик юк иде. Ишекләр ябылуга, мин автомат бикләрне эшкә җиктем дә зур тизлектә кузгалып киттем.

— Ә сез нигә русча эндәштегез? — дип нидер сизенеп алды ул. — Кая кенәгәгезне бирегез әле, мин күреп тә өлгермәдем.

— Шулай кирәк, — дидем мин ышанычлы тавыш белән. — Без күзәтү астында. Сезнен дошманнарыгыз турында бара сүз. Кабинетка кергәч тә рәхим итәрсез, теләгәнчә тикшерерсез документымны. Ә хәзергә ашыгу мөһим.

Күнеләнә корт кергән иде инде шайтан яралгысының. Шарт та шорт ишек тоткаларын боргаларга тотынды, тавыш күтәрде:

— Хәзер үк туктатыгыз! Ут белән уйныйсыз, капитан. Сез капитан да түгел бугай. Хәзер бер шалтырату житә, — дип кесә телефонының төймәләренә басканарга тотынды ул. Ярый кулының калтыраулары бу эшне озаккарак сузды. Мин барган шәпкә тормозга бастым. Чыелдап барып тротуарга менеп туктаган машинага игътибар да итмәстән, хатынкайга таба борылдым. Жилкә тарафында һәр адәмнең жан тамыры бар, белеп кагылсаң, кем дә тирән йокыга тала. Мин дә шул ысул белән юлдашымны тынычландырдым, йомшарып төшкән гәүдәне каеш белән эләктердем дә шәһәр читенә элдердем. Кирәкле урынга житкәнче һушына килергә тиеш түгел иде әле ул, юлда туктата гына күрмәсеннәр. Машинаны ышыкта калдырып, тәзелеш хәрабәләре аша Инганың гәүдәсен жилкәмә салып алып бардым. Жинелчә хушбуй исе танауны кытыклады, авыр да түгел иде аның жыйнак гәүдәсе. Куллар кагылган тыгыз аяклары әллә нинди яшерен теләкләрне уята иде. Ниһаять, сайланган урынга житеп, мин аны урындык төсләрәк такталар өстенә жайлаштырдым, кул-аякларын скотч белән урадым, авызын да томаладым. Әлбәттә, ул моннан качып китә алмас иде, тавышын да ишеткән кеше булмас, әмма, картлар әйтмешли, сакланганның сагы ятар. Мин һәр эшне жиренә житкереп эшләргә өйрәнгән, дөресрәге, тормыш шулай өйрәтте. Без утырган урыннан илле адым ераклыкта минем тарафтан бүген төш вакытында эленгән пәрдә агарып күренеп тора иде. Вакыт булудан файдаланып, шул тарафка барып әйләнеп килдем. Инга урынында боргалана башлаган иде инде. Тәмәке кабыздым да аның авызыннан скотч кисәген йолкып алдым.

— Бу ни кылануыгыз, капитан? Хәзер үк чишегез кулларымны. Нинди башбаштаклык бу, моның өчен беләсезме нәрсә булуы мөмкин сезнең белән? Чишегез, дим...

Минем тыныч кына тәтен суырып утыруымны күреп, ул туктады, гажәпләнеп йөземә текәлде.

— Сез кем? — диде ул куркынган тавыш белән. — Сез минем кем икәнлегемне беләсезме? Ни кирәк сезгә?..

— Минем кем булуым мөһим түгел. Ә сезне мин яхшы беләм: министр урынбасары, сейм депутаты Инга Мейта.

— Нәрсә кирәк сезгә? — диде ул, өзгәләнеп. — Сез әллә Рәсәйдәнме, алай дисәң, йөзегез латыш икәнлегегезне әйтеп тора. Сезнең куркынычсызлык комитетына кысылышыгыз юк бит?..

Мин баш кактым.

— Чынлап та, мин Рәсәйдән, дөрес сиземләдегез, — мин үземне яшерергә теләми идем, — куркынычсызлык комитетына да кысылышым юк. Татарлар турында ишеткәнегез бармы? Менә мин чеп-чи татар инде, Казаннан. Сафин Шәфкать минем исемем. Сафин Шәфкать, исегездә калдырыгыз...

— Саффинн Шаффкатт... Шаффкатт... Саффинн, — дип кабатлады ул мангаен жыерып, — ә нигә мин хәтеремдә калдырырга тиеш?..

— Без сезнең белән икенче тапкыр очрашабыз, беләсегез килсә. Кайчан очрашкан идекме? Соныннан исегезгә төшерерсез әле. Бәлки өченче тапкыр очраша калсак, үзем әйтермен.

— Сез каракмы, акча кызыксындырамы сезне? Күпме кирәк, әйтегез генә мин хәлемнән килгән кадәр бирермен. Тик жибәрегез мине.

Аның күзләрендә яшь тамчылары ялтырады. Бер яктан караганда, жәл дә иде ул миңа.

— Тынычланыгыз, — дидем мин булдыра алган кадәр йомшаграк, — әгәр минем шартларымны үтәсегез, сүз бирәм — бер начарлык та эшләмим сезгә.

Бу сүзләр анарда ниндидер өмет чаткылары уятты булса кирәк, батып барганда, салам бөртегенә булса да тотынабыз барыбыз да. Кайчакта бәхет тавы белән тәмуг чоңгылы арасын мизгел генә аера.

— Ә мин нәрсә эшләргә тиеш? Нинди таләпләр куясыз? Алдан ук кисәтәм, үземә ят булган киртәләр аша бервакытта да чыкмаячакмын. Минем хатын-кыз икәнлегем сезгә йомшаклык күрсәтергә сәбәп булыр дип өмет итәм.

— Зинһар, мине коточкыч зат итеп күзалламагыз, — дип уенны дәвам иттем мин, — сезнең бары берничә сорауга җавап бирүегез генә кирәк миңа...

Ул түземсезләнеп миңа текәлде. Шундый чибәр иде бу минутта тоткыным: ирексездән йомры җилкәләренә таралып төшкән чәчләре, ярымачык кабарынкы иреннәре, өмет тулы карашлары, чокырланып торган бит алмалары, атластай нәфис тәне... Язучыбызның әйткән сүзләре хәтергә килде хәтта: «В человеке всё должно быть прекрасно: и лицо...» Әйтәм бит, тышкы күренешенә сүз тидерерлек түгел иде аның. Күптәннән болай сокланып караганым юк иде минем хатын-кыз затына, бәлки кайчандыр кәләшем шундый күренгәндер... Тәмәкенең ачысы авыз эчен яндырып бара иде, йомшаграгына күчәргә кирәк булыр ахрысы.

— Инга, әйтегез әле, сез чынлап та биатлон буенча чемпион исемен яулаган легендар затмы?

— Күпмедер дәрәҗәдә уңышларга ирештем мин ул өлкәдә, — диде ул, җиңел сулап, — анысы сезгә нигә кирәк булды?

— 1994 елга каршы Яңа ел кичәсен кайда үткәрдегез сез?

— Ну сорауларыгыз, — диде, ул җиңелчә көлеп. — Үткән бәйрәмнәрнең барысын да кайдан хәтерләп бетерәсең ди, бу мөмкин хәл түгел. Бер нәрсә хакында шикләнми әйтә алам — икесенең берсе: йә туган өемдә, йә иң якын дусларым арасында. Һәм бу кичәләр бик тә күңелле үткән, бары яхшылык, изгелеккә төрелгән күрешүләр булган. Ниндидер гаеп эзләп булашмагыз, мин һәрвакыт яхшы кешеләр арасында гына вакытымны үткәрәм.

— Яхшылабрак уйлагыз әле... Бәлки сез иске елны берәр чит илгә сәяхәт кылган вакытта озаткансыздыр. Яшь вакытта бит, үзегез беләсез, җан яңалыкка омтыла, каядыр ашкына, дигәндәй...

— 1994 ел, дидегезме? Юк, юк, минем студент чак, акча ягы чамалы иде, нинди чит илләр турында сүз булуы мөмкин? Ни ягы белән билгеле соң ул ел, һич төшенә алмыйм. Миңа алдагы ел кадерлерәк, Ганноверда алтын медаль яулаган идем. Күпме сулар аккан ул вакытлардан соң, ничә еллар...

— Ә сезгә Рәсәйдә, Чечен җирләрендә булырга туры килмәдеме? — дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйдым. Шул мизгелдә аның йөзе киндер төсле ап-ак булды, хәтер сандыгыннан җиде кат бик астында, ныклап яшерелгән истәлекләре баш калкытты бугай. Күк йөздәй төпсез күзләрендә кыргый курку чагылып калды. Артыгы кирәкми дә иде инде миңа.

— Яңа елга моның ни бәйләнеше бар? — дип тигезләргә тырышты ул сулышын. — Әйтәм бит, иң якын кешеләрем белән... Миңа күп илләрдә булырга туры килде, эш буенча да, сәяхәт итеп тә: Париж, мәсәлән, Лондон, үзебезнең ут күршеләрдә — Таллинн, Брно. Рәсәйдә дә, әлбәттә, күп тапкырлар булдым, безне бәйләп торган җепләр санап бетергесез.

— Ә мин ул елны нәкъ Грозный шәһәренең Минутка мәйданында каршыладым. Харап үзенчәлекле булды ул Яңа ел...

Һаман аклана иде ханым, минем нәрсә белгәнемне чамаларга тырыша иде бугай. Хәзер менә, ачып салам бар күңелемдәгесен... Мин алдан ук әзерләп куйган спорт винтовкасын чүпрәгеннән арындырдым. Шулай да кулга ятышлы винтовканың сабы үзе елышып килә иде култык арасына.

Инга, кыланышларымны күреп алып, утырган урынында тыпырчынырга тотынды.

— Кирәкми, зинһар өчен... мин барысына да риза. Бар байлыгыбызны ал: банктагы акчалар, Ригада ике фатир, диңгез буендагы өебез... соңгы тиенәнә кадәр... Ирем минем өчен барысына риза булачак. Алла хакына...

Гомумән алганда, кеше үлеме куркыныч гамәл түгел, сизми дә кала бәндә, йә башы чәрдәкләнә, йә йөрәген ядрә айкап утә. Әнә шул үлемне көтүләре куркыныч. Бу ханым да, үзенең соңгы мизгелләре житә дип, үз-үзен белештерми башлаган иде. Мин аны тынычландырырга ашыктым:

— Мин вәгъдә иттем лә — тырнак очы белән дә кагылырга уйламыйм сезгә. Карагыз игътибарлап, спорт винтовкасы ич бу! Мондый коралдан сезнең ничә мең тапкырлар атканыгыз булды икән?! Бары мин сезнең осталыгыгызны гына тикшереп карарга телим. Әгәр бар ядрәләрегез дә түгәрәкнең нәкъ уртасына эләксә, ант итеп әйтәм, без дусларча хушлашабыз. Әнә каршыдагы ак япманы күрәсезме? Тезеп өч мишень сызылган анда, күрәсездер бит? Хәзер мин сезнең кулыгызга коралны тапшырам, анда төгәл өч патрон. Минут эчендә түгәрәкләрне юк итсәгез, безнең исәп-хисап тәмам. Килештекме?

Керфекләренең карасы юл-юл булып бит алмаларына агып төшкән Инга, килешкәнен белдереп, кат-кат баш какты. Мин аның кулларын чишеп, винтовканы тапшырдым да бил каешына кыстырган пистолетымны тубык өстенә салдым.

— Шаяртырга уйлама, мин үзем дә мәргән. Өч дигәндә башлыйсың. Бер... ике...

Сызгырып ядрәләр очты, ак япманың пуля эләккән жирләрендә куе кызыллык жәелә башлады. Ханымның аякларын кысып торган бауны бер селтәүдә кисеп төшердем дә:

— Сау бул, Инга Мейта, мин киттем. Ә син барып кара инде үзеңнең мәргәнлегеннең нәтиҗәсен, — дип торып бастым. Ул, ниндидер хайвани сизенү белән фажига көтеп, абына-сөртенә япмага таба ашыкты. Мин беразга гына туктап калдым. Япма артына чыккан Инганың илереп кычкырып жибәргәнен ишеткәч кенә, винтовканы бер читкә атып бәрдем дә машинама ашыктым. Ничә еллар омтылган теләгемә, ниһаять, ирешкән идем мин.

Чик аша чыгулар авырлык тудырмады. Өч көннән дустым Митяйның мунчасында ах-вах килеп арка чаба идем инде. Баштагы көннәрдә кылган кыюлыгым өчен канәгатьлек хисе кайный иде күнелдә. Вакыт үткән саен, бар халәтне салкын бушлык биләде, йөрәк урынына әйтерсең лә котып бозының бер кисәген алыштырып куйдылар. Үткәннәрне уйласам, бары үкенеч уянды, киләчәккә өмет юк иде. Мин түтәлдә үсеп утырган бер шалканга тиң идем, һич тә артык түгел. Менә Митяйның таныш уйгуры килер, мина ялган документлар алып килер. Ул — йөреп өйрәнгән кеше, хәвеф-хәтәрсез генә чик аша Кытайга да чыгарбыз. Теләсәм, Европа илләренең берәрсендә төпләнеп калырмын. Йә, шуннан, анда бәхетле булып яши алырмынмы? Кемгә кирәгем бар минем дә мин кемгә хаҗәт? Нинди чаталы-боталы тәкъдир язылган булган инде минем өлешемә? Мин генә гаеплеме монда? Ә Жир шары зырылдап әйләнә, каядыр томырылып оча, минем газаплы сорауларымны ишетми дә, белми дә...



Эльнар
Байназаров

## ЕРАКТАГЫ КИЛЕШ ЯКЫН

### Без

Күперсез, көймәсез утраулар.
Арада мен дингез, бер яра.
Талчыккан күзләремә, зинһар,
Утравыңнан ялгыш бер кара...

Утравыңа яңгыр коядыр,
Куышың аша үтә тамчысы.
Бөкеле шешәдә хат — кемгә,
Кайларга адресын куясын...

Дингезләр давылсыз. Жил тыныч.
Утраулар да түгел бик ерак.
Нигә соң һаман юк бәйләнеш?
— Күперсез, — дисең син, — жайлырак...

Арада дингезләр булганда,
Булганда арада мең упкын.
Чынлыктагы түгел, син миңа
Ерактагы килеш якын...

***

Ярылды күк кинәт,
ишеттем мин генә.
көн әкрен саташып
авышты тәрәзгә.
Үзгәрде мин белгән
һәр көе жиһанның,
үзгәрде тынлыгы,
һәрбер уй, һәрбер ым.
Салкын куллы берәү,
ник сина юлыктым?

Эльнар БАЙНАЗАРОВ (1994) – *Казан федераль университетының халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты студенты; I Бөтенроссия «Ак җилкән» әдәби әсәрләр конкурсы җиңүчесе.*

Офыкның җебендә
болытлар буыны,
тотрыксыз ал кояш
кисте кан тамырын...
Сөнлаган трамвайлар
бушлыкка китәләр.
Берсенә шуларның
уйламый утырдым.
Салкын куллы берәү,
ник салкын кулларың?

Һәм утсыз фатирдан
мин йокы таптырам.
Күршедәге кемдер
тибрәтә кылларын.
Ә өске катларда,
талчыккан кешеләр,
еш сулап, онытa
галәмнең тарлыгын.
Салкын куллы берәү,
ник миңа кагылдың?..

***

...Мүкләнгән диварлар җылысын кызганды,
бәсләнгән иреннәр дәшмәде артыгын;
бер язга сыймады атасы таңнары,
бер таңы җитмәде әйтергә актыгын.

Мөгаен, бу сырхау бик тансык булгандыр.
Җил-карчык, көнләшеп, җибәргәндер каргыш...
һәм нурлы күзендә чагыла шуңадыр
таллардагы дардай ак сагыш...

Кайчандыр булса да китәсе бу яктан.
Күзләренә туры бик читен каравы...
Керфекнең очыннан сыйпады, юатып,
дуамал язларның сагышлы кыравы...

## Кечкенә мәгънәсезлек

Ялалы түшәмнән агылды тамчылап
яшьләре кемнеңдер — бик таныш
һәм ачы.
Төнге өч тулганда, өч тапкыр ишеккә
шакыды берәү нык ялгышып.

Бу тоныk фатирда һәр сулыш санаулы,
кулларны чәнчүле бәс сара.
Күксегән чәйләрдән гадәттән тыш төсле
бу җиһан:
мин — кызыл, син — кара...

Син бүтән күзләргә чумгансың, югалып...
Каргамыйм, акланма, бул серле.

Үтәли тишелгән йөрәктә укларын —
тимичә калдыру хәерле.

Бу шигырь сина дип багышлап башланды...
Кем соң син — зәхмәт йә дәвамы?
Ертылган читләре юка ак дәфтәрнең —
булмасын шигырьнең дәвамы.

## Хушлашу җыры

Сагынып, ялгызым жырладым талларга
жил-малай сызгырган көйләрнен тәүгесен.
Кин офык артында бу айлы төндә син
кемнәрне уенда йөртәсең?

Кемнәргә дәшәсен, елмаеп эченнән.
Кем жәзан соң синең? котылу?
Бәлки, ул ярату чын һәм дә күптәннән,
мин генә вакытлы тын алу?

Басмадан узамын, селкетә жил бавын,
чак кына кагылсаң — өзелер.
Очраклы ишетеп бу төнге жырымны,
юлымда очрасаң иде бер...

Таратсаң иде бар шигемне бер карап
шом тулы күзләргә, син — усал.
Күнлем дингезенә кагылма кул белән,
туфаннар чыгуы ихтимал.

Телгәли жанымны тулган ай яктысы,
янартып күнелдә дуамал тай чагын...
Кочаклап башканы, уз безнең урамнан,
юклыгыма төшен һәм сагын...

Төн ныграк суыта, ә күктән куылган
йолдызлар, адашып, эзли юл.
Керфектән керфеккә йөри төш, адашып,
калтырый шәмнәрне яккан кул.

Калтырый шәүләләр, әзерләп мина дар,
һәм гади дар түгел — жан дарын.
Беркатлы, берьяклы, беренче сөюем —
кызганыч, бер жырдан яшәмәссең ары.



Төрле төбәкләрдә яшәп иҗат итүче яшь язучылар Матбугат йорты янында. Сулдан уңга: Әхмәт Гадел, Азат Вергазов, Шамил Маннапов, Вил Ганиев, Мәхмүт Газизов, Ренат Харис, Фатих Макаев, Равил Фәйзуллин, Минкадыйр Сибгатуллин, Нур Әхмәдиев. 1971 ел.



Булачак мәшһүр галимнәр юл башында. Сулдан уңга: Мирфатыйх Зәкиев, Мансур Хәсәнов, Фәрит Хатипов. Үткән гасырның 60нчы еллары.



Мәшһүр калмык шагыйре Давыт Көгелтинов бөек сынчы-рәссам Бакый Урманче янында. 1981 ел.



*Сара Садыйкова һәм аның ире Газиз Айдарский. Мәскәү. 1924 ел.*



*Шагыйрь Нәби Дәүли һәм рәссам Лотфулла Фәттахов. 1978 ел.*



*Германиядән килгән Салиха ханым белән «Казан утлары» журналы редакциясендә очрашу. Сулдан уңга: Җәүдәт Миңнуллин, Тәүфикъ Әйди, Мансур Вәлиев, Рашат Низамиев, Флүс Латыйфи, Рәдиф Гаташ, Салиха ханым, Кояш Тимбикова, Нияз Акмал, Шамил Маннапов, Мәдинә Маликова. 1989 ел.*

# СӨЛӘЙМАН

ШАГЫЙРЬ ҖӘҮДӘТ СӨЛӘЙМАННЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

## Исемнәре Сөләйман...

Кешегә ата-ана фатихасы белән мулла кушкан исемнең серле мәгънәсе, күк җисемнәре белән бәйле тылсымлы асылы турында фәнни, уйдырма, хыялый характердагы биниһая күп язмалар булуы мәгълүм. Кыз бала исемендә — йолдызлар балкышы, чәчәкләр нәфислеге, ир-ат исемендә китап вә гасырлар акылы, кылыч чыңы чагыла, дигән канатлы гыйбарә дә яши халык телендә. Безгә Ислам дине аша кергән Сөләйман — күңелгә, рухка якын, элегрәк еш кушыла торган исемнәрнең берсе. Арабызда яшәп иҗат иткән, дистәгә якын шигырь мәҗмугаларына бабасының исемен тәхәллүсе итеп куйган Сөләйманның тормыш юлына, башка сүз осталарын кабатламаган шигъри үзенчәлекләренә күз салыйк...

## Кем соң ул Сөләйман?..

Чувашстан Республикасының Батыр районы Кызыл Чишмә авылында укытучылар гаиләсендә туып-үскән Җәүдәт Шәүкәт улы Сөләймановны (1955) җөмһүриятебезнең галим-голәмәсе, зыялылары күренекле математик, университет профессоры, академик, кампитрларны (анынча, санак) татарча укырга, сөйләшергә өйрәтүче фидакарь шәхес, җәмәгать эшлеклесе буларак хөрмәт итсәләр, яшь, үсмер балалы, рәхмәтле ата-аналар аны Бөтендөнья татар яшьләре «Сәләт» оешмасының җитәкчесе, илһамчы — Ата Камы (Тәңречелектә дин башлыгы, кешеләр белән күк арасында арадашчы — илаһи рух, шигърияtenең бер образы) сыйфатында беләләр.

Гамәли-гыйльми шөһрәтенең югары үренә күтәрелсә дә, күңеленә табигать кодрәте белән салынган шигъри орлык аңа тынгы бирми. Ул уйлана, эзләнә, татар әдәбиятын, халык иҗатын ныклап өйрәнү аша тарихыбызның сәхифәләрен, күңел матурлыгын шигырьләренә, поэмаларына алып керә. Татар шигърияте күгендә Сөләйман кушаматлы йолдыз кабына.

Ниндирәк уйлы, хисле шагыйрьне алып килде соң татар әдәбиятына ике гасыр кисешкән чор? Сөләйман иҗатына багышланган мәкаләсендә күренекле шагыйрь Р.Харис мондый нәтиҗәгә килә: «Сөләйманда шаккату хисе гаҗәеп көчле. Ул катлаулы нәрсәләрдә һәр кешегә аңлашыла торган гади мәгънә күргәндә дә, гади генә күренгән әйберләрдән, күренешләрдән шактый катлаулы процесслар актарып чыгарганда да, чын шагыйрьләргә хас шаккату белән хисләнә һәм хисләрен үзенә генә хас алымнар белән сурәтләп бирә»[1]. Ошбу бәядә Сөләйман иҗатының бер үзенчәлегенә — бүгенгебез, үткәнебез, киләчәгебез белән хисләнүен интеллектуаль фикри югарылыкта ачуына, сине өермәгә тарган йомычкадай бөтереп алган кичереш дулкынына алып керү сәләтенә басым ясала.

Сөләйман иҗатын өйрәнү юнәлешендә кайбер адымнар ясалса да (Р.Рахман, «Тарихка чигелә каберләр...», Шәһри Казан, 1995, 23 июль; А.Галиәхмәтова, «Акыл

[1] Харис Р. Сөйләйманның шигъри дөньясы. Китапта: Сөләйман. Казык шигырьләр, поэмалар. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2002. — 7 б.

күрке», Мәйдан, 2004, №5), тулаем алганда, аның шигъри бәргәләнү-эзләнүләре, татар тарихына «сәяхәтләре» тәнкыйтьнең мәрхәмәтле мөнәсәбәтенә эләкмиләр. Аның иҗаты, үксез бала кебек, игътибардан читтәрәк кала килә. Бу хәлнең мөгез кебек алга чыгып торган берничә сәбәбе бар. Аның язганнарын күрмәмешкә салышуның бер сере — Сөләйманның «обоймага» эләкмәвендә яисә буыннар арасында, Ф.Әмирхан әйткәнчә, урталыкта калуында. Алтмышынчы елларда, буаларны агызган язгы ташкын кебек, шигъриятькә килгән, дөньяның «астын өскә» китергән Р.Фәйзуллиннар буыны өчен ул яшь булса, Р.Зәйдулла, Г.Морат, Л.Лерон, аларның үкчәсенә басып килүче Р.Аймәт, И.Иксанова, Р.Рахман кебек шигъри уен «даһиләре» өчен ул артык житди, чит (безнең өлешкә кермичә, математикасы белән мәш килсен) һәм «карт» күренде. Һәр яна каләм тибрәтүченең, башыннан сыйпап, үсендереп торган Х.Туфан белән С.Хәким дә мәңгелеккә күчкәннәр иде. Ниһаять, мондый битарафлыкның сәбәбен шигъриятенең серле сандык, Наполеон торты кебек катмарлы, сурәтле фикерләвенең ифрат үзенчәлекле, үзен традицион шигъри калыплар белән генә чикләмичә, верлибр, ак, иркле шигырьдә тәҗрибәләр ясавы белән дә бәйләп карарга кирәктер. Шигырь китапларының исемнәрен генә искә төшерик: «Ямаулыклар» (1995), «Таш билге» (1996), «Күләгәләр» (1997). Көнбатышның азгын фәлсәфәсе йогынтысы сизелеп торган «Мин минсез дөньяда» (1996), «Казык» (2002), «Кизләү» (2003) ... Йөрәк сере, йөрәк бәйрәме, җәрәхәтле йөрәк, күнел күзе кебек баллы, татлы исемнәрдә тәрбияләнгән «колакларга» бу прозаик атамаларның илаһилыктан, шигърияттән ерак, сәер, Р.Харис әйткәнчә, шаккаттыру өчен уйлап табылгандай тоелуы табигый. Көндәлек тормыштан алынган сүзләрне мин дә әүвәл, төгәл фәннәр белгеченең гуманитар белемле шагыйрьләр арасында югалып калмау өчен, чытыклануыдыр кебегрәк кабул иттем. Бәхетемә, ялгышканмын, шагыйрь ин гадәти әйберләрдә шигъри очкын, илаһилык табып, чакмадан ут үрләтә икән. Казык, күләгә, ямаулык кебек төшенчәләр символик, эчке, тирән мәгънәләрен ачып, шигъриятенең ачкыч сүзләре, «Сөләйманнары» дәрәҗәсенә күтәреләләр.

Вакыт агыннан иң соңгы «Сүтелә йомгак» (2011) шигырьләр тупланмасының бер бүлеге «Казык кактым» дип атала. Шул исемле шигыренең беренче юлында казык үз туры мәгънәсендә кулланылса, алдарак ул лирик затның сагыну, шатлык кебек эчке кичерешләрен сынландыручы билге-символ буларак үстерелә.

*Казык кактым, / Сагынуларым, / Шатлыкларым, Уй-хисләрем бәйләп / бер казыкка. («Казык»)*

«Казык кактым» бәйләмендә шагыйрь гадәти тормыш-көнитеш күренешләрендә шигъри матурлык, иплe гармония, илаһилык эзли («Үз мохитен тапкан кеше ...», «Бер түмгәгә бер гомергә тигез...»). Ямаулы күлмәк-ыштаннар «ләззәтен» татыган сугыш һәм аннан соңгы унъеллык балалары бу сүз-төшенчәне мул тормышта яшәгән профессорның хәерчелектән мыскыллап көлүе дип фаразлап, рәнҗеп куярга да мөмкин иде «Ямаулыклар» (1994) бу көфер шигемне татар сүзенең күпмәгънәлелеге белән сокландырып, шагыйрьнең изге ниятенә ышандырып, яна рухи матурлыкны ачуына таң калдырып таратты.

*Елак күкне ямыйм әле, тасма кисеп балкыштан, / Аллы-гөлле елмаюдан тамчылар ясын һуштан!*

Яктылык, өмет, гүзәллек дошманнары — шомлы, куркыныч, кара күләгәләр — Сөләйман шигырьләрендә гадәти фикер иясенең башына да килмәслек унай, нәфис яклары белән, позитив символлар буларак ачылалар.

*Күл өстендә / шәүлә түгел — / өмет күләгәләре, / Кибеп килгән уймак — күлнең / Сизелә кинәнгәне. («Күл өстендә»)*

Бу мисаллардан күренгәнчә, Сөләйман иҗатында сүз-билгеләр үз табигый мәгънәләреннән башка, күп төрле бәгланышларга кереп, уй-кичерешне эзлекле аңлау, күпмәгънәлелек хасиятенә буйсыналар. Димәк, шагыйрь иҗатының төп бер үзенчәлеге — метафорик шартлылык, сурәтле фикерләвенең шул юнәлеше аны, бер шагыйрь дә читләтеп уза алмаган, күләмле, мәңгелек образлар даирәсенә алып чыга. Алар — Вакыт һәм Хәтер галиҗәнапләре.

Беренчесенең мәгънәви, символик, эзотерик — серле офыгын ачу юнәлешендә эзләнүләре шагыйрьнең «Ташъязмалар» (1994-1995) поэмасында вакытны игәүгә

тинләвендә күренә. Төп игътибарын чагыштыру объектның эчтәлегенә ачуга юнәлтә.

*Вакыт — игәү, / ә бу игәү үзе / Ниднән пәйда булды дигәндә, / Уйланулар, хәтер сызланулар. / Акыл — кырлар ята игәүдә.*

Бер караганда, гайре табигый, хәтта парадокс күренгән сынландырулар ярдәмендә шагыйрь вакыт алышынуны, үтеп баручы вакытны тою, сиземләү юлларын эзли («Вакыт — елга», 1996). Фани дөньяда вакыт шәрифләренә баш бирмичә, үз эчке кануннары хәрәкәтендә яши торган көч тә бар икән. Ул — истәлекләр, миф-риваятьләр, күчемле аң төпкеле саклаган, бүгенгене үткәннәр белән бәйләп торучы — Хәтер.

2009 елда шагыйрь бу нисби төшенчәнең фәлсәфи вә гамәли эчтәлеге турында уйлануга корылган сәяси вә милли яңгырашлы «Хәтер» әсәрен каләменнән төшерә.

*Борынгы түгел эзләр, / Эзләр җир үзәгеннән, / Җир тарихын язып булыр / Төркиләр эзләреннән.*

«Бармы ул халык хәтере?» (2009) шигырендә өметле рухның, көткән азат, бәйсез тормышның киләсенә ышанычның кимегәне сизелә. «Адәм кешеме соң, илен җуйган хәлендә» җөмләсе шомлы, тәшвишле, җанны эретердәй хисне сагыш дәрәҗәсенә күтәрә. Дәүләтен югалткан халык телен дә саклый алмый, теле беттеме, ул мөстәкыйль милләт буларак яшәүдән туктый.

Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, Сөләйманның шартлылыкка, чуар төсләр уенына, яшерен серлелеккә, символларга корылган шигърияте тар традицияләр йогынтысында гына бәяләү мөмкин түгел. Ул Көнчыгыш шигъриятенә барып тоташкан романтик алымнардан йөз чөермәсә дә, робагый, газәл, мәдхия, мәрсия кебек жанрлар белән тоташ мавыгу чорында да бу «чиргә» бирешмәде. Интертекстуальлеккә, шартлылыкка, метафорага таянуында, шигырь шәкелен төрләндерүендә рус һәм дөнья әдәбияты казанышлары белән танышлыгы сизелә. Шагыйрь татар сүз сәнгатенең ачышларына киң таянса да, берәүне дә кабатламыйча, чуер ташлар өстеннән аякларын каната-каната атлап, үз сукмагын эзли. Ул үзенең остазлары итеп Орхон-Енисей язмаларыннан алып, суфый шагыйрьләрнең Аллаһка табынуларын да читкә тибәрмичә, Акмулла хикмәтләрен, Тукайның мәрсия-мәдхияләрен үрнәк итеп алып, Такташ, Туфан, Ш.Анак, Р.Фәйзуллин («Бәягезне беләсез Сез»), Р.Харис («Җир өстендә чак-чак...») эзләнүләренә таянса да, фәлсәфи-интеллектуаль юнәлеш вәкиле Сөләйманның рухына иң якын, иҗади аң үсешенә иң тирән тәэсир ясаган шагыйрь Дәрдемәнд хәзрәтләре. Иҗатына эчке ышаныч, зиһен императивы, фикер юлламасы биреп торучы эпиграфларның күбесе атаклы «Кораб» авторы әсәрләреннән алынуы да шуна дәлил. Милли рухтан югалмаган һәр татарның йөрәгендә, телендә яшәгән, тәне белән бер иткән Дәрдемәнд каләменнән төшкән шигъри кодар Сөләйман әсәрләренең аһәнен, интертекстуальлеген билгелиләр.

## Халык хәтере — мәңгелек

*... Җир йөзенә карап,*
*Тәңре уйга калды.*

Сөләйман. «Җир йөзенә»

Әдәби әсәр үзәгенә тарихи теманы алган язучыны мин ике яклы пычак өстеннән баргандай күз алдына китерәм. Бер яктан, вакыйга-хәлләрне дөрес яктырту ихтыяҗы, хакыйкать хакы чабуыннан «тартып» торса, икенче тарафтан, ул сурәтле фикерләү, сәнгатьлелек, кызыксындыру чаралары турында да онытa алмый. Ике якка да хилафлык китермичә, алтын урталыкны таба алганда гына сүз остасы төрле даирә укучысының зәвыгын канәгатьләндерә ала.

«Ташъязмалар», «Тамырлар» (1998-1999), «Иске Казан» (2010) поэма-дастаннарында, күпсанлы шигырьләрендә, Сөләйман миф-риваятьләрне, сакланып калган истәлекләрне, халык аңында безгә килеп җиткән мәгълүматларны, үз хыял җимеше белән тулыландырып, шанлы вә аянычлы тарихыбызны иңнәргә омтыла. Бу әсәрләреннән Сөләйман татар җанлы шагыйрь буларак кына түгел, ә гомерен тарихыбызны төрле чыганакларга таянып өйрәнүгә багышлаган археолог, халык

ижатын өйрәнүче галим кебек тә күнелдә кала. Әмма ул поэзиянен, гыйльми хезмәтләрдәге шикелле, тарихны коры тел белән, эзмә-эз сөйләп бирүне өнәмәгәнен сиземләп, чыганакларны әдәби алымнар, лирик чигенешләр, үз хисләре белән аралаштырып, бизәп, чигеп барырга тырыша. Җөмләдән, «Ташъязмалар» поэмасы кышкы озын кичләрдә ил картынын мажаралы әкиятен тынлап утыргандай алым белән башланып китә.

*Борын-борын заманда / Казан атлы калада. / .... / Яшәгән, ди, торган, ди, / Татар атлы бер халык.*

Автор композицияне «уйнатып», тарих баскычларын сурәтләүгә керешкәнче, халкынын хәзерге аяныч хәлен образлы, хәтта күпертү, гипербола алымы белән күз алдына бастыра.

*Бу халык булган эшчән, / Тәм таба белгән эштән, / Тик берчак хәтәр давыл / Акылын алган савып. («Ташъязмалар»)*

Кыйбласын җуйган һәм йокыга талган кавем «кышын урак» урып, «җәен буран» куып, ягъни унайнын гел киресен сукалап яши башлаган. Әле генә дөнья кендегеген кулында тоткан халыкнын карангылык базына тәгәрәвен, мескенлеккә төшүен көтеп, хәтта шуны оештырып йөргән «күрше көлә бот чабып», «кидереп сина камыт». Ваемсызлыгы, сизгерлеген югалтуы, бердәмлеге җитмәве нәтиҗәсендә шул халгә төшүеннән шагыйрь, Тукайнын «Безнен милләт үлгәнме, әллә йоклагангынамы?» мәкаләсе рухында, газиз халкыннан яшь аралаш көлә. Әкияти башлам олы бер милләтнен мәнгелек фаҗигасен сурәтләүгә алып чыга.

«Тамырлар» поэмасын автор, артык гади вә гадәти күренсә дә, көндәлек яшәешебездә ифрат мөһим, хәтәр елларда ач үлемнән алып калган бәрәнгегә мәдхия белән башлый. Кызык янәшәлек бит: дәүләтләр тарихы һәм бәрәнге.

*Кызыл чишмә. Арт бакчада. / Бәрәнгедә халык. / ... / Бакча тутырып / Җир елмаямыни — / Сызылып яткан буразналар / бәрәнгегә тулы.*

Туганнары, авылдашлары белән, дөньясын онытып, бәрәнге алып ятканда, «Алмас хан тулпары» шагыйрьнен инбашына кагыла, колгына тия. Шул рәвешле, ун гасырлар үтеп килгән «ут аргамак», үткәнне бүгенгегә ялгый.

«Иске Казан» поэмасынын тәүге юлларында, укучыны тәшвишкә салып, даны истәлек-риваятьләрдә сакланган борынгы шәһәр тарихы, корылган урыны турында фикере, гөманы белән уртаклашырга чакыра.

*Риваятьләр берсен-берсе этә, / Дистәләгән бәхәс, сүз — дары — / Иске Казан кайчан, кайда булган? / Кемнәр салган нигез ташларын. («Иске Казан»)*

Бу поэмаларны мавыктыргыч башлам гына түгел, ә фабула өлгесенен үсеше, үткәнебезгә хәзерге халәтебез вә ан үсешебез югарылыгыннан бәя бирү якынлаштыра. Структур үзәк-берәмлекләр буларак берничә юнәлеш өскә калка: Тарихи ан, Көчле шәхес, Гыйбрәт фәлсәфәсе. Алтай-Азия-Идел-Урал кинлекләрендә сугышып, мал үрчетеп, иген игеп, ямьле туйлар үткәреп яшәгән төрки кавеме мәдәни үсешендә дә шактый унышларга ирешкән икән. Шагыйрь фикеренчә, тиешле бәяләрен алмаган Орхон-Енисей язмалары — киләчәк ядкярлары. «Гасырлар үтәр, менәр еллар янә милләт янә эз эзләгәндә», Күлтәгин кинәшләрен әйләнеп үтә алмас! Төрки-татар ыруларынын тарихи унышлары белән «мактануны», бар җаваплылыкны үз өстенә генә алмыйча, шагыйрь сүзне әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелгән, һәр шәйгә битараф, тарих шаһиты җилгә «ышанып» тапшыра.

*Җил сөйләде: / — Бөек иде бу халык, / Җиде куктән куәт алып, / Җиде ил корган халык.*

Лирик каһарман, җае чыккан саен, үзенен шул халыкка мөнәсәбәте барлыгын сиздерергә ашыга.

*Урта дингез — Олы дингез — / Ияр тигән кыргый ат. / Таныдынмы мин — кыпчакны, / Хәтерен, дингез, янарт! («Урта дингез — олы дингез»)*

Татар-төркинен дала кинлекләрен йөгерек аргамакларда инләгән чорларын шагыйрь сөенечен яшермичә, буяуларнын жетеләрен кызганмыйча сурәтли.

Һәр дәүләти берләшмәнен башында кыю, тәвәккал, оештыру сәләтенә ия, аллан күрә белүче көчле шәхесләр торган, ди шагыйрь. Төрле чыганаклар, миф-риваятьләр, истәлекләр, язмалар (әйтик, Ибне Фадлан сәяхәтнамәләре) аша исемнәре безгә килеп

житкән Күлтәгин, Илтәреш, Билге каган, Атилла, Алмас, Илкан ибне Сәлим, Кубрат хан углы Кодрак, Мәрҗән шәһәре ханы Тырышмал, Габдулла хан һ.б. шәхесләребезне горурлык белән искә ала. Оялмыйча, яшермичә сүз катырлык олы тарихын, бөек драматург Шекспир әсәрен күтәрерлек («Отелло» трагедиясенә прототип итеп, «Җиһангир ир... Үлемсез төрки», һуннар каганы Атилла образын алган дигән фараз күпчелек галимнәрдә теләктәшлек таба) бабаң булганда, ничек инде күкрәккә какмый түзәсең! Үткәненне онытасың, юк киләчәген, дип, кызык сүз өчен генә әйтмиләрдер.

Элгәргеләр яулаган биеклекләр күнелен күтәрсә, жибәргән хаталары әрнү, сызлану, экзистенциональ сагыш, сыкрану уята. Чал тарихка барып тоташкан үткәнендә, замандашыбызда горурлык хисе уятырлык батыр уллары, матур, чая кызлары күп булса да, шагыйрь хыялы «тапкан» мифик көч — давыл (укы: ваемсызлык, битарафлык, хакимият, байлык өчен көрәш) бер-бер артлы Скиф, Һун, Сөн, Атилла төзегән төрки-кыпчак-һуннар дәүләтен, Күк түрк каганатын, Кубрат хан, Урта Идел болгарын, Алтын Урданың турыдан-туры варисы Казан ханлыгын тарих бар ханнары, вакыт зилзиләләре астында күмеп калдыра: *«Иске эз тузды кинәттән, / Тузды кыйбласын җуеп».*

Сөләйманның шигъри фикерләвендә миф-риваятьләр чыганакларнын иң мөһим катламын тәшкил итә. Телдән-телгә, буыннан-буынга тапшырыла килеп, безнең көннәрдә дә патриотик янгырашын югалтмаган кырык кыз турындагы легенда эчтәлегенә таяну «Тамырлар» поэмасының мәгънәви офыгын киңәйтеп җибәрә. Туган илне яклауда батырлык, кыюлык үрнәге күрсәткән каһарманнарны югары өслүб белән олылау, мәңгеләштерү героик дастаннарның бер юнәлеше, йөзек кашы. Биләр каласын монгол баскынчыларына бирмәс өчен кырык кыз, кулларына корал тотып, тигезсез көрәшкә күтәреләләр һәм тарихка «Кызлар тавы» дип кереп калган биеклектә барысы да һәлак булалар.

Халык хәтерендә, риваятьләрдә мәңге яшь, чибәр булып калган кызлар «Дошманга кол булганчы» сугыш кырында үлемнәрен артыграк күрәләр. Тормышны бизәп яшәргә дә яшәргә лаеклы гүзәлләр язмышы тезмәгә моң, сагыш алып керә. Бу әрнү — мәңгелек: «Уңлап гасыр яралардан кан тама».

«Аю каны» поэмасында рухи омтылыш, азатлык хыялы гомумкешелеккә хас гамәли-рухани эзләнүләр юлына алып чыга.

*Кайда кыйбла? Кайда урман? Кем ирекле? / Мин читлектә, мин — читлектә! / Бу читлекне күрә алмас маңгай күзе, / Күрелмәс ул, ачылмаса күңел күзен. («Аю каны»)*

«Кыйбла», «Күңел күзе», «Читлек» кебек күпмәгънәле символлар укучының хис-хыялын уятып, вакыйга-хәлләрне үзенчә бәяләргә урын калдыралар.

Сөләйман үткән белән хәзерге арасында туктаусыз диалог — әңгәмә алып бара. Җан әрнүе, уйланулары илә укучысына, замандашына, бигрәк тә милләт язмышына битарафларга мөрәҗәгать итеп, кирәк булганда усалланып та ала, *«Язганнарым сина түгел, битараф җан, Синең күңел кымшанмаста ...»* кебек әхлакый чигенешләр ясый.

*Җаны булган, бер уйланыр, ачылыр да, / Тик соң булыр милләт диеп очынырга.*

Татарның киләчәге бармы, таңы бер атармы дигән сорауга да, шагыйрь җавапны үзе бирми, үткән белән киләчәкнең бердәмлегенә нәзарасына таянып, халык иҗатына мөрәҗәгать итә, өмет чаткыларын шуннан эзли.

*...Татарга өмет багларга / Ике тамга төгәл, имди. / Гүя хәбәр бирә безгә / Риватьяләр төгәл, имди. / . . . / Һәр риваять илтә хакыйкатькә, / Ә хакыйкать бары Алладан. («Иске Казан»)*

## «Мәхәббәтне таный безнең күзләр...»

Сөләйманның мәхәббәт лирикасына күземне курс эшләре белән КДУның татар факультеты студентлары «ачты». Талибәләрнең кырыс вә төгәл фәннәр әһеле каләменнән төшкән шигырьләрендә мәхәббәт, сөю-сөелү бәхете, шатлану, сыктану, сызлану кебек һәр инсан башыннан уза торган мәңгелек хисне табигый нәфислегендә сурәтләвен яратып кабул итүләре турында мөкиббән китеп язулары һаман да хәтердә.

*Йөрәк әрнүеннән улый-улый, / Мендәр белән йөрәк арасында / Күпме төннәр сыттым / Мин юләр, /* — дип, эчке халәтенә үзенә кырыс бәя бирә алган лирик затның бәргәләнүләренә, гыйшык утында күбәләк кебек януларына багышланган «Таң калдым чәчкәгә күз атып...» бәйләменә кергән «Жылы сүз дип» (1996), «Сагынганда» (1996), «Янар чәчкә» (1994), «Үкенмәм» (1998), «Дөреслектән дөреслеккә» (2007), «Мәхәббәт» (2009) кебек берсен-берсе тулыландырып, ачыклап килгән шигырьләре Сөләйманны иң нәзберек мәүзугъта да үз сүзен әйтә алган лирик дип атарга мөмкинлек бирә. Югарыда өзек китерелгән «Йөрәк әрнүеннән улый-улый...» (1998) парчасында мәхәббәт Мәҗнүненең йөрәген сөйгәненә ача, олы дөньяда кыйбласын таба алмыйча бәргәләнүен, җавап хисләренә дәгъва итмәсә дә, тирән кичерешенә табынуын, алдануында да ләззәт табуын дулкынланмыйча, битараф кабул итеп булмый. Шигырьнең «...Җәрәхәтсез тумый Сөюләр», дигән соңгы юлы һәркемнең яшьлегеннән, ике кеше арасында җанлы күпер сузган, аң белән бәяләп булмастай сихри хисне гашыйкларны бер күкләргә чөеп, икенче очракта авырттырып җиргә ташлаган илаһи, тылсымлы көч булуына инандыра. «Янар чәчкә» шигырендә бу тойгы нәкъ шундый «бәясен» ала: *«Янар чәчкә — / Сөю — ачылмас мәңге дә, / Сагынмыйча, утлар йотмыйча»*. Тинсез мәхәббәт тойгысы кичергән затны кызганасың да, хисләренең риясыз самимилегеннән көнләшеп тә куясың.

Хатын-кызның гүзәллегенә, камил матурлыгына лаеклы чагыштырулар, буяулар, нәкышләр эзләвендә шагыйрь үзен чикләми.

*Синең күзләр зәңгәр күккә ятыш, / Кара күзләр зәңгәр алмалы, / Синең күзләр сихри күлләр булды, / Кергән идем — чыга алмадым. («Синең күзләр»)*

Сынландыру-метафораларны нигездә тиләлектән, табигатьтән алса да, бу даирә генә күркәмлекнең илаһилыгын ачып бетерә алмагандай тоелганда «ярдәмгә» күк җисемнәре чакырыла.

*Кил әле, таң гөлем, кил әле яныма, / Йөрәккә ут салып, бер елмай. / Ал кояш нурлары сирпелә йөзеңнән, / Бердәнбер тиңдәшең — тулган ай. («Кил әле, таң гөлем...»)*

Сөләйманның лирик каһарманы «Таң гөле», «Кояш нурлары», «Тулган ай», «Канатлы фәрештә» кебек шәрекъ шигъриятенә хас романтик сурәтләү чараларына таянып, сөйгәнен тинсез югарылыкларга күтәрсә дә, сөю хисеннән иреннәре иренгә тигәнче үк исерсә дә, натуралистик тупаслыклар дәрәҗәсенә төшми, зыялы, айдын шәхес булып кала. Сурәтләү чараларын сайлауда аның төп таянычы, үзен «тикшерү» бизмәне — халык иҗатында туган образлар системасы.

Авыл кызларының матурлыгын, тыйнак бөеклеген сурәтләүдә шагыйрь бизәкләү чараларының иң жителәрен таба. «Кизләү суы, чәй суы» шигырендә Тукай еш вә яратып кулланган 15-16, 16-15ле силлабик шигырьдә Сөләйман үзен иркен сизә.

*Вак-вак басып уза кызлар — сыгыла Бүре басмасы, / Җилфер-җилфер уйный җилдә ефәк калфак тасмасы.*

Халык иҗатында яшәү, тереклек чыганагы, сафлык, илаһилык символы — Чишмә, бигрәк тә гүзәл Чишмә кызы — Сөләйман лирикасында илһам, яктылык, нур чыганагы буларак үстерелә. Чишмә олы, бөек вә кодрәтле көч буларак калка.

*Кил яныма ком бураны булып, / Чишмә булып типсәм дә / Үкенмәм. («Үкенмәм»)*

«Чишмә кызы» Сөләйман иҗатында, А.Блокның «Прекрасная дева», Һ.Такташның «Урман кызы» кебек, тыйнаклык, сафлык, мәхәббәтенә тугрылык кебек сыйфатларны үзенә җыеп алган гомумиләштерелгән образ-маска дәрәҗәсенә күтәрелә.

Мәхәббәт хисен чуар төсләр уены, яшерен серлелек белән, аллегорияләр катламына, традицион образларга таянып иҗат ителгән интим лирикасындагы матурлыкка табынуын ул татар тарихына, якыннарына багышланган лиро-эпик әсәрләрендә дәвам иттерә.

«Иске Казан» поэмасында шагыйрь ике яшь йөрәкнең кушылуын, буяу-нәкышләрне кызганмыйча, ихластан, якын күреп сурәтли. Берничә гасыр элек булган хәл-әхвәлләр турында шагыйрь, шул вакыйгаларның шаһиты булгандай, үзе шул туйда катнашкан кешедәй, ягъни диахрон һәм синхрон алымнарны аралаштырып (берсе — Болгар дәүләтеннән, икенчесе — Казан ханлыгы кешесе), дәвамлылыкка, күчешкә ишарә ясый.

*Иң чибәр ул — Гайшә, / Иң батыр — Хаҗитаз, / Мәхәббәт чәчәге — кызыл туй, / Болгардан мон алып, / Казанда яр табып / Буллыгыз бертигез яр-ярлар. («Иске Казан»)*

Шагыйрь укучыны сөю-сөелү, мәхәббәт сынавы үтә алган кеше генә бәхетен таба дигән нәтиҗәгә этәрә сыман. Сөләйманның мәхәббәт лирикасында хис кичереш ничек кенә туарылмасын, ахыр чиктә, ул барыбер акыллы башлангычка буйсына. Ислам тәгълиматының төп таянычларыннан берсе — Акыл. Суфи шагыйрьләр иҗатындагы шикелле, өстен көчләр белән аралашканда, Аллаһка табынганда, Акыл өстенлек итсә, чәчәк, хатын-кыз матурлыгына мөкиббән киткәндә, хисчәнлек алга чыга, физиклар белән лириклар арасындагы мәңгелек бәхәстә үзеннән-үзе хәл ителә сыман.

«Мәхәббәт» (2009) шигырендә Сөләйман бу олы хисне ике кеше арасында туган мөнәсәбәтләргә генә кайтарып калдыруның берьяклы булуын искә төшерә. «Дөньяның киңлеге, барлыгы — ярату» фикерен калкытып куя да аның мең төрле чагылышлары булуын исбатларга керешә. Арада иң мөһиме, хәлиткече — «Аллага мәхәббәт, мәхәббәт — Аллага!» Гаилә корырлык, нәселенне калдырырлык мәхәббәтенне табу Аллаһ бүләге, бу илаһи хисннең кадерен белеп, аны бәллүр савытны тоткандай, саклый алырга да кирәк. Өченче мәхәббәт — дөньяга. «Дөньяга мәхәббәт — ярату» дигәндә, автор дөнья төшенчәсенә якыннарыңны, туып-үскән җиреңне, милләтеңне, туган телеңне, табигатьне яратуны да зиһен уңында тота.

Шагыйрьнең иң ихлас, тирән мәхәббәте — үз халкына, аның үзен татар дип атаудан курыкмаган, оялмаган һәр кешесенә. Бу төр шигырьләрендә ул халыкның язмышы сагышлы булуын, хәсрәтнең ерак тарихтан килгәнен һәм бүгенге сәбәпләрен ачарга омтыла. Милли мөстәкыйльлекнең, хәтта гаярь 90 нчы елларда да (ул чорда Җәүдәт Сөләйманов иҗтимагый хәрәкәтнең узаманнарыннан иде) тулы булмавын, кәгазьдә генә калуын, хәтта милли атрибутикабызны да үзебез теләгәнчә сайлый алмавыбызны тапталмаган, кәтелмәгән образ аша әйтеп бирә:

*Татарстан ярасына ак бинт булып / Ай сузылган... (Татарстан флагына карап...»)*

## Олы шәхесләр — милләт таянычы

Кысынкы, авыр шартларда үз милләтенең азатлыгы өчен көрәшүчеләр — чын фидаи каһарманнар. Шагыйрь милли рухлы, халкыбызның таянычы, эш-гамәлләре белән аның йөзек кашы булырдай, камил инсан турындагы идеалына туры килердәй олы җанлы шәхесләрне ерак үткәннән генә эзләми, ә бүген арабызда көн күргән яисә яшәп киткән затларыбыз арасыннан күреп ала һәм аларга ода-мәдхияләрен багышлый. Үрнәк алырлык шәхесләрнең берсе итеп ул, фәһемлеге, күп телләр белүе, милли мәсьәләләрне кыю рәвештә калкытып куюы белән әлегәчә эшләгән мәгариф министрлары арасында, дәрьядагы таш кыя кебек күтәрелеп торган, «Татар кешесе шундый була ул», дип, дөньяга күрсәтерлек ир-егет Мирза Мәхмүтовны шигъри пьедесталга күтәрә.

*Берәүнең газиз халкына / Шәм даулап китә көче, / Бар шәхесләр милләтенә / Үзен ялкын итүче. («Үтә еллар, уза гомер»)*

Икенче бер шигырендә ул аны бөек алман шагыйре Гёте һәм тел галиме Добровскийлар белән янәшә куя һәм өчесенең дә поэзия, фән, мәгърифәт белән үз халыкларына һәм алдынгы фикергә нур, яктылык алып килүләренә басым ясый. Аларның файдалы эшчәнлеген «сихри кайнар чишмәләр»нең шифалы сихәтенә тиңли: */ Аң сихәте, җан сихәте даһилардан, / Шигърият, илаһи тел һәм мәгърифәт... («Иоган Гёте, һәм Добровский, һәм Мәхмүтов»)*

Сөләйманның рухи дөньясына аеруча А.Арсланов, Х.Бигичев кебек сәнгать кешеләре, сүз тылсымына ия шагыйрьләр якын. Күренекле артист, нәфис сүз остасы Айрат абыйга багышланган «Ак битләрне каурый каләм бизәсә дә ...» (1994) исемле 12-12 иҗекле, «шигырь» белән «бәгырь»не кафияләштергән әсәре классик силлабик калыпта язылган. Әсәрне укыганда мәһабәт тавышына тин гәүдәле, ак күлмәккә кара күбәләк таккан, сәхнә күрке Айрат Арсланов күз алдында тора. Шул сурәт лирик каһарман күңелендә сызлану уята: *«Шырпы суырам бәгыремнән рифма бирлә. / Сызлануларым басылсын дим, тынсын бәгырь».*

Бөек җырчыбыз, «көмеш телле» Х.Бигичевка багышланган мәрсиясендә «ак кәфен», «язмыш лачын», «кара тамчы»га әйләнгән «яп-якты ай» кебек сурәтлелек системасы югалтуның зурлыгын, мәңгелеген йөрәккә җиткерә.

Шагыйрь Равил Бохараевның әтисе, атаклы математик Рәис Бохараев намена юлланган мәрсиясе («Ялгыз имән», 1993) Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романының символикасын искә төшерә.

*Идел кадәр Идел ярын тота / Тере субай — ялгыз имәннәр. / ... Ә елгала сал-сал имән ага, — / Имәнлектә кичә күргәннәр. («Ялгыз имән»)*

Әлбәттә, башка шагыйрьләр иҗатындагы шикелле үк, аның язганнарында да сәнгати биеклек дәрәҗәсенә күтәрелмәгән, үзенә генә таныш, милли мохитебездә эз калдырмаган кешеләргә багышлауларда җитәрлек (Флүскә, Илсурга, Аликка, Ш.Рамилгә һ.б.). «Безнең җизни мунчасы» (1985) кебек иҗатының башында язылган шигыре «Шәкерт дәфтәре»ндә калса да, Сөләйман тәхәллүсле әдип берни югалтмас иде. Исемнәре зурдан кубып бирелсә дә («Тормыш — балан...», «Тормыш — гармун...»), кебек юллыкларының чикләвек эчендәге төшенә җиту өчен берничә акыл тешенне сындырасы була.

Г.Исхакый әйткәнчә, «сүземез» милләткә мәхәббәт, аны яшәтү өчен көрәш, җан ату турында бара ич. Бу мәүзугъны ачыктан-ачык яктырткан, үз халкының язмышы, киләчәге өчен борчылып, әрнеп язылган шигырьләр Сөләйман иҗатында мөһим урынны алып торалар. «Татар булу-булмау белән үзгәрәме Җир йөзе?»нең асылында татарны саклап калуның үзеннән башка берәүгә дә кирәкми, ә кемнәргәдер аның башка халык эчендә эреп югалуы кулайрак, олы сәясәт нәкъ шул юнәлешне алып бара дигән фикер ята.

Татар халкының гореф-гадәтләре, туган теле белән тормыш сәхнәсендә саклап калдыру өчен көрәш рухы «Казан утлары»нда (2013, №9) басылган иң соңгы шигъри тупланмасының асылын тәшкил итә.

*Шигъри юл булып сузылган / Татарның яше — каны. / Әнә очларында тугел, / Шигырь эчендә жаны.*

Шул ук шигырендә ул халкының шигъри җанына, югары өслүб белән, нәкъ Тукай рухында, мәдхия яудырырга да онытмый.

*Һәр авазда саркыла моң, / Һәр авазы — бер гомер. / Халык — үзе шагыйрьдә ул, / Халык ул үзе — шигырь «Кайда татар? Кайда тел? дип...»*

«Мин татар» дип дөньяга оран салуның кайтавазы «тар-тар» булып кайтуы, кылы тартылган, өзеләм-өзеләм дип торган йөрәк рәнҗүе, җан әрнүе дәрәҗәсенә күтәрелә. Гаепне лирик зат читтән эзләми, шул хәлгә төшүебезне милли горурлыгыбызны югалту, аң үсеше дәрәҗәбезнең тиешле югарылыкта булмавы белән аңлата, мәгәр акламый.

*Татар диеп сөрән салдым миргә. / Тар-тар булып кайтты кайтаваз. / Татар үзе / Үзен югалтканда, / Татар иле кире кайталмас! / «Канатларны — каурый-каләм иттем...»*

Сөләйман туган халкының бүгенге аянычлы хәләтен бөтен гажизлеге белән йөрәге аша уздыра. Моңа инану өчен «Татарга», «Ә һәлакәт якыная минут саен», «Болгар җиле», «Дәүләтле татарлар», «Татар йорты», «Шәһре Биләр», «Әбиләр чуагы килер бер таҗ булып» кебек тулы бер бәйләм тәшкил иткән шигырьләрен укып карау да җитә.

*Олаулап татар сагышы, / Бәгыре челтәр-челтәр. / ... / Сагыштан сагышка чаклы / Тарих килә тоташып,* дип яза «Бәхет сагыш — бер коянтә» әсәрендә.

Ата-бабаларыбыз мирас итеп калдырган газиз телебезгә мәхәббәтендә, аны олылавында (дөрес, күп очракта публицистик рухтарак) шагыйрь берниндн чикләүләрне, пышылдап сөйләшүләрне кабул итми. Милләт балаларын, телдән башка, бер үзәккә җыйган, үзанын уяткан башка көч юк.

*Тел бит ул — җан, тел бит ул — моң, / Үксер дөнья, тел югалса, / Соң булыр, соң ... / . . . / Тел ул — Һава, / Тел ул — Диңгез, / Тел ул — Җир дә; / Кошлар кебек тезмә-тезмә / Оча сүзләр Тел күгендә... («Ташъязмалар»)*

Тел, аның төп берәмлеге сүз — Сөләйман өчен мәңгелек сер, тылсым. Аның кодрәтле, магик көчен ачу юнәлешендә шагыйрь туктаусыз эзләнүләр алып бара, кыю тәҗрибәләр ясый. Үз ягының сөйләменнән яңа сүзләрне әйләнешкә кертү, бер

хәрефтән ижекләр «үрчетү», башлам кафия, рәдиф — барысы да хисап фәнендәге шикелле, берсе икенчесенә ялганып, уртак мантыйкка нигезләнеп үсәләр.

*Җәһәннәм дә шунда, җәннәт тә... / Җиһан сыйпап исә житез жилләр ... («Же дигәндә ...»)*

*Тән — тәм, тән — бәдән, / Тән — пәрәвез, тән — эргә. / Тән — сулыш тулы куык. / Тән — биләү бер гомергә. («Өч бишек»)*

Урыны белән мәгънәгә хилафлык китерердәй тәҗрибәләрендә ул телебезнең могҗизалы да, серле дә көчкә ия булуын күргәзмәле рәвештә күрсәтү рухы белән яна. «Ташъязмалар» поэмасында «н» тартыгын төпкә «җиккән», күпмәгънәле «ни» ижеге белән башлаган сүзләрне уртак ритмик рәткә тезә.

*«Ни белән / Ниләрне / Нибары / Ничектер / Нигеннән / Ниткәндә, / Нигәдер / Нителде», — дигәндә, / Мәгънә — дәрья бирде, / Кара сүтеп — үреп! («Ташъязмалар»)*

Кемдер бу тезмәдә нибары шигъри «уен» галәмәте, постмодернизм йогынтысын күрер, мәгәр бераудә телебезнең чикләнмәгән мөмкинлекләренә, шагыйрь Сөләйманның изге тел чишмәсеннән сихәт алу сәләтенә шик белдерергә җөрьәт итмәс.

Дөрес, мәгънәсе артык «эчкә яшерелгән», какофоник мавыгуларында, тышкы янгырашка корылган тезмәләрендә, ул В.Брюсов, К.Бальмонт, В.Иванов, Ф.Сологуб, яшь Такташ, Г.Кутуй, К.Нәҗмиләрнең модернистик экспериментларына ияреп киткәндәй дә тоела. Менә «Тамырлар» поэмасыннан бер мисал.

*Көмеш тояк, / Тыбы-дып! Тыбы-дып! / Калбем тоя — / Ярымайлы ат тоягы / Җиргә бәхет уя...*

Татар шигъриятенең борактан килә торган асыл бер сыйфаты — табигатькә сабыйлык катыш хуҗаларча мөнәсәбәт. Сөләйман иҗатында табигать матурлык күрке генә түгел, ә кешелекнең фикердәше, яклаучысыз халыкның сыену, кайгы-хәсрәтен агызу, ярсыган күнелен тынычландыру бишеге. «Олы елга ташымый калмый язын» (1997), «Көмеш ятьмәле ул...» (1996), «Онытканда ник искәнен...» (1996), «Җәй. Ин рәхәте» (1996), «Кышкы урман. Аккош күле» (2010) кебек шигырьләрендә Сөләйман табигать тормышын каударланмыйча, рәссамнар төгәллеге, психологик күзәтү нечкәлеге белән «киндергә» төшерә. «Үлән арасында имән» (1996) шигырендә лирик каһарман табигатькә, җанын аңлаган затка мөрәҗәгать иткәндәй, якын итеп, дустанә сүз ката.

*Синен жанын, синең егәрлек / Сыямени фани гомергә! / Жиде буын китеп карау кирәк, / Жиде буын җыйган мон-зар кирәк, / Синен жанны: тулай күрергә.*

Табигатьне нечкә-иркәлек, саклык, тын алудан куркып сурәтләгән «Арыш мыегын кытыклап...» шигырендә С.Хәкимнең туган-үскән җиргә, аның матурлыгына мөкиббән китеп язган шигырь-җырларына, М.Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә», «Кеше китә — җыры кала» кебек монсу бәяннарына рухи якынлык, аһәңдәшлекне сиземләве кыен түгел.

*Арыш мыегын кытыклап, / Тирбәлә көмеш рәшә, / Рәшә белән тияр-тимәс / Арыш нилер серләшә. («Арыш мыегын кытыклап...»)*

Күренгәнчә, табигать Сөләйманның шигъри палитрасында катлаулы ассоциацияләрдә яши, тирәлек, мохит шәхеснең рухи дөньясын ачуда мөһим урын тота.

«Нәфес» дип аталган шигырьләр бәйләмендә Сөләйман галәм, дөнья, инсан төшенчәләрен аңлатучы, бар диннәргә дә мөнәсәбәтле эзотерик (яшерен сере аерым кешеләргә генә ачылган) тәгълиматка тоташкан «Каббала» (ярмо) сүзен күпмәгънәле «Кыйбла» га («Кабаланма кыйбла күренми дип ...») китереп бәйли. Халык теленнән әдәбиятка кергән бу сүз-төшенчә, бер яктан, җиһанның күнел күзе белән генә күренә торган ягына ишарә ясаса, икенче тарафтан, көнкүреш дәрәҗәсендә борынгыдан килгән, аеруча зыялыларга нисбәтән кулланыла торган, «аның кыйбласы юк, ана ышануы кыен», кебегрәк үтергеч бәяне эченә ала.

*Кыйбла юкта жил дә исми хәтта, / Жилгә кыйбла — һава жылысы. / Төрки халык дәүләт — жирен жуйган, / Алмаштыра торгач кыйбласын. («Ташъязмалар»)*

Сөләйманның шигырь-поэмаларында кабатлаудан туймый торган фикере — үз милли гореф-гадәтләребезне саклау, үткәндә яулаган үрләргә тугрылык, дәвамлылык. Ислам динен кабул итүне алгарыш, халкыбызны саклап калган ышану санаса да,

татарларның үз диннәре Тәңречелектән китүне, бигрәк тә, беренче үз алифбабыз рун имлясын саклый алмауны зур югалту дип саный. Үз диннәренә, тәүге әлифбаларына таянып, гаҗәеп зур икътисади, мәдәни, фәлсәфи биеклекләр яулаган япон, кытай халыклары белән соклануын яшерми. Яналиф имлясын, аның татар теле үзенчәлекләрен чагылдырудагы уңайлыкларын куәтләп, «латин — язма рун нигезле», дип, кирилл хәрефне «сыер сырты әлифбасы»на тиңләп, сарказмын чыгара.

«Ташъязмалар» поэмасының «Тел чишмәсе», «Рун язуы», «Әлифба» кебек бүлекләрендә төрки халыкларның уртак Дзен-жан фәлсәфәсенә туктала. «Жан шигърият — көмеш чишмә» — төрки халыкларының йөрәгендә яши һәм ул будда диненең Япониядә киң таралган бер мәзһәбенә (рус телендә чыккан шигырьләр җыентыгын «Фиолетовый дзен» дип атый) якын, шуңа тартым икән.

*Кичер, Тәңрем, серләреннән авыз итсәм. / Мин бер тамчын, фал салырга җөрьәт итәм: / Төрки телгә жан шигърият көмеш чишмә, / Татар теле шул чишмәдән инеш икән. («Ташъязмалар»)*

Сөләйман халыкның аң төпкелендә яшәгән мәзһәби юнәлешләрне әле капшап, барлап кына килә. Аларның тарихыбызда тоткан урынын, башка, алга киткән милләтләр белән уртаклыкларны, аерманы өйрәнү киләчәк эше. Һәм аны бер кеше генә, бигрәк тә шигъри юлларда, аңлатып бирүне үз өстенә ала да алмый. Икенче яктан, булсын шагыйрь, булсын галим нинди генә милли җанлы, аның мәнфәгатьләренә бирелгән булмасын, үз чорыннан сикереп чыга алмый. Шулай да: *Сизәсенме, якынайдык / чиксезлектә / Уйга уй бар. / Жанга жан бар / Өзелмәс җеп — / фикерләрдә очрашулар. («Җидегән йолдыз чүмеченнән...»)*

## Нәтиҗә урынына...

Сөләйман иҗаты — хәзерге татар сүз сәнгатенең тиешле бәясен алмаган күренеше. Ул татар әдәбиятының меңьеллык казанышларына, халык иҗатының, җыр-бәетләреннән бигрәк, мифологик катламына таянып үссә дә, аны традицион шагыйрьләр рәтендә өйрәнү нәтиҗә бирмәс иде. Сөләйман — көтелмәгән борылышлар, озын-озын поэмалар һәм ифрат кыска күләмле лирик шигырьләр авторы. Аның табигатенә экзистенциальлек, моңлы сагыш (көйле җыр мәгънәсендә түгел), шартлылык, сыну (сыгылу түгел) хас. Шагыйрьнең күпчелек әсәрләре сер, ачкычы еракка яшерелгән тылсымлы сандыкны хәтерләтәләр. Менә шул шигъри сандыкка пәйгамбәребез (Сөләйман) бүгенге яшәешебезне, бай тарихыбызны сыйдыру рухы белән яши. Үткәнебезнең җиһангир ирләре арабызда яшәгән, хәрәкәт иткән, ялгышкан, кызын кияүгә биргән җанлы шәхесләр булып җир катламын, күк капусын «ачып» алдыбызга килеп басалар. Хәтер җебе аңа үткән белән хәзергене бердәмлектә карарга мөмкинлек бирә.

Әйтерсең лә ул үзе шул вакыйгаларның шаһиты. Мәхәббәт, табигать лирикасында ул яшь белән санашмый яисә аның турында бөтенләй оныта, еллар эргәсен кояш нурларыдай кайнар хисләрендә эретә. Проза, драматургия, сәнгать ачышларына таянып, жанр төрләре арасындагы чикләрне кыскарта. Анафора, ялгау, юлларны бүлгәләү, авазлар тавышын мәгънәгә буйсындыру алымнарын иркен куллануы сокландыра, уйландыра, гаҗәпләндерә. Фабула канвасына юнәлешне зиһен җегәре билгели. Әлегә укучыга барып ирешкән җыентыкларының һәр бүлеге төз, эзлекле мантыйкка корылган һәм берсе икенчесеннән үсеп чыга.

Иҗат кешесенең киләчәген фаразлау, тегеләй язма, бу рәвешчәрәк яз, дип киңәш бирү шикелле үк, житди булмас иде. Тумыштан шигъри оеткы салынган шәхеснең күңел байлыгы, сурәтле фикерләү мөмкинлеге танылып, ачылып бетмәгән сәер вә тылсымлы дөнья. Эчке җегәре көтмәгәндә, уйламаганда, ничәмә еллар тыныч халәттә яткан вулкан кебек, тышка бәреп чыгу ихтималы бар. Шагыйрь Сөләйман белән нәкъ шулай булыр дип ышанам.

**Талгат ГАЛИУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы,*
*профессор*

# «ЮКСЫНУ»

*Җыр язмышы кош язмышы кебек,*
*Бер тирәдән үтә юллары.*
*Йә ул кайчак җиргә егылып төшә,*
*Күтәрелә яки югары...*


*Сибгат Хәким портреты.*
*Байназар Әлмәнов эше. 1950 ел.*

«Төшә-күтәрелә», «Җир-Биеклек»... Гади, хәтта көтелгән чагыштыру, капма-каршы куюу кебек. Ләкин шушы дүртъюллык аша Сибгат Хәким җыр-шигырьләрнең төрле язмышлы булуын төгәл ачып бирә. Әйе, һәр җырның үз тәкъдире, үз тарихы... «Сусау», «Әй, язмыш, язмыш», «Таныш өянкеләр», «Башка берни дә кирәкми», «Өзелгәнсең сиреньнән» – шагыйрь сүзләреннән яралган бу җырларның татар сәнгатендә аерым урын алуы бәхәссез һәм аларның һәрберсенең үз «биографиясе» бар. Бүген без Сибгат ага сүзләренә Шакир Мәҗитов иҗат иткән «Юксыну» (1938) җырының туу тарихын барларбыз. Гөлшат Зәйнашева сүзләренчә, «беренче һәм иң яхшы җыры»ның.

«Юксыну»ны Сибгат Хәким булачак тормыш иптәше Мөршидә Вилдановага багышлый. «Сибгат Хәким. Истәлекләр. Шигырьләр» китабында бу турыда илһамчы үзе менә нәрсә яза: «Безнең яшьлек заманның авыр елларына туры килде. Икебез дә әтисез ишле семьяда үскән кешеләр. Бик авырлык белән Казан уку йортларының ишекләрен ачып керә алдык. Сибгат педрабфак, аннан пединститут бетерде. Мин Казанның фельдшер-акушерлар мәктәбен тәмамлап, Дөбьяз районында Өнсә дигән авылда эшләдем. Безнең Сибгат белән дуслыгыбыз мин авылга эшкә киткәч тә дәвам итте. (...) Кияүгә чыгуымны сорап йөрүенә каршы килгән булып күп йөрттем әле мин аны шәһәр белән авыл арасында. Ялындырып йөргән чакларда, яшьләр газетасында «Юксыну» шигыре басылып чыкты. Нинди көчле шигырь! Ул мине тетрәндерде. Иннәремә канатлар чыктымыни – ничек ярата ул, нинди бәхет!»

Рафаэль Хәким «Эссе о Сибгате Хакиме» *(«Казань», 2011. №12)* язмасында әлеге мәгълүматны тулыландыра: «Бервакыт Мөршидәнең яшь лётчик белән озак биегәнен күргән Сибгат Хәким, ачуланып, Казанга кайтып китә. Күп тә үтми газетада әлеге шигырь басыла. Үзе дә иҗат белән мавыккан Мөршидәгә бу әсәр зур тәэсир ясый һәм ул Сибгат Хәким янына дуслашырга дип Казанга килә». Рафаэль Мостафин «Шигърият чишмәсе» мәкаләсендә *(«Казан утлары», 1966. №11)* шигырьнең ялу алдыннан булган психологик халәтне болайрак тасвирлый: «Лирик герой якын дустын көтә, сөйгәнен сагына (...) Кайчандыр сөйгәне укыган мәктәп яннарыннан юксынып уза. Иптәшләре белән шау-гөр килеп дусты килеп чыгар сыман...» Шагыйрь тәнкыйтьче белән бу юллар күнеленә кайчан килүен бүлешкәндер, күрәмсең, истәлекләргә караганда, алар Рафаэль Мостафин белән еш аралашканнар. Кыскасы, «Юксыну» – Хәкимовлар гаиләсе тууга зур этәргеч биргән әсәр. Ул Сибгат Хәкимнең «Беренче җырлар» (1938) тәүге шигырьләр җыентыгына да кергән.

Бөек Ватан сугышы елларында аның бу җыентыгын Шакир Мәҗитов еш кулга

ала. Кайчандыр Сибгат Хәким үзе бүләк иткән китаптагы шигырьләр арасыннан «Юксыну» дигәненә юлыга һәм төн эчендә ана көй яза. «Зифа Басыйрова» китабында *(Татар.кит.нәшр., 2011)* Флүр Баһаутдинов билгеләгәнчә, «таң атып, яктыруга, хөкем карары көтеп, Заһит Хәбибуллин янына йөгерә. Композитор дустын зур иҗат уңышы белән котлый: көй чыннан да әйбәт була».



*Шагыйрьнең Байназар Әлмәнов төшергән портретының «Казан» милли мәдәният үзәгендәге Милли мәдәният музее фондларында сакланган фотокүчермәсе.*

Шакир Мәҗитов – Оренбург егете, кечкенәдән музыка белән кызыксынса да, артист Сакаев йогынтысында театр училищесына укырга керә. Оренбург, Әстерхан театрларында артист, режиссёр булып эшли, бу театрларда аның пьесалары да куела. 1939 елда ул Казанга килә һәм академия театрында эшли башлый. Театрлар өчен музыка да язгалый. Мәсәлән, Шәриф Камалның академия театрында куелган «Карга оясы» спектакле өчен язган Шахтёр егет җыры үз заманында популяр була. «Юксыну» – Шакир Мәҗитовның композиторлык иҗатында хәлиткеч роль уйный. Монарчы көйләр язу аның өчен мавыгуларның берсе генә булса, Сибгат Хәким шигыренә иҗат ителгән җыр иҗатчының киләчәген билгеле дип фаразларга мөмкин. Әлеге әсәрнең халык арасында зур популярлык яулавы ана канатлар куя һәм ул, җитди рәвештә композиторлык эше белән шөгыльләнү максатыннан, Юрий Виноградовтан дәресләр ала башлый.

Шагыйрь генә озак вакыт әлеге җыр барлыгыннан хәбәрдар булмый. «Фазыл чишмәсе» җырлар китабының сүз башында *(Татар.кит.нәшр., 1974)* бу турыда ул болай дип яза: «Беренче җырым турында мин 1942 елның көзендә Калинин фронтында, Ржев янында, өйдән килгән хаттан белдем. «Синең җырыңны халык яратып җырлый», – дип язылган иде. Ул чакта миндә җыр кайгысы түгел иде. Плащ-палатканы бөркәнеп, хатны укыдым да кесәгә тыктым һәм җыр турында шундук онытгым».

Казанга Сибгат Хәким 1946 елның апрелендә генә кайта. Очрашу-күрешүләр, тормыш матавыклары белән җыр барлыгы искә төшми, ләкин көннәрнең берендә урамда ул артист, «Юксыну»ның беренче башкаручысы Зифа Басыйрованы очрата. «Үз җырыгызны тыңлаганыгыз бармы сезнең?» – дип сорады ул. Шунда ук мине радиокомитетның студиясенә алып кереп, берүземә җырлап та күрсәтте. Ул җыр «Юксыну» иде. Җырны мин кызыксынып тыңладым, һәм шулвакыт Зифа Басыйрова минем күңелемдә әле генә булып узган авыр сугышның бөтен кичерешләрен «Юксыну» аша халыкка җиткергән онытылмас бер образ булып гәүдәләнде», – дип яза соңыннан автор бу хакта «Халык язмышы – шагыйрь язмышы» *(Татар.кит. нәшр., 1979)* китабында.

«Таныш өянкеләр» *(Татар.кит.нәшр., 1997)* китабында Гөлшат Зәйнашева Сибгат Хәким белән Зифа Басыйрованың төгәл очрашу урынын ассызыклый – Горький урамы, 15 нче йорт, ягъни радиокомитет янында. Ул әлеге очрашуның шагыйрьнең берничә көнгә Казанга кайткан вакытына туры килүен дә яза. Мәгълүм ки, Сибгат Хәким 1941 елның июнендә армиягә чакырылып, шул елның ахырына кадәр запастагы гаскәри берәмлектә хезмәт итә, аннан кыска сроклы хәрби курслар тәмамлап, ул, чыннан да, 1942 елның кышында Казанга кайта. Байназар Әлмәновның Татарстан Республикасы милли музей фондларында сакланган шагыйрь портретына да нәкъ менә «Бөек Ватан сугышыннан командировкага кайткач төшерелгән» дип аңлатма бирелгән. Ләкин ул вакытта җырның әле тумаган булуы ихтимал (җырның 1942 елда язылуы гына билгеле). Сибгат Хәким истәлекләрендә «1942 елның көзендә Калинин фронтында, Ржев янында, өйдән килгән хаттан белдем», дип конкрет язган икән, бу очракта шагыйрь сүзләренә таянабыз. Хәер,

Юксыну

Күз карашың нинди уйчанланды,
Син беләсең микән, юк микән.
Син киләсе юлдан күзем алмыйм
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән.

Яратам мин, әйтмим генә аны,
Син йөрәкне күреп белмисең,
Коннар кайта безгә, син һаман юк,
Син һаман юк, никтер килмисең.

Бакчабызда шомырт агачлары
Җәй буена сине көттеләр.
Син килмәдең, көзге җилләр инде
Яфракларны җиргә сиптеләр.

Бу вакытлы гына юксынуым,
Дусларымның исе китмәсен,
Тик ярата белгән кеше генә
Сагына шулай үзенең иптәшен.

1968

*«Казан» милли мәдәният үзәгендәге Милли мәдәният музее фондларындагы шагыйрь архивында «Давыл чәчәкләре» китабы өчен әзерләнгән «Юксыну» шигыренең машинкада басылган варианты.*

әлеге мәгълүмат безнең эзләнүдә әллә ни зур роль уйнамый. Иң мөһиме, җырның чын мәгънәсендә халык күңеленә үтеп керүе. Хәсән Хәйри Сибгат Хәкимнең 1976 елда чыккан «Сайланма әсәрләр» җыентыгының кереш сүзендә «Сагыну» җырының төрле төбәк-районнарда 32 варианты җырлануын билгеләп үтә. Әлеге вариантлар Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан төрле елларда җыелган. Сибгат Хәким «Азат хатын» *(1976, №4)* журналында моңа карата үз фикерен болай дип белдерә: «Юксыну»ны хәзер инде минем җыр дип әйтүе дә читен. Минем текстның бары тик нигезе генә торып калды. Дөресрәге, халык аны үзе янадан язды шикелле». Мәсәлән, авторның «килер юлларыңнан күзем алмыйм» дигән сүзләре еш кына «кайтыр юлларыңнан күзем алмыйм» белән алыштырыла. Бүген яшь җырчы Айгөл Хәйри «син киләсе юлдан күзем алмыйм» вариантын куллана. Сибгат Хәким «Җыр язмышы» мәкаләсендә *(«Халык язмышы – шагыйрь язмышы» китабында)* мондый вариант турында да искәртеп үтә:

*Эш бетүгә, ашыгып өйгә кайтам,*
*Кемдер көтә микән, юк микән?*
*Гәүдәләрең йөри күз алдымда,*
*Ә үзең юк, юк бит син, иркәм.*

Әлеге юлларны «Юксыну» җырына эпиграмма итеп кабул итәргә дә мөмкин. Сибгат Хәким шигыренә хас нәзакәтле тыйнаклыкка капма-каршы дүртъюллык бу. Ни кызганыч, архивларда Сибгат аганың үз кулы белән язылган нөсхә сакланмаган, гомумән, аның кульязмалары бик аз – күпчелек материаллар машинкада басылган. «Казан» милли мәдәният үзәгендәге Милли мәдәният музее фондларындагы шагыйрь архивында «Давыл чәчәкләре» («Давыл чәчәге: шигырьләр һәм поэмалар» җыентыгы, Б.Бикбайның кереш сүзе белән, 1962 елда Уфада башкорт телендә дөнья күрә) китабы өчен әзерләнгән басма текстлар арасында «Юксыну»ның бары машинкада басылган варианты саклана (басма текстлар нәшрият өчен әзерләнгән 1930-1960 еллардагы әсәрләрне үз эченә ала). Әлеге архивта җырга кагылышлы тагын бер документ күзгә ташлана – Шакир Мәҗитов кызы Зөбәрҗәтнең Сибгат агага тәгаенләнгән хаты. Ул композитор вафатына 4 ел тулган елны – 1972 елның 15 сентябрендә язылган. Зөбәрҗәт анда шагыйрьгә «Синең җырың» мәкаләсе өчен рәхмәтен җиткерә, шулай ук бу хатта әтисенең вафаты алдыннан әйткән сүзләре белән уртаклаша: «Үзем үлсәм дә, җырларым кала. Халкым яшәсен! Ул яшәсә, мин дә яшим!»

Әйе, «Юксыну» – беренче чиратта, үзешчән композитор Шакир Мәҗитов исемен мәңгеләштергән җыр... «Шагыйрьдән халыкка таралган бәхетле җыр»... Югарыга күтәрелгән җыр...

**Гүзәл СӘГЫЙТОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

Миркасыйм
Госманов

# ИСТӘ КАЛГАН ЯКТЫ МИЗГЕЛЛӘР

Анын белән танышып, беркадәре аралашып алуыбызга чирек гасырга якын гомер узган икән. Күп нәрсәләрне онытгырып, күп мизгелләрне истән чыгара-чыгара аллә ничек тиз, хәтер төеннәрен яза-яза шомартып узып киткән икән ул еллар...

Шулай да анын бер гадәте — калын чәчле зур башын артка чөеп җибәреп, үзенә генә хас көр тавыш белән шаркылдап көлүе, балаларча сөенә белүе әлегә кадәр истән китми. Кара кучкылрак, төркиләр әйткәнчә, бодай төсле йөзенең аллә ничек күнелгә якын көләчлеге, хәтта битендәге эре шадраларының чыраена Ходай тарафыннан бары анар гына бирелгән бизәк-бүләк сыман сөйкемлелек, ягымлы гадилек биреп торуы да һаман күз алдыннан китми.

Анын шулай гел шат, калганнарыбызның да күнелләре күтәренке торуына, ихтимал, бергә-бергә ясаган сәяхәтебезнен, гизгән-танышкан җир вә илләрнен табигый хөрлеге, гыйбрәтле күренешләргә муллыгы да сәбәп булгандыр...

***

Нажар агай Нәжми белән танышу, ун көн чамасы бергә йөрү мина 1984 елнын көзендә, төгәлрәк әйткәндә, жылы, якты август аенын 18-27нче көннәрендә насыйп булган иде. СССР Язучылар берлегенен әдәби фонды тарафыннан Франциягә оештырылган туристик сәфәр вакытында. Мәскәүдә очрашып танышкан чакта анын ин элек: «Яхшы булды әле бу, үзебезчә сөйләшеп йөрергә дә кеше бар дигән сүз. Киленне дә алып әйбәт иткәнсен», — дип елмайганы истә калган. Шуннан сон гына Казан хәлләре хакында сораштырган иде ул.

Нажар агайнын безне күргәндәге әлеге беренче реакциясе очраклы нәрсә булмаган икән. Казан-Уфалардан килгән өчебезне, ерак сәфәргә Краснодардан чыккан Роман Солнцевны (Ренат Суфиевны), хатыны Галина белән, мәгълүм язучы Астафьевнын җәмәгате Лидия Андрееваны исәпләгәндә, 27 кешедән торган төркемнен зур һәм төп өлешен Мәскәү-Ленинградлардан оештырылган, гадәттә үзара гына аралашырга яратучан традицион әдәби зыялылар тәшкил итә иде. Мәсәлән, шагыйрь, тәржемәче, төрки телләрне беркадәре анлый торган Наум Исаевич Гребнев һәм шунын ишеләр. Сонра Нажар агайнын башкортчалатып көйләп әйткәненчә: «Йөрдек бергә Парижднын калаһында, / Йыйын йәһүд, хырансуз араһында».

Чит ил туфрагына аяк басуга ук игътибарны жәлеп иткән нәрсә «дәүләт чиген узу» процедурасы булды. Янда гына басып торган, элек тә чит илләргә чыккалаган Нажар агай, пышылдап кына: «Тикшерү кыланышына игътибар ит әле», — диде. Әйе, монда «чиктән» бөтенләй башкача уздыралар икән.

Минем искә ирексездән бездәге процедуралар төште. Ул атналар буе дистәләп документлар тутырттырту, үлгән ата-ананнын да кайсы зиратта күмелгәнлегенә хәтле әйттерү, эшләгән җирдәге партия оешмасында, аннары партиянен район комитетында инструкцияләр узу, карт большевиклар комиссиясендә «имтихан тоту»лар. (Түшенә өч-дүрт орден-медаль тезеп алган бер әби, гаять житди кыяфәт белән миннән: «Профессор, сез Де Гольнен кем икәнен беләсезме?» — дип сорагач,

ул чактагы райком секретаре, элекке университет доценты иптәш Латыйпов оялуыннан тәмам кызарып чыккан иде.)

Үзенне ничек тоту хакында Мәскәүдә дә өстәмә күрсәтмәләр алгач, аэропортта паспорт тикшерүче яшел погоннын, документны җентекләп тикшергәч, күзе белән тишәрдәй булып сина озак кына карап торулары, аркасында берәр нәрсә яшермәде микән дигән төсле арттагы махсус күзгегә караулары, ниһаять, «можете идти», дип, теләмичә сәдака биргәндәй, кырыс кына «хөкем чыгарып» паспортны бирүе...

Монда исә ярым хәрбичә киемдәге бер ир кеше, янәшәсендә утырган яшь ханым белән көлә-көлә шаяртып нидер хакында сөйләшкән килеш паспорт битләрен ачкалады да, күз кырые белән генә мина бер карап алып, шап иттереп мөһер сугып, «дубра пужалат!» дип эшне бетерде...

Шулай бик тиз «чикне» узуга безне урта яшьләрдәге Татьяна исемле бер ханым, безнен экскурсоводыбыз, урысча кызык кына сөйләшә торган болгар хатыны каршы алды.

Франция җирендәге сәяхәтебез Марсель шәһәре, анын тирә-юне, тарихи истәлекләре белән танышудан башланды. Икенче көнне кичен Авиньон дигән шәһәргә килеп урнаштык. Гаҗәеп үзенчәлекле, бай тарихлы, бүгенге хәле дә искитмәле кызыклы шәһәр булып чыкты ул. Бөтен Франция буенча, хәтта халыкара дәрәҗәдәге театр һәм җыр-музыка фестивальләре уздырыла торган шәһәр икән ул. Тарихи архитектура истәлекләре, пөхтәлеге, арулыгы белән «кычкырып» тора торган борынгы стильдәге урамнары, кварталлары — үзләре бер дөнья!

Көндезләрен автобуста Авиньоннын әйләнә-тирәләрендәге Арль, Карпантра, Ним дигән шәһәрләргә барабыз. Алардагы Рим империясе чорыннан калган бина калдыкларын, гладиаторлар мәйданы булган амфитеатрларны карыйбыз. Шулай ук әлеге кечкенә шәһәрләрдә элегрәк атаклы шагыйрьләрнен, рәссамнарнын яшәгән йортлары, эреле-ваклы төрле-төрле музейлары белән танышабыз.

Ним шәһәре тирәсендәге Пон Дю Гар дигән, озынлыгы бер чакрымнан артык акведук — ике тау арасындагы тирән үзән аркылы бу тауларнын өсте биеклегендә салынган су үткәргеч «күпер» исләребезне китәрде. Безнен эрага кадәр беренче гасырда, ягъни Цезарь-Август императорлар чорында, әле цемент-бетон бөтенләй булмаган заманда кисеп юнылган таштан салынган ул. Алтынчы гасырга кадәр Ним шәһәрен су белән тәэмин итеп торган акведук икән. Шундый борынгы истәлекләрнен ин зурларыннан, әйбәт сакланганнарынын берсе дә икән бу Пон Дю Гар.

Болай да һәр яналыкны балаларча кызыксынып, сөенеп, шатланып каршы ала торган Нажар агай, телләрен шартлата-шартлата башын чайкап, ташларны капшап-сыйпап карый, безнен төркемнән аерылып, «күпер» буйлап йөренә башлый. Күпчелегебез, артык исебез китмәгән төсле, үзебезне тынычрак тотарга тырышабыз. (Янәсе, совет кешеләре без — шулай «өйрәткәннәр» дә иде...) Нажар агай исә хисләрен, сокълануларын чикләми, кичерешләрен яшерми. Шулай сокланып йөри торгач, ул берара мине үз янына чакырып алды да: «Шушы күпер аркылы узып баручы император Юлий Цезарьны күз алдына китерәсенме?» — дип сорады. Экскурсия алып баручы ханым әйтмәгәч, башка мәгълүматым да булмагач, мин, әлбәттә, шик белдердем. Ул исә: «Әй, сүз андамыни?!. Рим чоры бит! Син Юлий Цезарьны шушы мәһабәт күпердә басып тора дип күз алдына китер әле!.. Һи, фантазия, хыял җитми сез галимнәргә!..» — дип кулын селтәп, бер үк вакытта шаркылдап көлә-көлә китеп тә барды.

Әйе, борынгылыкта дөньянын зур өлешен, бөтен Урта дингезне, анын тирә-юнен биләгән, бик күп илләрне, йөзләгән халыкларны дер селкетеп торган кодрәтле, бөек Рим империясенен бер өлкәсе җирләрендә, бер мәшһүр һәйкәле өстендә басып тора идек без. Шушы көннәрдә үзебез күргән шәһәрләр дә шул империянен шәүкәтле чорларыннан калган калалар иде. Хәтта унөченче-ундүртенче гасырларда бу яклар Италиянен бер өлеше булган. Монда мәшһүр Петрарка да озак еллар яшәп алган — ул гомер кичергән, мәгълүм әсәрләрен язган авылда да булдык. Без ике-өч көнгә туктаган Авиньон шәһәре ундүртенче йөзнен башыннан алып Рим Папасынын, ягъни бөтен католикларнын рухани башлыгынын пайтәхете дә булган икән. Бары унсигезенче гасырдан сон гына бу өлкә җирләре, әлеге шәһәрләре белән бергә, Франция дәүләте составына кергән.

Шундый тирән тарихлы, халыклар тарихында кискен борылышлар тудырган, төрле фаҗигаләргә бай, шунысы белән житди уйларга батыра торган җирләрдә йөрсәк тә, вакыт-вакыт шаяртып, көлешкәләп алгаларга да онытмый идек. Беркөнне Рим империясе чорыннан калган бер мәһабәт ир-егет сыны янында уйланып торган Наум Исаевич янына килдек. Нажар агай: «Нәрсә, яшьлегегезне искә төшерәме?» — дип сорады. Мона каршы Гребнев:

— Күптән түгел төркичә язган бер шигырем искә төште, — диде. — Тынлагыз:

*Я стал стар,*
*Слаб, убог;*
*Курсак бар,*
*Тот-то йок!*

Нажар агай башын чайкый-чайкый бераз елмаеп торды да татарчалап әйтте:
— Ә бездәге бер карт болай дигән икән:

*Итәгемә кайнар бодай салгач,*
*Малай торып тукте бодайны,*
*Ачуларым килеп бер каргадым*
*Шундый малай биргән Ходайны!*

Наум Гребнев шигырьне тагын бер кат кабатлатты һәм уйчан гына: «Ваш старик не прав, — диде, житди кыяфәт белән. — Не «каргадым», а «мактадым» должен быть!»

Рим Папасының тәхете Авиньонда булган, дидем. Монын шаһите рәвешендә гаҗәеп зур, мәһабәт таш сарай сакланып калган. Йөзләгән бүлмәләре бер якта торсын, аш әзерли, пешекчеләр эшли торган махсус ашханәсендәге казаннар, кәбаб-шашлык кыздырыр өчен кирәкле җайланмалар торган җирдәге төтен чыгарырга корылган торба-моржасының биеклеге, зурлыгы, ачуым килмәгәе, безнең Сөембикә манарасы кадәр иде. Минем бу чагыштыруымны Нажар агай өнәмәде: «Алай димә, охшаса да әйтмә! — диде. — Мондый дәү торба-моржалар бу якларда тагын да бардыр әле, ә безнең Сөембикә манарасы бер генә ул!»

Көндезләрен шулай әйләнә-тирәләрдәге шәһәрләрне гизсәк, алардагы тарихи һәйкәлләр, музейлар белән танышсак, кичкә таба Авиньонга кайтып, анын урамнарында, мәйданнарында йөреп, җылы, коры август кичләрендә саф һавада хозурлана идек. Бер кичне Папа сарае алдындагы урам өслегеннән югарырак итеп таш плитәләр түшәлгән, халык белән шыгрым тулы мәйданга килдек. Йөзләгән генә түгел, меңләгән кеше җыелган иде анда. Гел яшьләр, студентлар. Бер җирдә, кечкенә генә түгәрәк оештырып, ике-өч егет гитара уйнап ярыша. Икенче төштә скрипка сыздыралар, өченче урында әллә ни кычкырмыйча гына җырлыйлар. Итальян мотивлары янгырый. Дүртенче җирдә фокусчы тамашачыларны «сихерли». Чак кына читтәрәк, башларын аска иеп, изрәгән төсле тып-тын утыручылар булыр. Юлдашларыбыздан берсе: «Наркоманнар түгел микән?» — дип куйды. Ләкин бернинди тавыш күтәрү, сүзгә килү, талашу, ызгышу-тартышу кебек нәрсә күренми. Ыгы-зыгы бөтенләй юк. Һәрбер төркем үзенчә күңел ача, хозурлана, җырлый, уйный, рәсем ясый, сәнгатьчә һөнәрләре белән башкаларны таныштыра, үзләре дә таныша.

Бер төркемнең немецлар, икенче-өченчеләренең французлар, америкалылар, итальяннар, испаннар икәнлеге шик тудырмаса, менә монысынын латинамерикалылар, ягъни бразилиялеләр, аргентиналылар икәнлеге бәхәссез. Экскурсовод тутаебез янда булмагач, сорашып төгәлрәк белә алмадык, әлбәттә. Телсезлек...

Төркем-төркем булып японнар да йөриләр. Аларны тану һич тә кыен түгел... Бары русиялеләр генә күзгә чалынмый.

Бу көннәрдә Авиньонда махсус оештырылган фестивальләр бармаганга, менә шундый иркәле туристлар рәхәтләнеп хөкем сөрә икән монда.

Өчәүләшеп кенә кунакханәбезгә кайткан чакта, гадәттәгедәй шауламыйча, сүзсез генә уйланып атлаучы, шунысы белән үзенә охшамый башлаган Нажар агай әкрен генә әйтеп куйды: «Менә шулай аралашып, танышып, белешеп яшиләр инде. Кайлардан гына килмәгәннәр... Беркемнен беркемгә үче, дәгъвасы юк... Бездә бер җирдә бу кадәр халык җыелсамы?..» Фикеренен ахырын әйтеп бетермәде. Шулай да анлаешлы иде.

Шулай кайтып барганда, безгә Роман Солнцев белән Галина да кушылды. Бишәүләшеп тагын бераз, төнге уникe тулганчы урамда йөрергә булдык. Урам тып-тын, машина-мазар бөтенләй юк. Әкрен генә гәпләшеп барабыз. Артыбыздан тып-тып иткән үкчә тавышлары ишетелде. Тиз-тиз атлаган биек үкчәле туфлиләр генә бирә торган үзләренчә серле тавышлар. Алар тиз якынлашып, бездән узып та киттеләр. Шәп киенгән, искитмәле сынлы сылу, гаҗәеп төз, озын аяклы, йөз-чырайлары да матур ике кыз, бәлкем, ике яшь ханым иде болар. Тып-тып атлап барулары ни тора! Хәтта янибыздагы хатыннарыбыз да игътибар итеп карап калдылар. «Артистлар бугай бу гүзәлләр, — диде сокланган тавыш белән Роман, концерттан соң кайтып баралардыр... Бәлки рестораннардагы чыгышларыннан соң...»

Без дә шулай дип уйладык. Шикләнмәдек тә.

Әкрен генә сөйләшә-сөйләшә ике-өч квартал узуга, тагын әлеге ханымнарга тап булдык. Бер почмак янында икесе, үзара биш-алты адым аралык калдырып, сигарет капкан килеш, бармакларында ачкыч әйләндергәләп торалар иде алар. Анлашылды. Төнге күбәләкләр икән. «Әнә синен артисткаларын...» — диде Галина, Романга төрттереп.

Монарчы уйчан гына килгән Нажар агай, «һай, кызык булды!» дип шаркылдап көлеп җибәрде. Көлде көлүен Нажар Нәжми, ләкин берничә көннән, Парижда, үзе үк икенче бер төнге күбәләкләр белән безне дә рәхәтләнеп көләргә мәҗбүр иткән иде.

Икенче көнне Марсельгә кайтып, анда зур аэробуска төялеп, илнең башкаласына, сәяхәтебезнең төп максатына таба очып киттек...

Париж!..

Бу гаҗәеп шәһәрнең һәр районы, һәр урамы, һәр мәйданы гына түгел, хәтта һәр йорты, һәр ташы да тарихка ия икән. Соңгы дүрт-биш гасырда монда дистәләгән төрле вакыйгалар: канлы революцияләр, тәхет алмашулар шаулап, гөрләп узган. Аларда йөзләгән, хәтта меңләгән күренекле шәхесләр катнашкан: кодрәтле дәүләт эшлеклеләре, падишаһлар, тәвәккәл гыйсъянчылар, җинаятьчеләр, язучылар, шагыйрьләр, композиторлар, рәссамнар, артистлар...

Автобусыбыз урамнар гизгән чакта, экскурсовод кайсы йортта кемнәрнең яшәгәнлеге, нәрсәләр эшләгәнлеге хакында әйтеп өлгерми диярлек. Аларның яшәү рәвешләре, кылган гамәлләре истә калу түгел, исемнәре дә еш-еш кабатланып, үзгәреп истән чыга тора. Бары тик безгә электән үк таныш затларның гына исемнәрен онытмассың кебек. Тик тагын да мәшһүррәкләре аталып, элекке исемнәрне кысрыклап чыгара бара...

Кайбер мәшһүр тарихи, архитектура комплекслары, мәдәни, сәнгать үзәкләре белән танышыр, аларны өстән-өстән генә карап чыгар өчен дә күпләгән сәгатьләр, хәтта тулы көннәр кирәк булыр иде. Мәсәлән, Луврда узган ярты көнебездә бик күп сәнгать әсәрләрен күргән дә кебек, күрмәгән дә төсле булдык. Мона Лиза сурәте алдында җыелган әллә ничә йөз кешене күрүнең үзе дә гыйбрәтле иде...

Шәһәр тышындагы Версаль сарайлары комплексында зур вакыйгаларга, әллә нинди сәер интригаларга оя һәм шаһит булган серле сарайларны, искитәрлек гаҗәеп архитектура истәлекләрен, ясалган сурәт шикелле бакчасын күздән кичерер өчен генә дә төгәл бер көнебез диярлек китте. Сарай янындагы тукталышта йөзләгән автобус...

Мәшһүр Монмартрның үз тарихы, үз гайбәте, үз кыяфәте, үз ыгы-зыгысы... Әллә никадәр мәшһүр затларның исем-истәлекләре...

Сорбонна университетының, Латин кварталының да үз тарихы, үз атмосферасы. Алтмышынчы еллардагы студентлар, яшьләр хәрәкәте...

Советлар иленнән килгән туристларны Пер Лашез зиратына алып бару гадәткә кергән икән. Үзенчәлекле зират культурасы. Менә Эдит Пиаф кабере. Безне Париж коммунарларын атып үтергән дивар янына да алып килделәр. (Бүген уйласам, нәрсәгәдер ишарә булган кебек.)

Шәһәр аркылы ага торган Сена елгасында егерме дүрт күпер бар икән. Аларның шактые теге яки бу вакыйганы «күреп калган»...

Парижның бер үзендә генә йөз дә егерме алты музей бар иде без булган әлеге 1984 елда! Аларның дүрт-бишен генә йөгереп-җилеп дигәндәй уздык. Күптән түгел ачылган әлекке президент Жорж Помпиду үзәге исә яна чор архитектура үрнәге модерн стильдә салынган. Кызыклы да, безнең өчен беркадәре ят та кебек...

Кыскасы, җыеп әйткәндә, Париж белән чын-чынлап танышыр, аны азмы-күпме дәрәҗәдә әйбәтрәк белер өчен, безгә тәкъдиребез биргән биш-алты көн генә түгел, биш-алты атна, хәтта айлар да җитмәс иде...

Парижда чакта берничә мәртәбә кичләрен, аулакта утырып, Нәҗар агай белән әңгәмәләшеп алырга да насыйп булды. Әлекке зыялыларыбыз әйтмешли, хуш мәҗлесле, күңелле әңгәмәдәш иде ул. Әдәбият, әдипләр турында асылда аның үз фикере, үз хөкеме. Кайбер мәшһүрләрне яратмавын да яшермәс. Тик аларга карата агрессивлык, түземсезлек тә күрсәтмәс.

Хәзерге татар-башкорт мәсьәләсенә дә кагылдык. Дөресрәге, ул минем уй-фикерләремне «капшап карарга» теләгәндәй итте. Кайбер конфликтларның сәбәпләрен, спекуляция, фальсификация фактларын санап чыккач, мин, йомгак ясагандай: «Уфада гына түгел, саф башкорт авылларында да булгалаганым бар. Уфагызда адым саен диярлек синең Казаннан килгәнлегенне, татар булуыңны искә төшереп торсалар, авылларыгызда мин үземне татар да, башкорт та түгел, бәлки гап-гадәти бер адәм баласы, кеше һәм кадерле кунак итеп тоя идем — юкка ярышу да, мәгънәсез тарткалашулар да булмас», — дидем. «Нәкъ өстенә бастың! — диде әңгәмәдәшем, шатланып. — Бу милли ызгышлар шәһәрдә, бары интеллигенция арасында гына! Гади халыкта ул чыннан да юк!.. Дөрес, аны да бозарга тырышалар...»

Нәҗар агай кайбер дәрәҗәле әдипләрнең, галимнәрнең татар-башкорт ызгышларын махсус куертуларын, алар артында зур түрәләр дә торуын яхшы белә икән. Кайберләренең исемнәрен дә атады. Минем: «Аларны да читтән өстереп торучы югарырак көчләр дә бар бит. Бүлгәләү, шулай идарә итү — күптәнге алым», — дидем. Моңа каршы ул тиз генә җавап бирмәде. «Бәлки, — дип, карашын читкә борды. — Тик һәркемнең үз башы булырга тиештер бит!» Минем әлеге зур сәбәпкә күрсәтеп төрттерүемне ул хуплап та, чын-чынлап кире кагып та тормады.

Нәҗар агай, шулай итеп, күпне кичергән «карт чыпчык» буларак, үзенчә саклык күрсәтте. Шуңа күрә бу мәсьәләләргә соңра мин кагылмаска тырыштым...

Берара, автобусыбыз урам буйлап барган чакта, экскурсовод: «Әнә атаклы Мулен Руж!» — диде. Барыбыз да диярлек тәрәзәләргә сарылдык. Ишарә ителгән бина өстендә җил тегермәненең бизәкле канатлары әкрен генә хәрәкәтләнә... Юлдашларыбыздан бер егет: «Их, шунда бер керәсе иде, бер бокал француз шәрабын эчеп, сәхнәдәге матур кызларның биюләрен карап утырасы иде!» — дип кычкырып җибәрде. Аннары, үз идеясенә үзе дә ышанган төсле, сорап куйды: «Бу идеягә кем кушыла?»

Чак кына тынлыктан соң «мин, мин!» дигән тавышлар яңгырады. Нәҗар агай да кулын күтәргән иде. Ханымнардан да ике-өчесе «без дә» дип чәрелдәп алдылар. Моңа каршы экскурсовод, авызын гына ерып: «Шәраб эчеп тамаша карау түгел... Барчагызның кесәләрендәге франкларны җыйсагыз да ике-өч билетка да җитмәс...» — диде.

Шулай итеп, барыбызның да «кикрикләребез» шиңде. Янда гына утырган Нәҗар агай мыгырдап кына татарчалап бер сүгенде дә: «Чит илгә хәерче килеш чыгарып җибәрәләр бит», — диде.

Әйе шул, кеше башына нибары утыз җиде сум совет акчасын гына франкларга алмаштырганнар иде. Эссе көндә бер фужер салкын су эчәр өчен ярты франк кирәк...

Франк дигәч, ул чактагы безнең психологиябез өчен ят тагын бер вакыйга искә төште. Иртәнге чәйдән соң урамга чыксам, алданрак киткән Нажар агай мине канәгать кыяфәт белән каршылады: «Менә, дус-ишләргә бүләк өчен зажигалкалар алдым бит әле!» — дип, кулындагы дүрт-биш чакманы күрсәтте. «Кайдан, күпмедән алдың?» — дип сорадым. «Әнә, теге кара малайлардан, бер франкка икешәрне бирделәр», — диде ул, читтәрәк торган, күтәреп вак-төяк сатып йөрүче африкалы егетләргә таба күрсәтеп. Мин янәшәдәге кибеткә ишарәләдем: «Анда бер франкка бишәрне бирәләр... Ышанмасаң, кереп кара, кергәч сул як өстәлдәге әрҗәдә өелеп яталар...»

Кибеттән чыгуга, Нажар агай як-ягына каранды. Тик теге «кара малайлар» китеп өлгергәннәр иде.

Мулен Руж театрына керү өметен өзгән сәяхәтчеләребез экскурсоводтан төнге күбәләкләр тора торган җиргә алып баруын сорый башладылар. Ни өчендер мондый сорауга ханымнарыбыз активрак кушылды. Бигрәк тә Мәскәү маржалары, һәм бер якты кичтә экскурсоводыбыз безне без урнашкан барон Осман бульварыннан әллә ни ерак булмаган Сен Дени, ягъни «Изге Денис» дигән урамга алып китте. Якынрак килгәч, экскурсовод кисәтеп куйды: «Төбәлеп карамагыз, сөйләшеп маташмагыз».

Тар гына урамның ике ягындагы тротуарда, үзара җиде-сигез адым аралык калдырып, үзгәчәрәк киенгән хатын-кызлар басып торалар. Авызларында яки кулларында пыскып торган сигарет булыр. Кайберләре бармакларында ачкыч уйната. Бусы очрашыр урын барлыгын белдерер өчен икән.

Әкрен генә атлыйбыз. Ниндиләре генә юк «күбәләкләрнең»! Брюнетлары да, блондиннары да. Сары тәнлеләре дә, кап-кара африкалылары да. Тән-бәдән байлыкларын, бигрәк тә күкрәк һәм ботларын ачыграк күрсәтер өчен, ярым-ялангач киенгәннәре дә шактый. Ябыклары белән тазалары да, бәләкәйләре белән «тракторга җигәрлекләре» дә. Соңгылары кара тәнлеләр арасында ешрак очрый... Һәрхәлдә җаның, зәвыгың теләгәнен сайлап ал... Һәм сайлап алалар да иде: машинадан төшкән ирләр яннарына килеп бераз сөйләшәләр дә, ияртеп үк китәләр. Яки икенчесе янына юнәләләр...

Минем игътибарны бер яшь ханым үзенең гади төс-кыяфәте, ярым гына кием-салымы белән җәлеп итте. Ул башкалары кебек ярымялангач та, вульгар кыяфәтле дә түгел иде. Әллә ни бизәнмәгән, өстендә джинсы чалбар, шундый ук кыска күлмәк. Бармагында әйләндергән ачкычы да юк. Дөрес, чәлеме пыскып тора. Бөтен төс-кыяфәте белән студентка охшаган. Читтән килеп укучыдыр, стипендиясе беткәндер, ашарына юктыр дип уйлап алдым. Тик шунда ук әлеге уйларым челпәрәмә килде.

Чөнки дүрт-биш яшьләрдәге бер малайны җитәкләгән олы яшьтәге хатын, дөресрәге, әби кеше, әлеге «студентым» янына җитүгә, кулларын чаба-чаба тавышланып, аны кочаклап алды, битләреннән үбә башлады. Шунда ук аны янындагы малай белән дә таныштырырга онытмады, ханым баланың башларыннан сыйпады. Беркадәре шулай сөйләшеп тордылар. «Студент» та рәхәтләнеп гәпләште. Тик янып беткән тәмәкесен ташлап, икенче чәлемен кабызырга да онытмады. Бары шунда гына әлеге әби, әңгәмәдәшенең «эш урынында» икәнлеген искә төшергән төсле, саубуллашып, тагын йөзләреннән үбеп китеп тә барды, малай да кулларын изәп хушлашты. Берсенең дә уңайсызлануы кебек нәрсәсе сизелмәде. Гүяки гадәти, әйбәт урында очраштылар.

Ирексездән Мопассанның мәгълүм хикәясе, бер авыл кызының кияүгә чыгар алдыннан, егете белән килешеп, Парижга килеп, туй өчен акча эшләп китүе искә төште. Хикәяне укыган чакта, алай булуына ышанмаган идем...

Шулай гыйбрәтле манзара хакында уйланып торганда, урам буйлап таралып беткән безнен кешеләр җыела башлады. Кайтыр вакыт җиткән иде. Тик Нажар агай гына күренми. Биш-ун минут көткәч, борчыла да башладык. Бигрәк тә минем куркак хатыным вәсвәсәгә бирелде: адашып китмәде микән, урлап калмаслар микән үзен?!

Ниһаять, күренде Нажар агай. Кайда йөрдең дип сорашырга да өлгермәдек, ул тантаналы рәвештә хәбәр итте: «Урамның ахырына кадәр барып санап кайттым. Сиксән җиде тәтәй басып тора икән!» Барыбыз да көлештек, әлбәттә. Кызыксынучан, һәрнәрсә,

һәр күренешнең асылын белеп аңлар өчен экскурсоводның теңкәсенә тиеп беткән Нажар агай монда да үз гадәтенә турылыклы булып калган икән. Кемдер берсе: «Оһо, хороший счетовод», — дип шаяртмак булды. Тик Наум Исаевич кына: «Учёт — это социализм!» — дип төрттереп, шул чордагы бер канатлы тәгъбиргә ишарә ясады.

***

Иртәгә илгә кайтып китәсе дигән көнне төштән соң, кичкә табарак, Эйфель манарасы тирәсендә йөрдек. Манара турында лекция дә тыңлап алдык. Биеклеген 320 метр тәшкил иткән манараны төрле зурлыктагы меңләгән-меңләгән аерым детальләрдән (махсус үлчәмдәге корыч эшләнмәләреннән) җыяр өчен ике миллион болт кирәк булган. Бер кат буяп чыгар өчен дә җитмеш тонна буяу тотыла икән...

Барчабыз да диярлек аның тирәсендә рәсемгә төшәргә тырышып, фотоаппаратларыбызны эшкә җиктек. Нажар агай, мина үз аппаратын тоттырып: «Җыентыгыма кертер идем», — диде. Кеше плёнкасы җәлмени, баскаладым кнопкага. Тик көн томанлы, караңгырак иде.

Безне гаҗәпләндергән тагын бер яңалык Америкадагы, Нью-Йорк гаванендә тора торган Азатлык сынының тарихы булды. Баксаң, ул һәйкәлнең идеясе Парижда туып, кечерәк үлчәмдәге оригиналы да шунда ясалып, шунда ук саклана икән, ә Нью-Йорктагысы шуның күпкә зурайтылган варианты гына икән. Шуны ишетүгә Нажар агай, минем бөеремә төртеп, кыткылдап көлеп алды: «Теге бездә бихисап карикатураларга азык булган һәйкәл бит! Менә аның тарихы кайда!»

Эйфель янындагы мәйданда йөренә торгач, төрле зурлыктагы рәсемле камыш паннолар сатып торучы бер кытай ханымы янына килеп чыктык. Рәсемнәрнең һәммәсендә дә кытай пейзажы тасвирланган. «Чайна?» — дип сорадым сатучыдан. «Но, Тайван», — диде ханым, елмаеп. Нажар агай әкрен генә кинәш бирде: «Барыбер Кытай инде. Алып җибәр берәрсен, туган якларыңны искәртеп торыр...»

Тыңладым. Ләкин ул панно күп еллар Парижны, Эйфель манарасын искә төшереп торды...

Шул ук кичне Эйфель манарасына менеп, лифтта, әлбәттә, ресторанда кичке ашны ашадык. Дөресрәге, анда Париж, Франция белән хушлашу зыяфәте оештырылган иде.

Төрле шәраб шешәләре белән мул бизәлгән табын янында үзара ярыша-ярыша Франциядән, бигрәк тә Париждан алган тәэссоратыбыз хакында сөйләшеп бик озак утырдык. Кызыклы һәм гыйбрәтле фикерләр әйтелде. Мулен Ружда эчү насыйп булмаган шәрабны тагын да кәттәрәк җирдә — Эйфельнең үзендә (!) авыз иттек, дип көлде берәүләр. Башкалардан аермалы буларак, Нажар агай нигәдер күп көлмичә, уйга батып утырды. Чиратлашып тост әйтүләрдә дә артык катнашмады.

Тамадалык ролен башкаручы Татьяна ханым, экскурсоводыбыз, миңа карап: «Какое впечатление произвело путешествие на татарина?» — дип сорады. Бу — тост әйтер өчен сүз бирү иде. Мин бу кыска сәяхәттән бик канәгать калуыбызны әйтеп, сүзләремне бизәр өчен, Шәмсетдин Зәкинең мәгълүм «Булгай — булмагай» дигән шигыреннән: «Астыңда ат булган чакта илләр гиз, сәяхәт ит, дөньяның читенә җит, көтмәгәндә ул ат астыңда йә булыр, йә булмас», — дигән мәгънәдәге өзеген укып, тәрҗемә иткән булдым. Шигырьнең фәлсәфәсе юлдашларыма бик үк аңлашылып җитмәде шикелле. «Әйдә, балконга чыгыйк әле», — диде Нажар агай, пышылдап кына.

Балконга чыккач, ресторабызның шактый биектә икәнлеге беленде. Меңләгән-меңләгән ут белән яктыртылган төнге Париж шактый түбәндә иде. Беркадәре тын гына төнге Парижны күзәтеп торган Нажар агай: «Кабатла әле теге шигырьне», — диде. Кабатладым:

*Ат сәнең астыңдадыр, йөргел бу йирнең хәддән ал[1],*
*Нәгяһән[2] ул ат сәнең астыңда булгай — булмагай.*

[1] Хәддән алу — читенә җитү.

[2] Нәгяһән — кинәттән, көтмәгәндә

— Әйе, — диде ул, үзе белән үзе сөйләшкән төсле, — форсатны кулдан ычкындырмаска кирәк шул. Тагын бу якларга килеп булырмы, юкмы... Ә мин башта икеләнеп кенә, теләр-теләмәс хәлдә юлга чыккан идем. Эш күп, дибез бит... Ә хәзер сәяхәтемнән бик тә канәгатьмен. Нинди гыйбрәтле дөньяны белмичә яшәгәнбез бит!.. Дөрес әйткән шагыйрь: киләчәктә мондый форсат йә булыр, йә булмас...

Бераз сүзсез тордык. Күңелсезрәк төс алган сөйләшүне икенчерәк якка борырга теләп: «Үзегезнең «Татар телен» укыгыз әле, Париж өстендә дә бер яңгырасын!» — дидем.

Ул башта, хәтерләмим инде, дигән булды, аннары әкрен генә башлап, бер-ике строфасын узуга, кызып-кызып укыды.

*Туган җирең Идел буе:*
*Һәр телнең бар туган иле.*
*Туган җирең кебек назлы,*
*Җырдай моңлы татар теле...*

Гүяки бәйгегә кушылгач кызышып, авызлыгын чәйни-чәйни чапкан толпар ат төсле ярсып-ярсып, тагын ике-өч шигырь укыды ул...

Төнге Париж миллионлаган утлары белән җемелди, күңелләрне иләсләндерә. Бүген уй-фикер җитмәс серләре белән аста җәйрәгән, ә иртәгә иксез-чиксез истәлекләре белән артта калачак Париж...

***

Өйгә кайткач, һәрберебез, гадәттәгечә, үз мәшәкатьләребезгә чумдык. Шуңа күрә фотоплёнкаларны эшкәрткәнче шактый вакыт, хәтта дүрт-биш ай узып китте. Уртача гына сыйфатлы чыккан рәсемнәр арасында бер кадр Нажар агайның Эйфель манарасы фонында рәсемгә төшәргә теләвен хәтерләтте. Әйбәт рәсем булса, җибәрерсең, дигән иде ул. Шуны күздә тотып, шулай ук бергә булган көннәребезне сагынуым һәм аңа карата ихтирамымның билгесе булсын дип, әлеге чамалы гына сыйфатлы рәсемне Уфага җибәрдем. Шунда ук җавабы да килеп төште. Аннары тагын өч хаты ирешә.

1 Май бәйрәме белән котлаган тәүге мәктүбе «ачык хатның» эчке ике битенә язылган кыскача тексттан гыйбарәт иде. Аны, үз орфографиясен саклап, тулысынча күчерәм.

*Миркасыйм!*

*Бәйрәмнәр алдыннан нинди сюрприз эшләден, әй бик тә шатландым, чөнки минем плёнкаларны боздылар, житмәсә, үзем дә начар төшергәнмен. Бигрәк тә Эйфель янындагыда бернәрсә [дә] күренми иде. Искә алган өчен, сүзеңдә торган өчен рәхмәт сина.*

*Бергә йөргән көннәр искә килеп-килеп төшә. Сентябрь айларында бер поэма бәгыремә керде дә чыкмыйча йөдәтте. Аны язып беттем, хәзер инде Франция шигырьләре башта йөри. Чыгарлармы, юкмы?! Поэма бик арытты; бер ай больницада да ятып чыктым. Казанга барырга вакыт житми калды.*

*Барысы өчен сина тагын да зур рәхмәт. Салисә киленгә бик күп сәлам. Анын «Мир-ка-сыйм!» дип борчылып эндәшүе һаман колак төбендә.*

*Икегезне дә ике бәйрәм белән котлыйм. Икенчесе — үзем яулап алган бәйрәм. Ул, ничектер, ин кадерле бәйрәмнәремнең берсе. Шул ин кадерлесе белән аеруча кадерләп котлыйм!*

*Яна унышлар сезгә!*

*Нажар Нәжми. 29.IV.85*

Сентябрьдә җибәрелгән конвертында аның «Париж өстендә» дигән шигыренең машинкада басылган ике битле тексты килгән иде. Икенче битнең ахырында гына искәрмә рәвешендә түбәндәге сүзләр өстәлгән:

*Миркасыйм! Менә бер шигырь. Тел вә әдәбият кешеләре: «Бу кайсы берәүләргә*

*ошамас», — диделәр. Әгәр дә сина ошаса — миңа шул житкән. Салисә сенелгә сәләм. Бу шигырьне С.Хәкимгә дә жибәрәм. Сәлам белән: Нажар Нәжми. 12.IX.85*

Күп тә узмый, 16нчы сентябрьдә язылган өченче хаты да килде. Аны да тулысынча укып чыгыйк:

*Миркасыйм!*

*«Париж өстендә» дигән шигырьнен бер юлын, сиңа жибәрер алдыннан, «Тел, лөгать вә... әхлак алмашузар» дип төзәткән идем дә, уйлана торгач, үземә-үзем каршы килгәнемне аңладым. Бертуган халыкта нинди алмашулар булсын инде. Ул синен бәгыренә кадалуы мөмкин. Шигырьнен шул урыннары шулайрак булды:*

*Язык түгел беркем алдында бу,*
*Туры килгәч язмыш язмышка.*
*Ә язмышлар, «тел, лөгать вә... әхлак»*
*Бер тамырдан, бер үк сулышта.*
*Без әле дә бер үк сулыштабыз —*
*Чит бер илдә — француз җирендә.*
*Ярсый-ярсый шигырь укышабыз*
*Йә татар, йә башкорт телендә.*

*Хатларым белән вакытыңны алганым өчен гафу үтенәм.*

*Нажар Нәжми. 16.IX.85.*

Димәк, Нажар агай моннан дүрт-биш кенә көн элек жибәргән шигырьнен кайбер юлларын төзәтүне, дөресрәге, чынбарлыкка якынрак итеп әйтүне кирәк тапкан икән. Элек жибәрелгән беренче вариантта әлеге юллар болайрак янгыраган иде:

*Язык түгел беркем алдында бу,*
*Туры килгәч язмыш язмышка.*
*«Тел, лөгать вә... әхлак алмашулар»*
*Алып барган алга, узмышка.*
*Без әле дә гүя узышабыз,*
*Чит бер илдә — француз җирендә,*
*Ярсып-ярсып шигырь укышабыз*
*Йә башкорт, йә татар телендә.*

Үзгәртү, шулай итеп, принципиаль мәгънәгә ия иде. Күрәсен, Нажар агай элегрәк Парижда безнен арада булып алган шактый мәгънәле фикер алышуларны искә төшереп керткәндер бу төзәтүләрне.

Бу унай белән мин нәрсәләр яздым икән, анысын хәзер төгәл хәтерләмим. Чөнки монда махсус бәхәсләшергә бернинди урын юк кебек. Шулай да әлеге хаттан соң мин аңа үземнең берничә китабымны жибәрүне кирәк таптым. Жөмләдән «Жалованные акты» дигән, alma mater дип, туган университетыма атап, аңа багышлаган монографияне дә. Мона каршы килгән хатны да, аның соңгы мәктүбе булганы өчен, төгәл күчерәм.

*Миркасыйм!*

*Китапларын өчен һәм анда язылган фикерләрен, өчен рәхмәт сина. Мин ул китапларны беләм идем, кулыма тотып караганым бар. Теге шигырьгә alma materның килеп керүе дә синнән!*

*Синен бүләк сүзләрен өстәлгәч, алар минем өчен икеләтә кадерлеләр.*

*21.X. Железноводскига китәм. Су эчәм, бәлки бераз ял да итәрмен. Санаторийның ин шәбе, аерым палата, ә үзе профсоюзларныкы түгел. Шартлар әйбәт, әмма эшләнгән (?эшләр? — М.Г.) өчен башланган әйберем юк. Бер драма әсәре башта*

*йөри. Бәлки шул борынланыр. Бик арыдым. Сырхабрак та киттем. Аны врачларга әйтмәдем, җибәрмәүләре мөмкин иде.*

*Салисәгә һәм үзенә сәламәтлек телим.*

*Нәҗар Нәҗми.*
*15.X.85*

Соңгы хаттагы alma materның телгә алынуы беркадәре искәрмә сорый. Франциядә, бигрәк тә Парижда, төрле темалар хакында, шул җөмләдән тарих буенча да, әнгәмәләшкән вакытларда минем китапларым телгә алынуын хәтерләмим. Димәк, Нәҗар агай Уфага кайткач кына «Жалованные акты»ны, үзе әйтмешли, «тотып караган», шуның нәтиҗәсендә әлеге латин гыйбарәсе шигырьгә кергәнгә охшый.

«Париж өстендә» шигыренең язылу тарихы сыйфатында матбугатта ике төрле дата: 1984 һәм 1987 еллар күрсәтелә. Хатлардан күренгәнчә, ул 1985 елда тәмамланган булса кирәк. Шагыйрьнең «Татар каны» (Уфа, 1997) дигән китабындагы «1984» датасы, ихтимал, аның языла башлавына, яки сәфәр-сәяхәт вакытына ишарә булса, «1987» дигән ел әсәрнең Казанда («Казан утлары»нда) басылуы нәтиҗәседер. Димәк, шагыйрьнең иҗади хронологиясен төзегәндә, ихтыяҗ туса, әлеге шигырьнең датасын «1984-1985» дип күрсәтү дөрес булыр иде.

Ниһаять, сүзгә саран дип әйтерлек, ягъни артык сүзләргә урын бирелмәгән, мәгәр информация ягыннан конкрет эчтәлекле хатларда да Нәҗар агай Нәҗминең характер-табигатендәге төп сыйфаты — көчле рухы, ихлас илгәзәклеге тулысынча чагыла дип әйтсәм, әлләни ялгышмамдыр кебек.

***

Бу язганнарымнан күренгәнчә, ихлас табигатьле, туры сүзле олуг шагыйребез, шул ихласлыгы, шул туры сүзлеге аркылы затлы шәхесләребезнең берсе булган Нәҗар ага Нәҗми белән якыннан дустанә аралашу бәхете миңа бик аз көннәр дәвамында гына насыйп булган икән. 1985 елдан мин, административ эшкә чуму аркасында, элеккечә иркенләп йөри алмадым, ягъни Уфаларга бармадым. Аның Казанга килүләре дә мин өйдә юк чакларга туры килгән иде. Ягъни башка күрешергә насыйп булмады. Кичерешләр, хисләр янармагач, хатлашуларга да сәбәп табылмады...

Нәҗар агаебыз галәти көнкүреш, көндәлек эш-хезмәт, тормыш мәшәкатьләре шартларында нindирәк булгандыр, үзен ничекләр тоткандыр — мин боларны белмичә калдым. Мин аның белән гыйбрәтле сәяхәт, күңелле ял вакытында гына, күтәренке күңел белән көлеп-шаярып йөргәндә генә аралаштым. Истәлегем дә шуңа күрә төрле шаярулар белән бизәлде.

Тар дөнья адәм балаларын шулай төрле көтелмәгән җирләрдә очраштырып таныштырса да, аларның сукмак-юлларының гаҗәп күплеге еш кына шул юлларны кисештерми дә икән. Шагыйрь әйтмешли, «язмышка язмыш туры килеп, бер үк сулышта» булсак та...

Әмма ләкин Франция, Авиньон, Парижлар искә төшкән саен, күз алдына куе, калын чәчле зур башын артка чөеп җибәреп, шаркылдап көлүче Нәҗар агай килеп баса. Үзенчәлекле көр тавышы да гел ишетелеп торган сыман.

Ул бүләк иткән күңелле мизгелләр, аның еллар тәэсиренә дә бирелми торган якты истәлекләре һаман хәтердә...

*2008 ел, март-апрель*

# ШУНЫҢ БЕЛӘН ШУЛ... ВОКЗАЛДАН ЯЗАМ

МЕМУАРЛАР

Газетачы хезмәтенең үз жай-тәртибе бар, биредә эш вакыты «фәлән сәгатьтән фәлән сәгатькә» дип бүленми, кайчакта чираттагы санны басмаханәгә тапшыру төнге уникеләргә кадәр сузылырга мөмкин – әйтик, көн азагына таба КПСС Үзәк Комитетының мөһим карары имзаланып, редакциягә тапшырыла икән, газетаны өр-яңабаштан биткә салырга туры килә. Ә «Комсомолка», хәтерегездә булса, көн саен чыга иде, ул атнага алты тапкыр дөнья күрде, дәрәҗәсе буенча, «Правда» һәм «Известия»дән соң, өченче саналды. Мәртәбәле Ярослав Кирилловичка көн дә редакциягә килеп утыру мәжбүри куелмый, аның шәхси планы бар, шуны эшләсә – житкән, дөрес, ул-бу була икән, редакция чакыруга ук килеп житәргә тиеш.

Мөгаен, алдагы көнне шулай төнгә кадәр эшләүләре булгандыр – мәһабәт бинаның мөхәррирләр катында бер җан әсәре дә юк, хәзер озакламый килеп тә житәрләр инде, дип уйлап, аңарчы берәр чынаяк чәй яисә каһвәдән авыз итәргә ниятләп, бер кат аска төшә ул. Ләкин лифтка якынаюга ни күзе белән күрсен: киң коридор буйлап бер төркем комсомол житәкчеләре – алар арасында ВЛКСМ Үзәк Комитетының беренче секретаре Евгений Тяжельников та бар – ана таба килә. Тяжельниковның урынбасарлары ябык ишекнең әле бер, әле икенче тоткасына үрелә – һичкем юк, бары тик Голованов кына боларга гажәпләнеп карап тора. Кул сузымы ара калгач, Тяжельников хезмәттәшләренә борыла: «Әле дә ярый бирегә иртәнге якта сугылып чыгарга иттек, хәзер кемнең үз эшен яратуын, газетага тулаем бирелүен, хезмәт дисциплинасы белән исәпләшүен белдек инде». Аннары: «Саумысез, Ярослав Кириллович! – дип, Головановны кысып кочаклап ала да дулкынланып дәвам итә: – Мәкаләләрегезне, китапларыгызны бөтен Үзәк Комитет белән яратып укыйбыз. Без сезне болай да ихтирам итә идек инде, моннан соң икеләтә... юк, өчләтә ихтирам итәчәкбез! Кирәк вакытта – теләсә кайчан – минем янга килешүсез-нисез, алдан сөйләшмичә дә керә аласыз, «Комсомолка»да кемнең эш аты икәнен белеп китәбез».

Ярослав Кириллович сөйләвенчә, шаркылдап көлеп җибәрүдән чак тыелып, күзен дә йоммыйча тып-тын басып тора ул – озак еллар махсус хәбәрче булып эшләү дәверендә беренче тапкыр иртәдән үк эшкә кил дә, шунын кадәр түрә уратып алып мактасын әле үзеңне!

Бу вакыйганы Ярослав Кириллович болай дип тәмамлады: «Матбугатка кагылышлы һәрбер жыелышта, ә республикаларда ВЛКСМ Үзәк Комитеты карамагында газета-журналлар шактый иде, Тяжельников һәрвакыт «Комсомолка»ны мактап, башкала газетасын үрнәк итеп күрсәткән, минем эш сөючәнлегемә һәрдаим басым ясаган һәм барлык журналистларга миннән үрнәк алырга кушкан».

Бу кызыклы вакыйганы әлеге шәхеснең зурлыгы турында күзаллавыгыз мөмкин кадәр төгәлрәк булсын өчен генә бәян итеп киттем. Менә шушы кеше көннәрдән бер көнне Малеевкада... рулетка уенына нигез салды да инде. Әле кайчан диген – Василий Аксёнов тарафыннан тудырылып, Гаребтә басылганнан соң күпме шау-шу,

---

*Дәвамы. Башы 7нче санда.*

ызгыш-талаш уяткан «Метрополь» альманахы чыккан көннәр иде бит! Сүз уңаеннан, легендар басманың ике авторына кагылган күп кенә күңелсез вакыйгаларның шаһите булдык без — шушы кышкы айларны Инна Львовна Лиснянская белән Семён Израилевич Липкин Ижат йортында уздырды. Алар төп корпусның беренче катында, миннән бер бүлмә аша гына яши иде. Мөгаен, Мәскәүдән Малеевкага ике атна буе бертуктаусыз килеп-китеп торган кара «Волга»ларны миннән тыш та күпләр күреп, исендә калдыргандыр. Сонрак мина тугыз ел дәвамында Переделкинода алар белән янәшә торырга туры килде, без бик якыннан аралаша идек. Семён Израилевич татар классиклары — Муса Җәлил, Хәсән Туфаннар турында күп сөйләде мина, күземне ачты, баксаң, алар сугышка кадәр, утызынчы еллар азагында ук аралаша башлаганнар икән. С.И. Липкин иҗатларын урысчага тәрҗемә иткән. Татарның төп эпосы «Идегәй»нен дә Семён Израилевич тәрҗемәсе аша кырыгынчы елларда ук урыс телле укучыларга барып җиткәнен искә алыйк; әсәргә, дөрес, шунда ук «милләтчелек» ярлыгы тагыла һәм ул озак елларга тыелган әдәбият киштәсенә менеп кунаклый...

«Комсомолка»ның махсус хәбәрчесе Парижда күчтәнәчләр җыя, аны гаиләсенә, дусларына тарата, Малеевканы якын күргәнгәме, безне, малеевкачыларны да онытмый...

Малеевкага аяк атлавының беренче көнендә үк (кино башланырга күп вакыт калмаган иде инде) Голованов шагыйрь Виктор Гофман белән мине чакырып алды да, көтелмәгән яңалыгын әйтеп артка утыртты:

— Мин иртәгә биредә казино ачсам, каршы булмассызмы?

Тормыш сөючән Головановтан, аның иксез-чиксез, галәми фантазиясеннән теләсә нәрсә көтәргә мөмкин иде, әмма легендар Генрих Сапгир яшәгән иң ерак коттеджда рулетка уйнау... бусы да була алырмы икәнни?! Без, дөресен генә әйткәндә, югалып калдык, гәрчә провокация турында башка килеп карамады — андый кеше түгел иде Ярослав Кириллович. Ул, телебезне йотканны күреп, хәйләкәр елмайды:

— Тыелган уеннар уйнар өчен яшь каләм ияләренең кавырсыны нгымаган, ахры, әле?

Аның бу сүзләре кайнар ялкын сыман җанны өтеп алды — ирексездән, әтәчләнә башладык:

— Алай ук рәнҗетмәгез инде, теләсә кайчан уйнарга риза, әмма без, караңгы халык, сезнен кебек Парижлар белән Лас-Вегасларда йөрмибез бит, кем өйрәтер соң?

Шатлыгы йөзенә чыккан Головановның көлүе күкне ярды:

— Мин тагын, Малеевкага Лубянканың кара машиналары ешлагач, шыр җибәрдегезме әллә, дип шикләнгән идем инде, бу тиктормаслар да куркып калгач, бетте, янды барлык хыялларым, дип тә уйлап куйдым. Ә уен кагыйдәләренә килгәндә... бернәрсәсе юк аның, иртәгә минем бүлмәдә җыелгач, барыгызга да берьюлы аңлатып бетерермен.

Язучыларны кино залына дәшкән соңгы кыңгырау шалтырауга:

— Теләсәгез, тагын бер-ике дустыгызны иярт ә аласыз, үзем дә премьерага берничә кеше чакырдым, — диде дә, аска йөгереп төшеп китте — ул кино карарга җыенмый иде. Фильм караганнан сон туган искитмәле хис-кичерешләрдән, иртәгә буласы рулетка уенынннан, кинодагы исерткеч күренешләрдән әсәрләнеп, кичен бүлмәмә кереп киткәч тә, язу өстәленә утыра алмадым (гәрчә иртән язган биш бит материалны тагын бер карап чыгарга ниятләгән идем) — минем кешеләр янына чыгасым, алар белән аралашасым килде.

Ул гыйнвар киче хәтеремдә гомерлеккә сакланып калды: йомшак кына, ялкау гына — нәкъ кинодагыча! — ябалак кар төшә, мондый вакытта ысылдап-ысылдап алырга яраткан төньяк җиле дә тавыш-тын чыгармый; сукмаклар, аллеяләр, коттеджларга илткән юллар кырып себерелгән гүя — чип-чиста, баганаларда янган ут яктырып узган-киткән кешене сәламли. Ул вакытта электрны экономияләү турында уйлау да юк! Ә бит, баксаң, сонрак ачыкланганча, без шып-шыр торгынлык заманында яшәгәнбез икән... Баш очында, кино режиссёрының тылсымымыни,

салкыннан туңып-туңып алган алмаз йолдызларны янәшәсенә җыеп, тун-тулы ай балкый...

Иннәренә кар яткан зәңгәр күлмәкле чыршы янында басып торганда, кемдер мина дәште. Башымны күтәрүгә, баскычтан төшеп килүче Игорь Волгинны күреп алдым, йөзенә чыккан куанычына, елмаюына карап фикер йөртсән, көне уңган булырга охшый, яхшы гына язгандыр бүген, мөгаен, дип уйладым. Бөтен дөньяны онытып, кыза-кыза, «дошман дулкыннары»нда бүген Борис Парамонов чыгыш ясавын, тапшыруында бернечә нәрсәне аңлап бетермәвемне сөйләргә тотындым мин, башымда туган һәрбер сорауны аңа юлладым һәм шул арада ук тирән, төпле җаваплар ишетүдән әсәрләнеп калдым — шулкадәр белемле икән ул лабаса, гыйлеменен чиге юк, ирексездән аңа өлкән кешегә — абыйга караган кебек карый башладым, дөрес, бу ихтирамым Мостай Кәрим дәрәҗәсенә җитмәде — анысы алдында туфрак булып ятарга әзер идем.

Хушлашыр алдыннан гына Головановның тәкъдиме турында искә төшердем мин, һәм бу чараның аны кызыксындыра алуына тамчы да ышанмыйча, болай, бернинди максатсыз-нисез әйтеп салдым:

— Игорь, иртәгә рулетка уйнарга барасың килмиме?

Шаяртып әйтәм дип аңлады булса кирәк, бераз мыскыллырак тавыш белән:

— Рулетка уйнарга? Ә казино кайда, Глуховодамы? — дип сорады.

Мина Ярослав Кирилловичның ни-нәрсә кылырга уйлап торганын тәфсилләп сөйләп чыгарга туры килде.

— Голованов? Алайса, җитди нәрсә инде бу... Ә ничек уйнарга җыенасыз — чынлапмы, яисә кәнфит кәгазенәме? — Волгинның табигый сакчыллыгы уянды. Ул, әлбәттә, нәрсәнең ничек икәнен шунда ук аңлап алды: гәрчә, минем кебек, «Тайванец»ның язмышына шаһитлек итмәсә дә, Инна Львовна, Семён Израилевичлар белән якыннан аралашканга, кара «Волга»лар турында да, комарлы уеннар өчен җәза бирелгәнен дә белә иде. Игорь гүя яңа гына минем баштан үткән фикерләрне чүпләп алды — яшь чагында ук зирәк иде ул.

Ялгышканымны аңлап, вәкарь белән генә:

— Фантикка уйнарга бала-чагамыни без, — дидем.

Кинәт ул туктап калды, аннары, күзендә азарт очкыннары кабындымы, бик кызыксынып тагын бер мина күз ташлады да:

— Шәп фикер бу! — диде. Мин аннан мондый сүз ишетергә мәңге әзер түгел идем. — Рулетка, тәрәзә артындагы кышкы төн, тычкан уты да төшмәслек итеп капланган пәрдәләр, ишеккә «пароль» шакып керү, куелган акчалар, азарт, җиңү, җинелү, гаҗәпләнү, ачыргалану, өметләрнең җимерелеп төшүе, җинел табыш! Кызык, бик кызык фикер!

Мондый хәлләр бик җентекләп язган пьесаларда гына кабатланырга мөмкин, шушы вакытта аның күз алдына монарчы җиде кат йозакта сакланган дөнья килеп баскан, бу дөнья аның җанын күптән алгысытып, кытыклап торган булырга тиеш — ләкин боларның барысын да мин соңрак - өч елдан соң гына белдем әле.

Шулай хушлаштык. Мин артыма борылып карадым — баганадагы утлар сүнгән инде, хәтта ай да — төн хуҗасы — бердәнбер болытны мендәр итеп йокыга талган, Малеевканың тыныч аллеяләрендә беркемнең дә аяк тавышы ишетелми. Шулкадәр матур көн тәмам иде.

Иртәгәсен кичке аштан соң, Игорь белән Голованов яшәгән йортка юл тоттык. Без килеп кергәндә рулетканың исе дә чыкмаган иде әле. Унлап минут үттеме икән — Гофман пәйда булды, аңа заманында бик популяр язучы Пётр Проскуринның улы ияргән иде. Без Игорь белән бер-беребезгә карашып утырган арада яшь егет тумбочканың почмагында виски шешәсе белән бернечә кырлы стакан күреп алды — ни гаҗәп, мондый савыт дингез артыннан килгән эчемлеккә килешә иде — бу да, күрәсең, Кириллычтан күчтәнәч булгандыр. Ул вакытта виски товарны валютага гына биргән «Берёзка» кибетеннән кала беркайда да сатылмый иде. Яшь кунак, сый-нигъмәтнең бүгенге уенчылар өчен хәзерләнгәнен аңлап алып, шунда ук аның бөкесен борып чыгарды, кәгазендәге язуны күреп: «О, «Баллантайн!» — дип куанырга онытмады, хәтта сикереп тә куйды бугай әле, аннары, җинел, йомшак кына итеп

— оста бармен, диярсең! — савытларга бүлде дә безгә сузды. Мөгаен, әлеге эчемлекне тәү кат күрүе түгелдер — әтисе Пётр Лукич чит илләрдә еш басыла иде — табигый ки, «Берёзка»лардан да еш һәм мул файдалангандыр алар. Игорь минем колагыма пышылдарга ашыкты: «Бу бала өметле күренә, үз-үзен ничек иркен, рәхәт, тыныч хис итә... Ә син торараш булып каткансың!»

Озакламый Голованов пәйда булды. Безнең тарафтан бүлмә уртасына этелеп куелган өстәлгә ике зур яссы жинел тартманы ташлады гына, чыннан да, алданрак Игорь әйткәнчә, ишеккә кемдер шартлы рәвештә шакый башлады, хужа кеше кунакларны каршы алырга чыккан арада Игорь тәрәзә пәрдәсен тагын да ныграк тартып куйды.

Кара «Волга»да килгән дүрт ир-ат безнең күршеләр икән — икесе Рузадагы Кинематографчылар Ижат йортында, икесе — Композиторлар Ижат йортында яшәп ята. Без моңарчы еш кына аларның шәрабханәсенә сугылгаладык — ул, ялгышмасам, тәүлек буе эшли иде, урман буйлап турыга өч чакрым юл үтәсе — ләкин яшь вакытта бу ара сизелмәде, билгеле. Композиторлар, киночылар йортларында тәртипләр бездәге кебек катгый булмады — Домбай яисә Чегеттәге кышкы курортлар диярсең, анда яшәүчеләр безгә сирәк килде — берәр таныш-белешен күрергә яисә кино, театр өчен кирәк кешене табар өчен генә кереп чыккалыйлар иде.

Голованов кунакларга чишенергә булышты, кыйммәтле-кыйммәтле итальян һәм француз кайры туннарын аптырамыйча гына үзенең идәндә аунаган сары могжизасы өстенә ыргытты — мондый затлы киемнәр дә күпләрдә көнчелек хисе уята иде, аннары, һәммәбез турында жылы сүзләр әйтеп, үзара таныштырып чыкты. Ике тартма өстәлгә бушатылды һәм күз алдында юк урында кечкенәрәк рулетка барлыкка килде, дөрес, чынында гранит булырга тиеш урыннар — пластмассадан ясалган, ә Манчестердан кайтарылган яшел кыйммәтле тукыманы шундый ук төстәге калын картон алыштырган иде.

Киночылар белән көйчеләр уенның кагыйдәләреннән хәбәрдар иде, шуңа күрә Ярослав Кириллович «ликбез» уздырган арада алар, тәмәке тартып керәбез, дип коридорга юл тотты — бу гамәлләре, дөрес тоеп алган булсам, Головановның канәгатьсезлеген уятты. Ярослав Кириллович калганнарга ун минут дәвамында уенны аңлатты, кагыйдәләр жинел, аңлаешлы, бәхәсле урыннар туарга тиеш түгел кебек иде, без барыбыз да тын алмыйча тыңладык, ләкин, никадәр генә гади тоелмасын, Волгин барыбер Головановка берничә сорау сибеп атты — әйтик, теләсә кем крупье була аламы? Хужа кеше андый хәл көтмәгән иде, ахры, гажәпләнеп Игорьга текәлеп торды да: «Юк, теләсә кем түгел», — дип жаваплады. Аннары, бераз тынлык саклаганнан соң, тагын тезеп китте: «Чын казинода клиентның отышы өчен крупье түгел, ә оешманың хужасы жаваплы. Безнең очракта оешма хужасы вазифасын да крупье башкара, шуңа күрә ул, жиңүчегә тиешле сумманы түләү мөмкинлеген тәэмин итә алыр өчен, акчалы кеше булырга тиеш. Дөресен әйтергә кирәк: крупьега бәхет сирәк елмая. Галәттә уенчылар бер-берсен ота яисә бер-берсенә оттыра. Аның каравы, жиңүчегә биреләсе акча житәрлек түгел икән, калганын крупье үз кесәсеннән өсти, ә уенчыларның күпчелеге жиңелсә, куелган акча оешмага, ягъни мәсәлән, бу очракта — крупьега күчә. Бүген, башлап жибәрер өчен, әлеге вазифаны мин үтәрмен, бер позиция өчен куелган ставканың бәясе егерме тиеннән артмаска тиеш дип килешәбез, чөнки позицияләр күп булачак. Шыр ялангач калып, банкротка чыкмаган очракта, мин киләсе уенда да крупьелыкка дәгъва кылырга мөмкинмен, тискәре шартларда — башка кешегә, арагыздан берәүгә, мине алыштырырга туры киләчәк». Голованов өстәл янына кире жыелышкан киночылар белән көйчеләргә сынаулы караш ташлады — болар, ахры, бик хәлле затлар иде, кесәләрендә жилләр уйнамыйдыр...

Бер минуттан соң Ярослав Кириллович мажордом тавышы чыгарып: «Господа, ставка ясагыз», — дип игълан итте да уен башланып китте.

Валлаһи, «господа» сүзе минем колагымны ярып керде, сез ул елларда «господа»лы уйнауның, хәтта чынлап булмаса да, ни дәрәжәдә куркыныч икәнлеген күз алдына да китерә алмыйсыз. Безнең очрак турында әйтмим дә инде... Ул-бу килеп чыкса, мөгаен, монда Головановны да бернинди танышлыгы-белешлеге коткарып калмас

иде, Русиядә вакытыннан иртә онытылган гыйбарә раслаганча, күп нәрсәгә ирешкән кешедән күбрәк сорала да. Үземнең эшче-крестьян чыгышым белән анык тойдым мин – «господа» сүзе, чыннан да, нинди генә контекстта бирелмәсен, идарәне кулларында ныклап тоткан коммунистик режим белән идеологик яктан һичничек тәңгәл килә алмый иде.

Рулетканың тамашалылыгы җәлеп итте, Голованов артыннан күзәтү үзе кызык иде – ул, туры килгән номерны атауга ук, бер мизгел эчендә, чын крупье диярсең, житез генә, тиз, ишарәләр кылып, озын көрәкчегә ярдәмендә фишкаларны җинелгәннәрдән алып җинүчеләргә этеп китерә иде, һәм һәр юлы яңача, кәтелмәгәнчә – нәкъ артист инде менә! – эшләде ул моны. Ә фишкалар тукымада, ягъни, дөресрәге, картонда калса, аларны шаярып-көлеп, берәр фәлсәфи җөмлә дә кыстырып җибәргән булып, үзенә тартып ала иде. Рулетканың «хуҗасы» шулкадәр оста кылана иде ки, тәнәфестә, вискиның төбенә төшеп килгән чакта, яшь Проскурин Игорь белән мина дусларча гына әйтеп ташлады: «Ярослав чит илләрдән кайтып керми, чит телләр белә, сәләтле... Шикләнеп тә куям: Монте-Карло яисә Лас-Вегаста крупье булып та эшләштергәләмиме икән бу? Тикшерергә кирәк әле». Без Игорь белән кабат бер-беребезгә караштык – егет, чыннан да, бик игътибарлы һәм куркусыз иде.

Халык тиз арада уенның тәмен тоеп алды: кемдер ике-өч, кемдер – биш, яисә аннан да күбрәк позициягә куя башлады, ә Проскурин, гомумән, артык уйлап-нитеп тормыйча гына фишкаларын теләсә кайсы буш урынга сибәргә тотынды – әллә ни җинмәде дә, җинелмәде дә. Хәер, чираттагы тәнәфестән соң ана да бәхет елмайды үзе: шулкадәр аз акча куеп та, ярыйсы гына уныш алуга иреште. Җинелеп баручы киночылар белән көйчеләр, крупьеның күзгә күренеп «баеганын» абайлап, ставкаларны берәр сумнан ясыйк, дип тә карадылар – әмма Голованов әүвәл әйткән сүзеннән чигенмәде, уен четерекле өлешенә көчеп килә иде: вак-вак тәнәфесләр ешайды, кемдер тәмәке пыскытырга бүленгәләде, чөнки Голованов, үзе «төтен суырмагач», эш кабинетында (бүлмәсен шулай дип атый иде ул) һичкемгә тартырга рөхсәт бирмәде, калганнарыбыз дусларча эчкәләп-капкалап утырды. Руза кунаклары буш кул белән килмәгән: ике яна озын шешә «Столичная» аракысы һәм кабымлык – калай савытта килограмм ярымлык искитмәле югослав ветчинасы, авырлыгы килограммнан ким булмаган, кисәкле-кисәкле, чи килеш ысланган колбаса (ул вакытта мондый затлы ризык фәкать рестораннарда һәм махсус кибетләрдә генә сатыла иде), шулай ук киселгән һәм юка махсус кәгазьгә төрелгән нинлидер дингез арты сыры алганнар иде. Мондый патшалар табынына күз ташлаганнан соң Игорь минем колакка иелде: «Боларның буфеты яхшырак сыман».

Кыскасы, премьера матур гына башланып матур гына дәвам итте, һичкемдә кайтып китү теләге тумады. Чираттагы тәнәфестән соң, ниһаять, кунаклар Ярослав Кирилловичны үз ягына аудардылар – ставкалар берешәр сумнан ясала башлады, бу хәбәргә Проскурин аеруча куанган иде дә бит, ул хәтта кул чабып та җибәрде, әмма Голованов аны тиз үз урынына утыртты: «Бу сезгә кагылмый, яшь кеше, сез элеккечә куячаксыз». Шуннан соң студентның бар хис-кичереш-эмоцияләре шартлап чыктымыни – баксаң, анарда чеп-чи артист яшәп ята икән лә! Ләкин бу юлы Кириллыч сүзендә торды, Проскурин, үз чиратында, китәм дип никадәр генә янаса да, китмәде – калды.

**Рауль МИР-ХӘЙДӘРОВ**

*Дәвамы киләсе саннарда*

# МӘГЪНӘ

## Кем җаваплы?

Мәрхүм әдибебез Мөхәммәт Мәһдиев исән чагында Язучылар берлеге бинасының коридорында очрашкач, мине башкалардан читкә тартып, бик җитди кыяфәт белән әйтте:

— Карале, Батулла, сине Коръәнне тәрҗемә итә, дип сөйлиләр, дөресме шул?

— Дөрес, — дидем.

— Син бит гарәпчә укый да, яза да, сөйләшә дә белмисең...

— Мин Коръән аятьләренең төрекчә тәрҗемәсеннән татарчага аударам.

— Алай дөрес булырмы соң ул? — диде әдип. — Бер телдән икенчесенә «аудару» баба шулпасының шулпасы булып чыкмасмы?

— Минемчә, бик дөрес... Һәм бу шулпа шактый тәмле булачак. Инглизчә, алманча, французча язылган дөнья әдәбиятының шаһәсәрләрен без урысчадан татарчага аударабыз (французчадан — урысчага, урысчадан — татарчага, өч тел аша без шаһәсәрләр белән танышабыз, чөнки турыдан-туры төп нөсхәләрдән татарчага тәрҗемә итүчеләребез юк). Мин (Коръән аятьләренең мәгънәләрен төрекчәдән татарчага аударганымда) ике тел белән генә эш итәм. Гарәп теле һәм төрк теле. Дөньякүләм атаклы галимнәрнең гарәпчәдән төрекчәгә тәрҗемәсен алам да төрек теленең бертуганы булган төркчәгә (татарчага) аударам.

— Бабаларыбыз Коръәнне татарчага тәрҗемә итәргә ярамый, ул гөнаһ эш, дип санаганнар. Татарда гарәп телен, Исламны тирәнтен белгән дөньякүләм атаклы галимнәр булган, аларның берсе дә Коръәнне татарчага тәрҗемә итәргә алынмаган.

— Коръәнне татарчага тәрҗемә итүнең ихтыяҗы да булмаган. Чөнки һәр укымышлы татар Коръәнне гарәпчә укый белгән. Бүген гарәпчә белүче татарлар бармак белән генә санарлык. Шулай булгач, Коръән аятьләрен татарчалаштыру — ул саваплы гамәл.

— Ногманиның шәрехләре җитмәгәнме?

— Ногманиның үз нөсхәсен бүгенге урта белемле татар укый алмый, укыса да, чирегеп аңламас иде. Кириллга аударылган нөсхәсендә ялгышлар күп, өстәмә шәрехләүләр дә аятьләрне ачыклауга түгел, бутауга китерә. Аятьләрнең татарча мәгънәләре бүгенге урта белемле татар аңларлык телдә булырга тиеш. Минем төп максатым шул.

— Синнән сорыйм әле, мин укыган нөсхәсендә: яхшылык та, яманлык та Алладан килә, дигән сүзләр бар.

— Бар андый сүзләр.

— Димәк, мин яманлык кылсам, кеше үтерсәм, алдасам, фәхеш юлда йөрсәм — мин гаепле түгел, аның гөнаһысы миңа булмаячак! Шулаймы? Димәк, Алла минем яманлык эшләячәгемне алдан ук язып куйган, нигә мин аның өчен җавап тотарга, җәһәннәмдә янарга тиеш ди?

— Алла — син яманлык кыл, дип боермый бит, Мөхәммәт ага! Алла — ирек бирүче. Ул синең алга ике юл китереп куя. Берсе — яхшылык, игелек юлы; икенчесе гөнаһлы юл, яманлык юлы. Алла сиңа бу юлдан кит, дими. Синең үзеңә сайларга куша, бүгенгечә әйтсәк, «альтернатив юл» күрсәтә. Кайсы юлдан китүне син үзең сайлыйсың: яхшылык юлыннан китсәң — син оҗмахта, яманлык юлын сайласаң, синең урының җәһәннәмдә. Аллаһы Тәгалә диалектиканы бик яхшы белә. Единство борьбы двух противоположностей ведёт к прогрессу. Капма-каршы ике якның бербөтенлеге — алгарышның нигезе. Кылган гамәлләрең өчен Алла түгел, син җавап бирергә тиеш!

Бу безнең соңгы очрашуыбыз булган икән. Шуннан ул озак тормады, бакый дөньяга күчте. Урының җәннәттән әйләсен!

Адәми зат дөньяга әшәке генә яки яхшы гына булып туа алмый. Адәми затның табигатендә (рухында, бәдәнендә) ике төрлелеккә оеткы салынган була. Әнә шул ике

*Дәвамы. Башы 7 нче санда.*

якнын берсе кешенең ихтыярый гамәлләренә күрә алга чыга, ул яки начарлык ягына күчеп, аның яхшылыгы кими бара һәм, киресенчә, яхшылык тарафына күчеп, начарлыгы кими бара. Табигатьнең үзендә бернәрсә дә начар гына, бер нәрсә дә яхшы гына була алмый. Бәндә табигате тарафыннан үзенә бирелгән әнә шул яхшылыкны, яманлыкны куллануы аркасында дөньяда яхшылык яки начарлык өскә калка. Кешенең бәдәни табигатен алып баксак, анда начарлык та, яхшылык та тигез, әмма кешенең тәрбиясе, ихтыяры, ирадәсе[1] һәм хасталыгы аркасында, теләгәненең үти алмавы яки теләгәннән артыгын кылануы сәбәпле, яманлык өскә чыга. Башкача әйтсәк, табигать кануннары куйган чикләрнең теге яки бу ягына чыкканда (хәттин ашканда, артыгын кыланганда), Яманлык чәчәк ата. Дөньяда кылынган нинди генә яманлыкларны алып карасак та, без күрербез: ул яманлыкларны кеше үзе кылган. Дөньяда өч төрле кеше яши: яман кешеләр, яхшы кешеләр, калганнары яман да түгел, яхшы да түгел, менә шулар дөньяны болгаталар инде. Яман кеше кайчан да булса бер яхшылыкка кайтыр, әмма урталыклар — яманлык белән яхшылыкны аера белмәүчеләр — кешелеккә зыянны күбрәк эшлиләр.

Мәкер, яманлык ул — артык «купайтылган яхшылык». Кешенең үзен генә сөйгәннән барлыкка килгән теләк бирәнлеккә, фахишлеккә, садистлыкка, мал җыю хасталыгына алып чыга. Хәттин[2] ашуга китерә. Мохтаҗларга ярдәм итәм, дип аларны кабалага төшерү, артта калган илләргә ярдәм итәм дип «интернациональ» гаскәрләрнең басып керүе артык купайтылган яхшылык, ягъни мәкер.

Гөнаһка алып бара торган юллар бик күп, җәннәткә юл бер генә, ди шәрык мәкале. Җәһәннәмгә, мина калса, бер генә юл алып бара. Артыгын кылану. Артыгын ашау, артыгын эчү, артыгын рәхимсез булу, артыгы белән мал туплау, комсызлык, мина гына булсын, дип яшәү. Хәттин ашу тәмугка илтә.

Мина калса, җәннәткә юллар төрле-төрле. Иң башта бүтәннәр мәнфәгате турында уйлау, мохтаҗларга ярдәм итү, үзенә кыен булса да, башкалар өчен тырышу. Кеше өлешенә кермәү. Иманлы булу.

Бәндә бәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тырыша. Бу ихтыяҗларны үтәү юлында кеше иза чигә, интегә.

Бәдән таләпләре белән артык мавыгу кешегә яшәргә комачаулый. Шуңа күрә Югары Камиллеккә ирешкән шәхесләр үзләренең бәдәни таләпләрен өлешчә генә канәгатьләндергәннәр арасында булыр.

Бәдән-тән таләпләрен икенче чиратка куеп, рухи таләпләрне беренчегә чыгарып, иман белән яшәсәң, син бәхеткә ирешерсең.

Кешене Рух Кодрәтенә барып житүдән менә нәрсәләр тоткарлый:

1. Ачу-үч; 2. курку; 3. икеләнү-шикләнү; 4. үкенү, ачыну.

Ачулы булу беркайчан да кешенең үзенә файда китерми. Үчле кеше тирәдәгеләргә дә тискәре тәэсир итә. Ачулы кеше үч алганда чама белми, арттыра, хәттин аша, җинаять кыла. Ачулы кеше ачуын гаепле кешедән генә түгел, тирә-юньдәгеләрдән дә ала. Ачулы кеше үчлекле була. Үч алуга планнар кору аның эшен тоткарлый, нервларын ашый. Ул кеше үзен эчтән кимерә, чиргә сабыша. Ачулы кеше нәзик идеяләр турында уйлый алмый. Ачулы кеше югары белем алган булса да, рухи надан була. Әнә шул наданлык аны үч караңгылыгында тота. Үчле кешенең күңел күзе сукыр була. Ачулы кеше — агулы кеше.

Курку — ачудан да зарарлырак. Курку башта кешенең үзендә генә яши, аннан соң ул тышка бәреп чыга, башкаларны да яулый, курку паникага китерә, паника тилерер дәрәҗәгә җиткезә. Кешеләр бер-берсен таптый-сыта башлый. Курку хисе ул башта хуҗасын калтырата, бу калтырау, бу тетрәнеш башкаларга да күчә. Кеше үзе уйлап чыгарган куркынычтан курка. Аның аңында барлыкка килгән курку матдиләшә һәм ул курыккан нәрсә чыннан да килеп чыга. Судан куркып, ябылып ята торган кешенең бер ләгән суга егылып төшеп тончыкканы булгалап тора, еланнан курыкканны елан чага, яшеннән курыкканны яшен суга. Курку да наданлыктан килә.

Шикчеллек тә кешенең яхшы хисләреннән түгел. Бөтен нәрсәне дә шиккә алучы кеше — тәвәккәл була алмый. Шикчел кеше көнче була, хатынын яки ирен сәбәпсезгә көнли, дусларының уңышыннан көнләшә. Гаиләсенә, җәмгыятькә бәхетсезлек алып килә. Шикчеллек белән көнләшүнең нигезе - наданлык. Ул да күңел күзенең сукыр булуыннан килә.

Үкенү-ачыну-кимсенү-мескенлек тә — наданлык галәмәте. Рухы надан кеше,

---

[1] ирадә — теләк, омтылыш.
[2] хәт — чик.

күнел күзе сукыр кеше «Сәбәп» белән «Нәтиҗә» кануннарын белми, ул гаепсезләрне гаепләргә атлыгып тора, үзенең уңышсызлыкларын бөтен кешедән күрә, бары тик үзен генә гаепләми. Үзенең уңышсызлыгын, сәләтсезлеген ул башкалардан күрә. Бу кеше Иблис ягына күчкән хаин булырга күптән әзер. Форсат чыкса, ул туганнарын, дусларын, милләтен — барысын да сатачак. Хаинлекне булдыксызлардан күт тә тор.

Әлеге сыйфатларга ия бәндәләр югары белемле булсалар да, рухи яктан надан. Алар Аллаһы Тәгаләне хурлый, кешеләр табына торганнарга көлеп, мыскыллап карый. Ләкин аларның соң язмышы фаҗига белән тәмамлана.

Бу — «Укытучыларның белемен арттыру сыйныфлары»ндагы нотыгымда сөйләнгән сүзләр. Совет заманы иде. Залда утыручыларның күбесе коммунист. Арадан бер ир укытучы торып басты да мине кыен хәлгә куярдай итеп әйтте:

— Мөселманнар да мал суя. Мөселманнар да хайваннарын сөеп үстерә дә суеп ашый. Ит ашаган бәндә миһербан турында авыз суы корытырга тиеш түгел!

Дәресханә тынып калды. Барысы да көтә иде. Сорау бирүче егет, «мин җиңдем» кыяфәте белән җавап көтеп, һаман басып тора.

— Ләкин мөселманнар, — дидем, — Аллаһ рөхсәт иткәннәрне генә ашый. Аллаһы Тәгалә әйтә: хайваннарыгыз сезгә хәләл ризык ителде, ди.

Беренче сораудан соң башкалар да кызып китте, бер хатын торып басты:

— Атаклы язучы Гариф Гобәй: «Мөхәммәд динне башкаларга кылыч белән кертте, илләрне яулап алу сәясәтен алып барды», ди. «Коръән серләре» китабын укыйлар, безнең китапханәдәге ун данәсе дә тузып бетте инде.

— Исламда дингә керергә кыстау, ирексезләү юк. Ләкүм диникүм вә лиәддиин! Сезнең үз динегез, минем үз динем!

Аллаһ Тәгалә хәтта пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салаллаһу гәләйһи вәссәламне дә кисәтә:

**Хактыр ки, Без ул Китапны (Коръәнне) инсаннарга файда булсын өчен, Хакыйкать буларак, сиңа иңдердек. Кем тугры юлга басарга ихтыяр итә, бу аның файдасына. Кем юлдан язарга тели, аның да үз зарарына булыр. Син, Мөхәммәд, аларны ирексезләп дингә кертүче вәкил түгел!**

*39 (Зүмәра) 41.*

**Ии, Мөхәммәд, син аларны дингә ирексезләүче түгелсең!**

*50 (Каф) 45.*

Дингә ирексезләү юк! Диндә көчләү юк!

Күрәсең, Аллаһ Мөхәммәдкә: син минем динемә кер димә, син үз диненне тот, мин үз динемне тотармын, дияргә куша. Ә коммунист әфәнделәр (алласызлар, дәһриләр) иманлыларга иманнарын ташларга кушалар. Алар үзләре ышанганны гына хак диләр һәм дәһриләр дистәләрчә еллар буена мәчетләрне кырып, Коръәнне утка ягып, муллаларны атып бетерделәр. Русия коммунистлары надан иде. Алар Инҗилне дә, Тәүратны да, Коръәнне дә укымаган. Дөнья фәлсәфәсенең нигез ташы булган диннәрне белмәгән коммунист чын коммунист була алмый. «Бөтен кешелек барлыкка китергән культура әсәрләрен белмәгән коммунист кешелеккә зыян салачак», диде Лениныгыз һәм зыян салдылар да.

«Дин — халык миен томалаучы әфьюн», — диде Ленин. Шуннан соң китте дин белән рәхимсез көрәш. Бу — коммунистларның иң олы хатасы иде. Нәтиҗәсе күренеп тора, Русия кире чыга алмаслык әхлаксызлык сазлыгына килеп керде.

Иң зур гөнаһ — Аллаһны инкарь итү.

Дин әхлагы, Шәригать кануннары юкка чыккач, халык аракыга чумды, фахишлеккә батты, ата-ананы кыйнау, бала үтерү кебек җинаятьләр чәчәк атты. Гаиләләр тотрыклылыгын югалтты. Уйнаштан бала табу горурлык, батырлык дәрәҗәсенә менде. Көфер сүз сөйләү, сүгенү гадәти күренешкә әверелде. Дин белән, динчеләр белән көрәшү, динне сүгү, әдәбиятта муллаларны мыскыл итү батырлык санала иде.

Әлеге ир тагын калыкты:

— Коммунистларга чаклы да динне иң беренче Тукай сүгә башлады. «Кибәк башта кибән чалма, ишан булган, имеш, хайван». Аннан соң Тинчурин тотынды ишаннарга. Дингә, Аллага ышанганнарга әче сатира башка язучыларда да бар. Без моны әдәбият дәреслекләреннән укып беләбез.

— Тукай динне сүкмәде. Динне бозучыларны сүкте. «Рамазан аенда Иблиснең шайтаннарга хитабы»нда ул әнә шундыйлар турында яза:

*Инде динне ташлыйлар,*
*Уразада ашыйлар,*
*Оялмыйча Алладан,*
*Ничек гаеп ясыйлар?*

*Барсы качып ашады,*
*«Көндез сәхәр» ясады,*
*Тәкъва, суфый байларның*
*Чиктән узды фәсады.*[3]

*Без шайтаннар богауда*
*Гомер иттек бу айда,*
*Кодрәт бавын өзәргә*
*Без шайтанда көч кайда?!*

*Без тик тордык богауда.*
*Ник аздылар бу айда?*
*Гөнаһ эшне юк файда*
*Инде безгә сылтауда.*

*«Шайтан аздырган», имеш!*
*«Юлдан яздырган», имеш!*
*Кире татар, иң элек*
*Вөҗданың берлән килеш!*

Монафикълар турында яза шагыйрь. Икейөзлеләрне әче тәнкыйтькә тота. Мөселман булып күренергә тырышып йөреп тә, асылда кяфер булганнарга нәгъръә ора. Тукай беркайчан да имансыз булмады, шөкер!

*И бәһале, и кадерле, и гөнаһсыз яшь бала!*
*Рәхмәте бик киң Аның, һәр дәм таян син Аллага!*
*Артка бакма, дәһием, идеал һаман да алда ул;*
*Алга барганнарга тик табылса табыла: Алла ул!*

*1910.*

Эйнштейнның Тукайдан күпкә соң әйткән сүзе:
**Фәнни эзләнүләрнең олуг нәтиҗәсе — Аллага ышану!**

Тинчурин да Алланы инкарь итмәде. Тукай белән Тинчурин дин житәкчесе булган надан ишаннан көлде. Дин житәкчесенең дин кануннарын бозуына каршы чыкты. Шулай итеп, Тукай да, Тинчурин да икесе дә мәдрәсә тәмамлаган, Коръәнне белүчеләр, чын мөселман буларак, динне сакларга, якларга тырышты. Менә сезнең коммунистлар партиясендә торучы коммунист Фәлән Фәләнов жинаять кылса, исереп кеше кыйнаса, фахишәләр белән тотылса, бөтен КПСС гаепле булмый бит, Фәләнов үзе өчен генә жавап тотачак. Тукай да, Тинчурин да Исламнан көлми, надан дин башлыгыннан, дин бозучы муллалардан көлә.

Ир-егет актив иде, ул тагын минем бакчага таш ыргытты:

— Бүгенге муллаларыгыз да әүлия түгел...

— Түгел, чөнки аларның күбесе надан. Наданлык бөтен яман гадәтләрнең башында тора. Надан коммунистлар бөтен яхшы йолаларны жимереп, яман йолалар таратты. Бүгенге надан муллалар да кешеләрне диннән биздерә.

Дингә тупаслык белән түгел, ягымлылык белән, миһербан белән, игелекле гамәлләр белән тартырга кирәк. Вәгазьләрендә муллалар тупас. Алар куркыту, кычкыру, кеше алдында мөштәринең[4] йөзен ертуны тәрбия дип уйлый. Аллаһ исеме белән, дин исеме белән куркыту — ул үзе гөнаһ. Аллаһ үзенә тартып торырга тиеш, куркытып түгел. Без Аллаһ каршында гөнаһ эшләүдән куркырга тиеш! Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вәссәлам үзенең сабырлыгы, ягымлылыгы белән үзенә жәлеп иткән. Сөйкемлелеге белән ул барча халыкны үз артыннан ияртә алган. Шуннан үрнәк алырга кирәк муллаларга.

Иң югары, иң бөек Гүзәллек — ул Аллаһы Тәгаләдер!

Дога кылу ул мәңгелекне тану. Гыйбадәт ул гүзәллек, тәвәккәллек, батырлык, корбан булырга әзер тору, камиллеккә омтылыш, тайпылмастан яхшы максатка бару.

Коръәннең фәлсәфәсен, аятьләрнең мәгънәсен аңлап, башкаларга да аңлата алган имамнарга ихтыяжыбыз зур. Гади мөселманга аңлашылмаган урыннарын аңлата алыр дәрәжәдә белемле хәзрәтләргә мохтаж без. Кызганыч ки, андыйлар аз. Киләчәктә булыр, иншалла.

Укытучылар белән булган мәжлес шау-шулы узды һәм бу һич тә начар түгел иде.

**БАТУЛЛА**

*Дәвамы киләсе саннарда*

---

[3] Фәсад — бозыклык.
[4] Мөштәри — йомышчы (клиент).

*Елмаю кешене яшәртә, дибез. Дамир Гыйсметдинне, гел елмаеп йөргәч, 50 яшьләр тирәсендә генә дип уйлый идек. Бактың исә ул инде 65ен тутырган икән... Үзе әйтмешли, аңа карап Иделебез ярларыннан ташып чыкмады, доллар аска тәгәрәмәде, планеталар парадка тезелмәде, инфляция туктамады. Күрәсең, сатирик язучы, популяр җырлар авторы Дамир Гыйсметдин иҗатына бу әкәмәтләрнең бөтенләй тәэсире юктыр.*

*Ярты ел үткәч: «Исәнме, кода?» – дигәндәй, ел башындагы туган көнең белән сатирикларча котлыйбыз үзеңне. Ә бу жанрның маһиры икәнеңне журнал укучыларыбыз яхшы белә...*

**Редакция**

# ХИКӘЯЛӘР

## Үкенү

Үз көенә яшәп яткан Тиктормас шәһәрендә көннәрдән бер көнне шомлы хәбәр таралды. Ул кала администрациясе хезмәткәрләрен аеруча борчуга салды. Шәһәр башлыгы — әле генә эшкә килгән Шәрәфи Хәсәнович чираттагы киңәшмәдә чиновникларның барысын да ялганлау детекторы, ягъни полиграф аша уздырылачагы хакында белдерү ясады. Бу эчке тикшеренү замана шаукымы түгел һәм берәүне дә читләтеп узмаска тиеш дигән каттый күрсәтмә дә яңгырады. Иң булдыклы, иң әрсез кешеләр шәһәр администрациясе тирәсендә тупланганга-тукланганга, мондый яңалык һәр гаиләгә кагыла иде. Әлеге детектор турында мәгълүмат биредәге халыкка Әмрикә киноларыннан гына билгеле булганга, түрәләр, интернет, энциклопедия кебек чыганакларга дәррәү ябырылдылар. Ләкин анда да күңелне тынычландыра, мәсьәләгә ачыклык кертә торган мәгълүмат табылмады. Иң мөһиме — бу четерекле гамәлнең техник ягын кем оештыра да кем уздыра? Кем моның артында тора?! Беришә хәбәрләргә караганда, детекторны башкаладан алып киләләр вә шундагы белгечләр тикшеренү дә уздырачаклар икән. Монысы инде бөтенләй хафага салды. Чүпне әле урамга да чыгарырга ниятлиләр икән...

Әлбәттә, намусы чиста кешегә теләсә нинди тикшерүләр күркәне су асты көймәсе борчыган кебек кенә дулкынландырыр иде дә... Ләкин һәр түрәнең мәслəге, яшәү рәвеше, бигрәк тә сәмән казану ысуллары бик тирән яшерелеп эчендә зур сер булып сакланганга, полиграф аша җавап тоту курку булмаса да борчу тудырды. Аңлашыла ки, түрә халкы мондый мәсьәләләрне үз агымына куеп, читтән генә корбан тәкәсе кебек күзәтеп тора алмый бит!

Шул ук кичне Тиктормас башлыгының урынбасары Мәрдән Идрисович үзенең күл буенда урнашкан өч катлы патша сараенда гайре рәсми утырыш уздырды. Көн тәртибендә бер мәсьәлә: гыйфрит машинасы аша тикшерүне узып, урындыкны саклап калу. Урынбасарның сарае, мәсәлән, законны бозып, тыюлыктагы күл буена салынган иде. Хәер, шул ук җәннәти урында башка элитный йортлар да калкып чыккан чыгуын. Ә инде полиграфның «Йортыгызны нинди акчага салдыгыз?» — дигән соравы байтак түрәләрнең йөрәк тибешен дә, температурасын да, кан басымын да берьюлы күтәрер иде. Хәтта кичке киңәшмәдә катнашкан пыркарурның да, милиция башлыгының да, ягъни канун сагында торырга тиеш әфәнде-иптәшләрнең дә күңелләре бик тыныч түгел иде. Сарай бер җайсыз сөаль булса, иномарка-джиплар хакындагылары да йөрәк тибешен салмакландыра торганнардан түгел иде, әлбәттә. Кайбер түрәләр беренче мәртәбә үзләренең кыңгыр эшләрен искә төшереп, тәүбә кылу дәрәҗәсенә килгәннәр иде. Әле бит эштәге һәм читтәге сөяркәләр, елына ике тапкыр чит илгә ялга йөрүләр өчен дә җавап тотасы бар...

Беренче мәлгә, аллауны фаш итү машинасының тикшерүен узмаска, дигән

фикер өстенлек итте. Кайсылары ГАИ башлыгы полиграфны алып килүче машинага юл казасы оештырсын, диделәр. Икенчеләре, подстанциядә кинәт электр егәрен күтәреп детекторны сафтан чыгарырга кирәк дигән мәкерле фикерне алга сөрделәр. Кеше факторын исәпкә алып эшләүче бер житәкче, килгән операторны әйбәт кенә «кунак итеп» айныткычта кундырырга һәм проблеманы тамырдан хәл итәргә дигән эшлекле тәкъдим кертте.

Бу хәлиткеч адымнар шактый радикаль булганга, Мәрдән Идрисович уйга калды. Әле бит шәһәр башлыгы бар. Ул ничек фикерлидер бит әле? Ана, әлбәттә, жинелрәк. Яна килгән кеше, әле тамыр жәймәгән, гомер бизмәнендә үзенен дә гөнаһлары бардыр барын, анысы мәгълүм түгел, ләкин Тиктормаста кылган гамәлләре полиграфтан куркырлык түгелдер. Һәрхәлдә, ришвәт белән көрәшкән була, сарай салдырырга керешмәде, иномарка әлегә алдырмады. Бу шайтан тикшерүе дә шул адәм уйлап чыгарган нәрсә түгел микән?! Акыллы кеше жилгә каршы төкерми, аптыкаем!..

Урынбасарнын бу саллы фикерен шәһәр элитасы игътибар белән тынлады. Нәтижәдә, полиграф тикшерүен узарга кирәк дигән бердәм фикергә килende.

Тикшерү көнен нинди түрәләр нинди хис-кичерешләр белән каршы алуын тәфсилләп язып тору шактый урынны алыр иде. Ин мәзәге — кайбер гаилә башлыклары, кынгыр эш кырык елдан сон да беленә дигән гыйбарәне искә алып, алдан ук хәстәрен күрергә булдылар: хатыннарына кем белән зина кылулары турында сөйләп биреп, гафу үтенделәр, башка андый гамәлләрне кылмаска тәүбә иттеләр. Кем әйтмешли, иелгән башны кылыч кисми бит!.. Хәләл жефетләренен кайсылары мондый хыянәтне кабул итмичә, никахны өзүгә хәтле барып житте. Сөяркәләр һәм законный хатыннар арасында әледән-әле низаглар, разборкалар була торды. Ләкин тормыш иптәшләренен акча таба белгән ир-ат икәнен искә алып, ханымнарнын ин горурлары да, ин әрсезләре дә гаиләләрен саклап калырга булды. Шәһәр башлыгынын кабинеты бу көннәрдә кырмыска оясы кебек гөжләде. Тәүбә кылучы түрәләр, хилаф эшләрен өлешчә танып, гаепне бер-берсенә аударып, әллә кайчан булган кынгыр эшләрне ачып салдылар. Гәрчә жылы урыннан китәргә гариза язучылар булмады. Ә инде полиграф күрсәткән нәтижәләргә килсәк, алар шаккатыргыч иде. Шәһәр администрациясендә эшләүче түрәләр детектор тикшерүен тиешенчә, ягъни уннан-сулга чайкалмыйча, иплe генә уздылар. Әлбәттә, монда түрәләргә профессиональ ихтыяр көче вә калын тиреле булу нык ярдәм итте. Көненә йөз тапкыр ялган вәгъдәләр биреп, аларны үтәмичә, күзгә карап борчак сибеп утырган чиновникка мондый «әйе», «юк»ларга жавап бирү кроссворд чишү, йә симәнке чиртү белән бер иде. Һәрхәлдә, андый сынау температурага да, кан басымына да, йөрәк тибешенә дә тәэсир итәлмәде.

Барлык хезмәткәрләр арасында себерке директоры, гафу, урам себерүче Хамматхан абзый гына ялганлау детекторы куйган сорауларнын берсенә ихластан жавап биреп, полиграф операторында шик тудырды. «Кеше милкенә кул тидергәнегез булдымы?» — дигән сорауга ул: «Әйе!» — дип жавап бирде. Бу мизгелдә Хамматхан абзыйнын кан басымы күтәрелгән, йөрәге «дөп-дөп» тибә иде. Күзләре зур кызыксыну белән янган операторга туры карап, ул тирән сулап куйды:

— Булды шул андый хәл, энем, булды! Илле еллар элек балачакта күрше Шәяхмәт бабайнын бакчасына алма урларга кереп, әйеме, карангыда ялгыш бер алмагачын сындырган идем... Гомерем буе шуна үкенеп яшим, энекәш...

## Сукыр тавык

*(Бер мәхәббәт тарихы)*

Туй машиналарына дингез тубыктан дигәндәй, шәһәр урамнары буйлап жилдертәләр. Күз иярми торган тизлек белән. Әйтерсен лә йөзләгән чакрымга бер жан иясе очрамаган чүл-сафарида ярышучы ралли-мастерлар. Тизрәк өстәл артына кунаклап чөмерергә ашыгалар, сукыр жаннар!

Инде күптән буйдак язмышын сайлаган Минһади мондый кортежларны

күргән саен әнә шулай сүгенеп кала иде. Куштаннар! Житмәсә, өйләнеп өлгермиләр, аерылыша башлыйлар! Бу юлы Минһади әллә бераз уйланып калды, әллә саксызлык күрсәтте, ә бәлкем, руль артында утыручысы ачык авыз булгандыр — туй машинасы астына эләкте. Аның күз аллары карангыланып китте... Аңына килеп, күзен ачканда, Минһади тирәсенә кешеләр жыелган иде.

Кемдер, жинел сулап:

«Аллага шөкер, исән!» — диде. Кайсысыдыр Минһадиның кулын-аягын капшап карады.

— Исән бит!.. Сезгә больномы? — Зәңгәр күзле бер матур туташ аның чәченнән сыйпады. — Аягыгызга баса аласызмы?

Якында гына бер яшь гаишник күренде. Матур хатын аны ярдәмгә чакырып, алар икәүләп Минһадины аякка бастырырга тырыштылар. Ләкин бәлагә юлыгучы, уң аягынын авыртуына чыдый алмый, «һай!» дип, янә асфальтка утырды.

— Всё, егетләр, мин калам, — диде матур хатын туй кортежыннан чыкканнарга. — Аны больницага илтергә кирәк...

Бераз тарткалашып-үгетләшеп торгач, туй кунаклары, машина ишекләрен шалт-шолт ябып, китеп тә бардылар...

Ә бәйрәмчә киенгән зәңгәр күзле туташ һәм инспектор Минһадины хастаханәгә озата киттеләр. Мондый ягымлы хатын-кызны тайпылмас буйдак гомерендә беренче тапкыр күрүе иде. Хәер, андыйлар баштарак үзләре имгәткән кешегә зур игътибар күрсәтәләр инде ул... Ә аннары — син күр дә мин күр... Беләбез без хатын-кызларны... Минһади тирәсендә бөтерелгән нәфис карлыгачның исеме Рәмзия булып чыкты.

Инде кич тә житте. ГАИ инспекторы саубуллашып китеп барды. Шәфкать туташы берничә кат өенә кайтып китәргә тәкъдим итсә дә, Рәмзия бүльнистә калды. Төне буе Минһадины саклап чыкты.

Үзе турында тәфсилләп сөйләде. Кияүдә булмаган, шәһәр кызы икән. Балалар табибәсе. Әтисе машина алып биргән, рульдә бер генә атна йөргән әле. Фатиры бар...

Ә Минһади артык шапырынмады. Хәер, мактанырлык нәрсәсе дә юк иде бит аның. Институт тәмамлап, унбиш ел буе бер урында түмгәк кебек утыра. Төзелештәге прораб. Получкадан авансыка очын-очка ялгап көн күрә. Тулай торакта бүлмәсе бар. Һәм тагын бер байлыгы — кырыкка житкән яше бар. Шулхәтле яшәп тә чын-чынлап хатын-кыз жылысын, йомшак кочак, татлы ирен тәмен тоймаган ир сыныгы. Бер-ике тапкыр хатын-кыз тарафыннан нык алданып, төп башына утыргач, Минһади аларга ут сүндерүче пожарга караган кебек бага башлады.

Соңгысы Нажия булды. Бергә эшләп, дуслашып йөрделәр. Эш өйләнүгә борыла башлагач, Нажия чыгымчы бия кебек тәртәгә типте... Имеш, фатирың юк, машинаң да булырга охшамаган... Китте. Менә шул көннән бикләде дә инде Минһади йөрәген. Всё! Әнә, бар Азат дусты, Самат якташы. Житкән. Вакытны да кызык уздыралар. Йә балыкка ычкыналар, йә ауга. Кайчак авылга кайтып китәләр. Язмаган тек язмаган инде...

Шулай да табигать дигән нәрсәкәй үжәтләнеп үзенекен ала, ахрысы. Рәмзиянең атна буе үз баласын караган кебек яныннан китмичә бүльнистә утыруы Минһадиның хатын-кызларга булган бозлы карашын бераз эретә башлады. Күрәсең, барсы да бер себерке белән куылмаган болар. Кырык елга бер жүнлесе дә очрап куярга мөмкиндер инде...

Күп тә үтмәде, Минһади аякка басты. Һәм бу, әлбәттә, аның күңеленә кереп оялаган Рәмзия ярдәме белән булды. Кыскасы, аның бозланып каткан күңеленә беренче тапкыр яз килде. Һәм аны бердәнбер карлыгач китерде...

Син мәхәббәттән качасың, аны юк, ул пүчтәк дип кул селкеп, йөрәк клапаннарына йозак эләсең, сөюне тормышның башка гүзәллекләренә алыштырырга тырышасың. Ә ул, үч иткәндәй, киресен эшли. Бер билгесез көч синең дөньяңның астын-өскә китерә башлый. Алай да аңламыйсың икән — машина астына ташлый. Теләсәң ничек очраштыра. Нәтиҗәдә кулыңны

күтәрәсен. Рәхәт жинелүдер ул! Кемнендер сине иртәнге жылы жил кебек назлавы, тирән мәгънәле сүзләре, күнелне жилкендереп алган серле карашлары, өмет индерә торган елмаюлары... Дөнья матур, дөнья кин икән ул!

Кайбер баллы-майлы сюжетлы хикәя укырга яратучылар шушы урында: «Барысы да аңлашыла», — дип, бу язманы диварга ябыштырыла торган кәгазь өеменә ташларга теләр. Ашыкмагыз, жәмәгать!

Инде тәмам мәхәббәтнен барлыгына ышанган, иннәренә көчле канатлар үсеп чыккан Минһади буйдаклыктан ваз кичәргә ниятләп йөргән чакта кинәт... Ах, бу кинәтләр... Тормыш кинәтләрдән тора шул, агайне.

Эшләр жайлы гына тәгәрәгәндә, офыкта кинәт Нажия пәйда булды. Ул башкага чыгып, Лаеш шулпасын байтак чөмергән икән. Һәм дөньяны аңлаган. Бер кичне башын иеп, Минһади хозурына килеп гафу үтенде, үзенең нинди михнәтләр күрүен тәфсилләп сөйләде. Кулъяулык чылатты. Тел төбе шул иде: әйдә, дустым, искене онытып, яңадан башлыйк. Минһади мондый борылышка бөтенләй әзер түгел иде. Шуна да ул яшереп-нитеп тормады:

— Ә мин бит башканы яратам, Нажия... Соң инде...

Нажия Минһадинын муенына килеп асылынды.

— Юк, юк, мин сине беркемгә дә бирмим!

Шулчак Нажия яшьле күзләре белән телевизор өстендә торган зур төсле рәсемне күреп алды. Ул кинәт үзгәреп китте.

— Ничек?! Рәмзия! Шулмы жанкисәгең?!

Минһади Нажияне кәнәфигә утыртты.

— Әйе, әйе, Рәмзия. Без тиздән өйләнешәчәкбез. Ул бик яхшы кеше...

Нажия кинәт шаркылдап көлеп жибәрде:

— Кем, Рәмзияме? Син беләсенме соң анын ничәнче ире булачагынны?

— Беләм. Беренчесе!

— Һай, кеше көлдермә, Минһади. Мин белгәне генә өчәү иде...

Минһадинын өстенә бер мичкә кайнар су аудардылар диярсен!

— Ул әле... ни дә бит... табибә...

Нажия әңгәмәдәшенең сүзен шундук бүлдерде.

— Нинди табибә! Өстерәлчек! Без бер тулай торакта тордык. Штукатур ич ул! Анын йөрмәгән егете калмады. Әйтмәсәм әйтим: фахишәлектә акча эшләп баеган чикерткә бит ул!..

Минһадинын өстенә бу юлысы бер мичкә бозлы су коелгандай булды.

— Житте! — дия алды ул, актык көчен жыеп. — Житте! Алайса, берегез дә кирәкми!.. Әнә бусага!

Шушы урында кайбер нервылары какшаган түземсез укучылар тагын ошбу әсәрне читкә ташларга жыеныр... Бер генә минут! Кинәт... һай бу тормыш шул көтелмәгән кинәтләрдән тора да инде ул!

Минһади пыш-пыш тәмәке тартып, бүлмә буйлап арлы-бирле йөргәндә тәрәзә каршына кинәт машина килеп туктады.

«Рәмзия!» — дип уйлады Минһади һәм тиз генә тәмәкесен сүндерде. Ул арада ишектә кыңгырау шалтырады.

Бүлмәдә әйтерсен лә якты кояш балкып алды, бусагадан шомырт исләре аңкып яз керде.

— Хәлләрегез ничек, Минһади абый? Шөкер Аллага, савыккансыз икән! — Рәмзия жавап көтеп тормый дәвам итте. — Мин сезгә Радик белән икебездән туебызга чакыру китердем. Килегез инде, яме? Сезнең аркада танышкан идек бит. Әнә теге чакта. Гаишник ул... Йә ярый, китәбез...

Ишектәге кояш тәгәрәп чыгып та китте. Бүлмә янә сорыланып, карангыланып калды. Рәмзияне бары тик шомырт исләре генә хәтерләтә иде.

«Сукыр тавык икән мин!» Әнә шундый фикер Минһадинын азапланган күнелен чәнчеп узды. Һәм ул авторга шушы әсәрнең исемен куярга ярдәм дә итте...

**Дамир ГЫЙСМЕТДИН**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Һади ТАКТАШ**

## Сандугач сайрауларына рецензия

Без шагыйрьләрне начар жырлары өчен эт итеп сүгәбез: моның өчен диалектика материализмы белән яки турыдан-туры күсәк белән коралланган тәнкыйтьчеләребез бар.

Ләкин жыр фронтында дөньяда хәзергә кадәр һичбер кузгатылмаган, һичбер кул тимәгән урын бар.

Татарстанда зур-зур урманнар, матур-матур елгалар бар. Шул урманнарда, елга буйларында сайраучы меңнәрчә сандугачлар бар.

Алар жәй буена су буйларындагы әрәмәлекләрдә, урманнарда жырлар сочинять итеп яталар һәм, редактордан һичбер рөхсәт алмый торып, шул сочинять иткән жырларын жырлый бирәләр.

Әле бер генә тәнкыйтьчебез дә аларның жырларына тәнкыйть, рецензия биргәне юк. Ул жырларның идеология яклары һичбер тикшерелгәне юк.

Бу йонлы колак, канатлы урман шагыйрьләре бәлки буржуа жырын жырлый торганнардыр. Алар бәлки төрек, гарәп илләреннән Татарстанга кайтып пантюркизм жырларын жырлап, үзләренең идеяләре белән массаны сугарырга маташа торганнардыр...

Берничә факт алыйк.

Борнаев солтангалиевчә кебек кайбер кешеләр партия директиваларын үтәргә дип авылларга, сыйнфый көрәшнең кызган бер урынына жибәреләләр. Ләкин алар урман араларында, күл буйларында йөреп, сандугачларның жырларын тыңлап, шуңа исереп, сыйнфый көрәшне бөтенләй онытып кайталар.

Специально сандугачлар тавышын тыңларга дачага чыгучы Тарпищев (Тарпищев Хөсәен. 1884-1943. Дәүләт эшлеклесе) кебек кешеләргә сандугачларның тәэсире тагын да зуррак була.

Алар шул әрәмәлекләрдә сайраучы сандугачларның тавышларын тыңлый-тыңлый теория чыгаралар.

— Татарстанда матур елгалар бар.

— Татарстанда гөлгә күмелгән урманнар үсә.

Ул матур урманнарда моңлы итеп сандугачлар сайрый, аларның тынычлыкларын бозучы якын-тирәдә сыйнфый көрәш тә юк.

Шундый матур илдән аерып, Татарстан колхозчыларын социализм төзим дип ничек итеп Донбасс кебек ерак илләргә жибәрәсең?

Татарларны үзләренең жәннәт кебек матур илләреннән ничек итеп урыс-улак арасына олактырасың?

Сандугачлар йогынтысының никадәр тирән булуын бу теорияләрдән бик яхшы аңлап була.

Бигрәк тә Тарпищевнең кайчандыр «сул» булып йөрүләрен, аның 22 нче елларда шул ук Донбасс эшчеләре арасында «суллар» сүзләре астында русификация теориясен таратып йөрүләрен искә алганда, бу бигрәк тә ачык булып күз алдына килеп баса.

Дөрес, Татарстанда матур урманнар да бар.

Гөлгә күмелгән әрәмәлекләр дә бар.

Сандугачлар да сайрый.

Татарстан эшче-колхозчылары, партиянең социализм төзелеше өчен көрәшкә чакыру тавышын ишетү белән:

— Матур урманнарны да, сандугачлар тавышын да онытып, Донбасска, күмер фронтына 11 мең эшче бирделәр.

Вокзалда социализм төзү фронтына ирекле рәвештә Донбасска баручы 420 кешелек яна бер эшелон туктаган.

Оркестр вокзалны янгыратып пролетариатның бөек маршын уйный.

Бу марш «сандугачлар» жырын күмә.

Эшелондагы шахтёрларның йөрәкләре бу чакыруга җавап бирәләр:

*«Без — ударниклар, тауны тишәрбез,*
*Күмер пластларын без — ишәрбез.*
*Күмердә булган бишьеллык планны*
*Дүрт елда арттырып без үтәрбез».*

*1931*

**Мөхәммәд МӘҺДИЕВ**

## Көндәлектән

1980, август. Нукус-Каракалпакстанда йөрибез. Габдулла Шамуков белән бер машинада... Шамуков тәгәри-тәгәри көлә. Минем «Әйдә барыйк, кызлар карыйк» дигән язмамда «Бетховен һәм Казиле Зариф» дигән бүлек бар. Шамуков тәгәри: «Разница бик зур бит, каһәр», — ди.

***

Укытучы бер малайны сүгә рус теле дәресендә:

— Ну что стоишь, отвечай, что стоишь?

— Стойса ни.. (торса ни дигәнне әйтә).

***

Сугыш вакытында кыш көне врачлар килеп бөтен мәктәп баласына нинди дер бер кызгылт таблетка йоттырдылар. Ике көн буе авыл арасындагы кар өсте кызыл хәрефләр, фамилияләр белән чуарланып торды.

***

Бәләкәй малай солдаттагы абыйсына хат яза: «Сыер буаз, ала каз күкәй сала башлады, абзар түбәсен көрәдек, сыерчыклар килергә тиеш...» Иң ахырда: «Түтәй, кияүгә бармыйча гына, бала тапты...»

***

Берәү хат яза: «Фәлән көнне, фәлән поезд белән син мине каршы ал, сина кунакка киләм», — ди.

Тегесе җавап бирә:

— Сине каршы ала алмыйм, үземнең энекәшне җибәрәм, ул сине кулындагы каз түшкәсе буенча таныр, — ди.

***

Колхоз председателе әйтә:

— Үз хатының янында әтәчләнеп булмый, чөнки синең бөтен кимчелегеңне белүче кеше бу дөньяда бары ул гына.

Гамил АФЗАЛ

## Казан шагыйрьләре

Син гади Гаффар,
Мин гади Саттармын.
Син мине якла,
Мин сине якларамын.
Син мине макта,
Мин сине мактармын:
Син — даһи Гаффар,
Мин — даһи Саттармын.

***

Кешеләрдән, сүздән, эштән туеп,
Өстәленә кәгазь, каләм куеп,
Эшлекле кыяфәт чыгарып чырайга,
Кабинет саклый ул, Шөкер Ходайга.

Туфан МИҢНУЛЛИН

## Нәбирә Гыйматдиновага

Язучы дигән исемне алыр өчен,
Ходай безгә бүләк иткән гомер житми:
Бер бетәшкән хикәяне яза-яза,
Миләр кайный, бәгырь корый, күзләр бетли.
Без интеккән әдәбият фронтында,
Ничек димсең жинү яулый бу Нәбирә?
Чөнки ана повестьларын, төн утырып,
Багучылар, сихерчеләр язып бирә.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

# МӘКАЛЬ ӨМӘСЕ

*Татар халкы гел мәкальләргә таянып яшәгән. Үзе чыгарган мәкальләргә. Юк, халык үк чыгармаган инде аларны, аерым кешеләр чыгарган, халык исә шомарткан-иләгән, кешедән-кешегә, буыннан-буынга тапшырган. Рәхмәт бабаларыбызга. Рәхмәт мәкальләрне җыйган-туплаган һәм бастырып чыгарган (өч калын том!) Нәкый ага Исәнбәткә.*

*Соңгы мәкальләр кайчан чыкты икән? Һәрхәлдә, XXI гасырда түгел инде. Нигә тукталып калырга тиеш соң әле бу иҗат? Замана казанышлары — матбугат, радио-телевидение, Интернет – мәкальләрне халыкка җиткерүне тизләтәчәк кенә бит.*

*«Казан утлары» редакциясе бу игелекле, хәтта ки изге эшне терелтмәкче. Рәхим итегез, кадерле авторларыбыз һәм укучыларыбыз: XXI гасыр мәкальләренә журналда урын түрдән булыр... Мондый «тәти» сүзләрнең генә әлләни тәэсир итмәсен белеп, сезне кыздырып җибәрер өчен эшне үзебез, ягъни журнал хезмәткәрләре, башладык менә, гаеп итештән булмасын... Бәяне исә менә сез куегыз. Мәкаль дигәннәребезнең кайсылары еллар кичеп киләчәккә бара алырлык? Иң шәп дигәнен аерып күрсәтсәгез иде. Һәм шуннан соң дәртләнеп үзегез эшкә керешсәгез иде.*

*Журнал белән генә дә чикләнеп калмаячакбыз: китап та чыгарачакбыз! Шәп мәкаль ияләре бүләген дә алыр. Башлыйк, чордашлар. Хәрәкәттә бәрәкәт!*

***

- Үзенә сыймаган серне дустың да саклый алмас.
- Усаллыкка каршы усаллык белән җавап кайтарсаң, усаллар гына артыр.
- Серләреңне җилгә сөйлә, кире әйләнеп кайтмас.

***Лилия ГАТАУЛЛИНА***

***

- Җирдән җирәнгән чиргә кинәнгән.
- Бусагасыз түр булмый.
- Төчелек кечелек билгесе түгел, көчсезлек билгесе.
- Шигырьдән бизгәннең күңеле тутыгыр.
- Күзле бүкәннең дә анасы бар.
- Бар кәрлә дә Наполеон түгел.
- Бердәнбер бала нык биетер.
- Әйбере күбәйсә, йөзе кечерәя.
- Төштә ашаган тешкә керми.
- Шатлык кичергән — картлыгын чигергән.
- Ир ирдә тәхетле.

***Мөхәммәт МИРЗА***

***

- Күрсеннәр дисәң — морҗаң кыек булсын.
- Ауган агачка тукран да кунмый.
- Эре җиләк үсә торыр, кечкенәсе пешә торыр.
- Шигырь башына жыр житәр.
- Шома тимер тиз күгәрә.

• Алманың хакын ашагач сорама.

• Даның чыккан белән җаның чыксын.

• Яман сүз иясеннән алда йөри.

• Югалган көмешне, алтыным, дип эзлисең.

• Әтисез үскән бала җеннән дә курка.

• Синең хакта артыгын белгән дус дошманыңа әверелә.

• Чиратың якынайган саен ахирәтләрең арта.

• Сабантуй батырының үлеме сөзгәк тәкәдән.

• Ялкау байдан хәерче туа.

• Зур шәхеснең шәүләсе дә зур була.

• Караңгыда күз тими.

• Байның хәлен ярлыдан сорашма.

• Үз өеңдә йокы да бушлай.

• Язучыга якты чырай бирсәң, китапларын төяп килә.

• Зыялының шайтаны да зыялы.

*Камил КӘРИМОВ*

***

• Башны ормасаң ташка, башыңа орыр башка.

• Утырган кәнәфи никадәр йомшак булса, баш мие шулкадәр сыек.

• Каләм язар, гавәм түзәр.

• Эш беткәнче уяңырга ярый.

• Хак хат та хатадан хали түгел.

• Мәһдине мәнди анасы да белә.

• Көфер малае булганчы кефир малае бул.

• Хәмер капканның әмеренә капма.

• Тишектән кусалар, ишектән чык.

• Башы юктан башкисәр дә курка.

• Төшкән җирдә төш бул.

• Моржаң кыек булса да, төтене дөрес чыксын.

*Вакыйф НУРИЕВ*

***

• Дуңгызлар кимегәннән генә дуңгыз оясы дуңгыз оясы булудан туктамый.

• Кичке чәй – төнге йокыга тәнәфес.

• Ашның тәмсезлегендә телнең гаебе юк.

• Шигърияттә белгеч булыйм дисәң, Гаташ белән саташ.

• Күләгәнең шәүләсе булмый.

*Рамил ХАННАНОВ*

***

- Түрә дөньяны акаеп күрә.
- Түрә алдында жилфердәмә, эшең жилфердәсен.
- Акча колы төнлә дә богаулы.
- Мәкер төбен үзенә тәтер.
- Ана телен үги иткән — анасын да үгисетер.
- Тарихын онытკан, телен йоткан — үз тамырын үзе корыткан.
- Сөенә белмәс бәхеткә тиенмәс.
- Дуамал баш йөрәкне каезлый.
- Компьютерга күз генә сал, саулыгыңны салма.
- Йөргән аякка саулык иярә.
- Мәкаль ул — акыллы уйга тере һәйкәл.

*Рафикъ ЮНЫС*

---

*Кайтаваз*

# УЙЛАНДЫРА ТОРГАН ӘСӘР

«Казан утлары»ның жиденче санында Рөстәм Зариповның «Милициянең йөз кызыллыгы» дигән бәянын укыгач, кайбер фикерләрем белән уртаклашмак булдым. Ни өчен дигәндә, бу егетнең язмалары байтактан бирле «Татарстан яшьләре» газетасындагы сәхифәләрдән дә, башка басмалардан да миңа таныш. Мин аларда үземне бимазалап торган күп кенә мәсьәләләрнең чишелешен, уй-фикерләребезнең уртаклыгын табам. Бу табигый да — без аның белән чордашлар бит. Шул ук совет мәктәбендә, югары уку йортларында, алга киткән социализм, офыкларда коммунизм утлары шәйләнгән заманда яшәгән кешеләр. Икенчедән, үзем өч дистә елдан артык Эчке эшләр органнарында хезмәт итеп, азмы-күпме тәҗрибә туплап, лаеклы ялга чыккан зат та әле. Шуңа күрә бәянны бер утыруда укып чыктым. Әсәрдә тасвирланган кайбер образлар, вакыйгалар, матавыклы хәлләр миңе гүя яшьлегемә бөтереп алып кереп китте һәм һич кенә дә битараф калдырмады. Шул сәбәптән дә, шагыйрь әйтмешли, «кулым каләмгә орынды, анысы кәгазьгә тартты», чү, гафу итегез, клавиатура төймәләренә кагылды...

Лев Толстой әнә киләчәктә каләм әһелләренә образлар уйлап чыгарып, сюжет корып изаланасы да булмас, алар тормышны булганча тасвирларлар, дигән. Әйе, дөрестән дә, бүгенге сүз осталары, шул исәптән Рөстәм әфәнде дә, тормышны, вакыйгаларны түкми-чәчми, ничек бар, шулай бирә. Авторның ОБХССның (бүгенге укучыларга әлеге шомландыргыч биш хәрефнең «социалистик милекне урлау-үзләштерүгә каршы көрәш бүлеге» икәнлеген әйтү кирәктер, «кыдыл бодау» диалектында гәп куертучы инспекторы, чал чәчле милиция капитаны Фәйзи аганың яшь хезмәттәшенә сабак бирүләрендә мин «Очрашу урынын үзгәртергә ярамый» фильмындагы МУРның тәҗрибәле следователе Глеб Жиглов белән яшь оперативник Шарапов арасында килеп чыккан хәлгә ишарәне ап-ачык сиземләдем.

Хәтерләсәгез, алар шыгрым тулы трамвайда атаклы кесә карагы «Кирпечне» эләктерәләр. Глеб теге сизмәгәндә, акча янчыгын пинжәк кесәсенә турылый һәм моны күреп алган Шарапов остазына кайнарланып әллә нинди гаепләр ташлый, әмма Жиглов нык тора. Бәянда да бар моңа охшаш хәл. Бу — Мәсгуть исемле авыл егетен «йөгерттереп кенә» чәнечкеле тимерчыбык артына урнаштыру вакыйгасы. Бер машина ашлык үзләштерүдә гаепле Мәсгутьне ювелир кибетен басучы белән тигезләү «технологиясен» оператив хезмәткәрләргә ярдәмлек-кулланма кебек тә, шуна охшаш матавыкка дучар булган гади ватандашыбызга үзенең хокукларын ничек сакларга икәнлегенә күргәзмә әсбап буларак та файдаланырга мөмкин.

Монын ише вакыйгалар нәкъ тормыштагыча, әлеге бәянда адым саен. Образлар да истә калырлык, әйтик, участок инспекторы Ногман агай һәм Бөгелмәдән урлап китерелгән торбалар вакыйгасы. Югыйсә карак та билгеле, әмма аны фаш итәсе бар әле. Монын өчен мини-спектакль куела. Режиссёры да, төп рольне башкаручысы да Ногман абый. Эпизодларда — караклыкта гаепле шофёр егет, ике сарыгын юл һәлакәтендә «корбан иткән» Минзәлә кешесе һәм бер үк вакытта оператив хезмәткәр «Дәет Дарифулыч»...

Хәер, эчтәлекне сөйләп торунын хаҗәте юк.

Вакыйгалар шулкадәр дә гади, шулкадәр дә мавыктыргыч ки, менә дигән иттереп сәхнәдә куярлык, кинофильмнар төшерерлек! Аларның төп үзенчәлеге халыкчанлыкта, мәгънәлектә һәм нечкә юморга корылуында. Бу нисбәттән язучынын әсәре һич арттырусыз рус әдәбияты классигы, сатирик Салтыков-Щедрин памфлетларын хәтерләтә.

Инде көндәлек тормыштан бер мисал. Үзем яши торган тугыз катлы йорт матур гына урында урнашкан, тәрәзәләре зур гына күлгә карап тора. Сулык агач-куаклар белән уратылган, уртасында фонтаны да бар. Ике-өч ел элек күл тирәсен матурладылар: таш түшәделәр, фонарьлар куйдылар, чәчкәләр утырттылар, балалар мәйданчыгы ясадылар һәм халык утырып ял итсен, табигать күренешләре белән хозурлансын дип эскәмияләр урнаштырдылар. Мәрхүм Черномырдин әйтмешли, яхшыракка өметләндек тә, гадәттәгечә килеп чыкты. Әлеге утыргычларны жирле әтрәк-әләм, бомж-сукбай үз итте. Иртәдән кичкә чаклы шунда кайнашалар, эчәләр-сыйланалар, хаҗәтләрен башкаралар, бер-берсе белән кычкырышып-сугышып, кыйнашып мәш киләләр. Халыкның сабырлыгы төкәнгәч, полиция чакырта. Матур, ыспай гына формалы өч-дүрт полиция хезмәткәре килә, әдәпле генә итеп аңлату эшләре алып баралар, озаклап беркетмә төзиләр, сабыр гына үгетлиләр, прибор каптырып, промиллиларын үлчиләр дә кул куйдырып китеп тә баралар... Шуның белән эш тәмам! Сасып беткән, күгәргән-кутырланган яңаклы гидайлар мәҗлесләрен дәвам итәләр. Көн саен булмаса, атнасына ике-өч тапкыр кабатлана әлеге хәл. Без хезмәт иткән елларда эшләмичә йөргән әрәм тамакларны Җинаять кодексының бик тә шәп 209нчы маддәсе буенча эзәрлеклиләр иде. Без эшләгән чакларда бу сасыклар тараканнар кебек куышларында куркып утыралар иде, чөнки милициянең халык арасында дәрәҗәсе югары булды. Әйтәсе килгән фикерем шул: кануннар йомшак бездә, әле гамәлдәгеләре дә жиренә житкерелеп үтәлми, тиешле-тиешсезгә дә әлли-бәллиләү артты. Әлбәттә, «милиция»не «полиция»гә авыштыру, форма киеменен фасонын үзгәртү белән генә әллә нинди яхшы нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинме соң? «Полиция» дигән төшенчә үзе дә кеше арасында тискәре тойгылар уята. Хәзер инде хокук сакчыларының эшендә өр-яңа технологияләр киң кулланыла — компьютердан алып шампан шешәләренә чаклы, ни кызганыч, тормышның бөтен нечкәлекләрен белгән, тәҗрибә туплаган, йомры сүзгә, фикергә ия эчкерсез вә самими кордашлар кими бара хокук сакчылары арасында.

Менә шундый уйлануларга этәрде безне Рөстәм Зариповның ошбу бәяны. Аңа янадан-яна иҗади унышлар телисе генә кала.

**Мансур САДЫЙКОВ,**

*Эчке эшләр министрлыгы ветераны*

# СЫНАУЛАР

ПОВЕСТЬ

**«Мин сине көткән идем...»**

Бу уку елының да инде өченче аен башладык. Зур авырлыклар белән булса да, математиканы да үзләштереп барабыз. «Сеңдереп» укыгач аңлашыла да икән үзе. Укытучы апабыз һәр дәрестә кечкенә генә үзлектән эш ясап ала. Сыйныфны ике вариантка бүлеп, бифемнәрне тактага язып куя да күзәтә башлый. Кучертергә ирек бирмәскә тырыша. «Читкә баш боруыгызга күз йомып барсам, имтиханнарда хәйран кәчәнергә туры киләчәк», — ди ул, елмаеп. Нинди генә таләпчән булса да, яратам мин Роза апаны. Бар күңелен дә укытуга салган укытучы ул. Һәр дәрестә кулында тәртипләп язган планы була, биремнәрне да баштан үзе эшләп карый, төрле юллар белән безгә дә аңлата. Бер ачуын китерсәң, сиңа гел шикләнү белән карый башлый ул. Күптән түгел шушындый хәлгә тап булдык та без.

Апа гадәттәгечә сыйныфны ике вариантка бүлеп утыртты да биремнәрне тактага яза башлады. Биремнәр шактый катлаулы иде. Дүрт җавап вариантыннан берсен сайларга гына булса да, бик авырга туры килде. Өченче биремне башлаганда, көтелмәгән кыңгырау чылтырады.

— Эшләрне җыйдык. Бишкә кадәр санйым, аннан соң алмыйм, — диде, мәш килгән сыйныфка күз төшереп. — Бер...

Дәррәү битләрне, ерта-ерта, апага тапшырдык. Киләсе дәрескә нинди билгеләр булачагы һәркемнең йөзенә чыккан иде...

Сыйныфка менгәч, «бөек» математиклар Нәргизә белән Радик дәфтәрләрне җәеп салып эшли башладылар. Алар бөтенләй ике эшкә генә җавап язып өлгергәннәр. Бер баш — әйбәт, ике баш — тагын да әйбәтрәк! Тиз арада эшләп бетереп, сыйныфтан чыгып йөгерделәр.

Гүзәл көрсенеп карап калды.

— Төзәтергә киттеләр...

***

Безнең мәктәптә һәр бәйрәм саен диярлек спорт залы сәхнә ролен үти. Яңа ел җиттеме — чыршы алып кайтып, залның иң уртасына куялар. Чыршы алып кайткан көнне, малай-шалай ылыслары белән чеметтереп йөрергә дә ярата. Аны беренче сыйныфлар кәгазь җилеме ярдәмендә ябыштырып ясаган тәүге «шедевр»лары белән бизиләр, ара-тирә кибеттән кайтарган мишуралар да кунаклый, гирляндалар кабына...

Ә безнең тиздән көзге бал. Шуңа да спорт-залны бизәүне тугызынчы һәм унынчы сыйныфларга тапшырдылар. «Сынауларга әзерләнүче» унберләрне «беспокоить» итмәскә дигән карар чыгарып, безне мәктәп бакчасыннан сары яфраклар җыярга чыгарып җибәрделәр.

*Дәвамы. Башы 7 нче санда.*

Ара-тирә ризасызлыклар да ишетелде.
— Хе, унберләр, имеш! Без дә сынау бирәбез, между прочим!..
— Хәзер рәхәтләнеп ял итә инде алар.
— Залны өлкән сыйныфлар бизәргә тиеш!
Залны мәш килеп бизәгәндә, директор абый эшебезне күзәтеп торды.
— Болай тырышкач, дискотека да ясарбыз әле, бәйрәмнән соң, — диде ул, тыйнак кына елмаеп.
— Абый, бәлки каникулларга тагын ике атна өстәрсез, — диде Тәбрис.
Барыбыз да дәррәү көлеп җибәрдек. Абый, шелтәле елмаеп, баш чайкады да чыгып китте.
Егетләрнең шатлыклы тавышы ишетелде.
— Дискотека булса, шәп бит, мал-лай!
Бу бәйрәм гадәттә өлкән сыйныфлар өчен кич җиткәч була. Иртән — башлангыч сыйныфлар, көндез — урта, ә кичен безгә дә чират килеп җитә. Яфраклар белән тырышып-тырышып бизәлгән залга килеп керү ничектер күңелле. Спорт залын танып та булмый, әйтерсең, көз кереп кунаклаган. Стенатүшәмнәрдә сары өрәңге, каен яфраклары җилферди, ишек янында без ясаган плакатлар... Бәйрәм барышында директор абый, мәктәптә, район күләмендә булган ярышларга нәтиҗә ясап, грамоталар тапшырды. Егетләр бәйрәмнең бу өлешен тизрәк үткәрергә тели иде, барысы да дискотеканы көтә.
Музыка башлангач, тыйнак кына урыннардан куптылар. Кыюраклар зал уртасынарак шуышты, кайберләре урыннарыннан да кузгалмый калды. Клубта яңгыраган көйләр иде монда. Заманча көйләрне бик яратмасалар да, укытучылар бүген моңа күз йомдылар. Техничка апалар кулларына зур фонарьлар алып, аларны болгый-болгый безгә «светомузыка» ясадылар. Көй барышында берәүнең көлемсерәве ишетелде:
— Диджейлар шәп безнең!
Талгын көйне кабызып җибәргәндә, заманчадан тәмам туеп беткән идем инде. Зал уртасыннан барысы да читкә таралып бетте. Уртада бер-ике пар гына басып калды. Кызлар оялып кына җылылык батареяларына сөялделәр, егетләрнең батырлары гына аларны биергә чакырды. Әйе, әйе, батырлары. Киләсе көнгә кемнең кемне биюгә чакырганы, кемнең кемгә ризалык бирмәве мәктәптә бар колаклар аша да йөреп чыгасы иде. Кинәт берәү беләгемнән тотып алды.
— Биибезме?
Динар икән. Аптырап киттем. Ризалык биреп, ым кактым. Залның уртасында бер почмак табып, әкрен генә әйләнә башладык. Тик бу озакка бармады, талгын көйне бозып, заманчаны кушып җибәрделәр. Китте чинаш, сызгыру. Динар «диджейлар» тарафына бер-ике сүгенү сүзе юллады... Бу атмосферадан туеп, залдан чыгып киттем. Раздевалкада пальтомның сәдәфләрен каптырып бетерә идем, йөгереп Динар килеп җитте.
— Айсылу, мин сөйләштем. Хәзер тагын медляк куячаклар. Әйдә, биибезме?
— Юк, Динар. Мин кайтам инде...
— Кайтасың? Алайса көт! Мин хәзер.
Ул йөгерә-йөгерә залга юнәлде. Резин итекләремне киеп чыгып киттем. «Тышта көтәрмен әле».
Урамда шактый салкын. Көз үзен сиздерә, аяк асты пычрата башлады. Көндезләрен итеккә атлап булмаслык пычрак ябыша, аякларны өстери-өстери хәлдән таясың.
Мәктәп капкасына җиткәндә, машина кычкырткан тавышка айнып киттем. Алмаз икән ич бу. Бүген каршы алырга киләм дигән иде бит ул. Бөтенләй хәтердән чыккан. Машинага утырып, пычракта бата-бата өйгә юнәлдек.
— Ну, сөйләп җибәр, күңелле булдымы бәйрәмегез?

— Әйе. Кызык булды. Син нишләп бүген машина белән чыктың инде. Бу пычракта батып калсак...

— Яраткан кызымны шул пычрак буйлап җәяү алып кайта алмыйм бит инде, Айсылу. Кызык та инде син.

— Алмаз. Әйтергә дә әллә ничек инде, минем синнән биш яшькә кечкенә булуыма син ничек карыйсың?

Ул минем соравымны әллә ишетмәде, әллә җавап бирергә теләмәде, үзенекен сөйләп китте.

— Тиздән кабат укулар башлана инде. Кабат Казанга китәргә туры киләчәк. Барыбер авыл сагындыра, әллә сагыныр кешең булганга микән?

— Туган як һәрвакыт үзенә тарта инде ул...

Безнең тыкрыкка керерлек түгел иде. Шуңа да машинаны аскы урамда калдырып, җәяү тәпиләдек. Бераз баргач, Алмаз кулларына күтәреп алды.

— Киттекме?

Куллары көчле, беләкләре таза иде аның. Укытучы гына димәссең.

Өйгә җитәрәк, капка төбендә басып тордык.

— Карале, — диде ул, үтә бер шаянлык белән, — мин укырга киткәч, син бит мине көтәчәксең?

— Э-әә. Әйе, Алмаз. Нигә алай сорыйсың? Син бит атнага бер булса да кайтып йөрисең.

— Беләсеңме, — диде ул, кызып китеп, — ошыйсың син миңа, Айсылу. Синең белән таныштырган теге кечкә рәхмәтлемен. Син минем хыялымдагы кыз бугай ул. Сине озак күрми торсам, юксына, сагына башлыйм... Әллә ничек, күңел тарта сиңа. Аңлыйсыңмы?

Мин елмайдым.

— Айсылу, синең кебек кыз хакында хыялланып яшәдем. Мин сине көткән идем...

Алмаз белән хушлашкач, кара төнне ярып, сызгыру ишетелде.

— Айсылу! Син кай арада кайтып өлгердең соң әле? Мин бит сиңа көтәргә куштым.

Динар икән. Йөгерә-йөгерә чалбар балакларына пычрак кунган, еш-еш сулый.

— Кирәкмәс иде, мине бит Алмаз озатып куйды.

— Ал-маз?! Ничек инде? Ул Казанда түгелмени?

— Юк шул менә. Казаннан мине озатыр өчен кайткан. Ә син шулай эшли алмас идең әле, — дидем мин, елмаеп.

— Э-әә. Ни бар соң ул Алмазда шулкадәр?! Нәрсәсе белән кызыктыра соң ул сине? Алмаз дип башкаларны күрми дә башладың бит!

Динар беләгемнән эләктереп, нык итеп кысты, үзе һаман еш-еш сулый, ризасызлыгы йөзенә чыккан.

— Динар, кулымны җибәр әле. Авырта бит.

— Гафу... Айсылу, әйдә иртәгә район үзәгенә барабыз. Анда яңа кафе ачканнар. Шуны карарбыз.

— Син сынауларыңа әзерләнсәң иде, Динар. Мин керим, әни борчыладыр.

— Сау бул, Айсылу.

Хушлашып, капка келәсенә бастым. Эһ, бу Динар. Авылның бөтенләй икенче башында торса да, пычракта монда кадәр килгән. Кызгандым да инде үзен. Әллә нишләде соңгы арада. Мин Алмаз белән очраша башлагач, күзәтеп кенә йөри. Юк, ул минем иң якын дустым. Ни булса да, мин якын дустымны югалтырга теләмим...

**Алсу НУРГАТИНА**

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ТАНТАНА

Казанда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында Болгар тарихи-археология комплексын ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертү турындагы сертификатны тапшыру тантанасы булды. Аны ЮНЕСКОның генераль директоры Ирина Бокова ТР Президенты Рөстәм Миннехановка тапшырды. «Хәзер Болгар Татарстан белән Россиянеке генә түгел, бөтен дөньяныкы», — диде И.Бокова. Р.Миннеханов Болгар комплексының ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелүен көтеп алынган җиңү, моның ТР Беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең шәхси олы хезмәте икәнлеген, Болгарны торгызуда системалы зур эш алып барылуын әйтте.

Тантанада чыгыш ясаган Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев иң әүвәл Ирина Боковага олы рәхмәтен җиткерде, Болгарны яңарту проектын гамәлгә ашыруда Татарстан халкының бердәм катнашуын әйтте. Ул шулай ук барлык хәйриячеләргә дә олы рәхмәтен ирештерде. «Республикабыз җәмәгатьчелеге өчен бу зур вакыйга. Ул тарихи, мәдәни, рухи, дини әһәмияткә ия» — диде М.Шәймиев.

Болгар тарихи-археология комплексын ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертү уңаеннан Болгарда да зур бәйрәм булды, театральләштерелгән, тарихи тамаша күрсәтелде.

### КИҢӘШМӘ

Мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең ел саен үткәрелә торган республика август киңәшмәсе быел Саба районында булды. «Татарстан: инновацион төбәк мәгарифе» дигән темага багышланды ул. Зур педсоветта җөмһүриятебезнең барлык министрлары, ведомство җитәкчеләре катнашты. Киңәшмәне ТР Президенты Рөстәм Миннеханов ачты. ТР Премьер-министр урынбасары-мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов республика мәгарифенең торышы, үсеш тенденцияләре хакында чыгыш ясады, мәгарифнең яңа стандартларын эшләүдә катнашкан Мәскәү кунагы, Россия Мәгариф академиясе мөхбир-әгъзасы Александр Кондаков, Саба муниципаль районы башлыгы Рәис Миннеханов мәгариф системасын камилләштерү мәсьәләләрен күтәрделәр.

Президент Рөстәм Миннеханов үзенең йомгаклау чыгышында белем бирүдә түбән нәтиҗәләр күрсәтүчеләргә тукталды, мәгариф хезмәткәрләренә зур бурычлар йөкләнде.

Киңәшмә ахырында ТР Премьер-министр урынбасары-мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов «Яңа уку елына иң яхшы әзерлекле белем бирү оешмалары һәм балалар йортлары» республика смотр-бәйгесендә җиңүчеләргә дипломнар тапшырды. Иң алдынгы мәгариф хезмәткәрләре Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов кулыннан дәүләт бүләкләре алды.

### СЪЕЗД

Казанда татар теле һәм әдәбияты укытучыларының VI Бөтенроссия съезды булып үтте. Илнең 34 төбәгеннән җыелган делегатлар — туган тел дәресләрен алып баручы мөгаллимнәр укытуның инновацион методлары хакында фикер алышты, милли мәктәпләр кысыла барган шартларда да балаларны татар мәдәнияте нигезендә тәрбияләү турында сөйләште. Съездда ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин ТР Президенты мөрәҗәгатен ирештерде.

«Җир шарының төрле төбәкләренә сибелеп яшәүче татарлар өчен туган тел — берләштерүче көч ул. Кайда гына яшәсәк тә, дәүләт турында кайгыртырлык, заманга лаек яшьләр тәрбияләү — безнең уртак бурычыбыз», диелә әлеге мөрәҗәгатьтә.

ТР Премьер-министр урынбасары-мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов соңгы елларда республикабызда милли белем тармагының торышы хакында хисап тотты, киләчәккә бурычлар билгеләде.

Съездда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов, ТР Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибе Дания Заһидуллина, Ульяновск өлкәсенең татар милли-мәдәни мохтәрияте рәисе Рәмис Сафин, Самара шәһәренең «Яктылык» урта мәктәбе директоры Радик Газизов һ.б. чыгыш ясады.

Утырыштан соң мөгаллимнәр Казан шәһәре һәм Саба районы мәктәпләрендә тәҗрибә алмаштылар.

## ФОРУМ

Болгар цивилизациясен өйрәнүче галимнәр VI халыкара Болгар форумына җыелды. Быелгы форумда Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ИРСИКА генераль директоры Халит Эрен, Төркия, Молдова, Нидерланд, Болгария, Казахстан, Кыргызстан, Венгрия, Үзбәкстан, Азәрбайҗан һ.б. дәүләтләрдән, Алтай краеннан, Чувашия, Тыва, Кырым, Хакасия республикаларыннан вәкилләр катнашты.

## МӘСКӘҮДӘ ТР МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

20-24 августта Мәскәүдә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре үткәрелде. Беренче көнне Әсәдуллаев йортында ТР-ның иҗат интеллигенциясе белән очрашу булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, Татарстанның халык шагыйрьләре Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, язучы Вахит Имамов, Татарстан Кинематографистлар берлеге рәисе Илдар Матуров чыгыш ясады. Туфан Миңнуллин турында — «Туфан Туфан инде ул» фильмы (сценарий авторы Разил Вәлиев, режиссёр — Илдар Матуров) күрсәтелде. Мәскәүдә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре кысаларында Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы тарафыннан «Мулла» (Т.Миңнуллин), «МәхәббәтFM» (И.Зәйниев) спектакльләре, Татарстан Республикасы сәнгать осталары, ТР дәүләт җыр һәм бию, ТР дәүләт фольклор музыкасы ансамбльләре концертлары, «Ак бүре» операсы, «Рухи мирас җәүһәрләре», татар халкының музыка кораллары, Татарстан китап нәшриятында басылган китаплар күргәзмәләре, Мәскәүдә яшәүче татар рәссамнарының иҗат эшләре, кинофильмнар тәкъдим ителде.

ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Г.Тукай, М.Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр салды. Россиянең халык артисты Фуат Мансуров каберенә таш кую мәрәсимендә, Беренче Бөтендөнья сугышында катнашкан татарлар турындагы «Незаметные герои неизвестной войны» документаль фильмын тәкъдим итү кичәсендә катнашты һәм чыгыш ясады. Чыгыш ясаучылар арасында Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, тележурналистлар Николай Сванидзе, Сергей Брилёв, дикторлар, шушы фильмда катнашкан Фәридә Корбангалиева, Максим Шәрәфетдинов та бар иде.

Әлеге чараларда шулай ук ТР Премьер-министр урынбасары-Татарстан Республикасының Россия Федерациясендә тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин, ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин катнашты.

## ИСКӘ АЛУ МӘРӘСИМЕ

Бөек татар шагыйре Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләрен җәзалап үтерүгә 70 ел тулды. Бу уңайдан Казандагы 1 Май мәйданында, Җәлил һәйкәле янында искә алу мәрәсиме булды. Анда ТР мәдәният министрының беренче урынбасары Ирада Әюпова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, кунаклар Кабарда-Балкардан шагыйрьләр, «Минги Тау» журналының баш мөхәррире Әскәр Додуев, Моталиб Беппаев, Мәскәүдән шагыйрь, тәрҗемәче Сергей Гловюк, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим, шагыйрә Нәҗибә Сафина, шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшин чыгыш ясады. Җәлилнең кызы Чулпан ТР Мәдәният министрлыгына әтисенең китапларын бастырып чыгару үтенече белән мөрәҗәгать итте. Митингта Җәлилнең торыннары Михаил Митрофанов-Җәлилев һәм Елизавета Малышева скрипкада уйнады. Г.Камал театры артистлары каһарман-шагыйрьнең шигырьләрен укыды.

## СӘФӘР

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән Язучылар берлеге арасында хезмәттәшлек турында килешү кысаларында урып-җыю чорында язучыларның районнарга чыгып авыл халкы белән очрашуы, кыр эшләренең барышы, игенчеләрнең максат-хыяллары, ирешкән уңышлары, киләчәккә планнары белән танышу матур традициягә әверелде.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, язучылар Зиннур Мансуров, Шәмсия Җиһангирова, Рифат Җамал, Гөлзадә Бәйрәмова, Алмаз Хәмзин, Хөсәен Вәлиәхмәтов — Балтач, Рафис Корбанов, Вахит Имамов, Нәбирә Гыйматдинова, Шәмсия Җиһангирова, Салисә Гәрәева, Рифат Җамал, Алмаз Хәмзин, Рафаил Газизов, Хөсәен Вәлиәхмәтов, Камил Сәгъдәтшин, Вәрис Гали, Фидаил Мәҗитов — Мамадыш, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт, язучылар Марат Әмирхан, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Рифат Җамал, Флёра Тарханова, Илсөяр Иксанова, Рифә Рахман, Йолдыз Җамалетдинова, Хәбир Ибраһимов (Ахир) Буа районында булдылар.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: А.ЕГИН. Роман «Узбекхан» (нач.); А.МУТАЛЛАПОВ. Роман «Испытание»; стихи Р.КУРБАНА, Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ, Э.БАЙНАЗАРОВА.
«Конкурс на повесть малого формата»: К.КАРА. «Уголовное дело Инги Мейта».
«Литературная критика»: Т.ГАЛИУЛЛИН. «Сулейман» (творческий портрет поэта Д.Сулейманова.)
«Искусство»: Г.САГИТОВА. «Юксыну».
«Память»: М.УСМАНОВ. «Светлые мгновения жизни»; Р.МИРХАЙДАРОВ. Мемуары «Вот и всё... Я пишу вам с вокзала» (прод.).
«Жизнь и религия»: БАТУЛЛА. «Суть» (прод.).
«Сенной базар»: рассказы Д.ГИСМУТДИНА.
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
«Белый парус»: повесть (прод.) А.НУРГАТИНОЙ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: историко-археологический комплекс Булгар — под защитой ЮНЕСКО (2014); 30 августа — День Республики Татарстан. *Фотографии Ф.ГУБАЕВА.*

# IN THIS ISSUE:

«Prose and Poetry»: A.EGIN. Novel «Uzbekhan» (beginning) A.MUTALLAPOV. Novel «Trial»; poems by R.KURBAN, F.ZAMALETDINOVA, E.BAYNAZAROV.
«Competition for small-format novel»: K.KARA. «Inga Mate's criminal case».
«Literary Criticism»: T.GALIULLIN. «Suleyman» (creative portrait of the poet D.Suleymanov).
«Art»: G.SAGITOVA. «Yuksynu».
«Memory»: M.Usmanov. «Bright moments of life»; R.MIRHAYDAROV. Memoirs «That's it ... I am writing to you from the station» (cont.).
«Life and Religion»: BATULLA. «Essence» (cont.).
«Hay Market»: stories by D.GISMUTDIN.
«Pages of humor»: section is led by M.GALIEV.
«White Sail»: story (cont.) by A.NURGATINA.
From photo archives of the magazine.
Diary of the social-cultural life.
On our covers: Historical and Archaeological Complex Bulgar — protected UNESCO (2014); August 30 — Day of the Republic of Tatarstan. Photos by F.GUBAEV.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кергән (2014) Болгар тарихи-археология комплексы күренеше.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* 30 август — Татарстан Республикасы көне.
*Фәрит Гобәев фотолары.*

# Яңа китаплар




**Алмазова А.А.**
**ТАТАРСТАННЫҢ**
**МӘДӘНИ МИРАСЫ**
**(тарихи яссылыкта).** *– Казан: Казан университеты, 2013. – 187 б. Тиражы – 200 данә.*

Ислам тарихы һәм мәдәниятен тирәнтен өйрәнүче белгечләр әзерләү программасы кысаларында нәшер ителгән әлеге китапта сәнгать фәннәре кандидаты Аида Алмазова Татарстан сәнгате тарихының үсеш чорларына күзәтү ясап кына калмый, аның Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәнияте белән бәйләнешен күрсәтүне дә максат итеп куя. Автор, ислам традицияләренең татар сәнгате үсешенә йогынтысын өйрәнеп, фәнне диннән аермыйча, төрле жирлектә яктырта. Китап хронологик тәртиптә эшләнгән, җыентыкка әдәбият, декоратив-гамәли сәнгать, архитектура, сынлы сәнгать һәм музыка өлкәсен тикшерүдән чыккан нәтиҗәләр тупланган. Әлеге хезмәт татар тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынучы киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

---




**Мухутдинов Р.С.**
**ГАРМУН УЙНАТЫЙК ӘЛЕ.**
*Самоучитель игры на гармонике-тальян. – Казань. 2013. – 52 с.*

**Мухутдинов Р.С.,**
**Мухутдинова Н.Р.**
**Я БУДУ КУРАИСТОМ!**
*Самоучитель игры на курае. – Казань. 2013. – 104 с.*

Үзлегеннән гармун һәм тальянда, курайда өйрәнергә теләүчеләр өчен Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ринат Мөхетдинов һәм Наилә Мөхетдинова тарафыннан әзерләп чыгарылган әлеге дәреслек-кулланмалар бернечә бүлектән тора. Беренче бүлек теоретик өлешне яктыртса, икенче бүлекләрдә исә китапка кергән җырларның ноталары урнаштырылган. Татар халык җырларына һәм күренекле композиторларыбыз әсәрләренә, рус һәм чит ил классик әсәрләргә нигезләнеп эшләнгән бу җыентыклар, шулай ук балалар музыка мәктәпләре, үзешчән сәнгатьтә катнашучылар, гомумән, татар халкының җыр-моңына гашыйк һәммә кеше өчен дә кулланма була ала.

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2014
МӘДӘНИЯТ ЕЛЫ



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)